ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# Казан утлары

12.2013



# МЕҢЬЕЛЛЫК КАЗАН

















*Үткәнебез һәм бүгенгебез. Бер үк ноктадан бер гасыр аерма белән төшерелгән фоторәсемнәр.*

**Хажи Абдулла ДУБИН коллекциясеннән**

# Казан утлары
# Qazan utlari

2013

12
(1094)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст. 1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

**Факс** — (843) *222-09-83 өст. 1612.*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ. Яшәү өчен көрәш кискен. *Шигырьләр.* ....5
Кәрим КАРА. Матильда. *Бәян.* ....8
Флёра ТАРХАНОВА. Күнелемә ятты моңлы көй. *Шигырьләр.* ....42
Дания НӘГЫЙМУЛЛИНА. Бәхетемне сиңа бүләк итәм. *Шигырьләр.* ....70
Марат ӘМИРХАНОВ. Утлы камчы. *Хикәя.* ....73
ХӘЙДӘР. Әбиләр чуагы. *Хикәя.* ....90

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Минем дустым Чыңгызхан. *Сатирик комедия.* ....46

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Наил ШӘРИФУЛЛИН. Мең тиленең күмәк акылы яки гыйлемлелек «зарары» хакында. ....96

**СӘНГАТЬ**

Рашат НИЗАМИ. Яруллиннар йолдызлыгы. ....104

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Төрки дөнья хәзинәләре. ....108
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. «Ян син, йөрәк» *(Әнвәр Давыдов иҗатында замана сурәте).* ....114

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Рәсим ХӘБИБУЛЛА. Сынау... ....130

**ХӘТЕР**

Мөхәррәм ШӘРИПОВ. Нинди жир ул Суслонгер? ....146
Таһир ГЫЙЛАҖЕВ. Халыкка хезмәттә ямь дә, тәм дә бар... ....148
Шәһид ӘХМӘДИЕВ. Шагыйрь моңая. ....151
Чулпан ХАРИСОВА. Күренекле тел галиме. ....153

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

АХИР. Кабул итү бүлмәсендә. *Сатирик поэма.* ....155

**АК ҖИЛКӘН**

Линар ЗАКИРОВ. Җансыз мәхәббәт. *Хикәя.* ....163
Ләйлә ХӘБИБУЛЛИНА. Юксынулар җанга суык өсти... *Шигырьләр.* ....167
Факил САФИН. Туган ай. *Бәян.* ....171
Ильмира КАМАЕВА. *Шигырь.* ....178
Марат ЗАКИР. Ашкынып чак. *Шигырьләр.* ....180
Альберт ХӘСӘНОВ. Табигать турында парчалар. ....182

2013 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге. ....185
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть К.КАРА «Матильда»; рассказы М.АМИРХАНОВА, Х.ГАЙНУТДИНОВА; стихи Ф.ТАРХАНОВОЙ, Д.НАГИМУЛЛИНОЙ.
«Драматургия»: сатирическая комедия Р.ЗАЙДУЛЛЫ «Друг мой Чингизхан».
«Публицистика»: Н.ШАРИФУЛЛИН. «Суммарный ум дураков или о «вреде» образованности».
«Искусство»: Р.НИЗАМИ. «Созвездие Ярулинных».
«Литературная критика»: Х.МИННЕГУЛОВ. «Сокровища тюркского мира»; статья Т.ГАЛИУЛЛИНА о творчестве А.Давыдова.
«Память»: М.ШАРИПОВ. «Что за место Суслонгер?»; статья Т.ГИЛЯЗЕВА, посвященная 125-летию Ш.Ахмадеева; Ш.АХМАДЕЕВ. «Поэт грустит»; статья Ч.ХАРИСОВОЙ, посвященная 125-летию Г.Алпарова.
«Белый парус»: рассказ Л.ЗАКИРОВА; повесть Ф.САФИНА; рассказики А.ХАСАНОВА; стихи Л.ХАБИБУЛЛИНОЙ, М.ЗАКИРА, И.КАМАЕВОЙ.
Библиографический список произведений, опубликованных в 2013 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зимний пейзаж»; писатель Рузаль МУХАМЕТШИН.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by K.KARA «Matilda»; stories by M.AMIRHANOV, H.GAYNUTDINOV; poems by F.TARHANOVA, D.NAGIMULLINA.
«Drama»: satirical comedy by R.ZAYDULLA «My friend Genghis Khan».
«Journalism»: N.SHARIFULLIN. «Summary mind of fools or about «damage» of education».
«Art»: R.NIZAMI. «Constellation of Yarulins».
«Literary criticism»: H.MINNEGULOV. «Treasures of Turkic world»; article by T.GALIULLIN about creativity of A.Davydov.
«Memory»: I.SHARIPOV. «What a place Suslonger?»; article by T.GILYAZEV devoted to the 125th anniversary Sh.Ahmadeev; SH.AHMADEEV. «The poet is sad»; article by CH.HARISOVA devoted to the 125th anniversary of G.Alparov.
«White Sail»: story by L.ZAKIROV; novel by F.SAFIN; tales by A.HASANOV; poems by L.HABIBULLINA, M.ZAKIR, I.KAMAEVA.
Bibliography of works published in 2013.
Diary of social cultural life.
On our covers: «Winter landscape»; writer Ruzal MUHAMETSHIN.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 02.12.2013, график буенча 02.12.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2606. Тираж 3620.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Илдус
Гыйләҗев

# ЯШӘҮ ӨЧЕН КӨРӘШ КИСКЕН

## Һәркем шулай аңлый микән?

**Мин – банкрот! Соңгы алты айда
Ике шигырь бары язганмын.
Ничек түзә алдым икән болай
Матурлыгын күрми язларның?
Җәйне көткәнмендер. Ансы тагын
Узып бара миңа кагылмый.
Кеше күңелләрен кузгатырлык
Йөрәгемдә очкын кабынмый.
Түл җыяммы? Әйтер сүз беткәнме?
Уйлыйсы бар әле яхшылап.
...Чиле-пешле шигырь сырлаганчы,
Язмый тору – күпкә яхшырак!**

## Сискәнеп куям

**Ак күбәләк кунды тәрәзәмә,
Нәрсә тели икән әйтергә?
«Туганнарның җаны шулай кайта», –
Дигән сүзләр төшә хәтергә.
Болай да бит җанны актаралар
Бер-бер артлы кереп төшләргә.
Сәлам алып килсә ярый да бит,
Чакырырга булса... нишләргә?**

## Бергәләп уйлыйк

**Ир һәм хатын.Капма-каршы холык...
Уйлый башлау белән буталам.
Ничә еллар инде бер сорауга
Җавап таба алмый тукталам.
Бу бүленеш кайчан башлана соң?
Тән һәм җанның тәңгәл килеше:
Әллә безнең матди гәүдә төсле
Җаннар дамы ике җенесле?!**

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ (1946) — *шагыйрь; «Җир китабы», «Мәгарә», «Кадерле китап» һ.б. шигырь китаплары авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Азнакай районында яши.*

## Калыкмаска батты

Якын дусны күмдем... тере килеш...
Үзе исән, уйда җирләдем.
Гаебе зур, белгәч хыянәтен
Бизгәк тоткан кебек чирләдем.
Бер сыздыргач дуслык кагыйдәсен
Ул бит мине тагын сатачак.
...Күнел төпкеленә төшеп ятты
Мәңге өскә чыкмас саркофаг...

## Көнче зат уфтануы

*(шаяру)*

Гармун уйный белсәң икән лә ул
Киерелеп тартып күреген.
Урап алсын иде чибәр кызлар
Абзагызның күреп кемлеген.
Җырлый белсәң иде икән лә ул
Илһам Шакировны уздырып.
Тургай–сандугачлар хәйран калып
Карап торсын иде кызыгып.
Бии белсәң иде икән лә ул
Нуриевтан биек талпынып.
Түшәмнәргә кайчак баш тисә дә
Тормас идем һич тә тартынып.
Гел сәләтсез түгел мин дә ансы,
Гомер итәм ярсып, көрәшеп.
Уйный, җырлый,бии белгәннәрдән
Ничек үч алырга дип, көнләшеп.

## Шигырьгә тапшырдым

Миндә синең күпме серең яши
Хисең нечкәргәндә сөйләнгән.
Онытырга инде кирәк тә бит
Син кияүдә, ә мин өйләнгән.
Кайнар бөҗра булып төйнәлгәннәр,
Хәтер көйрәп җанны пешерә.
Истәлекләр – утлы күбәләкләр –
Бергә чакны искә төшерә.
Үз күңелең, белмим, тыныч микән?
Хәбәрең юк, нәрсә дияргә.
Шигырь саклар инде серләреңне,
Мин өйләндем,ә син — кияүдә...

## Таләпчән гадәт

Дусларымны кат–кат сынап яшим,
Энә күзе аша үткәрәм.
Шул тишеккә бар бит сыючылар,
Еллар, димәк, ярлы үтмәгән.
Авыр чакта барып егылганда
Алар куйды кире күтәреп.
Уйлый китсәң, күргән яхшылыклар
Күп җыелган, исең китәрлек.

Үпкәләрләр төсле, кичермәсләр
Берсен хурлап, берсен мактасам.
Исән калганнарын санар вакыт,
Ә мин һаман, сынап маташам...

## Үзем дә шул халәттә

Кай арада сакауланган,
Зарлана, ярсый күке.
Нигә аңа кагылганнар,
Ул, имеш, җайләр күрке.

Мыгыр-мыгыр тамак кыра
Ямьсезләп бакча түрен.
Яшьлек кыска булуына
Без бит гаепле түгел...

## Бер генә ысул

*(шаяру)*

Язгы кырау атап төшә,
Аның дошманы — төтен.
Төтен салсаң, күп чәчәкләр
Исән калырга мөмкин.
Безгә дә бит кырау тия,
Ярдәм итми тик төтен.

Еллар тиеп агарталар
Чәчләрең булса бөтен.
Күзне алдап яшәп була
Карага чәчне мансаң.
...Кырау тимәс, чәчләреңне
Иртәрәк коя алсаң...

## Әйтеп бетерсен

«Эсәнмэсэз», – дисә түрә
Татар гөҗли, алкышлый.
Икенче сүз ник әйтелми?
Шуны йөрим аңышмый.
Кемнәр соң без? Иптәшләрме,
Вассаллармы, коллармы?

Әйтелмәгән мәгънә өчен
Чәбәкликме кулларны.
Ничек дәвам итәчәген
Көтеп торам әсәреп.
...Эчтән көйлим Габдулланың
«Без китмибез!» әсәрен...

## Әрәмгә калган хисләр

Кемне кемнәр үстергәндер,
Безне урам үстерде.
Үз иткәннәр кәнфит бирде,
Кемдер көчек өстерде.
Кемне кемнәр яраткандыр,
Без – чеби чак – ояда.
Күпме хисләр харап була
Калкып чыкмый дөньяга...

## Безнең аермалык

Яшәү өчен көрәш кискен:
Маймычны чуртан йота.
Чебиләрне тилгән ала,
Күсене мәче тота.
Бар тереклек җан асраугa
Юнәлтә бөтен көчен.
...Кеше генә килә җиргә
Кемдер яратсын өчен...



Кәрим
Кара

# МАТИЛЬДА

БӘЯН

*— Син кем ул кадәр? – дип сорадым мин, аны урынына куярга теләп.*
*— Мин синең шатлыгың, — диде ул.*

Рәмилнен машинасы Чиләбе өлкәсендә ватылып калды. Бер колонна булып алты «КАМАЗ» Казакъстаннан кайтып киләләр иде алар. Турыдан суктырабыз дип әллә күпме адашып та йөрделәр ул көнне, сикәлтәле авыл юллары да «ярдәм» иткәндер, арткы күчәр түзмәде. Рәмилне машинасы белән ташландык хәлгә җиткән бер авылга сөйрәтеп китерделәр. Колонна башлыгы, үзара кинәшкәннән сон, сонгы сүзне әйтте:

— Көн ярымнан без өйдә булабыз. Запчастьлар төяп механикны җибәрермен. Ә син сүтә тор, каравыллап ят. Соңыннан хакын килешербез. Менә хәзер акча ягы такыррак. Кем уйлаган аны...

Соңгыларын җыештырып өч йөз сумлап акча таптылар. Авыл читендәге җиргә сенә башлаган бәләкәй генә өйнең капка төбенә бергәләшеп бардылар.Ишек каккан тавышка булса кирәк, эчтә бала елаган тавыш ишетелеп калды, нәрсәдер дангыр-донгыр идәнгә тәгәрәде. Кеше уятырлык чак түгел иде шул әле, шырпы яктысында сәгать алтыны күрсәтте. Ишекне куркынган йөзле, зур кара күзле, яшьрәк кенә хатын ачты. Барысы өелешеп торып калдылар, бригадир белән Рәмил өйгә үттеләр. Мич артында янган лампочкадан төшкән сүрән генә яктылыкта аягүрә таптанып әлеге хатын белән килешү төзеделәр. Ул шоферга ашарга әзерли, кунарга урын бирә, шунын бәрабәренә һәр көне өчен ике йөз сум акча алачак. Тик көтәргә, көтәргә риза булса гына. Авыл жирендә ике йөз сум әз акча түгел, әгәр риза булмаса, хәзер борылып чыгып китәләр дә, икенче капканы кагалар. Анда аларны кочак җәеп каршы алачаклар.

— Мин риза, риза, — дип ризалашырга ашыкты хатын.

«Килештек алай булгач», — дип күнелләнеп нокта куйды бригадир. Ул үзенең кешеләр белән сөйләшә белгәненнән бик канәгать иде.

— Ә син, Рамилька, бер капчык югары сорт онны кояш чыккач та

Кәрим КАРА (1956) – *прозаик; «Без әнкәй йөрәгеннән чыктык» исемле китап авторы. Тәтештә яши.*

алып кер моңа. Үзең ак күмәч ашап кына ятарсың. Ә хакың көн исәбенә чутларбыз.

Хатын чәй турында сүз кузгаткан иде, чыгарга ашыктылар. Бердән, юл йөреп үз тамакларын үзләре кайгыртырга тәмам өйрәнгәннәр, икенчедән, жиде төн уртасында кеше бимазаларга теләмәделәр. Чыгып баскач, юл аягына берәр тәмәке кабызып тарттылар да, хушлаштылар.

— Күңеленне төшермә, сенелкәш яшь күренә, ир-ат исе сизелмәде, үзең кара калганың, — дип шаяртты бригадир.

Якын дусты, бер йортта яшәгән Руслан:

— Әһә, кайтуга жиңгәдән сөенче алам, жилләнеп килеп житмәсең, — дип теленә салынды. Шулай шаулашып-гөрләшеп, уен-көлке сөйләп машиналарына таралдылар. Фаралар кабынды, двигательләр гөрли башлады. Авыр кузгалып, зур фургонлы машиналар карангылыкка кереп югала тордылар. Бераздан тавышлары да ишетелми башлады. Жиде ят урында ялгыз калган Рәмилгә ямансу булып китте. Шомланып та куйды, кем йөрмәс, товар үтемле. Кырык төрле уйларга чорналып, авыз эчен ачыттыра-ачыттыра тагын тәмәкесен тартты. Мәңге шулай басып тормассың бит. Авыр сулап ишеккә атлады. Кергәч тавышланмаска тырышып, авырайган итекләрен көчәнә-көчәнә салып, бишмәтен элде дә, хатын күрсәтеп куйган урын өстенә йомарланды. Аруы житкән булган күрәсең, онытылып та китте. Бераздан ул гырылдап йоклый иде инде.

***

Иртән Рәмил хужабикәнең кыштыр-кыштыр йөргәненә уянып китте. Иртә иде әле, тәрәзәләр кояш нурларыннан алланган чак. Рәмил күзләрен ачмый ята бирде, аңа ашыгасы түгел, барыр жиренә барып житкән. Тәнендә бер төрле авырлык сизелде, әллә арыганы бетмәгән, әллә салкын суктырган. Керде — чыкты хужабикә, савыт-саба шалтыратты, мичкә якты, чыртлап утын янганы ишетелде. Бераздан өйгә тәмле булып пешкән бәрәңге исе таралды. Уянганын белгертергә тамак кыргалап Рәмил торып утырды, барыбер йоклап булмас. Ябынып яткан юрганын төргәндәй итте, мендәрне каккалады-суккалады, өй эчен күздән кичерде. Ике-өч жирдән чаршаулар тарттырып бүлгәләнгән өй тавык кетәгеннән чак кына зуррак иде. Идәнтүшәм буялмаган, борынгы мич уртага килеп баскан, күз күргән ягында ул йоклаган карават та, тәрәзә буенда өстәл бар иде. Башка жиһаз-фәлән күренмәде, стенага эленеп куелган зур көзгене исәпкә алмаганда. Юл йөреп күпне күргән ир гажәпләнмәде, йокларга урын бар, өй жылы, тагын ни кирәк? Шул чакта мич буеннан теге хатын башын тыгып карады, мөлаем елмаеп куйды, әйтерсең кадерле кунагы уянган.

— Бик вакытлы уяндыгыз, бәрәңге пешеп чыкты, хәзер чәй кайный. Менә бу якта юынып алыгыз да.

— Ярый, нәрсә мәшәкатьләнергә, кирәкми иде, — дигән сыманрак сүзләрдән авыз эчендә ботка пешерде. Уңайсызрак иде ят хатын-кыз белән аралашу. Тизрәк тышка атлады, чыга-чыгуга авызына тәмәкесен алып капты. Коймага терәлеп дигәндәй туктаган машинасы янына чыкты, кабина ишегенең, фургонның бикләрен тикшерде. Зур көпчәкләргә ышыкланып кече йомышын үтәп куйды. Ахырда кабинасына кереп утырды да, рульгә ике куллап таянып, комсызланып тәтен суырды. Каршында бер урамлы, илле-алтмыш өйле авыл жәелеп ята иде. Яңа күтәрелгән өйләр, ниндидер төзелеш барганы сизелми иде. Киресенчә, ике өйнең берсендә дигәндәй йә тәрәзәсе юк, йә коймасы авып төшкән. Яшәмиләр дигән сүз инде анысы. Урыслар шулай шул, жиңел холыклы, яшәү авырая башласа, күчмә кошлар төсле китәләр яңа урыннар эзләп. Ә татар, гадәттә, жаны чыкканчы тырмаша

туган урынында,ата-бабайлар нигезе ди, тагы әллә нәрсәләр...Өч-дүрт көнне ничек үткәрергә монда, хәзердән үк талпына йөрәк туган якларга...

Кабинадан чыкканда юл капчыгын эләктерде, өстәлгә буш кул белән барып утырмас, иш янына куш булыр. Аш бүлмәсе ягына чыгып баскан иде, хуҗабикә җәһәт кенә мич астыннан ләгән тартып чыгарды, иңбашына тастымал салып, бер кулына сабын, икенчесенә чүмеч белән су алып юындырырга алынды. Су җылы иде, хатын бик тә житез кыланды. Ир бик тә риза булып, битен кызартканчы ышкып, күрсәтелгән түр урынга, өстәл янына килеп утырды. Төп сый-нигъмәт ярып пешерелгән ярмалы бәрәңге иде. Май-фәлән күренмәде. Рәмил ягына этелгән тәлинкәдә ике телем икмәк, чәй сөтсез, өстәп үлән чәе иде. Рәмил капчыгын чишеп ике консерва, бер кап печенье, йөз граммм тирәсе сало алып куйды. Күчтәнәчләрне күргәч хуҗабикәнең йөзе балкып китте.

— Житешегез әле, кайнар чагында тәмле була бәрәңге, — дип ирнең алдына тегесен-монысын этккәләде, пычак алып салоны юка телемнәргә кискәләп куйды. — Юграк чакка туры килдегез, гаеп итмәссез инде, кем дип әйтим, исемегезне белмим.

— Рәмил, — диде ир беренче бәрәңгене авызына озатып. — Рома дисәгез дә була, иптәшләр шулай дип йөртәләр.

Көтмәгән жирдән хатын чылтыратып көлеп җибәрде. Рәхәтләнеп, башын артка ташлап, ак, тигез тешләрен елтыратып көлде ул. Беренче кат Рәмил аңа ихласлап карады. Аның Мәймүнәсеннән кайтышрак булыр, яңаклары да суырылган, ә менә күзләре матур икән, төпсез упкыннар диярсең, тартып алырга да күп сорамаслар.

— Юк, мин сезгә Рома дип әйтмәм, — диде хатын күзләреннән очкыннар чәчеп. — Рәмил бик матур исем. Ник бозарга? Ә мин Матильда, — ул кечкенә кулын Рәмилгә сузды. Кытыршы учына алгач шул нечкә бармакларны нииндидер кош баласын тоткан кебек тоелды аңа, леп-леп итеп йөрәгә типкәне сизелә әнә... Шулчак чаршау артында, төшләнеп ахрысы, бала уянып китте. Уянды да авыз күтәреп еларга да тотынды. Матильда ялт торып чаршау артында югалды. Тавышына караганда өч-дүрт яшьлек ахрысы, малайга охшаган. Ана күгәрчендәй гөрләп нидер сөйләде, өзеп-өзеп тын алган бала да үпкә тулы сүзләр әйтте бугай. Ләкин алар сөйләшкәннән бернәрсә дә аңламады Рәмил. Нинди телдә бытылдыйлар соң үзара? Бер мизгелгә генә хатын тагын пәйда булды, гаепле елмаеп печенье алды да тагын югалды. Рәмил консерваларның берсен ачып кына бетергән иде, җинел сулап Матильда тагын килеп чыкты, сыгылмалы гәүдәсе белән килешле генә урындыкны урап үтеп үз урынына килеп утырды. Рәмилнең йөзенә килеп чыккан гажәпләнүне сизеп алган күрәсең, сораганны көтеп тормады.

— Ят тоеламы? Без романнилар, сезнеңчә әйткәндә — чегәннәр. Молдавиядән, — дип аңлатып бирде дә, кашларын жыера төшеп ашыкмый гына бәрәңге ашарга тотынды. Аның сүзләреннән соң гына уйлары яктырып киткәндәй булды Рәмилнең. Әнә нәрсәгә башта сәеррәк күренде бу хатын, йөзе дә каратут, күзләре дә кап-кара, кашлары-чәчләре карга канатыдай. Әйткән сүзләренә кадәр тамак төбеннән чыгалар, моңга уралып. Күрәселәре бар икән, менә инде чегән хатыны белән кара-каршы утыра, әкәмәт. Кара әле, рома дигәне теге... Кинәт аңлап алды ул.

— «Ром» булгач, сезнеңчә ни... ир кеше буламы инде? — диде ул үзенең башы шәп эшләгәненә шатланып.

— Әйе, — диде хатын серле елмаеп.

— «Роммани» — чегәннәр, шулаймы?

— Шулай.

— Ә менә син кем?

— Хитана, минем нәселем испан чегәннәренә барып тоташа, шуна күрә...

— Ә синең ромың кайда? — дип төпченә үк башлады Рәмил үзе дә сизмәстән. Матильда ирен чите белән генә елмаеп куйды.

— Ашагыз әле, суына бит, быел бәрәңге тәмле.

Шулай инде, ни эше бар анын, килеп керүгә сорау ала башлады. Анысы Рәмилнең үзенә дә ошап житмәде. Шулай да, бернәрсә турында әйтеп куюны кирәк тапты:

— Матильда, сез дә без дип безелдәп утырмыйк әле. Мин андыйга өйрәнмәгән. Телне әйләндереп әйтүләре авыр...

— Ярый, — дип берсүзсез ризалашты Матильда. Өстәл артында башка сүз ялганмады.

Тик ятарга исәбе юк иде Рәмилнен. Вакыт та тизрәк үтәр, барыбер ремонтлыйсы, әллә үз көче белән дә очына чыгар. Эш башлаганчы фургонны ачып, бер капчык он сөйрәп төшерде. Жирдән алып жилкәгә салу жайсызрак булды, өс-башы да онга буялып бетте. Анын кызара-бүртә он күтәреп кергәнен күргәч тә Матильда чәбәкәй чапты.

«Нигә мина әйтмәден, үзем алып кергән булыр идем», — дип һушны китәрде. Менә инде, аннан капчык күтәртеп йөртерләр иде имеш. Танавына кадәр онга буялган Рәмилне зыр әйләнеп йөреп өстен каккалады, алъяпкыч очы белән сак кына кагылып, бит алмаларын сөрткәләде. «Харап иткәнсен киемнәреңне. Мина әйтсән ни була, һич югында икәүләп алып керер идек тә», — дип шелтәләгәндәй итте. «Нәрсә булган ди, эш киемнәре алар», — дип кул селтәде Рәмил. «Болай гына һич бетерерлек түгел, чалбарына да балчык чәчрәгән икән, — дип өзмәде дә куймады Матильда. — Салып куй, тәртипкә китерермен. Алмаш киемнәрен бармы? Булмаса...»

— Бар, бар, алыштыра идем тегеләй дә. Машина астына керергә кирәк, — дип Рәмил чыгып киту ягын карады. Хатын-кызнын үзенә карата артык игътибарлы булуына күнекмәгән иде ул. Һәр шоферның майга каткан бер кат күлмәк-ыштаны үзе белән йөри. Төрлесе очрый юлда: ватылган чак була, пычракка кереп чумасын... Шундый киемнәрен алып киде дә Рәмил, бу онга чумдырып алганнарын чоланга кертеп куйды. Каккалап-суккалап киярга булыр әле. Машинасы ярый калкурак урында, туктап алган икән, күптән түгел яуган яңгырлардан сурыгырга өлгергән, ә уйсулыкларда күлдәвекләр жыелып ята. Көзге яңгыр шул инде, әз генә сибәләсә дә, аяк асты ерып чыккысызга әйләнә. Әйтсән дә, кояш жылысы юк инде, озакламый беренче кар да күз күрсәтер. Тегеннән-моннан такта кисәкләре жыештырып алды Рәмил, шуларны ике көпчәк арасына түшәп өстенә катлап брезент жәйде, ачкычларын чыгарып тезде дә муеннан эшкә чумды. Башта двигательдән килгән валны ычкындырды, арткы күчәрнен маен агызып алды, тирәләп тезелеп киткән гайкаларны сүтәргә керешт. Чалкан ятып эшләү жайсыз иде. Астан да билгә салкын бәргәне сизелеп торды, такта кырлары арканы кисеп керде. Һич әмәл калмаганда чыгып-чыгып тәмәкесен төтәтте. Анысы да беткәнгә якын икән. Вәйт, бәхетсез баш, ят инде шунда мазутка чумып, иптәшләре туган тарафларга якынлашып киләләрдер. Ишекне иненә ачып кайтып керәләр бит инде, алардан кадерле кеше юк, мунча чабыналар, пилмәнен-пәрәмәчен уралар, йомшак хәләл жефетләрен кочакка алалар. Хех, ә син монда, артына ут төртергә дөньясынын... Анын күнелсез уйларын хужабикә бүлде.

— Әйдә, Рәмил, тамак ялгап ал. Бераз сонга калдым, ачыгуларын житкәндер инде. Кара инде моны, бер акка буялып керә, икенче караганда, кап-кара. Ничегрәк килешер икән дисенме? Мина калса ак төс бара шикелле үзенә. Бу майны ничек агартмак кирәк? Белгән кебек жылы суны күп итеп өй алдына алып чыккан идем. Әллә тышта суык булырмы? — Һич сөйләргә иренми

бу хатын, анысыннан битәр, уенга алып тик тора барысын. Мәймүнә булса, тагын чучка булдынмы, дип яшелле-зәңгәрле тавышы белән бер акырыр иде дә ишекне шап ябып чыгып китәр иде.Хәер, нәрсә, ире түгел, майга буялган кешене дә башлап күрәдер әле, кызык кына тоеладыр. Ире Рәмил ике атна саен өсте-башы манып алгадай булып кайта башласа, тиз үзгәрер иде каршылаулары. Ләкин менә әлеге мизгелдә күңеле тыныч иде Рәмилнең, хәленнән килгәнне эшли, кемдер баш өстендә ажгырып тормый. Ә бәлки хөрмәтләп чакыралар,йомшак сөйләшәләр. Ишек төбеннән үк тәмле исләр танауны ярып керделәр. Тамак ачуы да хак икән. Матильда мич эченәрәк куелган табаны алып өстәл өстенә утыртты, капкачын ачып җибәрде. Чаж-чож килеп торган май эчендә бәрәңге пәрәмәчләре икән. Бәрәңге генә димә әле син аны. Рәмил башлап күрде моны: бәрәңгесе борчак зурлык кына иттереп ваклап туралган, суган белән аралаштырылган, һәр кисәге майда йөзә, камыры кетердәп тора, теленне йотарлык инде менә! Ике-өчне шудырганчы Рәмил табадан башка нәрсә күрмәде. Мангаена тир бәреп чыккач кына, иркенләп тын алды, үзенә аптырап куйды. Әйтерсең дә үз өендә, тартынырга да белми, әзрәк үлчәп тә капмый, хуҗадан болайрак тотына. Унайсызланып калганын сиздермәс өчен, тамак кыргалап алган булды, алдына ясалып куелган чәйне йотты. Чәй таныш үлән чәе иде, өстәлдә шикәр-мазар күренмәде. «Ә нәрсәгә икәүләп кенә кара-каршы утыралар соң әле алар?»

— Ә малай кайда? — дип кызыксынды Рәмил.

— Ул уйный, — диде хатын тыныч кына.

— Башта аны карарга кирәк, бала бит ул, түземсез була. Исеме кем, күрмәдем дә әле үзен, — дип ризасызлык белдереп куйды Рәмил. Ул монда авыз чапылдата, әллә төкерек йотып чаршау артында торадыр малай.

— Мин аның тамагын туйдырдым, иркенләп аша. Син бала җанлы икәнсен. Безнең халык та балалар дип үлә. Ә улымның исеме Гарсия. Бабаемның исеме.

Үлән чәен чөмерә-чөмерә тагын ике-өч пәрәмәчнең башына җитте әле Рәмил. Шактый хозурлангач, хуҗабикәгә игътибар итте. Өстенә купшы күлмәк киеп куйган, сөрмә тарткан шикелле, чәчләре озын икән. Теге бригадир әйтмешли, ничава, ул Рәмил урынында булса әллә нәрсәләр кыланып беткән булыр иде, әле кочакларга да өлгерер иде. Ә менә ул якка Рәмил җөмәй, хет нәрсә эшлә, ни төчеләнеп сөйләшә белми, берәр иптәше урынына күрә. Хатын-кыз андыйны өнәми, ул үзе белән сокланганны ярата, уйлап чыгарып мактаганны. Берәр стакан салганда әллә исерек катыш батыраеп китәргә булыр иде. Үзе авызга кереп бара бит, яшь тә, чибәр генә, бар җире төгәл. Ымсындырып тора, әле анда икәүләп кенә төннәр үткәрәсе бар бит әле, малайны исәпкә алмаганда. Бала йоклый инде онытылып.Менә Рәмилгә йоклап ятмаска кирәк. Кех-х.

— Ә каян килеп чыктыгыз бу урыс арасына? Нинди җилләр ташлады? Акылы бар кеше, — Рәмил тегесен-монысын уйлап тормый бүрәнәләре череп беткән өй эченә ишарәләп күрсәтте, — мондый җирдә үз теләге белән яшәп ятмас.

Матильда авыр сулады, йөзе карангыланып китте.

— Әйе, дөрес әйтәсен, уйламаган җирдән белмәгән-күрмәгән якларда. Әйтсәм әйтим инде, ирем калдырып китте мине. Без Чиләбедән чегәннәр төркеменә кушылырга килгән идек, кабул итмәделәр. Иремнең кем икәнлеге хакында хәбәр үзебездән алда килеп ишетелгән иде. Мине калырга өндәделәр, ләкин чегәннәр арасында ирдән аерылу юк, нинди булса да, безне Ходай чәчләребезне чәчкә бәйләгән. Ни булса да мин түзәргә әзер идем. Без җылы якларга китәргә карар кылдык, берәр ничек чикләрне үтеп, бәлки, минем ата-бабалар нигезенә житә алырбыз дип уйладык. Бәхетсезлеккә каршы, юлда мин чирләп киттем, без бу район үзәгендә идек. Әлбәттә больницага керү

турында сүз булуы да мөмкин түгел. Мин көннәр буе кәрт ачып бераз акча табам, барыбызны туйдырам. Ә ирем шул тиеннән җыелганны алып уйнарга китә. Шул авырып китүем харап итте. Менә бу өйнең хуҗасы, яхшы күңелле карчык, Шура әби, автовокзалдан алып кайтты безне. Беренче көннәрдә үз-үземне белми дә ятканмын. Ирен дә ияреп килгән иде ди, ике көн торгач, булган әйберләрне алып югалган. Әйбер, нәрсә, табылыр, баш сау булсын. Шулай да озак чирләдем мин. Нинди чир булгандыр, әле һушыма килгәч, җеп өзәрлек хәлем юк, күңелдә шундый бушлык, иремнең ташлап киткәне өчен генә түгел, ә бөтен дөньясы ялыктырган, күзләрне ачып карыйсы да килми якты дөньяга. Елыйм да елыйм, тыела алмыйча, ал мине дип, Ходайга ялварам. Шулкадәр тормышка нәфрәт булырга мөмкин икән кешедә, хәзер үзем дә аптырыйм. Рәхмәт инде Александра Васильевнага, ялгыз калдырмады, әллә нинди үләннәр эчерде, кулларында да ниндидер көч бар ахрысы аның, гел дога укыды. Әкренләп тернәкләнеп киттем менә. Ул көннәрдә тал чыбыктай гына калган идем, кигән юбкам билемдә зыр әйләнеп тора, хәл юк, күз аллары караңгылана, баш әйләнә. Хатын-кыз эт җанлы була диләр, дөрестер ахрысы, ай эчендә шап-шактай булдым, тик китәр җир юк. Кире Чиләбегә барасы килмәде. Сүз юк, кабул итәрләр иде, ләкин бер барып эләксәң, ычкыну юк, гомерең шунда үтәчәк. Үзем дә Гарсия турында уйладым. Наркотиклар белән булашалар андагылар. Гарсия читтә калмас иде, азагы нәрсә белән бетәсе ачык — төрмә көтә. Шулай бәргәләнгәндә, очраклы рәвештә үтеп барган чегәннәр төркемен очраттым. Яшермим, менә сиңа сөйләгән кебек, бар серләремне ачтым. Безнең халык бит аралашып яши, кайчан да булса бер очраша алар, минекеләрне күрерләр, хәбәр итәрләр. Без дала балалары, иректә үтә гомеребез, бездә хат язу юк, язсаң да барып җитмәячәк. Менә хәзер көтәм. Ишетү белән кем дә булса ярдәмгә киләчәк безгә, ләкин вакыт билгесез. Икенче ягы да бар, Шура әбинең гозерен үтим, бер балаларымны күреп ил гизеп кайтыйм әле, өйгә күз-колак булып тор, дип үтенде. Ничек каршы килим, ул бит мине үлемнән коткарган кеше. Менә бәрәңгесен казып алдык бергәләп, кәбестә, кыярын тозладык та ул юлланды. Авыр, әлбәттә, бәрәңгегә күбрәк көч төшә, ә безнең икебезгә күп кирәкми. Мин оста тегүче, кайчак авыл хатыннарына нәрсә дә булса тегеп бирәм, әзме-күпме хакын бирәләр, кәрт тә ачам әле, анысына киләләр. Менә соңгы көннәрдә өзеклек булып китте. Ходай биреп тора ул, әнә онлы булдык, берничә көннән иптәшләрегез килеп җитәрләр, тагын акча бирерләр. Юк, зарланырлык түгел, зарланып яшәү олы гөнаһ.

Шатланырга кирәк вак-төяккә дә, булмаса, уйлап чыгарырга. Терелә башлагач, мин үз-үземә сүз бирдем: Матильда, дидем, син иң бәхетле хатын дөньяда, дидем, улың бар дидем, әнә, кояш көлә синең өчен, җил исә, һәр мизгеленә шатлан яшәүнең дидем, шатлыктан тора бу тормыш дидем, син күрмисең генә, бик тә булмаса уйлап чыгар шатлыкны, дидем. Менә хәзер инде син безнең турыда барысын да беләсең.

— Шуңа үлән чәе, шуңа шикәр-кәнфит күренми, — дип азагына кадәр ачыклап куярга кирәк тапты Рәмил. Кинәт үтереп тәмәке тартасы килеп китте аның. Кесәсенә шап-шоп суккалап алды хәтта. Шулай ул, кеше хәлен кеше белми үз башына төшмәгәч. Тамак турында, өс киеме турында, урын-җир турында башына да кереп чыкканы юк мисал өчен Рәмилнең. Военкомат чакыртып, шоферлар курсында укып йөргәндә ашау ягы такы-токырак була торган иде. Ул чакта нәрсә, атна саен өенә кайтып йөри. Өйдә кайнар аш, үчти-үчти итеп кенә торалар. Алып килгән акчаны үзара җыелышып сыра, сигарет, тәм-том алып көнендә бетерәләр иде дә, йөриләр иде каткан икмәк кимереп. Кызык кына иде әле ул чакта. Армиядән кайткач бер кат өсте бөтәйгәнче, кызлар арасында кызарып йөрде. Ә бу бөтенләй икенче очрак, тамырлары башка...

— Шикәр дә юк, чәй дә, майның да соңгысын тоттым, аның каравы бәрәңге бар, токмач кисәргә була, — дип тезеп китте Матильда. Аның тавышында печтек кенә дә көенү сизелмәде. Яшибез әле, барысы да әйбәт дигән төслерәк тота иде ул үзен. Рәмил, мәсәлән, төптән уйлап, һәр адымын үлчәп атлый торган кешеләрдән. Хатынның елмаеп-көлеп утырганын килештереп бетермәде. Кан яшьләре түгеп еларлык хәлләре, ә ул... Тәк, дигән үрдәк, һәр очраган кешегә кесәнне әйләндереп салып булмас анысы, ну, үзенә кирәк бит, шикәр-чәйсез яшәп булмас, тәмәкесе дә бетте әнә. Бу караңгы почмакта магазины да юктыр әле аның.

— Тәмәкенең соңгысын тарттым, кайдан ала алырмын икән? — дип белеште. Менә шул урам белән атлыйсы да атлыйсы икән, уң якта зәңгәргә буялган өй күзгә ташланып торачак. Аның кырында кечерәк өй кадәрлесе бар, ишек башына «Волна» дип язылган, шул кибет инде. Искә төшкәндә барып килергә булып Рәмил чоланнан әйберләрен алырга чыкты. Каккалап-суккалап киярлек кыяфәткә кертергә иде исәбе. Куйган урыныннан тапмады. Баксаң бу өлгер хатын Матильда юып-элеп куйган имеш аларны! Вәт тиктормас җан, кем сораган аннан. Ачуланырга да көләргә дә белмәде Рәмил. Нәрсәдер мыгырданган булып, запаста йөргән нәрсәләрне табып өстен алыштыргандай итте. Кибетне ул, чынлап та, тиз тапты. Озак уйлап тормаганнар, бәләкәй генә бураны такта белән урталай бүлгәннәр дә пыяла астына, дивар буена киштәләргә товарларын тезгәннәр.

Рәмилне прилавка артында торган кып-кызыл йөзле, таза ир танышы кебек каршы алды:

— Әйдә, уз, юламан, ватылып калдыңмы? Була юлда андый хәлләр, үзем күп йөргән. Юра, — дип итләч кулын сузды. Кат-кат кысып һич сүздән тукталмады.— Хәзер менә якорь ташладым, яшь тә бара, йөрәк тә шаярта, ә тегеләй Рәсәйне иңгә-буйга үлчәгән кеше мин. — Алыпсатар икәнен дә онытмады. — Он белән туктагансың икән. Сатмыйсыңмы? Хакына килешсәк мин өч-дүрт капчык алыр идем. Үземнекеләргә генә, болай бу тирәләрдә онга кытлык юк. Бик арзанга очырсаң гына инде.

Авыз ачып тыңлап торды Рәмил. Кай арада белгәннәр, каян ишеткәннәр. Авыл авыл шул инде. Бер очында төчкерсән, икенче очында буылып йөткергән төсле булып ишетелә. Әйе дә, юк та димәде Рәмил, иртәгәсе көнне кем белгән, сүзне икенчегә борды. Тәмәкесен, чәен-шикәрен, хәтта көнбагыш маен алып җыйды, бәләкәчкә суыра торган кәнфитен үлчәтте. Матильданың елмайган чагында ачылып киткән тигез тешләре исенә килде дә, майтти ти дип, бер шешә «сафны» алды. Инде чыгарга җыенгач, тагын борылды. Ул кеше өендә авыз күтәреп эчеп утырыр, ә хуҗабикә риза булып карап утырырмы. Рәмил бик яхшы белә, ап-айнык булып кешенең каршыда эчеп исергәнен карап утырудан да күңелсезрәк эш юк бу дөньяда. Хатыны көн-төн талагач, күңеле булсын дип, ярты еллап авызына алмый йөреп алган иде ул. Үлемгә тиң иде инде мин сиңа әйтим кунакларда утырулары. Матильдага тәгаенләп бирәр кызылны алырга булды. Сорагач та, сатучы ир мәгънәле генә карап куйды. Телен тешләрдәй булды Рәмил, кызарып китте шикелле. Аннан үз-үзенә, артык акыллы бу алыпсатарга ачуы чыгып, рәттән алды. Бер баллон сыра, алма, тартмада шоколад, беләк буе колбаса. Акчасы беткәч кенә туктады. Ике кулына ике пакет тотып, мыш-мыш кайтып керде өйгә. Теге ир дә, Матильда да бу кадәр алып җыйгач, нинди планнар корганын ашадан аша күрәләр кебек тоелды. Төкерергә ,теләсә нәрсә уйласыннар, ә ул нәкъ киресен эшләр. Ашар-эчәр рәхәтләнеп, бер сүз дә кушмас Матильдага, күзләрен дә майландырмас. Әйдә көтсен чегән хатыны, әллә өмет тә итәдер әле, белерсең аларны. Тигезлек юк бу кояш астында, нигә тик ир кеше башлап һөҗүмгә күчәргә тиеш, ниндидер мәгънә салып сүзләр

сөйләргә, килеп кагылырга хатын-кызга?! Килешмәгәнне әйтеп куярсын, авыз күтәреп көләргә тотынса, нишләрсең? Йә, йомшак кына кагылыйм әле бәрхет төсле тәненә дип кагыла калсаң янагына чалтыратыр бар көченә. Каян беләсең кайчан нәрсә әйтергә дә, ни вакытта сыйпаларга? Юк, булмый ул якка Рәмилдән. Менә Матильда үзе килеп бассын иде аның каршысына, салсын иде назлы кулларын аның иңбашына, син мина ошыйсың, яки шуңа охшаганрак берәр сүз әйтсен иде. Карышып торыр идемени Рәмил? Йә берәр башка ир-ат кире кагыр идеме андый тәкъдимне? Беләләр бит шулай буласын хатын-кызлар, нигә этлиләр икән алар безнең халыкны? Башкасында беренчелекне үз кулларына алып бетерделәр, алар өй хуҗасы, алар начальник, алар депутат, менә бу өлкәдә алсыннар иде дилбегәне үз кулларына. Вәт булыр иде тигезлек. Рәмил көчләп-көчләп пакетларны өстәлгә бушаттыргач, өйгә байлык исе таралды. Шул чакта өстәл артыннан башы гына күренеп торган Гарсияны беренче тапкыр күреп алды Рәмил. Бөдрә чәчле, чем-кара күзле, түгәрәк йөзле малай нәни куллары белән өстәл читенә тотынып, аяк очларына баскан да, өстәл өстендәге тәмлекәйләргә түгел, күзләрен алмый Рәмилгә карый иде. Гаҗәпләнү дә, курку да, тартыну да чагылып кала иде ул күзләрдә. Рәмил төргәкләрне ача-ача малай алдына тәм-том өйде. Малай биргән берсен янындагы урындыкка күчерә барды, ләкин һаман да бер өн дә чыгармады.

— Нәрсә әйтергә кирәк? Рәхмәт әйт абыйга. Гарсия, шулай ярый димени, рәхмәт әйт, — дип көлә-көлә улының аркасыннан каккалады хатын. Аңа күзе төшеп калгач тагын бер аптырап калды Рәмил: алыштырып куйганнармы Матильданы? Аның янында бер ун яшькә яшәргән, чәчләре тузгыган җилбәзәк кызыкай басып тора иде. Шунда аракылар алганына шатланып куйды эчтән генә Рәмил. Куып чыгарса чыгарыр, мәгәр... Азагын уйлап бетермәде, үз уйларыннан үзе куркып китте. Исәр дә инде ул. Матильда кем дә ул кем? Ул, почык борынлы, кыска буйлы бер ир кисәге шундый матурлыкка кул сузмакчы була. Аракыга сатып алып була димени сөюне? Бая ялгыш уйлаган ул хатын-кыз турында. Ул бит ир-атның теләген канәгатьләндерү турында акыл сатты, ә хатын-кыз сөю-сөелү хисләрендә яши. Менә сине, кәкре аяклары белән җир таптаган кешене сөяргә теләге туарга мөмкинме соң берәр иркә затның? Әлбәттә юк, шуңа күрә баш ватып торасы да түгел. Иң әйбәте берәр йөз грамм капларга кирәк, көне дә суык, кәефе дә шуңа туры килеп тора, монысына,шөкер, әлеге янда торган затның кысылышы юк. Бу эшкә икәү кирәк түгел, ялгызың да җиренә житкереп башкара аласың. Аның уй йомгагы икенче сукмакка кереп киткәнен Матильда тоеп алды күрәсең, көлүдән туктады, малаеның колагына нидер сөйләп чаршау артына озатты, өстәлнең бер читен сөртте.

— Тозлы кыяр бар, кирәкме? — дип үз итеп эндәште ул кулына шешә тотып баскан Рәмилгә.

Үрелеп чәркә алып куйды.

— Бәлки, мунчадан соң? Мунча әзер...

Рәмил чак идәнгә утырмады, мичкә сөялеп калды. Ах, елан аягын кискән хатын, нинди мунча, кайчан өлгерткән. Әйдә, икәүләп барабыз, дип арттан тагылса?.. Кулындагы шешәсен онытты Рәмил. Кара әле, курка икән ич ул бу чибәр хатыннан, уттан курыккандай курка. Читтән карап шәбәергә генә оста шул ул. Булмый аннан. Мәңге шулай... Мәктәптә укыган чактан ук. Шул чәчбикәләр якын күреп туры карасалар да телдән кала торган иде. Сонрак әнә шул теленә ирек салып, башына нәрсә килә, шуны сөйләр булып китте. Аның сөйләгәнен көлкегә алдылар, күңелле егет исемен күтәрде. Шул телгә салынулардан ары китмәде. Өйләнгәндә Мәймүнәсе, дөресен әйткәндә, аны үзе өйләндерде. Ике яшькә олырак кыз йөргән егете белән пыр тузып

ачуланышкан иде, тегесе өстәп шәһәргә эшкә чыгып китте. Иләс-миләс йөргәнендә кул астына ерык авыз Рәмил туры килде. Аның көлдергечләрен тынлап тормады ул. Эшне кызу тотты, яныннан бер адым да читкә җибәрмәде, өйләренә дә үзләренә барып кергән төсле барып керде. Бер кич бөтенләйгә калды. Әнә шулай мажаралы булды Рәмилнең гаилә коруы.

— Да, анысы яхшы булыр, — дип шактый ышанычлы тавыш чыгара алды ул алай да. Шешәне кире өстәлгә утыртты. — Мунча шәп нәрсә! Менә без, шофер халкы, ерак рейсларга йөргәндә нәрсә юксына дисең?

— Хатыннарыгызныдыр, мөгаен, — диде Матильда шаян елмаеп. Монысына һич алдашмый җавап бирә ала иде Рәмил.

— Юк! — диде. Чынлап та ул кадәр хатынын күрергә ашкынып кайтканы булмады аның.

— Юк, — дип тагын кабатлады басым ясап, — эчә алмый зар-интизар булалардыр, дия кемдер. Ансын да капкаларга форсат табасың. Мунча сагындыра, күгәрченкәй! Теге ләгәнгә утырып юынулар, ваннаны әйтәм, мунчаны алыштыра аламы соң? Эссе пар, каен яфрак. Миннек бармы? — дип кисәк тукталып ачыклыйсы итте.

— Яфрагы бар да ул, — диде Матильда гаепле сыман, — ә менә сабыны — кер сабыны. Мин үзем чәчне ачы катык белән юам. Кирәктер бәлки?

— Кер сабыны самый раз, — диде Рәмил. Икенче иде әле аның уенда. Менә инде сүз арасында «Күгәрчен» дип тә дәштеме, озакламый «кошчыгым»... «сандугачым», «былбылым» дип тезеп китмәсме? Каян килеп керә телгә шундый төчеләнү. Иманы камил, ул сүзне беркемгә дә әйткәне булмады шикелле аның моңа кадәр.

— Мин күлмәк-чалбарыңны үтүкләп киптереп куйган идем, әнә урындык башында, — дип ымлады Матильда, — алмаш киемнәрең юктыр инде...

Рәмил чәчрәп чыкты, урыныннан сикереп торды. Ну бу чегән хатыны ни-нәрсә сөйләпләр ушны ала? Кемгә чутлый ул Рәмилне?

— Бар, бар, барысы да бар, озак йөрибез бит без, ярты дәүләтне үзебез белән төяп йөртәбез, а как же, без кыргый халыкмы әллә? Муеннан майга батып йөриләр дигәч тә...

Бераз тынычлана төшкәч гозерен әйтте.

— Син, ни, капкаларга бирәр нәрсә хәстәрли алмассыңмы? Менә уразаны бозарга иде исәп. Син уйлама... — Рәмил тагын үзенең кызара башлаганын тойды. Нәрсә уйламасын икән? Монда уйласы-нитәсе түгел, барысы көн кебек ачык. Фатирга кергән һәр шофер кайнарлыгы бөркелеп торган тол хуҗабикәне алдаштырырга омтыла, хәмер эчерергә ниятли, тел яздырырга, аннан инде түшәк уртаклашырга. Тик бу очракта шоферы юньсезрәк тә, хуҗабикәсе дәрте ташып торганга охшамаган.

— Син воопше уйлама.

— Мин аның турында уйламыйм да. Уйласаң ни дә, уйламасаң ни. Кыскасы...

Әллә нәрсәләр сөйләп буталып бетте Рәмил. Дулкынланса гел урысчаны ватып-кырып сөйләшә башлый ул, кирәкле сүз табалмый интегә.

— Ә мин бернәрсә дә уйламыйм, — диде Матильда тыныч кына, — өстәл әзерләргә дисең икән, ярый, хәлдән килгәнчә тырыштырырмын. Бар инде, уты яна, яфрак ишек төбендә, исе булгандай булса төнлегеен ач. Безгә Гарсия белән артык эссе кирәкми.

***

Бәрәңге бакчасында урнашкан мунча өйдән дә таушалганрак күренде. Чоланда идән дигән нәрсә бөтенләй юк икән, ишек алдына чыпта җәеп куелган. Киемнәрен кайда туры килә шунда элгәндәй итте дә, Рәмил эчкә

үтте. Чекрәеп янган лампочка да карангылыкны тарата алмый, мунча кара булып чыкты. Күптән мондый искелек калдыгында юынганы юк иде Рәмилнен. Тәвәккәлләп бер чүмеч суны чажлап торган ташларга тондырган иде, чак чүгәләп калды. Кайнар һава тыннарны куырды. Ичмасам мондый мунчаның эссесенә кинәнәсең инде ул. Бераз эссе таралгач, мунча белән бергә картайган ләгәнгә су хәстәрләде, яфрак пешереп алды да, тагын бераз эссе өстәп караеп ялтыраган ләүкәгә сузылды. Аяк бармакларыннан чәч төпләренә кадәр тирләп чыкты ул, бар әгъзалары йомшап изрәп төште. Кеше арасында сакланган пружина төсле кысылган киеренкелек эреп юкка чыкты. Рәхәт, әйтеп анлата алмаслык рәхәт иде Рәмилгә. Гомумән, кеше мунчада гына үзен үзе итеп хис итә ала шикелле. Кием дә юк, ә кием бит бик тиз үзгәртә кешенең халәтен. Син сәләмә киеп бас, йә энәдән-җептән киенеп атлап кара, болар икесе ике кеше, ә монда атабыз Адәмне саклаган яфрак та юк хәтта, тышындагы житешсезлекләрең күз алдында, эчке тойгыларын да киртәләнмәгән. Менә шулайрак уй уйлады Рәмил, кайда икәнлеген, вакыт исәбен югалтты. Ана әлеге минутларда шулкадәр әйбәт иде, ләкин бу тойгы мунчага кереп ләззәтләнүдән генә түгел, ә бәлки тагын нindидер таныш булмаган шатлык бөреләнгән иде анын йөрәгендә. Ниндидер үзгәреш барлыгын сизә иде ул, ә нинди икәнен әле анлый да алмады, анларлык билгеләр дә калыкмаган иде, тик бар иде кайдадыр ан төпкелендә шатлыклы сиземләү. Һәм шуны белә иде Рәмил, хәзер ул үзгәрә, ниндидер көч аны үзе артыннан әйди, теләсә дә элекке халәтенә ул кайта алмаячак. Ә нинди булды сон ул «үткәннәр»? Армиядә хезмәт итте, ул елларны искә алырга да түгел, әле дә жанны өшетә. Колгуев утравына алып барып бәрделәр дә, ике ел үткәч кенә Зур жирне күрә алды. Төрмә дә төрмә булды инде ул, унга карасан — дингез, сулга карасан — дингез, булган тере жаннар — пограничниклар, бар утрауга ике хатын-кыз, застава башлыгынын хатыны, бер стерва, солдатларны кешегә санамаган аждаһа, ул ук, фельдшер һәм повариха, пенсия яшьләрен үткән Мария Федоровна. Агачы да үсми иде ул бәрәкәтсез жирдә, тау-таш кына, үлән шытып чыга да саргая. Кайтты да район үзәгенә эшкә керде. Анда да эшләдең ни, эшләмәдең ни, акчасын түләмәделәр, әз-әзләп товарлата биргәләп тордылар. Егет кешегә он нәрсәгә дә, тоз нәрсәгә? Мәймүнә белән очраштылар. Анын эше жайлы иде тегеләй, милициядә язып-сызып утыра иде. Шундый канун бар: халык никадәр начаррак яши башлый, милиция халкы күбәя, һәм яхшы да яши. Мәймүнәгә дә акчасын вакытында түләделәр, төрле льготалары булды. Яшь гаилә бер-ике ай тернәкләнергә тырышып карады, аннан кул селтәп, Мәймүнәнең апалары янына шәһәргә чыгып киттеләр. Баштарак ятакханәдә көн күрделәр, сонрак Мәймүнә, үткерлеге белән, барактан булса да фатир шәрәмәте юнәтте. Ул чакта шәплелек белән алдырып була иде әле. Шуннан Мәймүнә икенче план корды. «Бала кирәк, — диде, — бала булса аны кочаклап мин президентнын үзенә житәм житсәм, әмма адәм рәтле фатирга ия булам. Исемем Мәймүнә булмасын!» — диде.

Жан-фәрман тырыштылар, хатынынын бармаган больницасы, күренмәгән врачы калмады, экстрасенслар, өшкергән-төкергән әбиләр турында сөйләп торасы да түгел. Икәүләп бернichә ел рәттән гел шуларга түләргә генә акча эшләделәр. Берсенен дә файдасы тимәде. Һаман да баракта көн күраләр. Инде булмас шәплеләр белән ил тулды. Хәзер Мәймүнәсе инде бар энергиясен үзен карауга бирә. Кырык төрле майны килолап алып битенә-тәннәренә яга,иннек, кершән, сөрмә ише нәрсәләрне бергә жыйсан кибет ачарлык. Кием-салым турында әйтәсе дә түгел, мода журналлары, төрле шоплар адреслары, ательелар да, тагын әллә нәрсәләр. Кем турында берәр сүз әйтергә теләсә, башта нәрсә кигән, ничек килешми ана, кайсы яктан көлкеле, кемгә

охшаган — ишәккәме, сыергамы? Иртән торып видеога карап кына чит ил зарядкаларын эшли, туры килгән саен ял йортларына китә, төрле клубларга йөри, чәчләрен атна саен өч буята, ачуым да килмәгәе? Кемгә кирәк? Рәмилгә охшарга тырышып шулай кыланамы? Анысы юк та юк инде. Аның тормышында ирнең урыны билгеләнгән һәм ул үзгәрешсез: ир акча китерергә тиеш, никадәр ешрак һәм никадәр күбрәк китерә — шулкадәр яхшырак. Ике арада сөйләшүләр нәрсә турында башланмасын, ирексездән акчага килеп кагыла, азагы син юньсез, син җөмәй, синең эшләгән акчаң тавык көләрлек, торма ичмасам каршымда саруымны кайнатып, дигән сүзләр белән гадәттә тәмамлана. Күнегелә икән барысына, хәзер Рәмил андый гаилә низагларын тыныч кабул итә, шулай булырга тиештер дип уйлый. Кайчакта башына мантыйкка сыймас уйлар килеп куя, ә берәр җирдә, бу якларда түгел дә ди, җиде дингез артында, мисал итеп тотарлык кына булса да акчага туйган хатын-кыз бармы икән ул? Барысында бер программа бит — акча кирәк... Тагын кирәк... монысы гына аз, кирәк әле, кирәк, күп кирәк, тагын, тагын акча... акча кирәк! Йә Хода, ничек яшиләр алар гел бер нәрсә турында уйлап, нык та була икән кыеклары. Рәмил үзенең чамасын үзе белә, әллә ни көтми, өмет итми бу дөньядан, шаккатыра торган егетләрдән булмады ул электән дә, хәзер генә могҗиза булмас. Пенсиягә кадәр суза алса, Мәймүнәсе икенче берәүгә тагылып китмәсә (ә андый куркыныч бар, сизеп тә кала кайчак Рәмил, сизмәмешкә салыша, ә нәрсәгә?) ятарлар карт белән карчык җыйган чирләрен дәвалап, иртәдән кичкә кадәр телевизордан кино карап. Аннан инде тю-тю... Бер аннан калмаган якты дөнья, артык дәгъвалар белдерәсе түгел, күпләр шулай яшиләр, ә шулай да нәрсәдер урап үтә кебек аны, нәкъ менә аны... Һе, нәрсә мәлҗерәп төште соң әле, нигә килгәнен онытты. Кайда әле чүмеч, кил әле монда миннек... Тач-точ чабынып хәлләре бетте аның. Чабынганда карт әнисенең әйтеп чаба торган теләкләрен тели-тели чабынды. Булган пычраклар, гөнаһлар, чирләр, арулар, кайгылар, бурычлар, авырлыклар коелып калыгыз! Чабынган саен тәнем-җаным чистарсын, гөнаһларым бетсен, шатлыклар тулсын, тәнем яшәрсен,саулык-сәламәтлек, байлык-барлык килсен! Хак, әле без, типсәк тимер өзәбез, вәт шулай, вәт шулай, раз-два, раз-два — дип кый-галәмәт килде. Тыңлап торган кеше була калса, сантыйга чыгарыр валлаһи, яңа туган сабыйдай сафланып, хәле бетеп кайтып егылды. Урынына ак җәймә җәелгән, ап-ак тастымал баш өстендә, кадерләп каршы алалар аны монда.

— Без дә барып юынып киләбез. Чәй кайнаса алып куярсың әле, зинһар, тамагың кипкәндер, үзең ясап эчә башла, — дип фәрманнар биреп Матильда малае белән мунчага китте. Кешегә бәхетле булу өчен таш пулатлар да, капчык-капчык акчалар да, алтын-көмеш тә кирәкми. Саналган нәрсәләр бит барысы да тупас матдәләр, ә бәхет ул — хис. Адәм баласы бары тик күңеле белән генә тоя ул бәхет хисен. Менә бу бәхет! диярлек жисем, матдә юк фанилыкта. Менә әле Рәмилнең кайсы җире арткан, шул ук Рәмил, ә күңелендә кошлар сайрый. Күзләрен ачып карарга курка хәтта: барысы кинәт юкка чыгар төсле.

Бигрәк мунча керә белмиләр икән: Рәмил урыныннан да торырга өлгермәде, ах-ух килгән булып малаен күтәреп кайтып та житте. Матильда чаршавы артына ышыкланды. Бераз тирләр кипкәндәй булгач, Рәмил торып урындык башыннан үтүкләнгән әйберләрен киеп куйды. Үзен матур, чиста, яхшы, бер дигән ир итеп тоя иде ул. Өстәл янына килеп, тышына ак аю төшерелгән сыраны ашыкмый, тәмләп кенә бер чынаяк каплап куйды ул, чарасына туры китереп алынган кыйммәтле сигарет кабып ишегалдына суынырга чыгып басты. Кызарып баеп барган кояшта чагылып, йөрәк кузгатып, кычкыра-саубуллаша торналар чылбыры очып бара иде. «Мин

дә шул торналар кебегрәк» — дигән хыялый уй килде Рәмилнең башына. Кайтам-китәм-кайтам. Юлда йөргәндә өйгә кайтасы килгән төсле, кайтсаң тагын юлга омтыла башлыйсың». Әллә берсе әнә теге басуда ялгыз калган инде. Шуна охшап ялгыз башың торып калуың да бар, барыр-кайтыр жирең дә булмас. Ашкынмассың да, ярсымассың да. Тукта, менә болайрак итеп әйтсән, ятешрәк килеп чыга түгелме?

Ялгыз торна басуда.
Басылдылар ярсулар...

Ә дәвамы? Ярсулар басылгач ялгыз башың үткәннәрне уйлап ятарга гына кала инде, тәк, болай дибез аны:

Ялгыз торна басуда.
Басылдылар ярсулар.
Үткәннәр бары төш кебек
Бакыры да көмеш кебек.

Тап өстенә бастым. Үткәннең начары да онытыла, сагындыра башлый. Ах син, агачтан юнып ясалган шагыйрь, әллә нәрсәләр кыланып бетерә адәм баласы, көлеп үләрсең. Үз уйларына үзе елмаеп жылы өйгә үтте ул. Мунчадан соң тыш салкынчарак икән шул. Иркенләп тагын урынына сузылды. Чаршау артында тавыш-тын юк иде, әллә йоклап киткәннәр? Малай булдырыр, хатын йоклап ятмыйдыр. Кузгаласы да килмәде Рәмилнең, күзләрен йомды да ята бирде. Уйлары болытлар сыман кисәк-кисәк йөзә бирделәр. Әлләкми-тагылмый, йөрәк кылларына кагылмый. Гадәттә без үзебезне һәрдаим ныклы киртә эчендә тотабыз, менә әз генә ял итеп алам да шуны эшлим дип, алдан планнар корабыз, йә булмаса, менә монда басып торганда, йә утырганда кеше арасында болай кылану килешмәс дибез, тураебрак басабыз, йөзгә акыллы чырай чыгарабыз, корсакны эчкәрәк алабыз, гомумән, һәрберебезнең эчке контролеры бар. Хәтта уйлар, хисләр аңа буйсынган: тукта, алай уйлама, азынма, дип туктата ул безне, йә, көлмә, житте сина, нигә айгыр булып кешнисең, дип кисәтү ясый. Менә әле Рәмилнең аның коллыгыннан котылган чагы. Теге, йоглар, суфыйлар, шундый сыйфатка керәләрдер инде. Кайгырмый да, шатланмый да, үткәннәрне онытжан, киләчәк — юк, бары бер мизгел эчендә үзен тоя. «Нирвана» диләрме әле. Тышта энгер-менгер...

Идәнгә шалтырап калак төшкәнгә сискәнеп китте ул. Битен угалап торып утырды. Әл-лә-лә, өстәлгә ямь кергән ләбаса! Янында елмаеп Матильда басып тора, ә бәләкәй малай әнисенең итәгенә чатырдап ябышкан да, Рәмилгә текәлгән. Барысы әзер булгач юри төшергән калакны мут хатын, әлбәттә шулай! Тегенди-мондый гына булса да, Рәмил бер кагыйдәне ныклы үзләштергән иде: хатын-кызны мактарга кирәк! Әнә шуны истә тотып тел шартлаткан булды өстәлгә карап, кулларын угалады, авызыннан сулар килгән төсле кыланды, ах-ух килде. Күнеле булды Матильданың, бит алмалары янып чыкты, гел елмаясы итте. Бер-берсен кыстап өстәл артына утырдылар. Ни гажәп: теге бөтерчек Рәмилнең күзләренә туп-туры карап алдына үрмәләргә теләк белдерде. Әнисе аһ итте, көлеп тә карады, әйтеп тә карады, гомер кешегә барганы юк иде, күрше карчыгын гына таный, нәрсә булган мона? Ә малай үзсүзләнеп, еларга житеп Рәмилнең чалбарын тарткалады. Нишләсең, күтәреп алды Рәмил бераз дерелдәгән куллары белән. Ят иде ана, бала күрмәгән кешегә, йөрәге леп-леп типкәне тоелган бәләкәй генә кеше затын үзенең кочагына алу, теге нәкъ үзенә кирәген тапкандай, песи баласыдай йомарланып утырды да тынып калды. Кузгалырга да курыкты Рәмил, аракыны авызына алмас борын иләс-миләс

килә иде инде ул. «Баш китәрлек эшләр, бара-бара нишләр?» — дип берничә тапкыр эченнән генә кабатлап утырды. Матильда анын хәленә керде. Кыздырылган бәрәнге бу юлы колбаса белән аралаштырылган иде, Рәмил алдына ук куйды, чәнечке-калак ише нәрсәләр тезде. «Салыргадыр инде», — дип ялт итеп кенә карап алды да каш астыннан, чәркегә «саф»ны коеп анын алдына шудырды.

— Үзенә дә сал, әнә кызылын, кызларныкын, — диде Рәмил карлыкканрак тавыш белән. Кинәт тамагы кибеп киткән Матильда карышмады. «Ярый, алайса, бәйрәм булгач бәйрәм булсын, күптәннән авыз иткән нәрсә түгел иде», — дип үзенә дә бүлде. Тавыш-тынсыз гына эчтеләр: Рәмил иякне түшәмгә күтәреп чәркене каплап кына салды, Матильда бер-ике йотудан үтмәде. Тегесен-монысын капкалаган арада, бала кеше утырып ялыкты, иркәләнеп ялтыр-йолтыр кәнфит сорап бәләкәй учларын тутырды да үз почмагына сыйланырга китте. Икенчесен Рәмил үзе салды, нәрсә яшерергә, эчүне күтәрә алмый иде Рәмил: йөзе бурлаттай кызарып чыга, күзләре төс югалта, үзе үзгә, тирә-як дөнья үзгәрә анын өчен. Барлык кешеләр яхшы булып күренә башлый, туктамый сөйләшәсе килә. Мондый кондициягә житүенең дәвамы ике төрле була, янында Мәймүнәсе утырса, бетте инде, кунак-фәлән икән, өстәл астында аягын изгәли, кулы житкән урыннардан чеметә, колакны бетерә: «Эчмә башка, хайван, аяклы каза, жирбит, ыстрам, подлец....» — дигәнрәк сүзләр белән. Түзә, Рәмил, түзә, ну бит кеше арасы, ә анын да әзрәк күнелен күтәрәсе килә бит, эшлә дә эшлә имеш, бәйрәм дә кирәк кешегә. Жаен табып тагын бер-ике чәркә түнәрә ул. Азагы начар тәмамлана. Туздырып алып чыгып китә дә, юл буена игәүли хатыны, кайткач йокы күрсәтми, котыра. Тәмам талашып, бер-берсен күралмас хәлгә житеп туктыйлар. Шуны шәйләгәне бар Рәмилнен, гәүдәгә таза хатыны чәркәләр күтәргәндә аннан калышмый, ник бер күзенә чыксын үзенен, мәгәр ирне хурлапмы хурлый инде, мингерәү ясый. Монысы ир белән хатыннын хәмер кергәндәге тормышы, ә иптәшләре белән үзара жыелышып алырга туры килсә, Рәмил теләгәнен туйганчы сөйли инде, күнелен бушата, тик бит анда сине тынлаучы кеше юк, барысынын хәбәре жыелган. Иптәшләр белән аралашканнан сон өйгә кайтырга туры килсә, азагы ничек булганын тагын чамалыйсыздыр инде. Иске гадәт ташланмый диләрме әле, бүген генә Рәмил үзгәреп китмәгән иде инде. Өч чәркәне бушатып, артыннан голкылдатып ярты чынаяк сыра йотып куйган иде, башы буталды, өйрәнгән роленә керде.

— Юк, беләсенме, Матильда, яратам мин чегән халкын. Бик әйбәтләр алар, еш уйлыйм мин алар турында, — дип башлап китте ул, ике терсәген дә өстәлгә салып. Савыт-сабага урын житми башлады, ә аракы үзенен эшен эшли иде, иблис токымы! — Менә син уйлый торгансындыр, фәлән-фәсмәтән, бу шофер, кешегә чутлап торырга шуны, дисендер. Алай түгел ул, Матильда, түгел, менә болай бит ул. Мин, пример, шофер гына дисенме? Минем образование, югары белем, мин инженер окладында, беләсенме күпме түлиләр? — дип бармакларын селки-селки тузга язмаганны тезде ул. — Мин бит болай гына руль артына утырып чыктым, тәжрибә үткәрәбез. Бик тә секретный бер тимер куелган минем машинага. Әйе. Мин бит ин яшерен берлектә эшлим, тсс, шым, шым бул. Сина гына әйтәм. Белденме инде минем кем икәнне? — дип уратыпмы уратты исерек башка килгән рәте-чираты булмаган уйдырмаларны. Әллә канында ир-атнын, эчеп алдымы, ул гади кеше булып кала алмый. Йә бик акыллы икән ул, йә бик талантлы, йә булмаса сихри көчләргә ия. Бигрәк тә алар үзләрен дәүләт күләмендә мөһим эш башкарган бик тә оста шәхес итеп сурәтләргә яраталар. Тик нигәдер һәрвакыт таныклыклары үзләре белән булмый. Рәмил шулар калыбыннан иде, ни әйтәсен. Матильда түземле генә анын әкиятләрен тынлады, эһ

тә димәде, артык бөгештереп җибәргән җирләрендә тыйнак кына көлеп тә алды, Рәмилнен йөзендә серлелек күренсә, ул да сүзсез калды. Кеше ышанмас, мәгәр бик игътибарлы тынлаучы иде ул. Ходайнын рәхмәте, Рәмил тәмәке тартырга чыгып китте.

— Сине дә тынлыйсым килә, — дигән булды кайнар чәй йоткалап.

— Нәрсә сөйлим икән, — дип уйга калды Матильда.

— Ә Испания турында син каян беләсен?! — дип кызыксынды Рәмил. Кызыксынырлык та, Рәсәй төпкелендәге бер ярым ташландык авылда чегән хатыны әллә кайдагы зәнгәр дингезле Испания хакында: «Анда минем туган туфрак» — дип утырсын да...

— Безнен нәселдә буыннан-буынга сөйләнеп килгән тарих ул. Әллә хакны сөйләгәннәрдер әбиләр, күбесе уйлап та чыгарылгандыр инде. Чегәннәр тамырлары белән төрле илләрдән алар. Мин хәтта ерак Һиндстаннан килеп чыккан төркемне очратканым булды. Румыния, Молдовия, Италия, Венгрия чикләрен үтеп-сүтеп йөрибез, анда төпләнгән кардәшләребез белән туганлашабыз. Безнен халык утрак тормышка күнекмәгән, җил кебек ирекле. Чегәнгә ат белән җыр булса җиткән ана. Кайда да өй, кайда дә туган җир. Сонгы вакытларда, бигрәк тә монда Рәсәйдә, байлык артыннан куып наркотикларга бәйләнделәр кайберәүләр. Ә шулай да күпчелек аларны хупламый, урап үтәргә тырыша. Ә Испания дигәне менә мондый гыйбарә. Безнен ерак бабабыз 1492 елда Палос — де-ла— Фронтера шәһәрчегеннән «Пинта» карабында Колумб белән сәяхәткә чыккан имеш. Ул чакта ана егерме биш яшь булган. Имеш, безнен бабабызны ирек сөюче бөек сәяхәтче үз иткән,бер тотам яныннан җибәрмәгән. Череп баеганнар икәүләп. Бабай үз өлешенә тигән алтыннарны биш атка йөкләп алып киткән. Төрле мажараларга хирыс чегән Америкага дүрт тапкыр барып кайткан имеш. Сонгы кайтканында ул иллегә якынлашкан булган инде. Акчаны исәпләми тоткан, баш җитмәс үткәннәре булган чегәнгә берсүзсез минем картәниемне, ул чакта уналтысы да тулмаган чибәр кызны димләгәннәр. Башта туйга кадәр, үз-үзен юк итәр дәрәҗәгә җитеп карышса да, соныннан язмышына буйсынган карт әнием. Яхшымы-начармы бергә гомер иткәннәр һәм бер кыз үстергәннәр. Әнә шул вакытларда безнен нәселдә бер гадәт сакланган. Һәрвакыт кыз бала туа, ул берүзе генә үсә һәм үзеннән күпкә карт кешегә кияүгә чыга. Бозыммы берәр төрле, әллә сәяхәттә чагында зур гөнаһка тарыган булган картатаем, бу уйлап чыгару түгел. Менә мин генә үзгәртәм шикелле бу тәртипне. Минем кызым түгел, улым туды. Ә ирем чынлап та карт иде. Кавышканыбызга биш ел, ә биш ай да бергә булмадык: ул гел юлда, гел чегән эшләре белән китеп югалды. Башка күрә алмам инде мин аны, өметләрем өзелде.

Менә чегән хатын-кызларын җинел холыклы, ир-атка сыланып баралар дип күз алдына китерәләр. Чегән хатын-кызларыннан да тугрырак хатыннар юк дөньяда. Әнә гарәпләрдә, кавказ халкында тәртип нык дип мактаналар. Булыр инде битен-башын каплап, бүлмәдә бикләп утырткач хатынынны. Ирек бирсән, башкаларны уздыралар алар, ни дисән, өйрәнмәгәннәр иреккә.

— Ә чегәннәр язмышына язылган ирне бар күнелләрен биреп хөрмәт итәләр, анын өчен генә яшиләр. Тамагын кайгырталар, өстен-башын юнәтәләр, күнелләрен күрәләр — бу изге бурыч безгә. Ходай ирләрне бездән артык итеп яраткан. Менә син нинди игелекле, яхшы күнелле, елмаюын матур синен, гел карыйсы килеп тора... Күпләр, безнен затларны әйтәм, тарткалашып, баш булу өчен көрәшеп ирне үзеннән түбән куярга тырышып гомерләрен үткәрәләр. Йөрәкләре белән анлап торалар алар: ир өстенрәк, анын күнеле мәрхәмәтлерәк, эшләгән эшләре мөһимрәк, тормышы чистарак, эчтә утырган шайтаннары көнләштерә, телләренә агу,

кылган кылыкларына ачу бирә. Әгәр ирне җитәрлек дәрәҗәдә хөрмәт итеп, яратып, аның тормышы белән яшәсә, һәр хатын бәхетле була бит. Менә синең җинел машинаң бармы?

— Юк, әлегә, — диде бу борылышны көтмәгән Рәмил.

— Ә хатынын комарланып акча җыядыр әле машинага?

— Анысы шулай инде, җыя, хакларны яттан белә, — диде Рәмил бу хатынның үтә күрү сәләтенә кәефе килеп.

— Менә алдыгыз ди, өзеп-йолкып өр-яңа машина, утырып чыгып киттегез ди парлашып, машина да юк, сез дә? Яхшымы? Кирәк идеме ул машина сезгә?

— Әллә шулай булырга тиешме? – дип курку йөгерде Рәмилнең. Анламассың уенмы-чынмы сөйләгәнен, әллә барысын— күреп белеп утырадыр?

— Юк, мин болай гына әйтәм.

— Андый нәрсәләр турында сөйлисе түгел, мин тиз ышанам ырым-шырымга, — диде Рәмил, сүзне үзгәртергә теләп.

— Ярый алайса, мин чәй яңартыйм әле, — дип Матильда чәйнекне алып мич арасына үтте. Ә Рәмилгә уйласа уйланырлык бар иде. Беренче кат ишетә ул хатын-кыз авызыннан ирләргә мактау сүзе. Андый хатын-кызлар да буламы икәнни? Уйларын ачыкларга салып куюны кирәк тапты. Алай һәр сүзгә ышанып барасы түгел, алар шундыйрак халык, елмаеп тора – күз буа. Тәмам үз иткән малай чәйгә чакыргач тагын Рәмил янына килеп басты. Чәй алдыннан дип тагын тоткан Рәмилнең күңеле почмакланган иде, туп-туп сөйде теремек малайны, тегесе килештереп кулындагы прәнниген өстәл буйлап ду-дулап йөртеп алды. Шул җитте Рәмилгә.

— Әйе, ду-у итеп йөртәм мин машинаны, күрдеңме аны тәрәзәдән? Шофер мин, водила, гадирәк итеп әйтсәк. Әллә син дә үскәч шофер буласыңмы? Уенчык машинаң бармы соң, ә?!

— Уенчыклары юграк шул, һич акча җиткерә алмыйм, — дип ике ир-ат нәселенә исе китеп карап утырган әни кеше.

— Әй, әттәгенәсе,ну ярый, алабыз без сина машина, яме, алабыз, ышан мина. Кара, ничек анлап утыра. Язарга, укырга өйрәтергә кирәк инде аны, — дип әмерләр бирде баланың яшен онытып.

— Бәләкәйрәк бит әле, өйрәнер, — диде әнисе.

— Ну, шигырьләр өйрәт, ятласын. Менә мондый бар бит әле:

Мишка косолапый
по лесу идет
Шишки собирает...

Тагын ничек иде соң әле, эх, тишек хәтер. Йә, ярар, татарча шигырь өйрәтәм мин сина!

Бала кешегә бу чәче тырпайган, йөзе кызарган, авызы ерык абыйның сөйләве кызык күренде шикелле, карый да чыркылдый, карый да чыркылдый иде үзе. Ә Рәмил аек баштан да шигырь сөйләмәгәнне, хәзер килеп исенә төшерә алмады. Шулай да, каяндыр ишетеп калган, менә әлеге мизгелгә кадәр хәтер төпкелендә сакланган икеюллыкны әйтеп бирә алды тагын.

— Тыңла әле, тиктормас, менә монысы татарча була:

Ыспай гына кодача
Тавыклар урлап кача.

Аның ят телдә сөйләвеннән әниле-уллы дәррәү көлеп җибәрделәр,

малай ычкынып төшеп йөгерде. Рәмил башына килгәнне куямы сон, эчкән баштан булгач. Уйлап-нитеп тормастан, янындагы хатынның нечкә бармакларын биртәйгән учына алды ул, һәм ни гажәп, әмерләр биреп сөйләшә башлады.

— Табышмак ул, Матильда, загадка. Тынла әле тагы: ыспай гына кодача.... Нәрсә була ул? Ә син анламыйсың. Төлке ул. Лиса. Телисеңме мин сине татарча өйрәтәм?

— Өйрәт сон, — дип килеште Матильда.

— Нәрсә дигән сүз өйрәтим, — өзмәде дә куймады Рәмил.

— Нәрсәме? Исәнмесез, дигән сүзне өйрәт.

Кайчак та исерек башка да акыллы фикер килә. Кинәт уйлап та алды, бу гүзәл затка карап, әйтеп тә салды.

— Авыр инде безнең тел. Кабатла: «Мин сине яратам!»

— Шулай күп сүзләрме? — дип кайтарып сорады Матильда гажәпләнеп.

— Әйтәм бит, бик авыр өйрәнүе. Еш кабатласаң гына хәтердә калдырырсың. Әйдә әле: мин сине яратам.

— Мин син ратам, — диде тырышып-тырышып Матильда.

— Ачык итеп. Мин си-не я-ра-там. Яле.

— Мин сине яратам.

— Ах, гүзәлләрнең гүзәле. Мине яратам дисеңме? Йа Хода, — дип татарчалатып тезеп китте Рәмил. Берни анламый авыз ачып карап торган Матильдага: — Кабатла, ике сүз әйт тә, кабатла. Онытыла ул. Мина исемне әйтмә, шул сүзләрне кабатла, һәрвакыт кабатлап тик йөре. Анладыңмы? — дип дәрес бирде. Йөрәгенең әллә кайсы төшендәге кылларына барып кагыла иде Матильданың нәфис тавышы белән әйтелгән ул могжизалы сүзләр! Ул төн озын булып чыкты. Матильда улын йокларга салгач та тагын утырдылар әле бергәләп өстәл янында. Батырланган Рәмил Матильдага көчләп-көчләп шәраб эчерде, еш-еш яна өйрәткән сүзләрне кабатлавын теләде. Бөтенләй йөгәнсезләнде ир, янадан-яна теләкләре туып кына торды аның.

— Син бик оста бии торгансыңдыр. Бер биеп тә күрсәт инде,Матильда, ну, телисеңме тезләнәм алдыңда. Менә мин үзем көй ишетсәм алпан-толпан аю кебек сикергәләүдән уздыра алмыйм. Сезнең халык өздереп бии бит ул, карап утырып түзеп булмый, чын сөйлим. Әллә испанча тыпырдыйсыңдыр әле, ә? — дип бәйләнде Рәмил.

— Испанча? — Матильданың күзләреннән очкыннар чәчелде, кыргый мәчедәй сикереп торып ул идән уртасына басты, нәзек гәүдәсе скрипка кылы төсле тартылды, горур башы Рәмилгә таба борылды, җәядән атылырга тарттырылган ук төсле иде ул. Рәмил хәтта кулларын сузып ана таба омтылып куйды. Белмәссең бу сер тулы хатынны: калкыныр да очып юк та булыр.

— Фламенко! — диде ярымпышылдап Матильда, каш астыннан сөзеп карап алды. Әнә шул утлы карашы белән сихерләде аны хатын. Тулы иреннәрен кыймылдатып кына үзалдына нәрсәләрдер әйтте, тәгаен сихер сүзләре булгандыр. Менә шул мизгелдә музыка яңгырар иде,ләкин Матильда сүрелеп калды, бар саннары йомшады, кузгалуларында битарафлык сизелде.

— Юк, булмый, сорама да, Рәмил, мин сине яратам, дөрес кабатлыйммы, фламенко бию өчен, син сораган испан биюен дим, ана икенче күлмәк кирәк, күнелне әзерләү кирәк. Кием гади чүпрәк кенә түгел лә хатын-кыз өчен, ул билгеле кәеф, хыял. Итәкләре яшен төсле уйнап торган озын бию күлмәген киеп куйсаң, бөтенләй икенче кешегә әйләнәсең. Телисеңме, мин сина үзебезнең бер җырны җырлыйм. Әкрен генә. Җәл, гитара юк, шәм яктысында, кыллар чиртеп матуррак яңгырар иде. Шулай килешәбез, җырның эчтәлеген әйтмим. Мин җырлап беткәч, син нәрсә тойганыңны сөйләп бирерсең, вәгъдәме?

Тукта, булгач булсын, утны сүндереп шәм яндырыйм әле. Бездә ут еш сүнә, шәмгә кытлык юк, күпләп запаслап куябыз, — дип тартмалар актаргалады Матильда. Арада сорап та куйды. »Хатыныңның җырлаганы бармы синең өчен?». Рәмил беравык тынып торды, барып җиткәлмәде башына сорауның мәгънәсе. Матильданың аптыраулы карашын күргәч кенә, юк җырламас, кире уйлар дип, йөзенә җитдилек чыгара алды. Шым гына йөреп Матильда өстәлнең баш-башына ике шәм куйды, утны сүндерде, үзе караңгырак почмакка сеңде һәм берзаман йөрәкне телгәләп таныш булмаган моң агыла башлады ул тарафтан. Көлемсерәп кенә тыңлый башлаган Рәмил бар булмышы белән шул күңел иңрәткән моңнар әсирлегендә калды. Җырның нинди телдә булуы да, нәрсә турында икәнлеге дә мөһим түгел иде инде аңа. Бу җыр аңа үзе турында сөйләде. Бөтенләй җырга кагылышы булмаган вакыйгалар күз алдына тезелделәр аның. Менә ул бәләкәй малай гына әле, җылы җәйге иртәдә чолан алдына чыгып утырган, йокысы да юньләп ачылып җитмәгән, күзләрен уа-уа утыра, ә ялан тәпиләре баскан таш шундый җылы. Зур таш ята торган иде шул аларның ишек алларында, ә ул бөтенләй оныткан. Әнә ул апасының табутын машинага салганда бер почмагыннан җан-фарманга күтәрә. Кышның зәмһәрир салкын көне, ә аның бите буйлап туктамый күз яшьләре ага, авыз читенә эләгәләр тозлы, җылы яшь бөртекләре. Көчәнеп-көчәнеп күтәрә ул калай табутны. Әнә әнисе дә килеп баскан, ничек картайган, бичаракай, нинди юка гына калган, әйткән сүзләре зәгыйфь кенә ишетелә, үлем алды көннәре ахрысы. Менә Мәймүнәсе биленә таянган да тетепме-тетә аны, хурлапмы-хурлый, колак тона тавышларыннан. Ул иң начары икән, иң юньсезе, бернәрсә дә хәленнән килми имеш, бар кешеләр аннан көләләр, ир кеше аның төсле булмый, нигә яши ул бу дөньяда?... Кинәт җыр өзелде. Тамагына ниндидер төер тыгылган, күлмәгенә сыймый башлаган Рәмил күтәрелеп карамый гына өстәлдәге шешәне бер кулына эләктерде, кадактагы бишмәтен йомарлады да тышка ташланды. Җил капканы ора-бәрә урамга атылып чыкты, йөгерә-атлый машина артына ашыкты. Чүгәләгән килеш шешәдә калганын комсызланып голкылдатып йотты, калтыранган куллары белән тәмәке кабызырга булашты. Шартлап бара иде ул, шулкадәр тулышкан иде шеш булып эчендә барысы. Бигрәк тә бәхетсез, шулкадәр дә мескен, мәңгегә рәхәт күрмәс бер тузан бөртегенә тиң итеп сизде ул үзен. Ниһаять булганы тышка бәреп чыкты, йөткергән төсле, көчек баласыдай чинап үксергә тотынды ул. Читтән караганда бик тә килешмәс күренеш ир-атның балавыз сыгуы. Нишлисең, без дә кешеләр, безнең йөрәк урынына таш түгел. Нәрсәгәдер тәгаен ачуланып, йә булмаса кемгәдер рәнжеп тә еламый иде ул. Гомумән язмышының шул сукмактан баруына, кәртләрнең шулай төшүеннән, бернәрсәне дә үзгәртә алмавыннан гаҗәпләнеп күз яшьләре түкте ул. Эчкән аракысының да шаукымы башланды ахрысы, елаганнан күңеле бушауы булгандыр, бераз тынычлана төште. Читтәрәк шым гына үзенә кушылып елап торган Матильда килеп йомшак куллары белән аның тузгыган чәчләрен сыйпады, колак яфрагына дымлы иреннәрен тидереп нәрсәдер сөйләде:

— Дөнья матур бит ул, исәркәй. Кара әле әнә йолдызларга. Көз көне генә гәрәбәдәй эре күренәләр алар, әйеме? Күк йөзенең аязлыгын кара син! Шул матурлыкны күрү бәхетенә ирешкән өчен генә дә шатланырлык. Һәр мизгеле яшәүнең бүләк ул безгә. Яшь, сау-сәламәтсең, дәртең-дәрманың бөркелеп тора, кулың эшкә оста, жимертеп эшлисең, тирә -ягыңда якыннарың, дус-ишләрең. Барысы бөтен, барысы җитеш, кадерен белмисең. Әйдә, тынычлан, кер, ял ит, салкын сукмасын. Карале, таулар күчерердәй шундый ир йомшарып торамыни?! Безгә, хатын-кызга гына килешә шыңшулар, нәрсәгә тотынсак та хәлебездән килми. Әйдә инде, акыллым, кузгал инде ...

Әнә шулай, Матильда, житәкләп дигәндәй Рәмилне алып керде, урынына китерде, баш астына мендәр кабартты.

— Ятмыйм мин, — дип киреләнде әле, үзенекен сөйләргә тотынды. – Син, Матильда, тынлатасың кемне дә, баштук сиздем мин тавышыңда, карашыңда әллә нинди көч бар синен, тәннәр чымырдый хәтта. Тыңла әле чак кына, менә гаделсезлек бит бу. Безнең бригадир, син күрдең аны кичә, төнлә без аның белән икәү кердек, әллә бүген иртәнме? Ну беләсең инде. Әнә шул, артык жире бармы аның миннән, йә әйт, турысын гына әйт, мин үпкәләмим. Ә, то-то, ул яшь ике катлы коттеджда, импортный машинада утырып йөри, малайны Америкага укырга жибәрәм дип хәзердән мактана. Ә нигә аның бар, минем юк? Хикмәте бар: ул урлый, почем зря урлый, Матильда аны белмисең генә. Рейска шулкадәр ягулык китте дип яза, аның чиреге дә тотылмый, калганы акчага әйләнеп аның кесәсенә ага. Аңлыйсыңмы? Ә мин урлаша белмим, беләсем дә килми, ә хатын, Мәймүнә, бер маймыл, аның исеме гарәпчә бер маймыл була икән, хә-хә, вәт кызык ә,вәт туры килгән исеме жисеменә. Әнә ул мәймүн минем йөрәкне талый инде, малай, син дә авызыңны ачып йөрмә, урла туры килгәндә ди, ә минем кул бармый. Сезнең халыкның кулы озын булган гомер-гомергә, өйрәт әле мине, Матильда!

— Нәрсәгә өйрәтим? — ди Матильда, үзе һаман елмая сихерче хатын.

— Урлашырга өйрәт, — ди Рәмил, торып утырырга тырышып.

— Өйрәтер идем,минем дә урлашып караганым юк шул, — дип тыелып кына көлә Матильда.

— Анысы бер. Калдырыйк ул угрыны. Син, Матильда, барысын да беләсең, аңлат әле миңа, һич башым житми, менә Руслан бар минем күршем, мировой егет, во! Күпме мактасам да әз булыр аны. Менә ул, ул урлашмый, кешеләргә яхшы, эштә яхшы иптәш, менә тагын әйтәм әле: безнең икебезне чагыштырсак, әйеме, жир белән күк арасы.Ул чибәр, ул буй, көч, мин чебеш кенә, хатыны Лиза күктән төшкән фәрештә, Руслан дип өзелеп тора, күптән түгел малайлары туды. Безгә күрше яшиләр алар, кирпеч өйдә ике бүлмәле фатир, жинел машинасы да бар, өе урап чыккысыз, өстәп быел лотерейга «Чероки» отты. Беләсеңме нинди машина була ул? Белмисең... Аны аңлатып та булмый. Бер кешегә тапалап-тапалап тутырганнар бәхетне өләшкәндә, ә берәүгә энә очы кадәр дә юк. Мин дә лотерейлар алып торам тегеләй, йөрәк жилкенә тираж булганда, ник күңел өчен йөз сум акча чыксын, юк. Ә нигә нәкъ минем машина ватылды. Менә бу бүлүләр нинди сыйфатларына карап икән кешенең? Кайда икән ул контора?... Әллә нинди планнар корып кичкә кергән Рәмил хужабикәнең һушларын алып юкны-барны сөйли-сөйли, ниһаять, йоклап китте. Авыл читендәге бу өйдә ут сүнгәндә сәгать төнге өч иде.

***

Малай елап уянып киткәч, күптән сызланып яткан Рәмил торырга булды. Һәрнәрсә тигезлеккә омтыла бу дөньяда: яхшы-начар белән, күңеллелек – хәсрәт, тән жиңеллеге — сызлаулар — алышынып кына тора. Бу бигрәк тә хәмер эчкәннең икенче көнендә нык сизелә. Ярамый Рәмилгә авызын ирекка куюы, мең тапкыр сынаганы бар бит инде, антлар иткәне бар, юк, нәфесе жиңә. Теле аңкауга ябышкан, тамагы кипкән, баш шаулый, жеп өзәрлек хәле юк, йә нәрсә кызыгып чөмерде инде шул сыер сидеген? Өмет белән өсталгә күз төшереп алды, кай арада жыештырып куйган, шар тәгәрәтерлек чип-чиста иде анысы да. Хәлләрен сиздермәскә тырышып, аякларын шудырып басып кына алай да су савыты янына барып житә алды. Йотлыгып-чәчәп бер чүмечне топ күтәрә эчеп куйды. Ә чаршау артында улы белән әнисе

күгәрченнәрдәй гөрләшәләр иде. Ярый мондый жимерек хәлдә өендә түгел, харап буласы иде. Маймүнәсеннән мәрхәмәт көтәсе түгел. Ава-түнә саф һавага чыга алды. Аяк астын туңдырган икән, кырпак-кырау каплаган жир өстен, өрсәң тыннар беленеп тора. Унбиш-егерме көн үтәрме-юкмы кар төшәр, аннан кыш инде. Тагын бер ел юк дип исәплә. Урамда аяк тавышлары әллә кайда яңгырап тора иде, ул бәс сарган үләннәргә борылды, чишмә ягына ук төшеп китте. Тешне камаштырган суны авыз итте, бит-кулларын юды, хәл кереп киткән төсле тоелды. Бар тәне ватылып торса да, әчтә бер төрле көлке ярчыгы төрткәләп, уйларын кичәгеләргә кайтарырга тырыша иде.

Койрыгын бот арасына кыстырган эттәй, үзен гаепле сизеп, Рәмил монсу гына өйгә үтте. Каршысына бәләкәй тәпиләре белән тып-тып басып Гарсия йөгереп килде. Күтәреп алганда суык куллардан кытыгы килеп шырык-шырык көлде. Ә Матильданың йөзендә ник бер ризасызлык булсын.

— Кайда югалдың, Рәмил? Ә без сине көтәбез, көтәбез... – дип шелтәләп алды үз итеп, ялт иттереп өстәлгә тулыга якын теге вино шешәсен китереп утыртты.

— Тәзәл, — диде ягымлы елмаеп, — хәлең авыр күренә.

Ике әйттереп тормады Рәмил, ясалган чәйне кире бушатты да, шул чынаякны тутырып салып эчеп куйды. Агулыкка агу да, дару да шул инде, ни әйтсәң дә. Күп тә үтмәде, күзләренә нур керде Рәмилнең, маңгайлары тирләп чыкты. Чәйдән баш тартты ул, икенче якка чыгып мендәргә башын терәп торды. Савыт-саба шалтыратты да Матильда олы якка чыгып утырды, нәрсәдер тегәргә тотынды. Шул чакта Рәмилгә кеше ышанмастай уйлар килде. Менә ул үзенең иң якын кешеләре арасында. Кеме бар аның? Кем тагын аны үз итә? Менә бу очраклы очраткан хатыннан башка тагын кем аны хөрмәт итә, кешегә саный, аңа ярарга тырыша, аны кадерли? Күптән аерылган туганнарыннан якынлык өмет итәсе түгел, һәрберсенең үз дөньясы, үз кайгысы. Очраша калсалар да — исәнме-саумы. Өстәл артында утырырга бер сәбәп, ә иртәгәсен «ауффиедерзеен». Авыр хәлдә кал, йә чирләп кит, борылып та карамаячак, үлсен иде дип теләкләр теләп яшидер әле. Менә инде, яшә яшә дә, бер барып сыенып, кайгыңны уртаклашыр кешең дә булмасын имеш. Ерткычлар да әнә төркем-төркем булып яши. Ә Матильда тынлаучы кеше барлыгына шатланып үзенекен сөйли иде.

— Минем әбием бар иде элек яшәгән жиребездә. Карт иде инде ул, әллә йөз яшьләр булгандыр үзенә, әллә күбрәктер дә. Менә аны кәрт ача дип әйтсәң дә була. Бер генә карый, барысын да дөп-дөрес әйтеп бирә: үткәнен дә, киләчәген дә. Бездә кызларны бәләкәй чактан ук өйрәтәләр төрле ырымнарга, кәрт ачарга, бараз алдашырга да. Мин дә беләм, телисеңме, сиңа да ачам. Ярар, соңыннан, әби турында сөйли идем бит әле. Менә ул миңа да кәрт ачты. Әнәсеннән – жебенә кадәр тезеп китте, әйтерсең укып бара минем тормыш юлын, ничек кемгә кияүгә чыгуымны, улым туачагын барысын-барысын әйтте. Ул әби, дөресен әйтсә дә, мәрхәмәтсез әби иде. Менә мин үзем, барлык чегән хатыннары да инде кемгәдер кәрт карарга туры килгәндә барысын да әйтеп бетермибез. Әйтик, кешегә карга тугызлы, туз белән тәңгәл төште ди, йә башкасы, нигә мин кешегә начар яңалык сөйлим,мин шомартам, шуннан, фәләннән сак булырга кирәк дим. Мин дөресен әйтсәм, ул үзгәртә аламы берәр нәрсәне? Алдан утка салудан кемгә файда? Ә миңа әби барысын яшерми әйтеп бирде, хихылдап көлә-көлә, бармакларын селеккәләп... Сине ирең ташлап китә диде, каркылдаганы кабул булды карганың. Анысы түзеп кенә яшәдем, ә менә улым...

— Матильда сүзеннән кисәк тукталып куллары белән битен каплады. Урыныннан ничек торганын сизми дә калды Рәмил, мәгәр нәрсә эшләргә дә белмәде, бер урында тапталды.

— Нәрсә булды, Матильда, кара әле син, нитмә... — дип кытыршы учы белән ефәк чәчләргә кагылырга җөрьәт итте, — Матильда, тынычлан әле, сөйләмә, кирәкми. Матильда мышык-мышык танавын тарткалап, кызарган күзләрен тынып калган улына юнәлтте.

— Эй, Гарсия, нигә туктап калдың, улым, Ду-ду! Әйдә, китәбез. Безне дә утырт, — дип шаярырга керешге.

Сөйләшү шунда өзелде. Иң кирәкмәгән эш — ир кешегә өй каравыллап яту, ә Рәмилнең һич тә пычранырга машина астына керәсе килми иде. Икенче төрле сукмак салырга дигән катгый карар туды аның башында. Дәшми-нитми чыкты да, кая дисезме, әлеге бизнесменга юл тотты ул, әйтергә кирәк, уйлаганнары гаять тә тәвәккәл кискен иде аның, үзеннән-үзе көтмәгән иде андый борылышны. Барысына Матильданың күз яшьләре сәбәпче булды, дисәк тә дөреслеккә туры килеп җитмәс. Кичәдән бөреләнә килделәр моңа кадәр таныш булмаган ят, яна тойгылар анда. Матильданың үзенә карата самими, беркатлы мөнәсәбәтләре башта рәхмәт хисләре уяттылар. Тора-бара соклана башлады Рәмил бу фәрештә затына, үзе дә сизмәстән, тәмам гашыйк булды. Барысы бер көн, бер төн эчендә. Гашыйк икәнен әле ул үз-үзеннән дә яшерә иде, әлбәттә, ир кеше матур хатын-кызга ярарга тырыша инде, дип акланган булды. Сүзләрдәмени хикмәт, менә инде Рәмил, бөтенләй үзен үзе танымый: гел Матильданы күрәсе килеп тик тора, магнитка тартылган тимер кисәгедәй тартыла ул аңа, күрмәсә дә барыбер күз алдында аның кыяфәте: йә елмая үз итеп, йә кашларын җыера, йә карый йотлыгып, башлар әйләнеп китә карашларыннан. Әллә шулай әкрен-әкрен ычкынамы икән кеше, шулай шатланып сары йортка барып керәме? Унсигез яшь түгел бит инде аңа, акылга утырырга күптән вакыт, ә ул монда Матильданың ирен читендәге килешле миңен уйлап хыяллана, иртән әсир иткән затның күз яшьләре йөрәген парә-парә телгәли. Кем аны аралар язмыш бураннарыннан, кем яклар гаделсезлекләрдән, кем ярдәм кулы сузар? Рәмилнең, әлбәттә, бу гүзәллек турында хыялланырга да хакы юк, ләкин икенче яктан килгәндә, ниндидер яхшылык эшләргә тиештер ләбаса ул яратканы өчен?! Әйе, яратканы өчен, нәрсә качышлы уйнарга, акылын югалтты ул бу хатын каршында, хәзер йөрәк нәрсә тели шуны эшли, сулкылдап тибә, күкрәк читлеген җимерердәй булып. Рәмил аңа буйсына, әйтсен Матильда, утка сикер дисен, бу шашкан йөрәк ике дә уйлап тормаячак. Аны аңларга була: гомергә бары бер тапкыр шулай дөрләп яна йөрәк, ә күпләр, бик күпләр, моның нәрсә икәнен белмичә картайганчы яшәп үлеп китәләр. Рәмил дә шулар исемлегендә түгел идеме соң? Кичә харап килештереп суган сулары агызды лабаса, бәхетсезләрдән икән ул, акчасы юк, машинасы юк, көлеп үләрсең: лотерейга акча отмаган. Хәзер ул тезләнеп Ходайга шөкерләр кылырга риза, акчага сатып алып буламы соң мондый хыялый ләззәтне, бер караш сине күкләргә күтәрә, бер сүз дөньяны оныттыра! Болай киноларда карап, китаплар укып шундый тарихлар очрыйдыр дип фаразлаганы булгалады. Әкият, тамчы да охшашлыгы юк, аларга — артистларга нәрсә, барысы ясалма, «аһ»лар орып сөйлиләр дә сөйлиләр сөю хакында, гел күзгә-күз карашып кына торалар, син монда бер күтәрелеп карасаң, тәнең эсселе-суыклы булып китә дә, әллә күпме йөрәк тигез суга алмый азаплана, сөйләшүләрен әйтәсе дә түгел. Ничек авыз күтәреп яратам дип әйтә аласың ди, ул егет-җилфәк, кыз-кыркынга килешә. Чынлыкта ир уртасы кешеләр ул сүзне шәрран яра әйтеп йөрмиләрдер, мәгәр Рәмилгә әйтсеннәр, асабыз-кисәбез, кычкыр авылны уятып: «Мин сине яратам, Матильда!» дисәләр, авызын да кыймылдата алмас иде. Ә Матильдага ничек килешә вата-кыра әйтелгән «Мин сине яратам» дигән сүзләр. Башлар әйләнеп китә, валлаһи. Мәгънәсен аңлап алса, нишләр иде

икән? Юк, житәр сина, Рәмил, чама бел, бәхет дулкыннарында тирбәлеп кенә вакыт үткәрмә. Матильдага синең утка керүеннән кирәге шул кадәр генә, ягарга утыны житәрлек күренә, син берәр файдалы эш эшлә, чын-чынлап ярдәм ит! Әллә башка күрә аласың аны, әллә юк, тәгаен юктыр, сагынып искә алырга гына калыр. Ул да сине исенә төшерсен дисәң, берәр егетлек күрсәт. Гомерендә бер тапкыр ир-егет үзенең кемлеген исбат итәргә тиештер бит инде?! Синең нәрсә хәлең нән килә?

Зәңгәр йортка килеп тәртелгәч кенә жиргә төште ул, әлегә болыт өстеннән атлады. Жирдә үз кануннары, монда матди дөнья, күз күргәч тә кул тотканга ышана адәм. Тормыш баштанаяк шуңа корылган. Бәй, шулай булгач.... Рәмил тәвәккәлләп кибетнең ишеген тартты, ышанычлы адымнар белән эчкә үтте. Бизнесмен Юра үзенең урынында иде.

— Oh-ho-ho, нинди кеше килә безгә, әйдә рәхим ит, — дип тагын да теленә салынып каршы алды ул, — бераз үзгәргәнсең кебекме, суырылып киткәнсең дип әйтимме? Әллә йокысызлыктан интектеңме? Була андый хәл яна урында, бигрәк тә янында шундый чибәркәй булса, хе-хе-хе...

Көлүе көлү түгел иде үзенең, авызлары ерылды, мәгәр күзләрендә зәһәр очкыннар уйнады. Иң авырткан жиренә килеп бәрелде Рәмилнең дә бу хихылдаулар, үзен тыеп калды, бары тешләрен шыгырдатып кысты. Алыпсатарның да бу темага сүз куертырга исәбе юк иде шикелле, гажәп, нәрсәгәдер чыгырыннан чыккан шикелле дә тоелды.

— Ярар, берәр иркенләп сөйләрсең әле. Баш авыртамы, — дип карамый гына артындагы киштәдән бер сыра алып, төбенә сугып кына капкачын ачты да Рәмил алдына куйды, бу икенчесенә үрелде. Рәмил:

— Сыйлаганыңа рәхмәт, үзенә ачма әле, — дип кабаланып кисәтте. Юра туктап калды,йөзендә, ә синең миндә ни эшең бар әле, «агай-эне — ак мыек», дигән төслерәк чырай чыкты. Кулы һаман шешә авызында иде үзенең.

— Эш бар, — диде Рәмил алдындагы сыраны йоткалап. Керем булачагын чамалап алган Юра, бар гәүдәсе белән борылып басты, уз итеп, башын иеп, тыңларга әзерләнде.

— Син он алырмын, дигән идең...

— Ну...

— Бер ун капчык сатарга ризамын...

— Нинди шартларда?

— Үзең әйткәнчә инде, утыз процентка киметәбез.

Юра күзгә күренеп үзгәрде, алыпсатар шул инде.

— Булмый-й, — дип сузган булды иренеп кенә, — миңа алай кирәк тә түгел күпләп. Хәленә кереп килешсәм генә инде, капчыгына өч йөз сум бирәм. Артыгына хәлдән килми. Теләсәң нәрсә эшлә...

Сатулашыр чак түгел иде, монда Юра кулында иде уен кәртләре.

— Ярый, — диде Рәмил, — ләкин алгач — ал унбиш капчык!.

— Базар юк, — дип Юра кин учларын сузды, тагы сырага үрелде.

— Туктап тор әле, — дип каршы төште Рәмил, — әле бетмәде сөйләшүләр.

— Синең башка товарың юк шикелле, — дип гажәпләнде Юра, — солярка дисәң, анысы үземдә муеннан, күрәсең бит — йөз метрда трасса үтә. Күпме кирәк шулкадәр табам мин.

— Алу-сату турында түгел иде сүз, — диде Рәмил, — ярдәм ит, район үзәгенә алып барып кайт әле. Ерак та түгел шикелле. Хакын килешербез.

Бер мәл Юра уйланып торгандай итте дә, кулын селтәде.

— Ярый, синенчә булсын, үземнең дә бүген йомыш төшеп тора иде. Ләкин алдан кисәтәм, көне буена түгел, бару-кайту ике сәгать, егерме минутта барып житәбез анысы. Мин эшләрне тәгәлләгәнче син әзерләнеп торасың. Бер капчык артык бирерсең.

Көпә-көндез кычкыртып талый иде бу акча колы, Рәмил сүз көрәштермәде, ул алдагысын үзе өчен хәл итеп куйган иде инде . Ризалыгын белдереп баш кына какты.

— Тәк, болай итәбез, — дип сәгатенә күз төшереп алды Юра, — ун минуттан синең янга «Газель» килеп туктар, төяп алырлар егетләр. Мин әзрәк капкалап алсам, туда-суда, ин күбе бер сәгатьтән кузгалырбыз, кереп алырмын. Ә акчасын барганда чутлашырбыз. Килештекме?

Эш йөртергә остарган икәне күренеп тора иде моның, килешәсе генә калды. Рәмил кайтырга ашыкты.

— Тәки сыраны эчермәден, әй, — дип көлеп калды арттан тегесе.

Уйлаганының барып чыкканына куанып шәп-шәп атлады Рәмил. Хәзер-хәзер һушын ала әле ул Матильданың, ничек гажәпләнеп карарлар икән аның сихри күзләре? Юраганы юш булды. Рәмил эре генә әйтеп салды:

— Хәзерлән, Матильда, бераздан машина килә район үзәгенә, Сосновкага барабыз. — Гарсия да барсын, жылыда, жинел машинада бер жилләнеп кайтсын.

— Нәрсә уйлап чыгарасың, Рәмил, — диде телгә килеп Матильда. Һаман ышанмый иде әле үзе.

— Кибетләрдә йөрербез, вак-төяк аласы бар, менә Гарсияга машина вәгъ дә иттем, сүзне үтәргә кирәк. Кеше карарбыз, үзебезне күрсәтербез. Гел өйдә генә утырырга димәгән. Менә сина мә, базар күрергә теләмәгән чегән хатыны булыр икән, әй?!

Бер агарды Матильда, бер кызарды, нәрсәгә барып тотынырга белмәде, ашкынган иде бер сүз белән әйткәндә.

— Ә акча? — диде шым гына, тишәрдәй булып карый иде күзләре.

— Машинада таварның яртысы минеке, — диде Рәмил тавышына гамьсезлек чыгарырга тырышып, — Юра белән сөйләштек тә, ана да файдалы, мин дә отылмыйм. Нигә сатмаска? Нәкъ акча кирәк иде.

— Алдыйсыңдыр әле, — дип һаман шөбһәләнде Матильда, — аннан соң Юра... Син беркатлы бит, Юра синең кебек кешеләрне төп башына утырта. Юкка бәйләнәсең аның белән. Иптәшләрең килеп житәрләр әле, өйгә кайткач тиешле хакын чыгарырлык итеп сатарсың...

— Мин үзем беләм, — дип нык торды Рәмил, — кем монда ир кеше, синме, минме? Ничек сөйләшәсең син? — дип шаплеген күрсәтеп алды. Шул вакытта урамда гудок тавышы ишетелде, Юраның егетләре килеп житкән иде. Әзмәвердәй өч ир, Рәмилнең кулын капчыкка да тидермәделәр, ул санап кына торды. Биш-алты минут үттеме-юкмы шаулашып китеп тә бардылар. Рәмил кире кергәндә Матильда кулын кушырып монсу гына мич буендагы урындыкта утырып тора иде.

— Йә, жыендыгызмы, килеп тә житәр хужа! — дип ашыктыргандай итте Рәмил.

Кымшанмады да хужабикә, күзләрен идәнгә төбәп утыра бирде.

— Ни булды тагы? — дип түземсезләнде Рәмил.

— Мин бармыйм, без бармыйбыз, — диде Матильда.

— Нәрсә булды соң?

— Минем дә, Гарсияның да киярга бернәрсәбез дә юк, бер кат киемдә килеп кергән идек без...

Күзләреннән яшь тәгәрәде Матильданың, Рәмил аңа аңа кушылып елап жибәрүдән чак тыелып калды. «И, түземлеләрем минем, сез күргәнне эт тә күрмәс, ә һаман гел яхшылык, гел яхшылык күңелегездә. Ярый ла уйлап чыгардым бу онны аткаруны, тишек кә ямау булыр», — дип уйлады Рәмил. Хәзер инде кире чигенү юк, һичшиксез алып барырырга кирәк боларны.

— Машина эчендә барабыз, Матильда, күз ачып йомганчы — без анда.

Кара тәрәзәгә, кояш көлә, киреләнергә уйлама да, һич югы әбиеңнең берәр әйберен киеп тор.

— Кем, Юра алып барамы? — дип сорашты бераз йомшаган Матильда.

— Әйе, Юра, кем булса да барыбер түгелмени, барырга машина булсын, — дип көр тавыш белән күнелен күтәрергә теләде анын Рәмил.

— Аh, юкка бәйләнәсең шуңа, бик начар кеше ул, — дип үзенекен сөйләде хатын.

— Шул начар кеше белән минем ялгызымны җибәрәсеңме? Берәр хәл булса ... — дип шаяртырга теләде ир, ә кыек атып туры тигезде. Ни хикмәт, Матильда анын сүзләрен чынга алды, ныклап әзерләнергә тотынды.

— Чынлап та, таныш булмаган шундый кеше кулына ышанып тапшырып булмас, Ходай сакласын, гомер җәфаланырмын... Мин бит аны якыннан беләм. Тернәкләнеп йөри башлагач, бездән чыкмый йөрәкләрне бетерде ул. Миңа бәйләнде, килә дә керә, килә дә керә, юк сәбәпне бар иткән була. Башта кабып йотарга уйлаган иде. Әби юкта бер хәбәр сөйли бу миңа: «Син килмешәк, белгән-күргән кеше юк сине, бүген машинага салып алып китәм дә, урман чытырлыгында буып бәреп китәм, эзләп тә тормаслар...», — ди. Котларым очты да инде. Сөяркәсе итәргә юллар эзләде. Мине ошата имеш. Ошаган кешесенә ничек теле барып шундый сүзләр сөйләр икән кеше? Кеше түгел ул, ерткыч. Анын күзләре дә боз кебек, салкын бөркелеп тора аннан. Төннәр йоклый алмый, шылт иткән тавышка да калтырап, елап чыга идем. Мәгәр, тегене күрсәм, каян көч килә, нәфрәт уяна, бер сүзенә биш сүз җавап бирәм, чамалагандыр да соң кем икәнлегемне, нәрсәдер кире уйлады, көч кулланмады. Икенче төрлерәк сайрарга тотынды, ул мине ефәккә, алтынга күмәчәк икән, ашаганым бал да май булыр, улымны үстерергә ярдәмләшергә риза, тик мин аңа карышмаска тиеш, теләгәнен үтәргә. Килгән саен күчтәнәчләр төяп килә, берни белмәгән әби, бигрәк яхшы безнең Юра, дип мактап бушамый. Ә мин шулкадәр ятсынган идем аннан, аяк тавышларын ишетүгә, ачуым ташырга тотына иде. Бу араларда сүрелеп тора тагын. Ялгыз калгач бигрәк тә шүрли идем, һаман да куркам мин аннан, гомер күрмәсәм иде... Син, бәйләнмә аңа, зинһар, әйткәнемне тыңла. Күз йоммый да барча товарынны тартып ала ул синен, үзеңне теге дөньяга озатырга да күп сорап тормаячак...

Рәмилнең үзенең дә Юра хакында уйлары шул чама иде, ләкин сайланып торып булмый, вакыт та бик аз бирелгән аңа, бик аз. Хәленнән килгәнчә Матильданың шомлы уйларын таратырга тырышты ул. Озак та үтмәде, Юра килеп тә житте. Өйдән чыкмый утырган Гарсия, аны да аласыларын белгәч, үрле-кырлы сикерде. Күнелен күрергә теләп, алдагы урынга авызы колакларына житкән малайны урнаштырдылар, арткы урынга парлап икәү утырдылар. Урнашкач та, Юра, борылып, Рәмилгә акча төргәге сузды:

— Санап ал.

Шуннан башка сүз дәшмәде, нәрсәгәдер сөмсере коелган иде анын. Рәмил белән Матильда тынып калдылар. Саргайган болыннар ярып җилдергән машинада күнеле тартылган зат янында утыру бертөрле ямансу да, шул вакытта рәхәт тә иде Рәмилгә.

Кайда, кайчан очрашырга сүз куешып, магазиннар янында төшеп калдылар. Юк, ни әйтсәң дә, яхшы көннәр булып тора бу дөньяда, көне матур, күнелен шат, якын кешең янында, өстәп кесәдә әзме-күпме акча да бар. Хатын-кызның тормышка карашы икенчерәк. Матильда беренче эш итеп, Рәмилнең нәрсә алырга теләгәнлеге белән кызыксынды. «Киемсалым, әйбер-чәйбер» — дигәнрәк җавап ишеткәч, базарга барырга димләде, хәзерге заманда базарда киемнәр арзанрак була икән, сыйфат ягыннан да

калышмыйлар. Базарга икән — базарга!. Әнә шулай башланды Рәмилнең үз гомерендә ин яратмаган шөгыле: әйбер сайлаулар, әйбер алулар. Әлбәттә Рәмил үзенә бернәрсә дә алырга жыенмый иде. Ләкин Матильданың күзләренә төтен жибәрде: ул, имеш, бик яхшыдан кәчтүм-чалбар эзли, бар максаты шул. Ачык һавада тезелеп киткән алыпсатарлар яныннан үткәндә теләгәнен тормышка ашыра барды. Менә килешле генә куртка күренә, Гарсияга таман булырга тиеш, өшетеп йөртмәссен бит инде баланы. Нәкъ үзенә үлчәп тегелгәндәй куян рәсемле курткасы киеп карагач, Гарсия салырга да теләмәде. Бераз алдарак балаларга башлыклар, жылы ботинкалар табылды. Йөри-атлый торгач, нигәдер Матильда кечкенә куллары белән ешрак Рәмилгә кагыла торган булып китте, әйбер сайлаганда бер-ике тапкыр бар гәүдәсе белән сыенып алды, тирләр бәреп чыкты Рәмилнең аркасына. Аяк талгач, алар шундагы кафега кереп тамак ялгадылар. Гарсия тагын көлдереп рәхәтләнде. Малай котлет өстенә сибелгән соусны яратты, тәлинкәне ялап-ялап ялтыратты, бите-борыны кызылга буялып бетте хәтта. Матильданың үзенә әйбер алдыру ин авыры булды. Кирәкми дип карышып катты, берничек тә ипкә китерә алмый аптырашка төште Рәмил. Чынчынлап тиргәшергә тотынды, тозлы-борычлы сүгенү сүзләрен аралаштырып жибәрде. Үткән-сүткәннәр борылып карый башладылар, берничәсе кызык эзләп туктап та калды. Ә Рәмил өзмәде дә куймады, үз туксаны туксан...

Матильда дәшмәде, Рәмил үҗәтләнеп алдан төште, арттан уенчык машинасын кочаклаган Гарсия йөгерде. Көзгеләр эленгән универмагка кереп туктап калдылар. Монда икенчерәк икән, мәртәбәлерәк. Урам базары түгел. Сатучылары гына ни тора! Күлмәк тә таптылар. Янып торган кызыл, бала итәкле, жиннәре-кулбашлары бөрмәләп чигелгән, күз явын алырлык купшы күлмәк иде ул! Хакына тормады Рәмил, бу хатынга йолдыз сораса, йолдыз артыннан күккә үрмәләргә риза иде ул!

Машина көтеп торганда юлчыларнын дәртләре почмакланган, бәхет капчыклары тулган иде. Юра озак көттермәде, бераз йөзе ачылган иде анысының да, боларнын байлыкларына карап тел шартлаткан булды, гел малайга сүз кушып, аны шаяртып кайтты. Ә Рәмил, басынкы күренгән Рәмил нишләде, Матильданың кулын эзләп тапты да, кайтканчы ычкындырмады, тегесе дә киреләнергә уйламады тагын, борылып карап елмаеп куйды да, тын калды.

Син әллә иблисне адәм баласына озын-озак бәхетле булырга ирек бирә дисенме?Көтеп кенә тора ул явызлык кылырга. Күкнең жиденче катында хис итеп, анын машинадан чыгуы булды, күзенә таныш йөз чалынды: Руслан! Машинасын уздырыбрак туктаткан икән. Юнып алгандай юкка чыкты Рәмилнең шатлыклары. Матильда белән Юра әйберләрне бушата калдылар, Рәмил күршесенә таба атлады. Шап-шоп арка кактылар да ,тәмәке кабып, жиргә чүгәләделәр. Механик килмәгән икән, чирләгән имеш, менә аны куалаганнар, запчастьлар бар, бергә эшләп кайтып житәргә дип наказ биргәннәр. Өйдәге яналыкларны сөйләп алды, барысы яхшы, Мәймүнә үзе сорашып кергән, анын яналыгы — киләсе атнада санаторийга китеп бара, очраклы путевка туры килгән икән...

Машина янына килделәр, яртылаш сүтелгән күчәргә текәлеп фикер алыштылар. Эше күп түгел икән, бер көн икәүләп маташсалар, очлап чыгалар, зырылдап кайтып та китәләр. Руслан канәгать түгел иде:

— Сүтеп бетергән булсан, иртәгә үк өйдә булган кешеләр идек, — дип кат-кат әйтте. — Ә бүген кайларда югалып йөрисен, мин килеп житкәнгә сәгать ярымлап инде...

Өйгә кереп чәй эчтеләр. Руслан, житезлек күрсәтеп, Матильдага якынрак утырды. Һич авызын япмады, бытбылдык. Сөмсере коелган Рәмил башын күтәреп карамады, берни капмый, чәй чөмерде дә чәй чөмерде.

— Менә без икәү булдык инде. Сез хафаланмагыз, озакка түгел. Жыелган хакын онлата түләргә диделәр. Сез каршы түгелдер бит? Ходовой товар, аны кайчан да акчага алыштырырга була. Шулаймы? – дип тезде генә Руслан Матильданың авызына керердәй булып.

— Он булса да мин риза, ә сез миңа мәшәкать түгел, гел ялгызым бит, кешеләр белән күңеллерәк, — дип жаваплады Матильда. Аның Русланга елмаеп эндәшүе, урынлы-урынсыз үзенең ялгызлыгын искә алуы йөрәгенә кан саудырды Рәмилнең.

— Хужалыкта бирәр эш чыкса, ярдәм итеп куя алабыз. Уңайсызланып тормагыз, дөнья көткәч, ир-ат кулы кирәк була. Бер авырлыгыбыз да тимәс. Рәмил абыйның ниндиерәк кеше икәнлеген чамалагансыздыр, мин үзем — мулла песие кебек, — дип теленә салына бирде Руслан.

Ниһаять, өстәл яныннан торып, ирләр ишек алдына чыктылар.

— Менә нәрсә, күрше, – диде Рәмил, кире каккысыз тавыш белән, — син запчастьларны калдыр да, өеңә юллан. Мин үзем эшләп чыгармын да, кайтып та житәрмен.

Руслан бу сүзләрдән телсез калды.

— Син нәрсә, Рәмил абый, башың тимергә сугылдымы әллә, ни сөйләгәненне аңлыйсыңмы? Мине Бычков жибәрде, бергәләп төзәтеп кайтасыз, дип тукыды. Тыңламый кара аны, ике уйламый эштән очыра ич ул мине, сине миннән дә алдарак. Тапты уйлап, — дип кабынып китте күршесе. Ул сөйләгәннәрнең хак икәнен дә яхшы аңлый иде Рәмил, шуңа карамастан, уендагы карары ныгыганнан-ныгый гына барды.

— Бер машина астында икәүләп тыгылып ятасы түгел. Син нигә кирәк, ватык арбага – бишенче тәгәрмәч? Гаиләң янында бул, уйна-көл, әнә, башкалар кунакка йөри, тагын рейска бит озакламый. Бүген күз бәйләнгәнче булашсам, иртәгә иртәрәк кузгалсам, кичкә кадәр үзем дә ерып чыгам мин аны.

— Юк, монда нәрсәдер бар, — дип бармак уйнатты борын төбендә Руслан. – Сиңа мишәйт итәм мин, шулаймы? Бу хужабикәнең култык астына оялагансың да, жылы урыннан чыгасың килми, әйт әле дөресен...

Инде кабынырга Рәмилгә чират житте:

— Син нәрсә сөйләгәненне уйлап сөйлә. Мин күрше дип тормам... Алайга китсә, уматывай, эзең булмасын...

Күзләрен кан басты Рәмилнең, буйга да озынрак күренә башлады кебек...

— Тукта әле, Рәмил абый, миндә гаеп, яшьлек юләрлеге белән, шаяртам, дип әллә нәрсәләр әйтеп ташладым, кызма, — дип юхаларга, юмаларга тотынды Руслан, әмма да шикләренең дөреслегенә ныграк ышанды, — Монда кабарынганнарыңны начальствога житкерәм, бел аны. Сине хатының аралар, минем эш югалтасым килми, — дип ачыклап куясы итте.

— Бар, бар, — диде күңеле күтәрелеп киткән Рәмил кул болгап, — күпдин күп сәламнәр тапшыр барысына да, бигрәк тә Бычковка!

Руслан, кузовына менеп, жан ачуы белән, алып килгән тимерләрне жиргә тондырды да, машинасын усал үкертеп таш юлга чапты. Өстеннән таш төшкәндәй булды Рәмилнең. Кара әле, ике көн элек кенә ул кан калтырап тора иде гадәтләнгән тормышы өчен: эшен югалтудан курка иде, түрәләр алдында биле бишкә бөгелде, Мәймүнәгә ярарга тырышып аяк очларында биеде. Берсе дә кирәк түгел икән ич аңа, әз генә күңелендә югалту хисе уянса икән, ичмасам. Ә машина янына чыгарга уенда да юк иде аның. Тәкъдир тарафыннан бүләк итеп бирелгән санаулы гына сәгатьләрне майга буялып үткәрсенме? Юк инде, житәрлек чокыды ул тимерләрне үз гомерендә, язган булса, тагын чокыр, ант эчми, ләкин бүгеннәрен-иртәләрен бөтенләй башка уйлар иләсләндерәчәк әле аның күңелен, шулай тоя ул.

Ирәеп кенә кереп бара иде Рәмил, Матильда каршысына басты:

— Учак ягыгыз. Иптәшен кайда?

Йөрәген чәнчеп алды Рәмилнен, «иптәш» кирәк булган ана, өч авыз сүз сөйләштеләрме-юкмы, ышанма хатын-кызга, кәкре кабыргадан яратылган бит алар,тугры була торганнары — юк!

— Ул кайтып китте, — диде ул авызларын бөрештереп.

Матильда ваклыкларга бирелеп тормады.

— Үзен як, ышыграк җиргә, ут-күз зыян салырлык булмасын, — диде.

— Нигә кирәк сон учак?

— Мин тәмле кичке аш белән сыйларга вәгъдә бирдемме сина? Апан сүзендә тора, белеп кал!

Күнеле уенчак иде Матильданын, күзләре елтырыйлар иде, анын халәте Рәмилгә дә күчте.

— Ах, апакай-алмакай, булдынмени шулай итеп? Синен мина «бабай» дип эндәшерлеген бар.

— Нинди бабай, минем каршымда алып батыр, яшь егет басып тора. Мин үзем дә уналты яшьлек оялчан кыз әле анысы. Менә минем фәрман: и, егет, тынла сүземне, яшел хәтфә үләндә зур учак як син, мин казан асармын, тамагынны туйдырырмын...

— Баш өсте, солтанбикә! — дип уенлы-чынлы билен бөгеп кушылганны үтәргә алынды Рәмил. Бергә эшләү кешеләрне аерата якынайта: әллә нәрсәләр сөйләшеп кенә, Гарсия йоклаган арада кичке аш пешерделәр: ир учак якты, хатын казан асты, ир суган турады, хатын бәрәнге әрчеде, берсе көлсә, икенчесе дә көлде, кый-галәмәт килделәр. Сүз арасында Рәмил Русланнын кайтып китүен килешенгән сөйләшү дигән төстә хәбәр итте. «Минем берүземә эш юк анда, нәрсә икәүләп ятарга?» — дигән булды. Матильда да төпченмәде, ә ярар, үзегез беләсездер, дип кенә куйды. Аларнын кичке ашы ресторан өстәлләреннән ким булмады. Матильда Рәмилне шәраб эчәргә өйрәтте. Шаккатырсын, эчүнен дә үз тәртибе бар имеш. Мона кадәр Рәмил, никадәр күбрәк салып, никадәр тизрәк озатасын ашказанына, шулкадәр остараксын дигәнрәк фикердә иде.

Шартына китереп, бармак очлары белән генә тотынып, хатын нәзакәтле генә шәраб агызды чынаякларга, төпсез карашлары исә Рәмилгә төбәлгән иде...

— Синен хөрмәтенә эчәм, тормышын шәраб төсле татлы булсын, ә ачысы бары үткәннәрне сагынуны билгеләсен. Сагынырлык үткәне булган кеше бәхетле, ә килер көннәр татлы, ышан мина, мин барысын да беләм. Эчәбез, — дип карашын да алмыйча ул ашыкмый гына шәраб йотты. Анын тавышына, карашына сихерләнеп утырган Рәмил уянып киткәндәй булды.

— Шулай булсын, — дип үз өлешен сизмәстән ике генә капты да куйды, авыл мокыты, хәзер килеп кенә өйрәнә алмас инде, нәрсә матавыкланырга. Тагын бернәрсәгә игътибар итте Рәмил, акны йотсан, бераздан башка йөгерә, мине томалый, телне ача, ә бу хикмәт, шәраб, кан юлларын кыздырды, тәнгә дәрт-дәрман керде, гел күнеллелеккә тартылды күнел, гомер биемәгән кешенен тыпырдатып бер биисе килеп китте. Әмма дә ләкин ничек тыпырдатып басалар икәнен күз алдына да китерә алмый иде инде үзе. Ике уртада утырган малай авыраеп, башын Рәмилгә терәде, арыганчы ашаган иде бала. Иплэп кенә күтәреп, Рәмил аны өстәл артыннан алып китеп, урынына салды.

— Ә хәзер күлмәгенне киеп күрсәт инде!

— Юк, сонрак, — диде Матильда йомшак кына, — беләсенме минем нәрсә эшлисем килә? Теге вакытта сөйләп бетермәгән идем. Әби кәрт

ачты дигән идем бит. Менә ул әйтеп бирде инде, синең гомерең озын түгел, кызым, диде, кинәт үләрсең, диде. Җен карчыгы, кем аны теленнән тарткан, йөрәккә язылып калган шуның сүзләре. Хәзер куркам мин, бигрәк тә һәр әйткәннәре чынга ашып килгәч. Һәр көн уянгач та уйлап куям, бүген соңгы көне түгел микән гомеремнең дим. Белмәсәң мең артык булыр иде, кинәт килгән үлемнән куркырга да өлгерми калган булыр идем. Ә ярар ла, күрәчәкне күрми генә гүргә кереп булмый ди, барыбер бер үләсе. Мин кемнән артык? Менә улым өчен генә йөрәгем әрни. Кем кулына калыр сабыем, кайсы почмакта зар елап утырыр? — Матильданың бит алмаларыннан күз яшьләре тәгәрәде. Ул яшьләрнең һәрберсе энҗе-мәрҗәнгә тиң иде Рәмил өчен, уйлары чуалды аның якынын җәлләүдән, күңеле тулды.

— Әле мин сөйләп бетермәдем бит. Теге карчык күп сөйләде ул. Ул чакта күбесе аңлашылмаган да иде, — дип тезеп китте чегән хатыны, — сиңа кагылышлы сүзләр дә әйткән булган дип уйлыйм.

Көлмә, көлмә, менә шуны тикшереп карыйсым килә минем. Ничекме? Сиңа мин кәрт ачып карыйм әле, нәрсә сөйләрләр икән? Ризасыңмы?

Әйдә, бер кызык булсын дип, Рәмил ризалыгын белдерде. Өске киштәдән Матильда таушалып беткән кәртләр алды да өстәл башына килеп утырды. Йөзе житдиләнеп китте аның, иреннәрен кыймылдатып үзе генә белгән серле сүзләр кабатлады, житез бармаклары тиз-тиз кәртләр тезде.

— Ой, күрәм, барысын күрәм, — дип ике кулы белән башын тотып сөйләп китте ул, — йөрәгең йомшак синең, мәрхәмәтле, ә тирә-яктагылар бу холкыңны гел үз файдаларына гына боралар, шул йомшаклыгың комачаулый сиңа. Эшеңдә тырышлыгың күренми, гаиләңдә баш була алмыйсың икән. Балаларыгыз юк, ә хатының белән бәйләнгән җепләр өзелеп бетеп барганга охшаган, ул әле... Юк, бәлки мин ялгышамдыр, кәрт нәрсә, рәсемле кәгазь кисәге. Менә болары әйтә, бер дә борчылма сүнеп барган уртак учак өчен ди, синең юлыңа тап була әле бердәнберең ди һәм... бу пикилар, трефлар ...

— Тузга язмаган нәрсәләр турында баш ватканчы, әйдә, вино эчик әле! — диде ир.

— Хәзер биеп күрсәтәм мин сиңа. Оп-ля, дөньяның атаклы биючесе Матильда! — дип кулларын күккә чөйде хатын. Ләкин шатлыгы ясалма иде... әнә Рәмил дәшмәде. Ул арада Матильданың чаршау артында күлмәк төрелгән төргәкне кыштырдатканы ишетелде.

Рәмил, уйламый-нитми, чаршауны тартып җибәрде, каршында арты белән борылып баскан Матильда тора иде. Билдән түбәнгә кадәр төшерелгән замок хатынның коеп куйган төсле нәфис билен, фәрештә канатларыдай калак сөякләрен, йомры иңбашларын, чокырланып торган озын муенын ачып куйган иде. Хатын-кыз тәне Рәмилнең башларын әйләндерде, уйларын иләс-миләс китерде, йә Алла, аның да хатын-кыз кочканы булды, гомер күргәне юк иде аның мондый гүзәллекне! Карады да катты ул, сизмәстән ыңгырашып та куйды шикелле.

— Йә, эләктер инде, — диде хатын иңбашы аша елмаеп. Шәпләнеп килеп тотынган булды Рәмил, ә бер кулы белән тимер яхшы шусын өчен аңа өстәнрәк ялангач тәнгә кагылып алырга туры килде, бетте ул шуннан, тәмам кешелектән чыкты, куллары калтырарга тотынды. Бер унга, бер сулга чыгып, шыбыр тиргә төшеп чак очына чыга алды. Бу хатын-кызның каптырмаларын каптырудан бер арба утын ярып бетерү күпкә җиңелрәктер, дигән фикергә килде. Ә Матильда «сәхнәгә» тиз генә чыкмады әле. Рәмил сусынын басырга теләп, теге башланган шешәнең төбенә төшә язды, ә «артистка» һаман бизәнде-төзәнде, киенде-ясанды. Нәтиҗәләре дә искиткеч

булды: Рәмил алдына озын буйлы, нечкә билле, ярымачык күкрәкләре горур кабарып торган, күз явын алырдай чибәр хатын авыр керфекләрен ачып йомды да... кисәк борылып басты.

— Фламенко! — дип бер генә сүз әйтте ул. Менә шунда Рәмил берәр төрле музыка булмаганына өзгәләнде. Ләкин Матильда кайдадыр үзе генә күргән чиксез ераклыкка төбәлеп күкрәк тавышы белән әкрен генә җыр башлады. Беренче мизгелләрдә бу көй һич тә бию көе булыр төсле тоелмады, ләкин Матильданың тавышы үзгәрә барды, җыр сүзләре бер-берсен этә-төртә ашыгып чәчелделәр, икенче караганда бары өермә кузгатырлык авазлар гына яңгырый иде. Аларга кушылып, Матильда үзе хәрәкәткә килде, күзне чагылдырган кан-кызыл күлмәк итәкләре терелделәр, тал чыбыгыдай назлы гәүдә зыр әйләнде, бәләкәй генә аяклар күз иярмәс тизлектә тыпырдапмы-тыпырдадылар! Матильда, бер-ике әйләнде дә, ай-вай килеп Рәмил өстенә капланды...

***

Бер юрган астында йоклаган кешеләр аерата якынаялар, уйлары берегә, йөрәкләре бергә тибә башлый, бер төрле төшләр күрәләр хәтта. Тәҗрибә өчен, мәсәлән, күгәрченнәр төсле гөрләшеп яшәгән парны билгеле вакыт эчендә аерым түшәкләрдә йоклатып кара: аралары суынчак, тора-бара эт белән песи кебек яши башлаячаклар. Фән әлегә белмәгән берәр төрле уртак микроблар ярала торгандыр аларда. Менә Рәмил белән Матильда икенче көн нәкъ шулай кыландылар. Рәмил берәр әйбергә барып тотынса, икенче очын Матильда кулына алды. Матильда чәй хәзерләде, Рәмил икмәк кисте, берсе мичкә утын тутырды, икенчесе чыра ярды. Энә белән җеп сыман гел тагылышып кына йөрделәр. Матильда шәлен бөркәнеп ишек бавына тотынгач, Рәмил бүрегенә үрелде.

— Мин үз йомышым белән чыгам бит, — дип тә карады, ә тегесе:

— Ә минем дә нәкъ шундый йомыш белән чыгасым бар иде, — дип арттан йөрде. Сөйләшеп сүзләре бетмәде, чырык-чырык көлделәр дә көлделәр, гел бер-берсенә кагылып кына торасылары килде. Рәмил туалетның каерылып төшкән ишеген каккалап куярга чыгуы булды, артыннан улын киендереп Матильдасы килеп басты. Әнә шулай бер-берсеннән башка торалмаска әйләнделәр алар. Ә кадерле минутлар сизелмәде дә, агыла гына тордылар. Рәмилнең һич кенә дә сөйгәне янынннан китәсе килмәде. Вәләкин уйлаган уйларын да тормышка ашырырга кирәк иде.

Ничектер, Матильданың үз эшләре белән булашкан вакытын туры китереп, ул урамга ашыкты. Бирәм дигән колына — чыгарып куйган юлына, — дигәннәре рас икән, каршына Юраның машинасы килеп туктады.

— Нәрсә, әллә тагын сатарга теләгең бармы? — диде тегесе тәрәзәдән башын тыгып. Сизенә иде ул Рәмилнең ут белән уйнаганын. Әллә юри этә иде упкынга, юлыма аркылы төштең дип, ачу тота идеме? — Ыслушай, ике-өч капчык нәрсә ул, тиенне-куяны гына кала миңа...

Авыздан тартып алды бу Рәмил әйтергә теләгәнне.

— Мин машинасы-ние белән дә бергә йота алам, — диде Юра көлеп, ә күзләре көлмиләр иде, үтә тишәрдәй карыйлар иде. Анысын ук уйламаган иде Рәмил, кинәт кенә ризалык бирәсе итмәде. Бәлки, кечкә кадәр тыныч кына яшәсәләр, күз күрер. Ни өчен дигәндә, бу зур статьяга тарта, Матильдага бер очы элэгәчәк. Югалырга уйласаң, төбәп кенә барыр урын да юк. Вакыт кысан, вакыты тар аның, ичмасам, беренче өлешенә өлгерергә кирәк.

— Шаяруларың хәтәр синең, көләсе дә килми хәтта, — дигән булды ул, — машина минеке түгел, машина шефныкы, ә менә товарның яртысына мин хуҗа!

Ышандымы, юкмы монысына Юра, анда эше юк иде инде Рәмилнең. Ин мөһиме — озатырга кирәк, акчага әйләндерергә, аннан күз күрер...

— Хакы шул килеш каламы? — диде ул.

— Ә син әйткән кадәресен төяп җибәрәм дисеңме? — Юра сынап, бераз көлемсерәп карап торды, күз бәбәкләрендә шайтаннар биешкән кебек иде аның. Чума бу муеннан, дип шатлануы иде ахрысы. Шулай карашып торганнан соң, ул ишеген ачып, кулын сузды:

— Килештек. Хәзер исәплибез, — диде. Тартмасыннан кесә калькуляторы чыгарып, шалт-шолт чутлый башлады. Утыз меңләп акча тиясе булып чыкты.

— Егетләр сиңа таныш, каршы алырсың, ташый башласыннар. Ә мине бераз соңрак көт, зур акча, җыештырырга кирәк.

— Берәр аракы онытма, шуңа дип чыккан идем, — дип кабатлады Рәмил. Бу эшне аткарса, чынлап та аракы кирәк булыр ахрысы аңа. Ерактан гына аларның сөйләшкәннәрен күзәтеп торган Матильда Рәмилне капка тышына ук чыгып каршы алды.

— Рәмил, тагын Юрамы? Нигә кирәк? — дип чытырдатып ябышты ул аның җиңенә. — Бәйләнмәсәнә шуңа, ялынып сорыйм синнән, менә шулкадәр әйбәт иде икебезгә генә. Нәрсә уйладың тагы...

— Матильда, — диде ул арыган тавыш белән. Чынлап та кинәт арыган төсле тойды ул үзен. — Барысы да әйбәт. Мин бары үземнең товарны Юрага тулаем сатып куярга булдым.

Үпкәләп торган хатынны тартып алып кочагына кысты. Әллә соңгы тапкыр шулай кочаклыйдыр әле...

— Матильда! — диде ул туя алмый газиз күзләргә карап. — Хәзер игътибар белән тыңла мине. Бел: мин синең ирең шушы минуттан, син минем хәләл хатыным. Мин сине өзелеп яратам, шулкадәр яратам, аны сүз белән генә әйтеп аңлатып булмый. Хәтереңә салып куй: мин бервакытта да сиңа начарлык теләмим. Шуңа күрә синнән таләп итәм, син миңа каршы килмә, әйткәннәремне берсүзсез үтә. Ышан миңа: барысы синең өчен, минем өчен яхшы булсын дип эшләнә. Килештекме?

— Ярый соң, — диде Матильда башын иеп.

— Кабатлап әйтәм, Матильда, зинһар нәрсәдер үзгәртергә теләмә, мин кушканны җиренә җиткереп үтә, яме? Нәрсә булса да мин сине яратам, гомер буе мин сиңа таба барырмын.

— Нәрсә булырга тиеш соң? Куркытма мине, Рәмил, әле генә таптым сине, ә син әллә нинди сүзләр сөйлисең, — дип тынычлыгын җуя башлады Матильда.

— Юк, юк, барысы да яхшы, бар, кер инде, бала юксыйгандыр, — дип аны тизрәк озату ягын карады Рәмил. Калганы кем әйтмешли, майланган төсле барды. Килә торды «Газель», китә торды, сәгать тә үтмәде — ярты машина бушады. Юра да көттермәде, соңгы капчыкны чыгарып салгач, Рәмилнең кулына резинка белән будырылган бер пачка акча тоттырды.

— Санап ал, акча санаганны ярата, — дип үз яныннан урын бирде. Рәмил санаган арада утыргычы астыннан шешә тартып чыгарып, стаканнарга бүлде. Рәмил акчаларны түш кесәсенә күчергәч, ым какты.

— Әйдә, юыйк, азагын яхшыга юрыйк.

Ах-ух килеп торганнан соң, тагын бер җөмлә әйтәсе итте:

— Ахрысы соңгы сөйләшү бу безнең, миңа шулай тоела. Азагына килгәндә: ничек кенә булмасын, минем хакта теш агартма. Хәер, андый егеткә охшамагансың. Менә шешәнең сиңа дигәне. Бигайбә, — дип китеп тә барды.

Артка чигенү юк иде инде, Матильдадан да яшерәсе түгел. Бары катырак торырга кирәк, тупасрак булырга. Кулыннан килгәннең барысын да эшләде

сөйгәне өчен. Матильданың үзен шуна ышандырырга кирәк, соныннан рәхмәтләр укыр. Кергәч тә шап итеп өстәлгә шешәне утыртты ул, шунда ук акчаларны ыргытты.

— Матильда, җаным, кил әле утырыйк икәүләп, — дип нәүмизләнеп калган хатынны янына тартты. — Син карама алай, барысы да яхшы, барысы да әйбәт. Ах, ничек рәхәт мина синен янда, белсән иде! Ләкин безгә аерылышырга кирәк, Матильда.

— Син мине ташлап кайтып китәргә булдынмы? — дип сораулы караш ташлады Матильда. Мизгел эчендә күзләре яшьләнде аның, ләкин үзе башын күтәреп читкә карап җибәргән булды. — Ихтыярын, шулай буласын алдан чамаларга була иде. Тик ... нигә ул матур сүзләрне унга-сулга чәчкән булдың, нәрсәгәдер ышандырдың? Алдан ук дөреслеккә барып ниндидер өметләр уятмаска була иде бит... мин дә юләр инде, ах, юләр...

— Матильда, уйдырмаларыңны читкә куеп тор, безнен вакыт бик тар. Беләсең сине яратканымны.

— Яратам дигән кеше каядыр китәргә җыена түгелме соң? — диде үпкәләп хатын. Ике ут арасында калган иде ул. Әле генә күкләргә күтәрде бу ир, яшәү тәмен бирде, инде килеп калдырырга җыена.

— Мин үз теләгем белән китмим. Их, әгәр мин теләгәнчә булса, гомергә бергә булырга тиешле кешеләр без. Ләкин тормыш дигән нәрсә аяусыз, менә аңа мин кулдан килгән кадәр каршы торырга булдым. Зинһар, син «Юк!» дип әйтмә. Менә акчалар. Алар сина. Минем теләгем шул: син акчаларны аласың да, улым белән бергәләп, ә Гарсия минем улым, туган тарафларга кайтып китәсез, яхшылап урнашасыз, туганнарың белән кавышасыз...

— Үзең булмагач, акчаларың миңа нигә? Кирәкми, кайтарып хатынына бир, оныт безне, — дип ярсып тезеп китте Матильда, кулы белән акчаларны идәнгә сыпырып төшерде.

Рәмил идән буйлап йөреп туздырылган акчаларны җыйды. Өстәлгә алып куйды.

— Син мине тыңла, соңыннан тиргәрсең, соңыннан үпкәләрсең, вакыт күп булыр әле анда. Сүз бир миңа, бернәрсәгә карамый син туган якларына кайтып китәсең, киләсе атнада эзең дә калмасын бу авылда...

— Ә син?

— Ә мин, — Рәмил елмайды, — ә мин сезнең арттан ук юлга чыгам. Кайчан куып җитәрмен, күпме вакыт үтәр — анысы билгесез, тик бел, һәрвакыт, һәр мизгелдә сиңа ашкынган булачакмын. Очраган бер киртәләрне җимереп, ә җимерә алмасам, уйларымда-хыялларымда булса да мин юлда булырмын. Мин сиңа бервакыт барып җитәрмен. Нинди шатлыклы булыр ул сәгать! Ә хәзер хыялыбыз тормышка ашсын өчен икебезгә дә юлга әзерләнергә вакыт.

— Әллә нәрсәләр сөйлисең син, Рәмил. Син өенә дә кайтырга җыенмыйсың бугай, тел төбеңнән шулайрак аңлашыла кебек. Әйтеп бетер, аңлат зинһар, уртага салып сөйләшик. Ике баш яхшырак дигәндәй... Кая барырга уйлыйсың соң, нигә безне ашыктырасың?

— Башта сүз бир: акчаны алам, кайтып китәбез дип, нәрсә булса да син әйткән сүзләрдән чыкмыйм, дип әйт! — дип ялваргандай кабатлады Рәмил.

— Ярый, сүз бирдем, — диде Матильда, Рәмилнең карашы акчаларда икәнен күреп, аларны алып каядыр куйгандай итте.

— Йә, мин тыңлыйм.

Рәмил аракы салып йотты, ачысын-фәләнен сизмәде дә ул. Җәя керешедәй тартылган иде аның нервылары. Артына ут төртердәй бу дөньясы, тагын бер төн генә булса да бүләк итсә соң аларга?!

— Менә әле искә төште, синең теге диңгезләрне айкаган картатаең. Кайчан булган хәл, ә һаман сөйлиләр анын турында, Матильда! Әй, Матильда, син минем турыда Гарсияга сөйләрсен әле, яме?! Менә шулай он сатып безне озатып калган иде туган якларга диярсең. Ә бәлки ул үзенең улына сөйләр, таралыр чегәннәр арасында шундый риваять, буыннан буынга, ә, Матильда?!

Матильда исерә башлаган Рәмилнең янына ук күчеп утырды, тынычлыгын югалткан иде ул. Ничектер ямансу булып китте аңа, өнендә төш күргәндәй тоелды, югалта бит якын кешесен, югалта...

— Рәмил, акыллым, сонынннан иркенләп сөйләрсең аларын, ә хәзер әйт яшермичә, нигә бәргәләнәсен, нәрсә булды, җәфаланма, әйт... — дип кирәген ишетәсе килде Матильданың, ләкин соң иде инде. Тышта машина тавышы ишетелде, нәкъ аларнын тәрәзә төбендә тукталып калды. Рәмил айнып киткәндәй булды, каударланып торып тәрәзәгә капланды:

— «Мицубиси», һа, Бычок үзе килгән, — диде ул кулларын угалап. — Ә син, Матильда, мина жиде ят кеше булып кылан, белмисең дә күрмисең дә, анладыңмы? Үзлегеңнән чыгып нәрсәдер эшләсәң, мәнге риза-бәхил түгелмен. Их, Матильда...

Рәмил ашкынып Матильданы кочаклап алды, тыны куырылды хатынның.

— Кемнәр алар? Сезнекеләрмени? — дип сорашырга өлгерми калды, Рәмил ашыгып чыгып та китте. Машина янында аны Руслан, бригадир, башлыклары Бычков каршы алдылар. Рәмил чыкканчы алар КамАЗ тирәсендә йөреп әйләнгәннәр иде инде, фургон ишеге төбендә тапталган эзләрне дә, күчәрнең шул килеш сүтелмәгән икәнен дә күрделәр. Табактай бите кызарынган-бүртенгән Бычков шунда ук кычкырырга тотынды:

— Син, недоношенный, нинди кәмит оештырдың монда? Моның өчен мин бит синең жаныңны суырып алачакмын, падла...

Сүзләр нәрсә ул? Аларга исе китми иде инде Рәмилнең. Ул үз теләгәненә иреште, күнеле түгәрәкләнде инде аның, ниндидер Бычокның авызыннан төкерекләр чәчкәненә илтифат итәсе юк. Йөзенә гаепле төс тә чыгармады Рәмил, башын да аска имәде, тегенең күзләренә туп-туры карап тора бирде. Отыры кызды түрә, күзе-башы акайды.

— Ач фургонны, хайван, — дип җикерде ул, башкаларны узып алдан машина артына чыкты. Бер Рәмил тыныч иде арада, булыры булган, унасы унган, кем әйтмешли, ул алда нәрсә тәгаенләнгән, шуны кабул итәргә әзер иде. Ашыкмый гына тимер ишекләрне ачып җибәрде. Каян жинеллек килгән, корсагын күтәреп ялт сикереп тә менде Бычков, канат итеп кулларын какты:

— Бетергән, суйган, талаган бу адәм актыгы мине! — дип калын тавышы белән шар янгыратты ул бушап калган фургон эчен. — Вор! Беләсеңме нәрсә эшләтәм мин сине моның өчен? Сизгән иде аны күнелем, ничә көн рәттән төшемдә кара киемнәргә чорналып йөрдем. Күрәчәкне эшкәрткәннәр икән төш аша. Эх, хайван... — дип зилзилә куптарды хуҗа.

— Кайда озаттың, әйт, падла, күпме акча алдың? — дип ул бөтереп алды төшә төшүгә Рәмилнең якасыннан. — Эндәшмисең, әһә, тукта, әйттерерләр, энәсеннән җебенә тиклем сөйләп бирерсең, шуышып йөрерсең әле минем алда... — дип хәтәр кыланып янады ул Рәмилгә.

Эшне кызу тотты. Русланны үз машинасында милиция хезмәткәрләрен алырга җибәрде, ә үзе, бригадирга Рәмилне сакларга калдырып өйгә юнәлде. Өй хуҗасы нәрсә булса да күргәндер-белгәндер, яшерен эшләнә торган эш түгел. Бригадир икәү торып калгач Рәмилгә тәмәке сузды, шырпы кабызды, үз итеп хәлен уртаклашты.

— Эх, Рамилька, — дип мул итеп тәтен өрде ул, — күпме йөрдек без синен белән рейсларда, ышанычлы егет булдын. Ялгышып киттен. Бычокнын акчасы безгә була торган түгел инде беркайчан да. Тәвәккәлләрлек акча да түгел, миллион эләктерсән икән әле — башны алып чыгып китәргә булыр иде берәр якка. Кушканны үтәгән булсан, хәзер хатынынның жылы кабыргасында пиво эчеп, телевизор карап ятасы гына иден. Бычокны беләсен, хәтәр адәм, башынны ашар. Әле юлда килгәндә хатыны өчен юри миннән үч ала дип сөйләнеп килде. Төкерергә иде икесенә дә, янадан башлап карарга иде тормышны. Ялгышкансын, брат, эчүдән дисән, артыгын тотканын да булмады мона кадәр. Син, ни, әзрәк унаена тор тегенен, хужалар баш игәнне яраталар бит алар. Бәлки, ипкә килер, тынла сүземне. Юк кына нәрсә өчен башынны төрмәдә черетер, күнеле таш ул адәмнен...

Берни дәшмәде Рәмил, тынлап кына утырды. Рәхмәтле иде ул бригадирына, анын хәлен жинеләйтергә теләгәненә күнеле булды. Ләкин кеше хәлен кеше беләме? Рәмил, үзе, мәсәлән, янабаштан башла бу көннәрне дисәләр, нәкъ шулай яшәр, шул ук гамәлләрне кылыр иде, бәлки, артыграк яратыр-кочаклар иде Матильдасын, шунысы гына үкенечле. Ә тегеләй тамчы да үкенми иде ул. Бригадир әйтмешли, өендә булыр идеме, Бычокнын сөяркәсе белән берни белмәгән булып кыйланып сөйләшер идеме, шул үзәккә үткән гаиләгә ябышып ятар идеме? Гомерен буе кол булганчы, бер тапкыр башынны калкытырга көч тап, үзенә хөрмәт белән кара! Караклыкта гаепли аны теге нәсел үгезе. Урлашу буламы икән ул — ничә еллар кемгәдер байлык тупларга булышып, тиешлесен алып бетерми эшләгәннән сон, үз белдеген белән хисап ясау? Әйдә, караклык та булсын, ә Бычков ишеләрнен гади кешенен сонгы тиенен дә акыртып талауларын караклыкка исәпләмиләр. Бер Ходай хөкемдар. Рәмил сонгы чиккә терәлгәч барды бу адымга. Әгәр сөйгәненен рәхимсез дөньянын сазлыгында тыпырчынганын читтән карап күзәтеп торса яхшырак булыр идеме? Тиешле жәзасын үз иннәре белән күтәрер, төрмә ишеген ачып керергә язылса, тәкьдиренә күнәр... Кайда да адәм балалары, гомерлеккә бикләмәсләр әле. Бер котылыр барыбер, эзләп табар Матильдасын...

Өй эчендә берара Бычковнын тавышы ишетелгәләп алды. Ниһаять, үзе күренде. Тынычланмаган иде һаман, мыгыр-мыгыр сөйләшеп, чыккан ишеккә карый-карый атлады ул.

— Разврат оештырганнар монда, — дип хәбәр салды ул кулларын болгап, — өстәлдә аракы, эчкәннәр-типтергәннәр. Акча кирәк булса, шалт очырган онны. Ну, юеш урын да калдырмыйм әле мин бу сагызак оясыннан!..

Бераздан ишектә Матильда үзе күренде. Йә Хода, үзгәрсә үзгәрә икән кеше кыска гына вакыт эчендә! Күзләре томаланган иде анын, чәчләре тузгыган, баскан адымнары ышанычсыз, куллары кайда тукталырга белмиләр... Өзелеп төшәрдәй булды йөрәге Рәмилнен ана карап.

— Әнә, чыккан сихерче бичә, — дип күзләрен усал елтыратты Бычков. Берни белмим, берни күрмәдем, «әйе», «юк», бар булган жавабы. Ни аласын аннан, чегән кайда да чегән, аларнын урлашып даны чыккан. Бергәләп урлаганнардыр...

Анын нәрсә бытылдаганын тынламады да Рәмил, торып Матильдага каршы атлады. Ул да шәйләп йөгерә-атлый килеп, якынынын күкрәгенә башын терәде.

— Рәмил! — диде ул инрәп, — син мине алдагансын. Безнен өчен башынны югалтырга телисенме? Акылына кил, сөйлә дөресен, әле сон түгел... ялварып сорыйм, телисенме тезләнәм алдына? — дип чүгәли башлады ул жиргә, үзенен күзләреннән яшь коела иде.

Рәмил тартып торгызды жанкисәген, кочагына кысты да колакларына пышылдады:

— Болар вакытлыча барысы. Артыгын сөйли күрмә тагын, бернәрсә дә үзгәртә алмассын. Мина начарракк кына булыр. Мин коры чыгам бу хәлдән, ышан, бер ай, күп булса ике ай, синең арттан килеп тә житәрмен. Син бу авылга үзең турында хәбәрләр жибәреп тор яме? Ходай хакына сорыйм синнән, кош теле кадәр генә булса да хат яз. Күрше әбигә әнә, үзеннең фатир хужана, Юрага, бик тә булмаса. Мин шул хәбәрләр аша сине эзләп табармын. Монда торма, бер кызыгы да юк мине алып китүләренең, Гарсия да елый торгандыр. Шул безнең хушлашу булсын! — дип кат-кат үпте аның иреннәреннән Рәмил.

— Ха! Күрденме? Шаһит бул, бригадир. Бер банда болар. «Ну и парочка, баран да ярочка» — диярргә генә кала. Каян табышканнар, кайчан кавышканнар? Теге сөйрәлчек, бер иркәләгән дә бу юкабашны, төп башына утырткан инде. Ха-ха-ха....

Рәмилне бу сүзләр ярсытып жибәрде. Ул өйгә керергә ымлап, Матильданы эткәләп дигәндәй үз кырыннан жибәрде дә, бар гәүдәсе белән үзеннән бер баш биек булып басып торган шефка таба борылды. Теге селәгәйләрен жыеп ала алмыйча һаман мыскыллап көлә иде әле.

— Синамы кеше тикшерергә, ата чучка? Маймунә белән себерелгәннәреңне исенә ал да, яп сасы авызынны! «Карак» дип дөнья янгырата. Угрыныкын бур урлаган. Синең урлаганнарыңны исәпкә алсаң, мин синең алда чүп кенә. Кайда ул сина житү! Паразит син, менә кем йөри дөнья пычратып... – дип жиргә төкереп куйды Рәмил. Төкереген тырышып-тырышып изгәләде әле. Күптәннән үзенә каршы сүз әйткәннәрен ишеткәне булмаган хужа башта катып калды, бер агарды, бер күгәрде. Һәм үгездәй үкереп, ике кулын алга сузып Рәмилгә ташланды. Якасына барып ябышып унга-сулга селеккәләргә тотынды, буыла-буыла сөйләнде үзе:

— Сгною, көл-талкан ясыйм, гад буду ...

Тагын нәрсәләр әйтергә теләгән булгандыр, Рәмил артыгына ирек бирмәде. Кинәт кенә башы белән тегенең ияк астына бәрде. Телен тешләп теге чалкан егылды. Тимер сугып мускуллары ташка әйләнеп беткән Рәмилгә каршы тора ала димени бу олы корсак? Рәмил иплəбрәк басып торырга маташкан хужага, йодрыгына бар ачуын туплап, тагын берне ямады. Әйбәт эләкте, тагын капланып төште ит түшкәсе. Һушына килгән бригадир, йөгереп килеп, Рәмилгә асылынды:

— Рамилька, не дури, тагын бер суксаң жанын жәһәннәмгә очырасың бит. Ал кулына үзенне, тимә, букка тисәң, үзең буяласың! Гомерлеккә башыңны ашарлар, — дип тынычландырырга теләде.

Ул арада чәчрәп Матильда килеп чыкты. Тәрәзәдән күреп калгандыр инде, бер кат күлмәкчән көе, анысы елап-сыктап Рәмилне читкә тартты. Нәкъ шул чакта олы юлдан авылга ике машина борылды. Алдагысында Руслан иде, арттагысыннан бер-бер артлы резин күсәк белән коралланган «омон»нар коелды. Аларны күрүгә, авызы-башы кан булган Бычок калкынды, бармагын Рәмилгә төрәп чәрелдәргә тотынды:

— Коткарыгыз! Алыгыз аны! Үтерергә һөжүм итте! Түлим, күпме кирәк түлим! Бирегез кирәген!

Таза егетләр эшне озакка сузмадылар, кемнең кем икәнен дә сорашып тормадылар. Матильданы кулыннан сөйрәп читкәрәк аттылар да бригадир белән Рәмилнең баш өстендә «демократор»ларын уйнатырга тотындылар.

Руслан килеп житеп ничек тә бригадирны аралап алды. Коты очкан Матильда ничә тапкырлар шар елап Рәмилне якларга талпынса да, аны кызык кына күрделәр, берсе хатынның очасына таягы белән эләктереп тә

алды шикелле. Бераз эшләп аргач, тын алырга тукталдылар, тәмәкеләрен кабыздылар, эшнен нидә икәнен тынларга Бычковны тирәләп бастылар. Матильда һушын югалткан Рәмилнен канга баткан йөзен сөрткәләде, чәчләрен сыпыргалады, үзе дә сизмәстән, чегән теленә күчеп, Ходайдан бердәнберен коткаруын ялварды. Игътибар үзәгендә Бычков иде. Кулларын болгап кына торды ул, теле телгә йокмады:

— Куркыныч жинаятьчене җәтмәгә эләктердегез, егетләр. Мин сезгә ияреп барам идарәгезгә. Монда тиресен тунагыз сез анын, ләкин жаны туган ягына кайтырлык калсын. Анда полный катушкага булачак әле ана. Кем белән бәйләнергә уйлаган?! Ә сезне, барып житкәч ризалармын, анысы хәлдән килә. Ну, мона да танытам әле кем икәнлегемне, исән котылса, үлгәнче онытмас.

Инрәп елаган Матильда үкереп чапкан машиналар артыннан хәлдән тайганчы йөгерде. И, тилекәй, куып тотып була димени үткән бәхетле мизгелләрне?

***

...Ел ярымнан соң, челтерәп ерганаклар ага башлаганда, таныш юл аермасында, үтеп йөргән машиналарның берсеннән мескен бүрек, кирза итек, бушлат кигән берәү төшеп калды. Күкрәк тутырып язгы һаваны сулады ул, зәңгәр күктә үзәк өзгеч тавышлар чыгарып очкан торналар төркеменә карап торды. Яшел үлән дә озакламый баш калкытыр, кояш шифалы нурларын мул чәчәр, әллә саулык-тазалык алып килер бу елның мизгеле. Өметне өзәсе түгел, өмет яшәтә кешене! Анын өчен кадерле булган бу почмакта бәлки куанычлы хәбәрләр көтә торгандыр?! Яхшы хәбәр бит үзе бәясез дару. Шәүләсе генә торып калган иде шул Рәмилнен, ә бу адәм — Рәмил иде. Аягын көчкә сөйрәп авылга таба атлап китте ул. Бер адым, ике адым, өч адым... Әйтерсең әнә шулай үткән көннәрне, тәкъдиргә язылган вакыйгаларны исәпли иде ул.

Суд залы, рәхимсез суд карары, парлап авыз ерып утырган Бычков белән Мәймүнәсе... Төрмәгә эләккәч тә Бычковның акчалары ярдәмендә житәрлек төйделәр аны. Зекларның «яраткан» чирен — туберкулез йоктырды, урман кискәндә агач астында калды, бер бөерен кисеп алдылар. Теш коелу, ашказан ярасы, ирлек көчен югалту кебек вак-төякләрне санап та торасы түгелдер инде. Тәмам кешелектән чыгардылар аны. Тормыш тәмен югалтты ул, үткәннәрен онытты, киләчәк кызыксындырмады. Бәлки, муенына бау да салган булыр иде, ләкин күнеленең иң төбендә, төпкелендә бер куз сүнәргә теләми көйри иде әле: Матильда! Аны уйлап яшәде ул, дога урынына исемен кабатлады, йоклый алмый интеккәндә төннәр буе анын белән сөйләшеп чыкты. Бергә булган һәр мизгелне кадерләп хәтерендә саклады, кат-кат яңартты, аны уйлап кына үлгән жиреннән терелде, акылын югалтмады. Менә әле дә һәр атлаган адым саен каны жылына бара анын, йөрәге ныграк тибә. Бер-бер хәбәр тәгаен көтәдер аны, берәр төрле билге жибәргәндер сөйгәне. Бергә-бергә гаилә булып яшәрбез, дигән төсле тормышка ашмастай юләр уйлар түгел башында, үз хәлен үзе белә. Бары тик бер күрәсе иде күнел шатлыгын, яшәвенең иң кыйммәтле бүләген, бер кочаклыйсы иде төз аякларын, йомры тезләренә тәмугларны кичкән башны салып тын каласы иде. Аннан дөньядагы иң гүзәл, иң мөлаем, иң серле күзләргә карап, күз яшьләренә ирек биреп пышылдыйсы иде: «Менә кайттым, Матильда!...» — диясе иде...



Флёра
Тарханова

# КҮҢЕЛЕМӘ ЯТТЫ МОҢЛЫ КӨЙ

## Яңа ел!

**Җем-җем карлар яткан урамнардан**
**Сузылып киткән килер таңга юл.**
**Күңелләргә өмет, шатлык сала**
**Якынлашып килгән Яңа ел!**

**Күбәләкләр булып очкан карлар**
**Иреннәргә куна иркәләп.**
**Яңа елга илтер юлга чыктык,**
**Соңламыйк дип, бераз иртәрәк.**

**Болытлардан ачылып торган чакта**
**Зәңгәр күктә йолдыз яктыра.**
**Серле айдан сихри нурлар иңеп,**
**Сөю хисен җанда арттыра.**

**Үпкә-ялгышларны ташлап китик**
**Яңа елның ишек төбендә.**
**Бары кайнар кояш балкып торсын**
**Һәммәбезнең күңел күгендә.**

**Килеп җитте зарыгып көткән минут –**
**Хәбәр бирә әнә курантлар.**
**Кадерен белеп яшик һәрбер елның –**
**Без бу җирдә бары кунаклар.**

**Яңа елда сөенечләр генә**
**Җилкендерсен безнең йөрәкне.**
**Бәхет керсен ишек-капкалардан –**
**Чын хакыйкать итсен теләкне!**

Флёра ТАРХАНОВА – *шагыйрә, прозаик, тәрҗемәче; «Яшьлек эзем калган сукмаклар», «Язмышлар язылганда», «Хисләр дәрьясында» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Йөрәгем тулы яра

Бар нәрсәнең рәте китте –
Бу дөнья кая бара?
Җиргә иңгән затсызлыктан
Йөрәгем тулы яра.

Якын дус, кайчак туганның
Хөсеттән йөзе кара.
Иманның, деннең китүе
Йөрәккә сыза яра.

Миллионлаган үксез бала
Хак юлдан чыгып бара.
Аларның язмышы сала
Йөрәккә тирән яра.

Үз милләтен санга сукмый,
Халкым читләшеп бара.
Шуңа җаным сыкравыннан
Йөрәгем тулы яра.

Тормышны җайлап барырга,
Милләтне саклап калырга,
Үксезне юлга салырга,
Мең ярадан арынырга
Кем ярдәм итә ала?
Сораулар җавапсыз кала –
Бу дөнья кая бара?
Әдәп күперләре яна –
Йөрәгем тулы яра.

## Тик миңа төбәлгән карашың

«Һәр көнне керәсең төшемә», –
Дип җырлыйсың миңа, җанашым.
Ялварып төбәлгән, тик миңа төбәлгән
Сагнулы, әрнүле карашың.

«Өзелеп яраттым, — дисең син, –
Сөюем бирмәде сулырга.
Күкләрдә Ходаем язмаган күрәсең
Гомерлек сөйгән яр булырга.

Язмышым чикләде өметне –
Сүзләрем калды тик уемда.
Җанымда бер теләк: назыңа төренеп
Янарга ялкынлы куйныңда».

## Нигез

*«Татар дип танымыйлар бит,*
*Шуңа киселә тамыр...»*
(сөйләшүләрдән)

Милләт рухы бүген шактый таркау –
Кешесе аз иман тергезгән.
Бик күбесе тел һәм ил югалтты,
Тамырларын өзеп нигездән.

Үзәгенә балта чабу белән,
Сеңде алар башка халыкка.
Үз милләтен хәтта түбәнсетеп,
Яраклашты чит бер калыпка.

Танымыйлар, диеп, куркасы юк –
Горур булып калсак, танырлар.
Нигез тамырыңа үтеп кара –
Бик тирәндә безнең тамырлар.

**Шул тамырлар чиксез киңлекләргә**
**Үрләгәндә меңгә уралып,**
**Тарихларда шаһит булып калган**
**Идел, Чулман, Ука[1], Уралы...**

**Бар да алар безнең төп нигездә –**
**Белмәгәннәр белеп торсыннар!**
**Катлам–катлам яткан шул җирләргә**
**Милли җаннар нигез корсыннар.**

**Җир ташланып, нигез җимерелсә,**
**Алар белән тел дә китәчәк.**
**Җире, теле беткән һәр милләтне**
**Җире булганнар кол итәчәк.**

**Баба җирен мирас итеп алып,**
**Колы булыйк тик бер Алланың.**
**Теләсә кемгә кушылып, рәнҗеттермик**
**Тамырдагы төркиләр канын.**

**Ныгытмасак борынгыдан килгән,**
**Бәгырьләргә тоташ тамырны,**
**Нигез корытып, телен «өзеп» аткан**
**Маңкорт халык яшәп калырмы?**

**Һич югалмас бөек татар халкы,**
**Дәрәҗәсен белеп яшьнәсә,**
**Нигезенә бәйләп тамырларын,**
**Җир хуҗасы булып яшәсә!**

## Туфан[2]

**Ике Туфан күңелемдә яши:**
**Берсе аның — шагыйрь якташым,**
**Икенчесе исә — гомере буе**
**Милләт өчен янган ут ташы.**

**Яшь чакларын аның хәтерләмим –**
**Шактый кече идем мин аннан.**
**Шунысын беләм: тирән акылы белән**
**Туфанлыгы йөрде гел алдан.**

**Ә бит аның шушы сыйфатлары**
**Соң минутынача сакланды.**
**Акыл–дәрте гел бербөтен булып,**
**Бар гамәле илдә якланды.**

**Заманында Гаяз Исхакыйлар**
**Кайгырткан күк үзенең милләтен,**
**Гел көрәштә булды: саклыйк, диеп,**
**Халкыбызның телен, кыйммәтен.**

**Күпме бала укый үз телендә**
**Ул салдырткан күпме мәктәптә.**

[1] Ука — хәзерге Ока елгасының элекке исеме.
[2] өермә, зилзилә, давыл

Йөрмәсә ул,
Татар мәктәпләре инде күптән
Беткән булыр иде әлбәттә.

Чакматашның утлы очкыннарын
Йөрәгендә җыеп йөрткәнгә,
Наданнарның кара йөзен борды
Киләчәккә, шанлы үткәнгә.

«Үткәненә борылып карамаса,
Киләчәге юк бит халыкның», –
Дия-дия, милли дулкыннарда
Алып батыр булып калыкты.

Һәрбер сүзе аның үткен чакма –
Кадалды ул һәрчак ук булып,
Кайберәүнең хәтта туң йөрәген
Ялмап алды ялкын-ут булып.

Бармы бездә хәзер мондый шәхес –
Кем күтәрә милли әдәпне,
Кем кайгырта милли горурлыкны,
Чын хакыйкый милли сәнгатьне?

Туфан булып үтте бар гомере,
Туфан булды һәрбер чорында.
Өермәләр тузгып калды хәтта
Мәңгелеккә киткән юлында.

## Бетеп бара татар авылы

Туган авылыма кереп киләм –
Күңелемә ятты моңлы көй.
Тик моңнарым күчте әрнүләргә –
Авыл тулы нурсыз ялгыз өй.

Җиргә сеңеп барган бу өйләрнең
Гөлләре юк тәрәз төбендә.
Йолдызлар да хәтта җемелдәми
Моңсыз калган авыл төнендә.

Җимерелеп яткан һәр нигезне
Тузан итә язмыш давылы.
Бәгырьләрне кисә шомлы уйлар –
Бетеп бара татар авылы.

Бетеп бара авыл, бетеп бара,
Исеме калыр, бәлки, телләрдә...
Дистәләгән бала урынына
Җилләр уйный ялгыз өйләрдә.



Ркаил
Зәйдулла

# МИНЕМ ДУСТЫМ ЧЫҢГЫЗХАН

САТИРИК КОМЕДИЯ

**Катнашалар**
Чыңгызхан — соңыннан хәзрәт була.
Таймас — тормышта үз урынын эзли, ләкин тәбәнәк.
Гөлназ — кияүгә чыгарга тели, ләкин яратып.
Мөслимә — Гөлназның әнисе, яңа диндар.
Илүсә — бизнесвумен.
Илгизә — аның шоферы. Ирдәүкә.
Илдар — уңышсыз шымчы.
Ике санитар — өнсезләр.
Сәркәтип кыз — тавышы гына ишетелә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

*Фатир бүлмәсе. Сулда икенче бүлмәгә ишек. Уңда фатир ишеге. Бүлмәдә өч караваt, җиһазлар гадәти. Китап киштәсе дә бар. Таймас йоклап ята.*

*Таймас төш күрә. Гүяки ул Чыңгызхан белән очраша. Чыңгыз хан татарча сакаллы, кәгеле ярты маңгаен каплаган, баш түбәсендәге учма чәче толымлап үрелгән. Өстендә җилән, билен көмеш тәңкәләр белән бизәлгән кушак белән буган, аңа кәкре пычак аскан. Аягында читек.*

Чыңгызхан. Тор, егетләр солтаны! Иртә уянган юлдан уңар, иртә өйләнгән улдан уңар.

*Таймас лунатик сыман килеп Чыңгызхан алдында йөгенә.*

Таймас. Бу чыннан да синме, бөек Җиһангир?! Күзем ялгыш күрмиме?

Чыңгызхан. Мин! Мин килдем. Йортыгыз имин булсын! Малыгыз саф сулы елга буйларында, яшел келәмле болында йөрсен. Алдыгыздан ит вә сөт өзелмәсен.

Таймас *(чәрелдәп җибәрә)*. Яшәсен Чыңгызхан! Азат-лык! Азат-лык! *(Кулын өскә чөя.)*

Чыңгызхан. И егетләр солта-

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) – *шагыйрь, прозаик, драматург; «Ил», «Мәгарә», «Ташка ордым башны» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

ны! Син арыган чакларымда рухымны күтәрүче, сагышлы чакларымда юата алучы аякчым булырсың.

Т а й м а с. Йа, Тәңрем! Йа, Зәңгәрдән дә Зәңгәр Күгем! Йа, дөньяны учында биеткән ерак бабам — бөек Чыңгызхан! Нигә мине сайладыгыз?

Ч ы ң г ы з х а н. Синдә күк түрекләрнең, бөек магулларның каны тибә. Без бөек халык идек! Ә хәзер без кем? Сина Тәңре үзе карап тора! *(Тантаналы төстә.)* Син коткарырга тиеш татарны!

Т а й м а с. Ничек? Мин бит гаптади бер малай гына.

Ч ы ң г ы з х а н. Малай чагында мин дә малай идем.

Т а й м а с. Коткарырга, дисең инде. Татарны, дисең инде. Кемнән? Нәрсәдән?

Ч ы ң г ы з х а н. Мескенлектән!

Т а й м а с. Ул мескен түгел. Кайчагында аңа әле дә бөек диләр.

Ч ы ң г ы з х а н. Әһе-һе... Кайсы телдә?

Т а й м а с. Ну, без бераз бирештек, канишны. Үзгәрдек довольнотаки.

Ч ы ң г ы з х а н. Сине бөек эшләр көтә!

Т а й м а с. Башта үземнең эшләрне жайларга иде бит, Чыңгызхан абый. Өйләнәсе бар, фатир аласы. Машина да юк. Машина бит инде ул сезнеңчә ат дигән сүз. Синең заманда атсыз татар булмагандыр да.

Ч ы ң г ы з х а н. Ир-егетнең иң зур бәхете — ат һәм хатын-кыз өстендә...

Т а й м а с. Әйтәм ич инде: атларны хәзер ипподромда гына күреп була.

Ч ы ң г ы з х а н. Ахмак! Ат власть дигән сүз ул!

Т а й м а с. Кичер, бөек жиһангирем! Син — дөньяның йөзек кашы! Син — татар данын буыннан буынга югары тотарга Тәңре тарафыннан жибәрелгән олуг зат. Йа, Тәңре! Йа, Зәңгәрдән дә Зәңгәр Күгем! Бөек Чыңгызханның ышанычын акларга ярдәм ит миңа!

*Сул як ишектән Илгизә керә. Ул эчке күлмәктән генә, яңа йокыдан торган булса кирәк.*

И л г и з ә. Тор! Саташа-саташа йоклый, вәт бичара...

*Таймас сикереп тора.*

Т а й м а с. Ә?

И л г и з ә. Эшкә соңга калабыз. Жыен тизрәк.

Т а й м а с. Шулай кинәт уятмасаң... Илгиз тәре! Әх, шундый чакта бүлдең. Шәп төш иде! Беләсеңме, кемне күрдем?!

И л г и з ә. Гөлназныдыр инде. Иреңенне бик тәмләп чәпелдәтә идең. *(Киерелә.)* Трусик-майкаларыңны чайкап элгән идем. Алмаштыр.

Т а й м а с. Юк шул менә. Өр-яңа төш керде.

И л г и з ә. Тагын Наполеонны күрмәгәнсеңдер бит?

Т а й м а с. Наполеон... Наполеон маймыч бит ул моның янында. Чыңгыз хан үзе төшемә керде!

И л г и з ә. Кем? Авылдашың мәллә?

Т а й м а с. Чыңгызхан! Син нәрсә, Чыңгызханны белмисеңме?

И л г и з ә. Синең кебек универда тарих укып ятмадым, Аллага шөкер. Башым сау-сәламәт.

*Ишек шакыйлар.*

Т а й м а с. Кем ул? Кем йөри инде тан тишегеннән...

*Тавыш. Хужа әйткәндер бит... Урнашырга килдем.*

Т а й м а с *(Илгизәгә).* Бу бүлмәгә тагын бер кешене урнаштырам, диде шул. Карун! Буржуй! Бар, ач инде *(чалбарын кия башлый.)*

И л г и з ә *(ишекне ачып).* Әнекәй генәм! *(Чигенә.)*

*Бүлмәдә Таймасның төшенә кергән Чыңгызхан пәйда була. Ки-*

*емнәре таушалган, жине ертык, бер күз төбе кара янган. Ун кулында зур иске чемодан.*

Чыңгызхан. Исәнмесез *(Таптана.)* Менә... Ни... Урнашырга дигәннәрие.

Таймас *(шаккатып).* Сез? Сез бу кыяфәттә?!

Чыңгызхан. Ә-ә, синмени бу? Нигә исең китте, дөнья бу, энекәш. Үзең дә ерак китмәгәнсең...

Таймас *(үзен-үзе кулга алып).* Узыгыз. *(Кулы белән күрше караватка ымлый.)* Менә ятагыгыз. Урнашыгыз.

Илгизә. Бу нинди карачкы, ә?

Таймас. Бу — Чыңгызхан!

Чыңгызхан *(Илгизәгә).* Исәнмесез... *(Чемоданын аска шудырып, үзе караватка утыра.)* Менә...

Таймас *(уенга кереп, Чыңгызханга).* Ул сине танымый, бөек Җиһангир! Кичерә күр аны, мәрхәмәтеннән ташлама.

Илгизә. Таймас! Нәрсә кәмит уйныйсың! Бу хуҗа әйткән кешеме? Кертмибез! Күренеп тора — бу бит шизик! Билендә пычак та бар. Төнлә суеп чыкса? Син теләсәң нишлә, мин бу бомж белән күрше булмыйм. Әнә күз төбен кара! Чүплектән чыккан бит бу сәләмә...

Таймас. Әлбәттә, Чыңгызхан — иң бөек бомж! Әйт сүзеңне, Җиһангир! Сина мескенлек килешми.

Чыңгызхан *(сикереп тора, рольгә кереп).* Тик тор, хатын-кыз! Сина сүз бирүче юк. Югыйсә!

Илгизә. Ах, хәчтерүш! Синнән сүз сорап торалар ди монда... *(Чыңгызханга очып кунып, биленнән пычагын алмакчы була, тартышканда агач пычак сынып чыга.)*

Чыңгызхан. Туктагыз, туктагыз... Бу бит... бу бит... *(Караватка утыра. Таймаска.)* Менә, энекәш, гел кагалар мине. *(Йөзен каплап сулкылдый.)* Бәхетсез мин.

Илгизә *(кулындагы пычак сыныгын әйләндергәләп).* Артист...

Таймас *(Чыңгыз ханнын иненнән кагып).* Чү, абый, чү... Илгиз шундый инде ул. Тиз кызып китә. Алай усал түгел үзе. Шулай бит, Илгизә? *(Илгизәгә.)* Бар, су китер әле.

Илгизә. Һи, ике җүләр. Сезнең белән булашып торырга... Эшкә соңга калам *(чыга).*

Таймас. Менә, Чыңгызхан хәзрәтләре, бездә хәлләр шундый.

Чыңгызхан. Тәмам беткәнбез икән.

Таймас. Сез мине танымыйсыздыр?

Чыңгызхан. Таныдым. Бик сәләтле студент идең. Фән юлыннан китсәң... Тьфу! Кая китәр идең инде...

Таймас. Ничек болай булды соң?

Чыңгызхан. Теге вакытта, туксанынчы елларда, бөтен халык кубып мәйданга чыкканда, мин өйдә утырдым. Хәзер халык өйдә утырганда мин мәйданда йөрим.

Таймас. Чыңгызхан булып... Туристлар белән фотога төшеп. Акмаса да тама диген.

Чыңгызхан *(кулын селтәп).* Ә-әй.

*(Илгизә су алып керә. Ул киенгән: өстендә «RUSSIA» дип язылган футболка, джинсыдан.)*

Илгизә. Мәгез, абзый *(су бирә.)* Кыйнаганнар да, ахры, үзегезне, күз төбегез янган.

Чыңгызхан. Сталин сукты. *(Йотлыгып су эчә.)*

Илгизә. Нәрсә-ә?

Таймас. Ул Азатлык мәйданында эшли. Ну, күргәнең юкмыни: анда Лениннар, Сталиннар йөри. Туристлар белән фотога төшәләр. Менә ул Чыңгызхан булып эшли.

Илгизә. И бичара... *(Чыңгызханга.)* Чыңгызхан булганчы кем идең, абзый?

Таймас. Универда безгә татар тарихын укытты. Аңарчы партия тарихын укыткан.

Чыңгызхан. Менә хәзер тәмам кыскарттылар. Пенсиягә китәргә аз гына калган, мин кая барыйм?

Илгизә. Нигә Сталин гына булмадыгыз соң? Аны халык ярата.

Чыңгызхан. Конкуренция. Бездә болай да өч Сталин, ике Ленин. Үзара кан талашалар. Һәрберсенең үз фракциясе.

Илгизә. Сезгә дә җинел түгел икән.

Чыңгызхан. Азатлык мәйданы кисәкләп бүленгән. Һәркемнең үз урыны. Шуна да мине кысып маташалар. Туристларның күбесе гел минем янда. Сталиннар, Лениннар Мәскәүдә дә күп. Казанга килүчеләргә Чыңгызхан кирәк. Менә болар көнләшә. Үтерәбез дип яныйлар.

Илгизә. Бигрәк куркыныч бизнес икән.

Чыңгызхан. Ну ничего. Хуҗа рәнҗетмәс.

Таймас. Сезнең дә хуҗа бармыни?

Чыңгызхан. Һы... Крыша. Ансыз адым да атлый алмыйсың. Полковник! Монда ничек урнаштым дип уйлыйсыз? Минем хуҗа сезнекенә чылтыраткан — и мин сезнең белән. *(Таймаска.)* Бу әйбәт ханым синең хатынмы?

Илгизә. Аллам сакласын!

Таймас. Илгиз... Илгизә дисәң дә ярый, безнең фирмада шофер булып эшли. Әби патшаны йөртә. Без өйдәшләр — ул күрше бүлмәдә яши.

Чыңгызхан. Әби патша?

Таймас. Безнең хуҗа — хатынкыз. Кушаматы Әби патша. Мин шунда менеджер.

Чыңгызхан. Нинди фирма соң ул? Нишлисез?

Таймас. Бик шәп ширкәт. Тиздән дөнья мәйданына чыгабыз.

Илгизә *(Чыңгызханга).* Әйтсәм әйтим инде, абзый, прафисыр башың белән фатир да алалмадыңмы?

Чыңгызхан. Киттем. Хатын игосына түзеп булмады. Чыңгызхан булып йөрүемнән гарьләнде.

Таймас. Хатын-кызгамы Чыңгызханны аңларга!

Чыңгызхан. Дөресен әйткәндә, мин үземне хәзер генә шәхес итеп сизә башладым.

Таймас. Һәм дөрес! Үз юлыңны тапкансың.

Илгизә. Үз исемең ничек соң, абзый!

Чыңгызхан. Нигә ул? Аның өч тиенлек тә файдасы юк.

Илгизә. Шулаймыни? Ярый, алайса, Чыңгызхан абзый. *(Таймаска.)* Син эшкә җыенасыңмы, юкмы?

Таймас *(көлмәгән килеп).* Мин әзер. *(Чыңгызханга.)* Әби патша командировкада, шуңа беразсонарсак та ярый.

Илгизә. Киттек. Үз өеңдәге кебек бул, Чыңгызхан абзый. Менә сиңа ачкыч. *(Ачкыч бирә.)*

Чыңгызхан. Барыгыз, бар. Минем эш соңрак башлана.

*Таймас белән Илгизә чыгалар. Чыңгызхан караватка сузылып ята.*

Чыңгызхан. Ордым эшегезне! Ул үлгәч тә өч көнлек кала.

**Икенче күренеш**

*Шул ук бүлмәдә Чыңгызхан тирләп-пешеп чәй эчеп утыра. Ул шул ук кыяфәттә. Таймас кайтып керә.*

Таймас. Сәлам!

Чыңгызхан. Әйбәт кенә иде әле.

Таймас. Син нишләп киемеңне алмаштырмадың? Цивильный киен, дидем бит. Толымыңны алып ташла. Сакалыңны да... Хәзер килеп җитә бит!

Чыңгызхан *(толымын тотып).* Ничек алыйм... Ул бит чын.

Таймас. Чын? *(Толымны тартып карый.)*

Чыңгызхан. Алла! Авырта!

Таймас. Чыннан да чын. Мин

бит аны ябыштырып кына куйгансын дип торам.

Чынгызхан. Ана хатын да, бәйләнеп, тенкәне корытты. Шунын аркасында аерылыштык та.

Таймас *(кайчы алып)*. Бир әле, кисеп ташлыйм.

Чынгызхан. Тимә! *(Таймастан кача.)* Синең өйләнәсе килә дип газиз толымымны корбан итимме? Ул бит минем эш коралы!

Таймас. Гөлназ алдында шушындый чүчмәк булып утырмассың ич. Ул шундук чыгып качар. Тү-тү аннан өйләнү. Мин бит аңа әйттем: әтинең энесе килде Бүздәктән, дип. Ул, мәйтәм, анда җәмигъ мәчетнең имам-хатибы. Гөлназның әнисе бәәк диндар карчык икән. Мөслимә әби...

Чынгызхан. Исеме җисеменә туры килгән.

Таймас. Чын исеме Лена аның. Ленычка да булган, Лена Шафиковна да.

Чынгызхан. Ну-у, андыйлар пәйгамбәрнең үзеннән дә динлерәк була.

Таймас. Давай кыркып ташлыйбыз. Бу килеш сине кем мулла дип белсен? Чып-чын мәҗүси! Язычник!

Чынгызхан. Нишләп мәҗүси? Без Тәңре динендә идек.

Таймас. Сез?

Чынгызхан. Ул әле янадан кайта, Алла боерса. Пәйгамбәрләре дә бар инде берничәү. Иярүчеләр дә табылыр.

Таймас. Озын сүз бозау имезә. *(Утыра.)* Ну, болай булмый бит инде. Син бит аларга кода булып барырга тиешле. Ну йортлары, малай! Бабай салып калдырган. Бик крута бизнесмен булган икән, атып үтергәннәр хәтта! Ну йорты шәп, ул бакчасын әйтәсеңме...

Чынгызхан. Син ул кызны яратасыңмы?

Таймас. Гөлназнымы? Аны яратмаска мөмкин түгел!

Чынгызхан. Әлбәттә, шундый йорты булгач...

Таймас. Йорт ул мәхәббәткә мишәйт итми. Үзең дә бирнәгә бик шәп кеш тиресе алгансың бит әле. Синең заманда ул дөнья бәһасе торган.

Чынгызхан. Кем?

Таймас. Ә-әй, ул теге чын Чыңгыз хан бит әле. Әйдә, әйдә, киемеңне алмаштыр, сакалыңны... *(Якын килмәкче.)* Сакалың да чынмы?

Чынгызхан *(чигенеп)*. Чын, чын. Син мине Америкадан дип әйтәсең калган. Чию-чию кабиләсенең юлбашчысы дисән, һе-ей. Дәрәҗәң дә күпкә үсәр иде, мин дә, шул килеш барып, түрдә утырыр идем.

Таймас. Ярамай. Чаманы белергә кирәк.

Чынгызхан *(тирә-ягына карап)*. Син соң аны нигә монда чакырдың?

Таймас. Үзе бит... Ну, мин монда вакытлыча гына торам ласа! Салмачыда коттеджым өлгергәнче генә. Мин бит аның өчен зур фирма башлыгы. Крута бизнесмен *(тәкәллефсез булырга тырышып)*. Һым... Бөек җиһангирем, син миңа бераз әҗәткә биреп тор. Кәләшне берәр затлы кафега алып керергә кирәк бит инде.

Чынгызхан *(кесәсеннән акча чыгарып)*. Син болай да муеннан бурычта. Ничек түләп бетерерсең?..

Таймас *(тиз генә акчаны алып, кесәсенә шудыра)*. Булыр, булыр! Бүген көне буе интернетта утырдым. Австралиядә зур корпорация белән килешү төзергә сөйләштек. Алдында булачак миллионер басып тора!

Чынгызхан. Нинди килешү... Ташла ул буш хыялларыңны. Әнә төрекләргә төзүче булып бар.

Таймас. Артта калган икән син. Безнең бизнесның киләчәге һу-һу! *(Киемен алмаштыра башлый.)*

Чынгызхан. Нинди бизнес инде ул?

Таймас. Һава сатабыз. Татар һавасын. Саф һавага кытлык хәзер. Инде урамнарга саф һава сулый торган кабиналар куя башладык. Па-

кетларга да тутырып сатабыз. Буыла башласаң, ач та сула, пажалысты.

Чыңгызхан. Алаларммы?

Таймас. Көндәшләр күбәйде. Ну, без миллилек белән бәреп егабыз. «Изге Болгар жилләре» дигәне бигрәк тә шәп сатыла. Соңгы вакытта «Алтын Урда сулышы»н егылып алалар. «Казан язы» да өмет уята. Тиздән бөтен татар дөньясы милли һавага тиенәчәк.

Чыңгызхан. Ул милли һава дигәнне кайдан гына табып бетерәсездер.

Таймас. Кайдан, кайдан... Исемнәре үк әйтеп тора бит.

Чыңгызхан. «Казан язы», һы... Сулап буламы?

Таймас. Әле генә Финляндиягә бер эшелон җибәрдек. Читтә Казан һавасы да тансык *(күлмәк кигәч)*. Йә, килешәме?

Чыңгызхан. Шәп инде, шәп. Алтын Урданың нәрсәсе диден әле?

Таймас. Сулышы.

Чыңгызхан. Анысы кайдан?

Таймас. Һи, барысын да белер иде бугай. Фирма секреты! *(Ботинкасын киеп.)* Йә, ничек? Каблугын биш сантиметрга озынайттырдым!

Чыңгызхан. Егылып төшә күрмә.

Таймас. Кызлар озын буйлы егетләрне ярата, чурт.

Чыңгызхан. Кыз кем диден әле, эшлиме, укыймы?

Таймас. Укый. Татар журналисты булмакчы.

Чыңгызхан. Вәт бахыр!

Таймас. Киеменне алмаштыр! Терәлгән дә тора.

Чыңгызхан. Мин болай да шәп!

*Ишек кыңгыравының тавышы.*

Таймас. Чукынды *(Чыңгызханны Илгизә бүлмәсенә этеп кертә.)* Киенмәдең, хәзер анда утыр инде. Тының да чыкмасын *(шул вакытта кесә телефоны чылтырый)*. Алло! Әйе, Илүсә Робертовна. Сон, эш вакыты бетте бит инде. Әйе... Әйе... Әйе... Илүсә Робертовна! Минем бит һич кичектерүсез очрашуым бар иде, пажалысты. Ә? Ә? Ә? Машина җибәрдегез? Киләм, киләм хәзер... Сау булыгыз. *(Ишекне ача. Илгизә керә.)*

Илгизә. Ә, җыенгансың икән. Чылтыраттыммы? Командировкадан кайтуга сине таптыра башлады. Сагынга-ан...

Таймас. Буржуй ул! Эксплуататор! Эш вакыты беткәнгә ике сәгать. Нинди сүз булырга мөмкин?!

Илгизә. Анда хәлләр! Кайтуга буран куптарды. «Алтын Урда сулышы»на әрем исе кушарга оныткансыз.

Таймас. Ул минем эшме? Минем эш әзер продукцияне олактыру!

Илгизә. Аны беләсең бит...

*Ишек кыңгыравы тавышы.*

Таймас. Хәзер нишлим инде мин? *(Ишекне ача, анда Гөлназ.)* Гөлназ! Бәгырем, килеп тә җиттенме? Әйдә, әйдә, үт.

Илгизә. Бәгырем, йөрәк маем, җан кисәгем... Ай-яй-яй... *(Гөлназ тирәсендә әйләнеп.)* Шушымыни инде синең краля?

Гөлназ *(аптырап)*. Исәнмесез...

*Таймас Гөлназны түргәрәк алып килеп урындыкка утырта.*

Таймас. Гөлназ! Бу минем шофер. Илгиз...

Илгизә. Илгизә!

Таймас. Әйе... Гөлназ, бәгырем. Гафу ит мине, зинһар. Тиз генә офиска барып киләсе бар. Әле генә Япониядән делегация килеп төшкән. Көтмәгәндә. Алар иртәгә генә килергә тиеш иде әле. Ышан син миңа япошкаларга. Контракт янарга мөмкин. Мин иң күп дигәндә бер сәгатьтән бушыйм. Көтеп тор монда гына, ә? *(Киштәдән китап ала.)* Менә Ленинның китабын укый тор. Автограф язып бүләк иткән.

Гөлназ *(аптырап).* Ленинмы?

Таймас. Әйе, Чынгызханга... *(Анга килеп.)* Ә-әй,хе-хе, шаяртам инде. Киттем.Хәзер кайтып житәм.

Гөлназ. Мин дә барыйм. *(Тирәягына карана.)* Шунда гына көтәрмен.

Таймас. Ярамый. Анда чит кешегә ярамый... *(Ашыгып.)* Мин хәзер кайтам, бәгырем. Әле сина дигән бүләгем дә бар. Сюрприз!

Илгизә. Сафсата сатма сана!

Таймас. Бер аягым монда кала! *(Илгизә белән чыгып китәләр.)*

Гөлназ *(узалдына).* Бигрәк сәер шофер... *(Бүлмәне карап әйләнеп чыга.)* Сәер...

*Илгизә бүлмәсеннән Чыңгызхан чыга.*

Гөлназ *(кулындагы китабы төшеп китә).* Абау!

Чыңгызхан *(китапны иелеп ала).* Курыкма, сенелем. Мин кеше ашамыйм.

Гөлназ. Сез кем?

Чыңгызхан *(ни әйтергә белмичә).* Мин... ни... Таймаска кунакка килгән идем.

Гөлназ. Таймас Бүздәктән абый килә, дигән иде. Сезмени ул?

Чыңгызхан. Мин инде ул.

Гөлназ. Мулламы? Анда муллалар шундыймыни?

Чыңгызхан. Мулла ул Бүздәктә дә мулла. Мин әле анда тарих жәмгыятен дә житәклим. Менә Казанда күргәзмә оештырабыз.

Гөлназ. Ә-ә... Мин тагын әллә нәрсә уйлаган идем. Сез күргәзмәгә дип шулай киендегезмени...

Чыңгызхан. Әйе, мин Чыңгыз хан... Үз тарихыбыз белән кызыксыну көчәйде бит хәзер.

Гөлназ. Ә-ә, Лениннан автограф алучы сезмени ул?

Чыңгызхан. Соңгы вакытта ошамый башлады әле ул миңа.

Гөлназ. Таймас монда кайчан күчте соң?

Чыңгызхан. Анысын әйтә алмыйм, сенелем. Сез, яшьләр, өлкәннәргә хисап тотмыйсыз бит хәзер.

Гөлназ. Теге кыз... шофер... Ул да монда торамы?

Чыңгызхан. Әйе, теге бүлмәдә. Ишеген бикләп ята ул.

Гөлназ. Әле генә сез чыккан бүлмәдәме?

Чыңгызхан. Мин анда... ялгыш кергән идем. Килгән кеше бит... белештермим. Ишекләрне буташтырдым... Мин анда бәдрәф дип торам.

Гөлназ. Бәдрәф бу якта.

Чыңгызхан. Әйе... Инде хәзер кирәкми.

Гөлназ. Алай икән... Берегездән берегез сәер.

*(Ни әйтергә белми тынып калалар. Чыңгызхан кулындагы китабын Гөлназга суза.)*

Чыңгызхан. Укырга жыенган идегез, ахрысы.

Гөлназ *(китапны өстәлгә куя).* Көтим микән инде... Әллә китим микән?

Чыңгызхан. Хәзер кайтып житәм, диде бит.

Гөлназ. Сез ишетеп тордыгызмыни? Ишекләрне буташтырып...

Чыңгызхан. Монда бит стеналар юка. Таймасның тавышы әче. Кайчакта Бүздәккә кадәр ишетелә.

Гөлназ. Анда сездән башка туганнары да калмаган бугай.

Чыңгызхан. Әйе, тома ятим ул.

Гөлназ. Ярый абые бар әле. Туганнарсыз кыен бит.

Чыңгызхан. Мине әйтәсезме? Әйе, мин аңа зур таяныч.

Гөлназ. Юк, Мәскәүдәге бертуган абыйсын әйтәм. Генерал абыйсын.

Чыңгызхан. Генаралны? Ә... Әйе шул, генерал. Ул инде иң якын туган. Генерал...

Гөлназ. Аралары якынмы соң?.. Туганнар арасында да төрле хәлләр була. Таймас бит ул артык турыдан яра. Уенда ни булса, телендә шул. Бигрәк хәйләсез.

Чыңгызхан. Шундый ул... Яратасызмы?

Гөлназ. Таймаснымы? И, абый, әллә нинди сораулар бирәсез.

Чыңгызхан. Бик гади сорау. Бик гади нәрсә: йә яратасың, йә юк.

Гөлназ. Ошый ул миңа. Неординарный.

Чыңгызхан. Ул шундый...

*Пауза.*

Гөлназ. Танышып китүебез дә сәер булды. Театрдан чыккач, машина тота идем. Бүтән транспорт йөрми. Безнең өй бит шәһәр читендә. Шуннан бер шәп машина килеп туктады. Таймас өенә кайтып бара икән. Ул чагында шоферы бүтән иде. Нормальный мужик. Таймас шул көнне генә Франциядән кайтып төшкән икән. Алжыган. Алай да, сүз иярә сүз чыгып, таныштык. Өйгә кадәр озатып куйды.

Чыңгызхан. Акча алмагандыр бит. Шоферын әйтәм...

Гөлназ. Сез бигрәк. Дөрес, мин бирергә тырыштым. Таймас ул бик кызык кеше. Кесәсендә акча йөртми. Вак акчаның рәтен дә белми. Гел зур суммалар белән эш йөрткәч... *(Көлеп.)* Вак-төяккә гел миннән алып тора.

Чыңгызхан. Ул шундый... Таркаулыгы да бар — бурычын гел бирергә оныта.

Гөлназ. Аның бит башында мең проблема. Шундый зур фирманы житәкләү җиңел түгел.

Чыңгызхан. Әниең белән танышмы соң ул?

Гөлназ. Ярты еллар элек, беренче тапкыр Америкага барганда, кереп әни белән күрешеп чыкты.

Чыңгызхан. Әниең нәрсә ди?

Гөлназ. Ошатты, ахрысы. Таш яра торган үткен кешегә охшаган, ди. Абый, мине ярәшергә килгәндә болай... Чыңгыз хан булып килмәсәгез иде. Әни бик динле хәзер. Мулла булып килсәгез, эш унар...

Чыңгызхан. Борчылма, сеңлем.

*Ишек кыңгыравы тавышы.*

Әллә кайтты да, ул шундый... *(Ишекне ача.)*

*Илгизә керә.*

Таймас юкмыни?

Илгизә. Кайтмадымы?

Гөлназ. Аны сез алып кайтырга тиештер бит?

Илгизә. Нишләп мин?

Гөлназ. Сез аның шоферыдыр бит?

Илгизә. Ә... Ул соңрак кайтам диде. Банкет анда.

Чыңгызхан. Банкет?

Илгизә. Борчылма, тиздән кайтып керер.

Гөлназ. Сез аны барып алмыйсызмыни?

Илгизә. Ә... Ул мине кайтарып җибәрде. Такси белән кайтам, ә син кайт, ял ит, диде.

Чыңгызхан. Ул шундый. Шоферына бик игътибарлы.

Гөлназ *(күңеле төшеп)*. Мин китим инде. Болай да соңардым.

Илгизә. Нишлисең, кызый, бизнес. Син зерә Таймаска кызыгасың. Таймас Харисовичка димен. Эшкуар ул, гаилә кешесе түгел. Берәр бюджетникны каптыр, гел янында гына утырыр.

Гөлназ. Сез... Сез... *(Ашыгып китәргә җыена.)*

Чыңгызхан. Чү, Илгизә, иплəп сөйләш. Гөлназ Таймасны исәп-хисапсыз ярата.Чын күңелдән. Каккан казыгы булмаса да, аны сайлар иде ул, шулай бит, Гөлназ?

*Гөлназ күз яшенә буылып чыгып китәм дигәндә ишектән Таймас килеп керә. Кулында чәчәк.*

Таймас. Кичер, бәгырем. Тиз генә котылып булмады. Очып кайттым, очып... *(Чәчәк бәйләмен бирә.)*

*Илгизә читкә китеп баса.*

Гөлназ *(чәчәкне алып).* Рәхмәт.

Таймас. Киттек, әйдә! Бүген безнең көн! *(Чыңгызханга ымлап.)* Минем абый бераз сәер кеше. Сөйләштегезме, килештегезме?

Чыңгызхан. Килештек, килештек. Иртәгә мин — мулла!

Таймас *(Гөлназның биленнән кочаклап).* Менә бит, майлаган кебек бара. Киттек, бәгырем! *(Икәү чыгып китәләр.)*

Илгизә *(үчекләгән тавыш белән).* Киттек, бәгырем. Кыланмышын гына кара хәчтерүшнең. *(Йөзен каплап елап җибәрә. Чыңгызханга.)* Абзый! Мин яратам бит шул шамакайны! Ярата идем...

Чыңгызхан *(юатып).* Чү, сеңелем, чү, бетеренмә алай. Син әле... Син әле... Егет солтаның пар итәрсең...

*Ишек кыңгыравы чылтырый.*

Кем йөрер бу вакытта... Кире кайттылармы әллә? Хәзер, хәзер, чичас, чичас *(ишекне ача.)*

*Бусагада Илдар. Ул базык, яшь булса да чәче сирәк — пеләшләнә башлаган.*

Илдар *(Чыңгызханга карап).* Һо-о! Бамбардия! Татарча беләсеңме?

Чыңгызхан. Мин татарча гына сөйләшәм дә.

Илдар *(Илгизәгә).* Сәлам, братан! Нишләп борының кызарды?

Илгизә. Нәрсә кирәк? Хәзер күп сөйләшеп торсаң... ипи шүрлегенә менеп төшәрмен.

Илдар. Син нәрсә, братан?! Килешми. Кайсыгыз монда староста? Менә кәгазь... Мин бу бүлмәгә өченче кеше булып урнашам. Шушымы минем карават? *(Сумкасын өченче ятак өстенә куя.)* Мин — Илдар! *(Чыңгызханга кул бирә.)*

Чыңгызхан. Чыңгыз Ясукаевич.

Илдар *(Илгизәгә кул бирә).* Илдар!

*Илгизә аның кулын бәреп, үз бүлмәсенә кереп китә.*

Чыңгызхан. Илгизә исемле ул.

Илдар. Илгизә? Мин бит аны пацан дип торам. Ха-ха-ха. Менә сиңа мә! Илгизә, дисең, ә! Шайтан алгыры! Экология начар шул хәзер.

Чыңгызхан. Кем дип белик үзеңне? Кайда эшлисең?

Илдар. Әлегә эшсез. Профессиональный эшсез. *(Торып йөренә.)* Биржада торам әлегә. Табылыр эше дә, саулык булсын *(утыра.)*

Чыңгызхан. Тукта, тукта... Тор әле, тор. *(Илдарның йөзен бер яннан, бер алдан карый, читкә китә.)* Охшаган, охшаган. Суйган да каплаган инде. Йөрешеңне генә үзгәртәсе бар. Менә болай... *(Йөреп күрсәтә.)* Ике якка авышыбрак атла. Уң кулың селкенмәсен. Телевизор караганың юкмы әллә?

Илдар. Абзый, син әллә болайракмы *(баш тирәсендә бармагын уйната.)*

Чыңгызхан. Син үзең җүләр. Шундый охшашлык белән... *(Путинча атлап күрсәтә.)* Йәле, кабатла әле. Президент адымы бу!

*Илдар ул кушканча атлый.*

Менә, менә... Хәзер елмай! Тик күзең елмаймасын. Авызыңны гына ер. Яхшы кеше дип уйласыннар. Без синең белән, энекәш, бөтен Азатлык мәйданын яулап алабыз.

Илдар. Ә, аңладым! Син бит Чыңгызхан!

Чыңгызхан. Аңладыңмы? Менә шәп.

Илдар. Син күрсәткән кеше булып кылансам, беләсеңме, мине нишлиләр. Сиңа җинел ул, син моннан мең ел элек яшәгән.

Чыңгызхан. Куркасыңмы?

Илдар. Белмим, сезнең профессия ничек аталадыр. Тик минем өчен түгел ул.

Чыңгызхан. Бер эшнең дә ояты юк. Кеше өлешенә кермибез.

Син сон нинди һөнәр беләсең? Гомер буе эшсез йөрмәссең бит.

Илдар. Мин гомеремне милләтемә багышлыйм! Үземә берни дә кирәкми. Халкым бәхетле булсын!

Чыңгызхан. Милләтче булып эшләргә уйлыйсың инде, алайса. Ул да һөнәр.

Илдар. Һөнәр түгел ул, язмыш!

Чыңгызхан. Белмим, минемчә, һөнәрчеләр генә калды хәзер. Һөнәрчеләр заманы. Милләтчеләр бар, милләт үзе юк.

*Бүлмәсеннән Илгизә чыга. Ул матур күлмәк кигән, бизәнгән, чибәр кыз кыяфәтенә кергән.*

Илгизә. Юкны бушка аударып утырмагыз, зинһар. *(Илдарны култыклап ала.)* Исемең ничек әле?

Илдар. Илдар.

Илгизә. Илдар! Киттек әйдә.

Илдар. Кая?

Илгизә. Ресторанга.

Илдар. Минем бит...

Илгизә. Борчылма, үзем сыйлыйм. Киттек! *(Аптыраган Илдарны алып чыгып китә.)*

**Өченче күренеш**

*Илүсә Робертовнаның кабинеты. Илүсә зур өстәл янында утыра. Сәркәтип кыз тавышы: «Илүсә Робертовна! Сезнең янга бер апа кермәкче була. Мөслимә апа. Сезнең туганыгыз, ди».*

Илүсә. Керсен.

*Мөслимә керә.*

Мөслимә. Әссәламәгаләйкүм, Илүсә. Исән-сау гына яшисеңме? *(Ике кулын сузып күрешергә килә.)*

Илүсә. Ба, Лена Шафиковна! *(Урыныннан торып күрешә.)* Жиңги... Сине күрмәгәнгә инде... Йөз ел бардыр.

Мөслимә. Ильясым үлгәннән бирле күрешкәнебез юк. Килеп тә чыкмыйсың.

Илүсә. Әй, әйтмә дә инде, Лена Шафиковна. Тормыш бит шундый. Мәшәкать өстенә мәшәкать.

Мөслимә. Ташладыгыз жиңгәгезне. Аннары, Илүсә, әйтмә миңа Лена Шафиковна дип. Мин Мөслимә хәзер, Аллага шөкер.

Илүсә. Ишеттем, ишеттем, дин юлына баскансың икән.

Мөслимә. Әлхәмделиллаһи... *(Карана.)* Кабинетың бик затлы. Эшең уңышлы бара, ахрысы. Сөбханалла, шулай булсын.

Илүсә. Жиңги! Вакытым бик тыгыз. Йомышың булса, боргаламый гына әйт.

Мөслимә. Шулай инде... *(Пауза.)* Ахирәттә рәхәтләнеп сөйләшербез, Алла боерса. Ярый инде, мин жиңги генә... Жиде ят. Гөлназның да хәлен белгәнең юк. Ул бит бертуган абыеңның кызы!

Илүсә. Ни булган Гөлназга... Әйбәт кенә укып йөридер бит...

Мөслимә. Аллага шөкер. Күз тимәсен. Тик менә... Кияүгә китәргә жыена. Зур эш бит... Синең белән киңәш-табыш итим мәллә дидем.

Илүсә. Кияүгә... Гөлназ да кияүгә чыга диген. Менә бит, гомер ничек тиз уза... Бәхетле булсын. Туйлары кайчан?

Мөслимә. Иртәгә ярәшергә киләләр. Син дә шунда килеп кияүгә бәя бирсәң, әйбәт булыр иде.

Илүсә. Иртәгә... һым... *(Календарен карый.)* Иртәгә мин бушый алмамдыр. Ну туйга киләм!

Мөслимә. Син бит, Илүсә, бер күрүдә кешене таныйсың. Иртәгә килсәң, әйбәт булыр иде.

Илүсә. Син дә хаклы. Кемне сайлады соң Гөлназ?

Мөслимә. Яшь кенә булса да зур бизнесмен. Персональный машинада йөри. Туйга коттедж да өлгертеп маташа икән. Таш астын-

нан чыккан инде, сөбханалла, күз тимәсен.

Илүсә. Гөлназ акыллы кыз шул. Әтисенә охшаган! Тапкан бит менә әйбәт егет. Андыйларны хәзер көндез чыра яндырып эзлисе.

Мөслимә. Шулай да син дә күреп бәя бирсән, мишәйт итмәс иде. Абыеннын кызы бит, жиянен. Уйлап карасан, анардан да якын туганын да юк бит.

Илүсә. Ярар, ярар, булды. Тиз генә килеп китәрмен. Тәк... Башта Гөлназнын үзе белән сөйләшеп алырга кирәк. Чылтыратып әйт әле, хәзер үк монда килсен.

Мөслимә *(телефоннан чылтыратып)*. Гөлназ... Саумы, кызым? Мин әле Илүсә апаннын кабинетында утырам. Хәзер үк монда кил әле. Әйе, хәзер үк! Адресымы?

Илүсә. Мөштәри урамы, унДүртенче йорт.

Мөслимә. Мөштәри урамы, йорт нумеры 14. Тоткарланма.

Илүсә *(урыныннан торып)*. Ярар, сау бул, жинги...

Мөслимә. Кызым белән бергә кайтып китәрбез дигәнием.

Илүсә. Юк, безгә икәүдән-икәү генә сөйләшергә кирәк. Житкән кызнын әнисеннән дә яшерен серләре була.

Мөслимә. Миннән яшерен сере юк анын! Ул әтисеннән биш яшьтә калды. Үзен кеше иткән әнисеннән нинди сере булсын ди?! Мина охшаган ул!

Илүсә. Дөнья бу, жинги. *(Мөслимәне житәкләп, ишеккә алып бара.)* Иртәгә сездә сөйләшеп бетерербез. Егет син сөйләгәнчә булса, озак уйлап торасы түгел. Әйтәм бит, андыйлар аяк астында аунап ятмый. Хәзер бит, үзен беләсен, чын ир-егетләр аз. Әнә бездә бер мәми авыз эшли. Теле белән тегермән тарта, кулыннан бер эш килми. Коточкыч ялганчы. Менә бүген дә эштә юк. Сонгы тапкыр сөйләшәм дә, кумыйча булмас эштән *(ишекне ача, сәркәтип кызга.)* Теге балаболка килмәдеме әле?

*Сәркәтип кыз тавышы: «Чылтыратты, биш минуттан килеп житәм, ди. Өйләнеп йөри икән ул, Илүсә Робертовна.»*

Илүсә. Менә, ишеттенме, жинги, шул эшлексез дә өйләнә, ә?! Кулыннан бер эш килми, ә өйләнә. Нинди бәхетсез кызны эләктергәндер. Шалапай. Күрсәтәм әле мин ана туй, килсен генә. Ярый Гөлназ шундый әтрәк-әләмне сайламаган. *(Сәркәтип кызга.)* Ләйсән! Тиздән минем сеңелем килергә тиеш, туры мина керсен.

Мөслимә. Алла сакласын, Алла сакласын.

Илүсә. Сау бул, жинги.

Мөслимә. Рәхмәт, жаным. Туганнар кирәк шул, кирәк. Ике бармак арасына ит үсми *(китә.)*

Илүсә *(үз-үзенә)*. Туганнар искә төшкән.

*Сәркәтип кыз тавышы: «Илүсә Робертовна, Таймас килде.»*

Илүсә. Керсен!

*Таймас керә.*

Таймас. Исәнмесез! Чакырган икәнсез, Илүсә ханым.

Илүсә. Син нигә эштә юк? Кайда йөрисен син?

Таймас. Илүсә ханым! Әйтсәм ышанмассыз да, гаҗәп бер эш килеп чыкты бит әле. Болай булса...

Илүсә. Әйтмә дә, ышанмыйм да... *(Торып йөренә.)* Син мина турысын әйт: син чыннан да бераз жинелрәкме, әллә кыланасын гынамы?

Таймас. Авырлыгым житмеш сигез килограмм!

Илүсә. Башынны жүләргә салма. Менә нинди саяк-сандырак яшьләр килде, акылыннан шашарсын, билләһи. Ахырзаман! Болардан нинди ир чыга? Иртән мыш-мыш килеп носкиларын эзләүче, бәдрәфкә керсә, унитазга туры китерә алмаучы мәхлуклар басты дөньяны. Вакы-

тында эшкә килмисен, килсән, интернетны чүплисен, телефоннан төшмисен. Кемнәр белән генә сөйләшәсең син? *(Өстәлдән кәгазь алып селки.)* Менә күпме түләргә килгән! Эш хакыңнан тотып калам.

Таймас. Сөйләшмичә генә клиентлар табып булмый.

Илүсә. Кайда соң ул синең клиентлар?

Таймас. Австралиядән Садри әфәнде килгән. Әле шуның белән сөйләшеп кайттым. Бик зур партия заказать итте. Контракт төзисе генә калды.

Илүсә. Сөйләмә! Туйдым мин синең ялганнарыңнан. Гарык! Син! Эшлексез бер бәндә. Нишләтергә инде сине, ә! Куып чыгарсам, кая барасың инде син? Хәер сорарга туры килә бит. Телең телгә йокмый, бәлки әйбәт хәерче чыгар иде синнән?

Таймас. Илнең яртысы хәер теләнә. Кем урамда кулын сузып, кем түрәләргә хатлар язып, проектлар тәкъдим итеп.

Илүсә. Әле өйләнергә йөрисең икән. Кемнең генә газиз баласын бәхетсез итәсен, ә?

Таймас. Ул минем белән бәхетле булачак! Туйда сез түрдә утырырсыз инде, Илүсә ханым. Сез бит минем әни урынына калган кеше.

*Гөлназ ачык ишектә пәйда була. Илүсә белән Таймас аны күрми.*

Илүсә. Житте! Соңгы тапкыр кисәтәм! Теленне чарлама да, мин сине үтәли күрәм.

Таймас. Илүсә ханым...

Илүсә. Бүлдермә! Йә син тәртибеңне үзгәртәсең, йә — әнә ишек. Мин синең әниең урынына калмаган. Әрәмтамак асрап ятмам. Син бит эшкә килгәннән бирле трай тибәсең.

Таймас. Илүсә ханым. Зинһар, тыңлагыз...

Илүсә. Тик тор! Мин әйтәсен әйттем. Кинәшем шул: өйләнмә! Кемнеңдер баласын бәхетсез итмә.

*Гөлназ йөзен каплап чыгып йөгерә.*

Таймас. Ничек өйләнмисен, Илүсә ханым. Соң инде хәзер. Балага узды.

Илүсә. Нәрсә-ә?

Таймас. Ә сез мине булдыксыз дисез.

Илүсә. Оятсыз! Жир бит! Бар, кайтып кит. Бар! Күземә күренмә.

Таймас. Китәм, китәм.

*Таймас чыгып китә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Дүртенче күренеш

*Фатир бүлмәсе. Таймас компьютер каршында утыра. Интернетта skype аша төрекчә сөйләшә: «Әвәт. Чук гүзәл һавадыр». «Изге Болгар рузгәрләре». Болгар герекли диил? «Күк түрк динлекмеси» вар. Тәшәккүр идәрем.»*

*Ишек кыңгыравы тавышы. Таймас ишек ача. Гөлназ керә.*

Таймас. Гөлназ! Кер, әйдә. Гомерең озын булыр. Сине генә уйлап тора идем.

Гөлназ *(төксе)*. Алай үзенне тинтерәтмә.

Таймас *(кочакламакчы)*. Нинди черки тешләде кәләшемне? *(Житдиләнеп.)* Берәр нәрсә булмагандыр бит? Мөслимә апаның хәле әйбәтме? Кәефе яхшымы? Тиздән бит ул әби булачак. Минем әби!

Гөлназ. Бездә кияүләр хатыннарының әнисенә әни диләр.

Таймас. Аңа гына калса... Үз әнием бит вафат. Мөслимә апага рәхәтләнеп әни диярмен. Әйдә, уз әле.

Утыр. *(Урындыкка утырта.)* Ничек болай күтмәгәндә?.. Юк, мин сине һәрвакыт көтәм. Азга гына аерылышканда да син һәрвакыт күңелемдә.

Гөлназ. Мин дә шулай...

Таймас *(кочакларга теләп)*. Гөлназ, жаным. Мин сине шундый яратам. Яратам! Яратам! *(Үпмәкче була.)*

Гөлназ *(читкә этеп)*. Таймас! Килешкән идек бит. Сузылма миңа. Сабырсызланма, озак калмады.

Таймас *(читкә китеп)*. Менә шундый булган өчен тагын да ныграк яратам да инде сине, Гөлназ. Шикләнеп тә куям: бер елга якын йөрибез — җүнләп үбешкәнебез дә юк.

Гөлназ. Әйттем бит инде: андый кыз кирәк булса, минем янда йөрмә.

Таймас. Шулай! Дөрес! Их-х... ну без яшәрбез, Гөлназ. Шундый итеп яшәрбез, име, шундый итеп яшәрбез...

Гөлназ *(ирония белән)*. Коттеджың туйга өлгерәме соң?

Таймас. Өлгерергә тиеш. Әз генә калды. Проблема юк. Туйга өлгермәсә дә без бәхетле. Нәрсә диләр әле? Гашыйкларга шалашта да шәп, диләрме? Дөресен әйткәндә, Гөлназ...

Гөлназ. Дөресен әйткәндә, Таймас, озак кына уйладым-уйладым да... Бәлки безгә туйны кичектерергәдер?

Таймас. И, акыллы да инде син, Гөлназ. Кичектерик соң, нигә кичектермәскә?

Гөлназ. Бер-беребезне яхшырак белергә кирәк безгә.

Таймас. Кеше бер-берсен беркайчан да төбенә кадәр белеп бетерми. Ир белән хатын булгач та бер-беребезне озак өйрәнербез әле. *(Жанланып.)* Чыннан да, кышка табарак үткәрсәк туйны, ә? Кыңгыраулар таккан атлар жигеп, кар бураннары туздырып...

Гөлназ. Хыялый син.

Таймас. Юкса машиналарда урамны кем дә әйләнә. Кырык, илле, житмеш машина. Ничаклы күп, туй шулкадәр шәп, янәсе. Бу бит ахмаклык!

Гөлназ. Дөрес, нигә ул машиналар...

Таймас. Иң мөһиме, никах. Менә, Алла боерса, Мөслимә апаның... әнинең фатихасы белән никахлашырбыз да... Әйе, туйны кайчан үткәрсәк тә ярый.

Гөлназ. Никахны да кичектерергә кирәк...

Таймас *(тавышы үзгәрә)*. Гөлназ! Нәрсә булды?

Гөлназ. Булмады. Киңәш-табыш итәм бит.

Таймас. Киңәшле эш таркалмас дисеңме? И акыллы да инде син, Гөлназым. Юк, никахны кичектермибез. Ул бит бездән генә тормый.

Гөлназ. Кемнән тора тагын?

Таймас. Никах күкләрдә укыла диләр. Анда инде фәрештәләр укырга әзерләнгән, тәһарәт алганнар. Ә без тотабыз да — бац! — кире уйлыйбыз. Аларга бу ошамас.

Гөлназ *(көлеп җибәрә)*. Җүләр син.

Таймас *(Гөлназны кочаклап күтәрә дә бер урында әйләнә)*. Әйе, җүләр! Җүләр! Көл, көл, бәгырем, турсаеп утыру сиңа килешми. Гөлназ, мин бит сиңа бик нык ышанам. Безнең арада бер сер дә булырга тиеш түгел, шулай бит? Без бер-беребезгә тырнак очы кадәр дә ялганларга тиеш түгел, шулай бит? Менә мин дә... әйтәм, теләсәң нишләрсең...

*Ишек кыңгыравы тавышы.*

Әйе! Кем йөри инде *(ишекне ачарга китә.)* Кем ул?

*Чыңгызхан тавышы: «Мин.» Таймас ишекне ача, Чыңгызхан керә. Ишектән керүгә ыңгырашып идәнгә ава.*

Таймас. Менә сиңа туй бүләге. *(Чынгызханны күтәреп, караватка илтеп яткыра.)* Тар-мар иткәннәр.

Чыңгызхан *(ыңгырашып)*. Изеләр.

Таймас. Сталинмы? Барып иманын укытам, ант әгәр.

Гөлназ. Кем дисең?

Таймас. Сталин! Бандит.

Чыңгызхан. Яра-амый.

Таймас. Дөрес әйтәсең, ментларга хәбәр итәргә кирәк.

Гөлназ. Чыңгызхан абый, хәзер су алып керәм. *(Аш бүлмәсенә чыга.)*

Чыңгызхан. Сталин белән без хәзер дус. Лениннар белән дә сүз килә.

Таймас. Соң, кем кыйнады, алайса?

Чыңгызхан. Ике ыспай егет килде дә... Алар йөзгә сукмый, бавырга бәрәләр... Бәгырьгә...

Таймас. Ни өчен? Бер дә юкка кыйнап киттеләрме?

Чыңгызхан. Яныйлар. Тагын монда йөрсәң, үтерәбез, татарская морда, диләр.

Таймас. Ярар, шыпырт.

*Гөлназ керә.*

Гөлназ. Мә, Чыңгызхан абый, су эч *(су бирә.)* Җиңел булып китәр.

Чыңгызхан *(эчә)*. Рәхмәт. Рәхмәт, сеңлем. Сезгә караган саен күз куана. Бигрәк пар килгәнсез.

Гөлназ. И инде...

Чыңгызхан. Әйе, әйе. Иртәгә ярәшергә барам, Алла боерса. Баш кода булам. Чистарынып, госел коенып... Изге эш, бик изге эш...

Таймас *(Гөлназга)*. Менә күрдеңме?

Гөлназ. Белмим инде. Бөтенләй башым катты.

Чыңгызхан. Бәхетле булыгыз, балалар. Миннән фатиха. Иннә лиләйһи вә иннә иләйһи рәҗигун.

Таймас *(Гөлназга)*. Менә күрдеңме?

Гөлназ. Ярар, кайтыйм мин, әни анда көтә-көтә көтек булгандыр. Ул инде бүген үк табын әзерли башлады.

Таймас. Менә әйбәт. Машина белән озаттырыр идем дә... Төркиядән бер дус килгән, шуңа биргән идем.

Гөлназ. Борчылма, мин машина белән.

Таймас. Машина белән?

Гөлназ. Әйе, машина алдык кичәгенәк.

Таймас. Менә шәп булган! Нинди марка?

Гөлназ. Әллә тагын... Чит илнеке инде.

Таймас. Әйдә әле, әйдә, чыгып карыйм әле.

*Кыңгырау чылтырый. Таймас ишек ача.*

*Илгизә керә.*

Илгизә. Салют, Чыңгызхан абый. Авырыйсыңмы әллә? Бик иртә кайтып яткансың... (Таймас белән Гөлназны күрмәмешкә салынып үз бүлмәсенә үтә башлый.)

Гөлназ. Исәнме, Илгизә.

Илгизә. Исәнлегемнән зарланмыйм.

Таймас. Нәрсә турсайдың, Илгиз?

Илгизә. Ничә тапкыр әйттем, мин сиңа Илгиз түгел! Илгизә мин, аңладыңмы, Илгизә!

Таймас. Аңладым, аңладым *(Гөлназга.)* Әйдә, Гөлназ, әйдә, машинаны карыйк *(Гөлназны өстерәп диярлек алып чыгып китә.)*

Илгизә *(кычкырып кала)*. Йөгер, йөгер! Бай кызлары шулай йөгертә.

Чыңгызхан. Алай итмә, сеңлем. Сиңа килешми.

Илгизә. Син дә сару кайнатма әле... Иш ишен тапкан. Ике аферист.

Чыңгызхан *(торып утыра)*. Нинди аферист булыйк инде без? Без — җәмгыять корбаннары.

Илгизә. Эшләмичә ашарга өйрәнгәннәр. Гел сүз, гел сүз. Ә кулдан бер эш килми.

Чыңгызхан. Сүз иң зур эш инде ул. Әле аңламыйсың син. Барысы да сүздән башлана.

Илгизә. Ә төгәлләргә безгә каламы? Ярар, юк белән минем дә башны катырма әле. Илдар күрендеме?

Ч ы н г ы з х а н . Күренми нигәдер. Эш эзләп йөридер.

И л г и з ә . Менә аңа чын эш кирәк. Ул сезнең кебек сүздән бозау имезми.

*Таймас керә.*

Т а й м а с . Илгиз-ә! Син нигә алай тырт-пырт? Гөлназ алдында авторитетны төшерәсен.

И л г и з ә . И хәчтерүш! Авторитет дигән була бит әле. Без капчыкта ятмый. Ялганың ачылгач, нишләрсең? Артына тибеп чыгарырлар бит. Ай-яй-яй, кара инде син аны *(атлап күрсәтә.)* Нәчәлник булып уйный. Бизнесмен! Ыштансыз килеш.

Т а й м а с . Менә күрерсең...

И л г и з ә . Нәрсә күрәм? Алдакчыны күрәм. Хатын-кыз дисәләр, күзебашы тона. Юк, аңа бай кызы кирәк. Үзенен борын астын белми... Алдакчы! Алдакчы! Яшь гомерем әрәм булды.

Т а й м а с *(гажәпләнеп).* Синен?

И л г и з ә . Әйе, әйе. Ташларга булгач, нигә өметләндерәсен?

Т а й м а с . Мин?

И л г и з ә . Әле бер атна элек кенә «күзен зәңгәр икән», — дип авыз суын корыттың. Оныттыңмыни?

Т а й м а с . Күзең зәңгәр булгач...

И л г и з ә . Зәңгәр шул. Күзгә карамаган кеше аның төсен кайдан белсен?

Т а й м а с . Илгизә, без бит дуслар.

И л г и з ә . Дусларның күз төсен тикшереп утырмыйлар. Аның өчен күзгә күз карашып торырга кирәк. Күнеле йомшак дигәч тә... *(Еламсырый.)* Кыз баланы рәнжетеп... Гонаһын кая куярсын, шулай бит, Чыңгызхан хәзрәт?

Ч ы ң г ы з х а н . Кызларның күнелен күрергә кирәк, дигән китап.

И л г и з ә . Дөрес! Ә син, өч ел күрше яшәп, ресторанга алып бардыңмы мине? Театрга? Чәчәк бирдеңме? Юк та юк инде. Күнел өчен бер тапкыр ишегемне дә шакып карамадың...

Т а й м а с . Илгиз... ә! Тукта әле...

И л г и з ә . Менә Илдар — егет дисәң дә егет. Кичә үземне ресторанга алып барды. Сыйлады. Янымнан баруларын күрсәң... Жентельмен! Ниләр генә юк иде өстәлдә. Ул кайберәүләр кебек саран түгел шул.

Т а й м а с . Кем инде ул саран?

И л г и з ә . Нишләп мин теләсә нинди гауна белән тел әрәм итеп торам соң? Илдарым кайткан төшкә чәй куйыйм әле *(аш бүлмәсенә чыга.)*

Т а й м а с . Менә сиңа мә...

Ч ы ң г ы з х а н . Хатын-кызлыкны чалбар төбенә яшереп булмый шул...

Т а й м а с . Соң... мин аны... *(Сүзен бүлеп кесә телефоны чылтырый.)* Гөлназ?! Алло, алло! Ә? Кем бу? Нәрсә? Аварияга эләкте?

*Илгизә керә.*

*(Югалып кала.)* Ничек бәрелде? Кайда? Гарифьянов урамы? РКБга? Хәзер килеп житәм... *(Ишеккә ташлана.)* Гөлназ бәрелгән...

И л г и з ә . Тукта! Икәү барабыз.

*Икәү чыгып китәләр. Чыңгызхан торып аксый-туксый тәрәзәгә бара.*

Ч ы ң г ы з х а н . Идрит-кудрит! *(Йодрыгын селки.)*

**Бишенче күренеш**

*Шул ук бүлмә. Илгизә киенгән-ясанган, ниндидер жыр көйләп, бүлмәдә йөри. Илдар караваты янындагы тумбочка өстенә чәчәк бәйләме куя.*

И л г и з ә . Менә шулай. Хуш ис кенә бөркелеп торсын әле үзенә. *(Көйли.)* Илдарым, Илдарым, мәнгелек син ярым. Нигә сон монарчы белмәдем син барын... *(Үз бүлмәсенә кереп китә.)*

Ишекне үз ачкычы белән ачып, Илдар кайтып керә. Ул кучер киемендә. Керүгә ялт-йолт карана да Чыңгызханның караватъ астыннан чемоданын тартып чыгара. Ачып тенти башлый.

Илдар *(үзалдына).* Берни дә юк. Хәйләкәр! *(Чемодан кесәсеннән визиткалар тартып чыгара.)* Орхан Памук... Төрек. Харуки Мураками. Япон. Менә бит! Чит ил шпионы бу тучны. Бәхәссез. Мин сон тикмәгә шикләнәммени инде. *(Визиткаларны кесәсенә шудыра.)* Чыңгызхан булып кыланып, мәйданда информация җыя, сволочь. Казанның йөрәгендә! Әле ул бәлки революция ясарга задание алгандыр?!

*Илгизә чыга.*

Илгизә. Нишлисең син?

Илдар *(югалып кала).* Мин? Нишлим?

Илгизә. Әйе, син! Нишлисең?

Илдар *(тынычланып).* Күрмисеңмени, Чыңгызханның чемоданын карыйм.

Илгизә. Күрәм. Син шундыймыни? Ә-әх *(кулын селти.)*

Илдар. Тукта әле, кызма. Карак түгел мин. Чыңгызхан миннән бер китап алып торган иде. Өстәлдә юк, киштәдә юк. Чемоданына салмаган микән дип караган идем. Син инде бигрәк. Чыңгызханның урлардай нинди әйбере булсын?

Илгизә *(бераз икеләнеп).* Чыннан да... Мин әллә ни уйлап бетердем. Шулай да кеше чемоданын актарырга ярамый инде.

Илдар. Юкка бәйләнмә! Берни юк анда. *(Чемоданны ябып, караватъ астына шудыра.)*

Илгизә *(тәмам тынычланып).* Ә син бүлмәдә берәр үзгәреш сизәсеңме?

Илдар *(як-ягына каранып).* Бернинди үзгәреш юк. Чыңгызханның аяк исе дә таралып бетмәгән.

Илгизә. Син яхшырак кара.

Илдар *(ниһаять, чәчәк бәйләмен күреп).* Ә-ә, чәчәк. Син куйдыңмыни?

Илгизә. Кем булсын тагын?

Илдар *(Илгизәгә текәлеп).* Кара әле, нигә син болай киенден?

Илгизә. Матурмы? *(Итәген тотып әйләнә.)* Ошыймы сиңа?

Илдар. Ошамый.

Илгизә. Ошамый? Ә син үзең? *(Илдарның киеменә ымлый.)* Нигә болай клоун кебек киенден?

Илдар. Эшкә урнаштым мин

Илгизә. Болай киенеп кайда эшлиләр инде?

Илдар. Кучер. Үзәктә шәп фаэтон җиккән пар атны күргәнең бармы? Кузласында хәзер мин утырам!

Илгизә. Кучер? *(Көлеп җибәрә.)* Алайса, без икебез дә кучер. Мин машинада, син атта.

Илдар. Фаэтонга утыру ул, братан... Машина гына түгел. Беләсеңме, минем пассажирлар кем? Чит ил туристлары! Ә байлар хәзер фаэтонсыз туй да үткәрми. Модасы шундый. Шуннан чамала инде.

Илгизә. Ничек эләктердең соң андый төшемле урынны?

Илдар. Биржада тәкъдим иттеләр.

Илгизә. Ай-яй...

Илдар. Теләсә кемне алмыйлар, әлбәттә. Академия бетерергә кирәк.

Илгизә. Академия?!

Илдар. Әйе, ветеринарный... Кара син *(Калын олтанлы ботинкасы белән нык басып атлап китә.)* Шәп бит! Кара эшләпәне! Кучер түгел, маршал! Ә син кызларча киенмә. Килешми.

Илгизә. Нигә килешмәсен? Бик шәп күлмәк. Беләсеңме, күпме тора? Француз кибетеннән алдым... Әни күрсә, әй сөенер иде. Юкса минем малайлар кебек йөрүемә гел хурланды. Гел бәйләнде. Шуңа чыгып киттем дә мин өйдән.Үз көнемне үзем күрәм, дидем. Нәрсә,без,кызлар, сездән ким мәллә? *(Пауза.)* Кайтып күренергә кирәк әле әнигә. Шушы күлмәкне киеп. Шаккатсын бер. Әйдә, бергә кайтабыз!

Илдар. Кая?

Илгизә. Чаллыга. Булганың бармы? Без «Түбәтәй» янында гына

торабыз. Бергә кайтсак, әнинең күңеле булыр иде. Минем бит беркайчан да егетләр белән йөргәнем булмады.

Илдар. Кит әле! Син кызмыни? Чып-чыны?

Илгизә *(итәген тотып әйләнә).* Әйт инде дөресен. Күлмәгем матурмы?

Илдар. Болай һәр кыз киенә ала. Син мина элеккечә ошыйсың. Бар, элеккечә киен.

Илгизә *(ялварулы).* Илдар...

Илдар. Бар, бар, чалбарыңны ки, футболкаңны... Чәчеңне яткырып тара... Шулай син оригинальный.

*Илгизә теләр-теләмәс бүлмәсенә кереп китә.*

Илдар *(кесәсеннән чыгарып Чыңгызханның визиткаларын карый).* Их-ма, ай да Илдар, ай да сукин сын! Шпион тоту ул уен-муен түгел. Котларга кирәк үземне моның өчен. *(Илгизә бүлмәсенә кереп китә.)*

*Чыңгызхан кайтып керә. Ул кызмача. Өстәлгә коньяк куя, азыктөлек тезә.*

Чыңгызхан. Котларга кирәк үземне! *(Коньякны ачып йомрыга коя. Эчә.)* Их! *(ике кулын өскә күтәрә.)* Йа Тәңре! Йа Зәңгәрдән дә Зәңгәр Күк! Ярлыка мине! Гаярьлек камчысын сабырлык сандыгына салып куйдым.

*Чалбарын рәтләп, күрше бүлмәдән Иллар чыга.*

Илдар. А, Чыңгызхан хәзрәтләре! Кайтып безне бәхетле иттең. *(Өстәлне күреп.)* О-о, нинди хөрмәткә бу?

Чыңгызхан. Булды хәлләр. Без, энекәш, андый-мондый гына түгел. Без тарихны... Тарихны бар иткән кешеләр.

Илдар. Ана беркем шикләнми. Йә, ни булды?

Чыңгызхан. Кил өстәл янына. *(Коньяк суза.)* Мә, дөңке!

Илдар. Яшәсен Чыңгызхан! *(Эчеп куя.)*

Чыңгызхан. Әйбәтме?

Илдар. Инде.

Чыңгызхан. Сине танырлык та түгел.

Илдар. Эшкә урнаштым. Пар ат жиккән фаэтон күргәнең бардыр. Дилбегәсе минем кулда.

Чыңгызхан. Күчер һәрвакыт алда утыра.

Илдар. Чумара әйбәт төшә. Тик... безнең байлар саран. Тьфү. Ә менә чит ил туристлары! Чәйлексез калдырмыйлар.

Чыңгызхан. Котлы булсын. Әйдә, тагын берне. Син ашап эч.

*Эчәләр.*

Илдар. Безнекеләр саран... Юкса бит тиктомалдан баедылар.

Чыңгызхан. Әйдә, манчы!

Илдар. Тукта! Синең нинди бәйрәм?

Чыңгызхан *(кыстый).* Әйдә әле, әйдә әле. Жиппәр.

*Эчеп куялар.*

Илдар *(исерә төшеп).* Әйбәт утырабыз, име? Әйбәт. Гел туйга чакыралар. *(Блокнотын чыгара.)* Монда ике ай элек язып куелган. Туйда әйбәт тама. Салгач, безнең татар да юмартлана.

Чыңгызхан. Дингез тубыктан.

Илдар. Йә, әйт, ни булды?

*Илгизә чыга. Джинсы кигән, өстендә футболка.*

*(Илгизәгә.)* Менә бит! Нинди шәп син. Кил монда!

Чыңгызхан. Әйе, Илгизә, кил, ризыгыбызны бүлеш.

Илгизә. Син бит хәзер пачти мулла. Килешми, килешми, Чыңгызхан абзый.

*Илгизә алар янына утыра. Утыр-*

*ганчы Илдар аның күтен чәбәкләп ала.*

Илдар. Их! Шәп бит!

Илгизә. Нишлисең син?

Илдар. Әйбәт! Коньяк та шәп. Чыңгызхан Ясукаевич! Син кин күңелле, юмарт кеше икән...

Чыңгызхан. Теге ике ыспай егет тагын килделәр бит.

Илдар. Кит аннан!

Чыңгызхан. Күренүләре булды, без тезелеп бастык. Мин, ике Ленин, өч Сталин. Шаярма-а безнең белән.

Илдар *(бармакларын бөгеп саный).* Ике Ленин, өч Сталин... Кыйнадылармы алтыгызны да?

Илгизә. Кыйналган кеше куанычтан коньяк күтәреп кайтамы?

Чыңгызхан. Борылдылар да киттеләр. Көлә-көлә...

Илдар. Мин сине яратам бит, Чыңгызхан Ясукаевич! Мин сиңа яхшылык кына телим. Үзең өчен әйтәм: кит син мәйданнан!

Илгизә. Нигә китсен ул? Ыбырчыбырдан куркып.

Илдар. Син тыгылма! Эч!

Илгизә. Илдар...

Илдар *(Чыңгызханга).* Яхшы чакта ташла бу эшеңне, әйе. Кайтканда башыңа кирпеч төшәргә мөмкин. Йә машина астына эләгерсең... Алар тагын сары йортка ябарга ярата. Ә? Чыннан да син шуннан качмадыңмы? Чыңгызхан! Ә мин Наполеон. Ха-ха-ха...

Илгизә. Ял итеп ал, Илдар...

Илдар. Тыгылма, дим! *(Чыңгызханга.)* Мин дә бит татар. Аңлыйм сезне. Ну инде шпионаж... Бу инде... бу инде. Йә, күпме түлиләр сиңа чит илдәге хуҗалар?

Чыңгызхан *(Илгизәгә).* Ни сөйли ул?

Илгизә. Илдар, ятып тормыйсыңмы?

Илдар. Бар әле, кер үз бүлмәңә! Ә болар нәрсә? *(Кесәсеннән визиткалар чыгара.)* Резидентлармы?

Чыңгызхан. Ахмак!

Илдар. Син! Сатлыкҗан! Без немец фашистларына каршы кан койганда, син кайда идең, ә? *(Исерек.)* Төркия шпионы! *(Калкына.)* Мин, беләсеңме, кем? *(Кесәсеннән таныклык чыгара.)* Күрдеңме? Кара, кара, яхшылап... Контора йокламый! Һәр адымыгыз...

*Илгизә тора да Илдарның аяк астына тондыра. Илдар идәнгә ава.*

Илгизә. Житте сиңа, бук!

*Чыңгызхан Илдарның таныклыгын алып карый.*

Чыңгызхан. Әһә-һәй... менә ул кем икән! Тегеннән... (Илгизәгә.) Кагылмаска иде, буялуың бар.

Илгизә. Буялдым инде. Әйтәм синең чемоданда актарына иде ул.

Чыңгызхан. Хәзер нәрсә инде?

Илгизә. Йөрсен аяк астында буталып. Алардан барыбер котыла алмыйсың...

Чыңгызхан. Син аны яратасың түгелме соң?

Илгизә. Ярата дип... Таймаска үч итеп яратып карадым да... Кешечә түгел бит ул. Гел егетләр киемендә йөрергә куша. Маньяк.

Чыңгызхан. Булыр, булыр. Ни ди? Мине шпион диме? Жинел генә шпион итүләре дә бар. *(Уйланып тора.)* Юк, Чыңгызхан заманы түгел бу! Вакытында китәргә кирәк.

Илгизә *(битараф).* Кая китәсең...

*Кыңгырау тавышы. Илгизә ишек ача. Таймас керә.*

Таймас *(Илдарны күреп).* Ни булды? Нигә бу идәндә ята?

Илгизә. Аяк сөртергә җәйдек.

Чыңгызхан. Менә хатын-кыз, ә?! Файдалана белә.

Таймас. Ишек кырынарак җәяргә иде... *(Илдарны, күтәреп, караватка сала.)* Вәт исерек авыр, әй... *(Ботинкасын салдырып, карават астына шудыра.)*

*Чыңгызхан өстәлне жыештыра башлый, Илгизә ана булыша.*

Илгизә. Чыңгызхан абзый, син дә ял итеп ал...

Чыңгызхан *(Илдарга ымлый)*. Монарга да шулай дигән иден... (*Караватына барып утыра.)*

Таймас. Мин кайтуга өстәл жыештыра башладыгыз.

Чыңгызхан. Син бит эчмисең.

Таймас. Эчмәсәм, ашыйм.

Чыңгызхан. Ашарга ипи белән сало гына. Син бит дуңгыз ашамыйсын.

Таймас. Сиңа да килешми. Мулла буласың бар.

Чыңгызхан. Бетте! Иртәгәдән башлыйм. Мин инде догалар өйрәнә башладым. «Колһуаллаһы әхәд, аллаһы самәд... ләм йәл иде...» иде, иде... Һич кенә дә отып булмый. Әхәт белән Саматны искә төшергәч кенә сеңде монысы....

Таймас. Кәгазьдән карап укырсың.

Чыңгызхан. Безгә килешми... Бүздәкнең атаклы мулласы, шту син. *(Пауза.)* Синең хакка укымый да булмас шул.

Илгизә. Гөлназнын хәле ничек соң?

Таймас. Чыкты бүген хастаханәдән. *(Чыңгызханга.)* Иртәгә, хәзрәт, ярәшергә барырбыз.

Чыңгызхан. Арагызны ачыкларга кирәк сиңа. Чын дөресен әйтеп... Гөлназ акыллы кыз, аңламый калмас. Яратса, кичерер. Яратмаса инде, синен шәп бизнесмен булуыңа гына кызыгып йөрсә, кирәге дә юк.

Таймас. Ничә тапкыр әйтергә жыендым, жае гына чыкмый бит...

Илдар *(төшләнеп)*. Ишетәсенме мине, иптәш майор?

Илгизә. Һы... Майорлар белән саташа.

Чыңгызхан. Төшендә дә эшли.

Илгизә *(Таймаска)*. Тегеннән икән ул...

Таймас. Тегеннән? Нинди тегеннән?

Илгизә *(учын авызына куеп)*. Тегеннән.

Таймас. Ә-ә? Ничек белдегез?

Чыңгызхан. Аңа нигә шаккатасың? Өчәү жыелса, берсе әбәзәтелне тегеннән... *(Чыңгызхан белән Таймас Илгизәгә текәлә.)*

Илгизә. Нигә миңа карыйсыз?

Таймас. Вирусы сиңа да күчкәндер...

Илдар *(төшләнеп тантаналы сөйли)*.

Нет слов таких, чтоб ими передать
Всю преданность нашу на этом пути.
Нет слов таких, чтоб ими рассказать,
Как мы любим тебя, товарищ Путин!

Илгизә. Әллә кемнәр белән сөйләшә...

Чыңгызхан. Ерак китәр бу...

Таймас. Уйлап карасаң, мин Гөлназга ялганламадым бит. Әби патша эштән кумаса, йөз миллионга контракт булачак иде. Ну, ярар. Тиздән үз фирмам булачак. Һаваны мин анардан башка да шәп сатам. Гөлназ анлар. Яратам икән мин аны! Миңа анардан берни дә кирәкми. Йорт та, машина да *(пауза.)* Машинасы — коймак. Төзәтеп булырлык түгел.

*Алар сөйләшеп утырганда ике ак халатлы ир-ат кереп — санитарлар, ахрысы — Илдарны күтәреп чыгалар. Бүлмәдәгеләр моны күрми.*

Илгизә. Ай, онытканмын! Илүсә Робертовна эзли бит сине. Көне буе тинтерәтте. Телефонын жавап бирми.

Таймас. Бер киселгән икмәк кире ябышмый.

Илгизә. Алай димә. Начар кеше түгел Илүсә Робертовна. Тиз кызып китә анысы... Тиз сүрелә дә.

Таймас. Эт итеп сүккәч, аның сүрелүеннән ни файда? *(Пауза.)* Нигә эзли икән сон ул?

Илгизә. Белмим. Ләкин син аңа бик кирәк, ахрысы.

Чынгызхан *(Илдар караватынын буш икәнен күреп ала).* Ә бу кайда соң?

Таймас. Менә сиңа мә...

Илгизә. Чыгып киткәне дә сизелмәде.

Таймас. Бу, малай, чыннан да тегеннән. Күз алдында юкка чыкты. Һавага әйләндеме әллә?

Илгизә. Татар һавасына!

Чынгызхан. Үзебез саташмыйбызмы? Бар идеме соң ул?

Илгизә. Булмыйча... Әнә бит ботинкасы! *(Ишекне ачып карый.)* Яланаяк киткәнме?

Таймас *(ботинкаларны күтәрә).* Авыр.

Чынгызхан. Бәласеннән башаяк, ташла...

*Таймас ботинкаларны тәрәзәдән ыргыта. Анда кемнендер чинап куйганы ишетелә.*

Илгизә *(пышылдап).* Нишләдең, җүләр?

Таймас. Ташла, диде бит.

Чыңгызхан. Тәрәзәдән карамагыз. Без берни белмибез. Берни күрмәдек.

Илгизә. Нишлибез инде хәзер?

Таймас. Бернишләмибез. Безнен ни гаебебез бар?

Чынгызхан. Теләсәләр, алар гаеп таба.

Илгизә *(Таймаска).* Татар һавасын бөтен дөньяга таратып ятучы син түгелме соң? Ә Чынгызхан? Исеме үк куркыныч!

Таймас. Ә син?

Илгизә. Мин шофер гына. Миңа тимәсләр. Мине кыстырмагыз.

Таймас. Ә-һә! Үзе генә чиста калмакчы.

*Ишек кыңгыравы тавышы.*

Чынгызхан. Тсс... Утны сүндерегез!

*Ишекне дөбердәтәләр.*

Илгизә *(пышылдап).* Башыма җиттегез... *(Утны сүндерә дә сак кына атлап үз бүлмәсенә кереп бикләнә.)*

Таймас *(пышылдап).* Нишлибез?

Чынгызхан *(пышылдап).* Без өйдә юк... Без монда түгел...

**Алтынчы күренеш**

*Гөлназлар өе. Йорт җиһазларының егерме еллар элек алынганы күренә. Уртада ризыклар тулы өстәл. Мөслимә белән Гөлназ.*

Мөслимә *(табынга карап).* Булды бугай инде. Күренмиләрме? *(Сәгатькә карый.)* Безнең татар үз вакытында килә белми инде ул.

Гөлназ. Килсәләр, керми калмаслар. Илгизә бушамыйдыр.

Мөслимә. Кем?

Гөлназ. Шоферлары.

Мөслимә. Хатын-кызмыни? Кем хатын-кызны шоферга ала инде? Аның үзен көтәсе була бит. Шаяртасыңдыр?

Гөлназ. Шаяртам.

Мөслимә. Чәйне башта чыгарырбыз.

Гөлназ. Юк инде, әни. Һаман үз ягыңа каерасың. Сезнең якта гына бит ул иң башта чәй эчәләр. Агып киткәнче...

Мөслимә. Ярар, ярар, сезненчә булсын. Шулай да чәй алдан килсә дөрес, аппетитны ача ул. Безнең халыкта гел шулай иткәннәр. Казаннар бит алар йоланы җуйган халык.

Гөлназ. Кемнең арбасына утырсаң, шунын җырын җырлыйсың инде, әни.

Мөслимә. Тоз куйдыңмы? Хәзрәт алдында тоз торырга тиеш.

Гөлназ. Куйдым, куйдым. Хәзрәт бик канәгать калыр.

Мөслимә. Исеме ничек диден әле хәзрәтнең?

Гөлназ. Чыңгызетдин хәзрәт...

Мөслимә. Бәрәкалла... Чын мөселманча икән исеме дә. Юкса хәзер Альберт, Венер исемле муллалар да килеп чыкты.

Гөлназ. Бу инде хәзрәтнең хәзрәте.

Мөслимә. Нәселендә шундый могтәбәр зат булгач, Таймас та игелекле кеше булыр, иншалла. Син больниста ятканда, яныннан китмәде дә бит, рәхмәт төшкере. Кырык эше кырык җирдә кырылып яткандыр. Миллионнар белән эш итәм, диде бит. Әтиең булсамы? Минем янда утырыр идеме? Эш дип җанын бирер иде. *(Пауза.)* Бирде дә... Ә нәрсә калды үзеннән? Менә шушы йорт калды бердәнбер. Миллионнары кая киткәндер, Алла белсен.

Гөлназ. Әни, һаман шул бер балык башын чәйнәмә инде.

Мөслимә. Үткән эшкә салават. Байлыгыбыз булмаса да, нәселебез затлы. Борынгылар әйтмешли, йортыбыз булса да читәннән, сортыбыз бүтәннән.

Гөлназ. Торасың да нәсел, дисең. Ул кадәр кем бар соң безнең нәселдә?

Мөслимә. Безнең тамырлар Юныс морзага барып тоташа. Сөембикә белән бер нәселдән без!

Гөлназ. Әни! Үзең әйтәсең бит: кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә, дип. Зинһар, кунаклар килгәч, нәсел тикшерә күрмә.

Мөслимә. Мактанырлыгым булгач, нигә мактанмыйм? Аллага шөкер, гидайлардан түгел.

Гөлназ. Хәзрәтне шаккатыра алмассың. Ул үзе Чыңгыз хан булган кеше.

Мөслимә. Нәрсә?

Гөлназ *(тәрәзә янына килеп)*. Әнә, килделәр!

Мөслимә *(тәрәзәдән карап)*. Машинасын гына кара син! Ничек килеп туктады. Шуфиры ишекне ача... Хатын-кыз, диден мәле? Әстәгъфирулла... Хәзер хатын-кызны ир-аттан аермалы да түгел.

Гөлназ. Әни, килгән кеше керер. Ашка токмач салыйммы?

Мөслимә. Юк, юк, бераздан... Юкса куерыр. Шундый егет, ә! Япь-яшь башыннан зур нәчәлник. Буе гына бераз тәбәнәк. Хәер, нәчәлник булсаң, килешеп тә тора ул. Әһә, хәзрәт тә төште...

Гөлназ. Тәрәзәгә капланма инде, яхшы түгел.

Мөслимә *(тәрәзә яныннан китеп)*. Илүсә апаң килерме икән?

Гөлназ. Килсә, кызык күрәбез инде.

Мөслимә. Нинди кызык? Кыз ярәшү ул изге йола. Бә-әк борынгыдан калган. Дөресен әйткәнгә ачуланма, елан ул Илүсә апаң. Әтиең үлгәннән соң, бер тапкыр булса да хәлебезне белмәде. Башы-күзе тонган байлык дип...

Гөлназ. Алайса, нигә чакырдың соң?

Мөслимә. Йолабыз шундый. Авызың тулы кан булса да, ят кеше алдында түкермә, ди. Киттем, каршы алам. Син, бар, эчке бүлмәгә кер.

*Гөлназ эчке бүлмәгә кереп китә. Таймас белән түбәтәй кигән, җилән ябынган Чыңгызхан керә. Аның кулында ашъяулыкка төрелгән түгәрәк күмәч.*

Таймас. Исәнмесез, Мөслимә апа! *(Ике кул биреп күрешә.)*

Чыңгызхан. Әссәламәгаләйкүм! Рәхим итеп алыгыз. *(Күмәчне бирә.)*

Мөслимә. Вәгаләйкүм әссәлам! Хуш килдегез, кадерле кунаклар. Түргә үтегез. *(Күмәчне, ашъяулыгын ачып, өстәлгә куя. Аның өстендә тоз да бар.)*

Чыңгызхан. Ни хәлләрдә яшәп ятасыз? Сау-сәламәт кенәме? Йортыгыз бик иркен, бәрәкалла.

Мөслимә. Әйдәгез, дога кылып алыйк.

Чыңгызхан. Ә, әйе шул...

*Утырып дога кылалар.*

Гөлназ кызыбыз өйдә түгелме әллә?

Мөслимә. Өйдә, өйдә. Эчке бүлмәдә. Йола кушканча...

Чыңгызхан. Булмаса, башлыйк. Киләсе кеше юктыр бит?

Мөслимә. Туганыбыз килергә тиеш иде. Каенсенелем. Бераз көтик инде.

Чыңгызхан. Кызыгыз сәламәтләнгән икән. Зур бәладән исән калды, молодец!

Мөслимә. Аллага шөкер.

Чыңгызхан. Чыксын монда. Аның язмышын сөйләшәбез, шәригать шулай куша.

Мөслимә. Шулай дисеңме, хәзрәт? Гөлназ!

*Гөлназ керә.*

Гөлназ. Исәнмесез...

Чыңгызхан. Аллага шөкер. Сеңлем, утыр әле Таймас янына. Шәригать шулай куша.

*Гөлназ утыра. Ни сөйләшергә белми тынып калалар.*

Мөслимә. Таймас улым, теге атнада тагын Америкада булдым, дидеңме әле? Бик еш йөрисең анда да.

Таймас. Эшлекле визит белән барып кайтырга туры килде, Мөслимә апа.

Гөлназ. Чит илләрне төненә өч мәртәбә урап кайта ул.

Мөслимә. Бигрәк тынгысыз эш икән.

Чыңгызхан. Америкада Ислам диненә күчүчеләр күп ди соңгы арада.

Гөлназ. Таймас бик еш барып йөргәнгә күрәдер инде...

Мөслимә. Америкада Татарстан турында беләләрме соң?

Таймас. Беләләр, бик беләләр, Мөслимә апа. Бик хөрмәт итәләр. Хезмәттәшлеккә өмет баглап торалар. Әле Хиллари Клинтонның визитын әзерләп йөрибез.

Мөслимә. Бәрәкалла...

Таймас *(тәмам кызып китә).* Татарстанның иң зур байлыгы — кешеләр, диде Клинтон. Бездәге кебек кешеләр дөньяда юк икән. Америка шаккатып карап тора.

Мөслимә. Машалла...

Таймас. Әйе. Мөселманнар белән керәшеннәр бик тату яши бит бездә. Шуның серен беләселәре килә. Менә шулай гаугасыз да яшәп була икән дип бик кызыгалар. Америкада бит анда гел гауга.

Гөлназ *(ялварулы).* Таймас!

Чыңгызхан. Туганыгызга чылтыратып карагыз әле?

Мөслимә. Һе, ана тиз генә чылтыратырсың. Гел кыска гудоклар.

Таймас. Без башлый торыйк. Соңга калучыны сәгатьләр буе көтеп булмый инде.

Гөлназ. Ул соңга калмый, тоткарлана гына.

Таймас. Ә-ә? Алайса, тагын бераз көтик.

Мөслимә. Көтмибез! Гөлназ, бар, ашка токмач сал. Ә сез, кадерле кунаклар, табынга рәхим итегез.

*Гөлназ чыга.*

Чыңгызхан. Мин инде монда, Мөслимә ханым, үзең беләсең, баш кода булып килдем. Шәригать кушканча...

Мөслимә. Әйе, әйе. Менә монда, матча астына утыр, хәзрәт. Йола шулай куша.

Чыңгызхан. Әһә, мендәр дә куйгансыз.

Мөслимә. Йоласы шундый.

Чыңгызхан *(утырып).* Бисмиллаһи... Менә шул, Мөслимә, сезнең алтыныгыз, безнең көмешебез бар, шуларны бергә кушсак, бик яхшы булыр иде.

Мөслимә. Белмим шул, хәзрәт. Кыз бик яшь бит әле. Ашыкмыйк. Атасының йортында туйганчы яшәсен иде әле бераз.

Таймас. Яшәсен, яшәсен! Минем коттедж өлгергәнче, бергә яшәрбез.

Чыңгызхан. Бүлдермә. Мөслимә ханым! Заманы башка булса да, без инде йола буенча эш йөртик.

М ө с л и м ә. Шулай итик, хәзрәт, йоласыз кеше — юлсыз кеше.

Ч ы н г ы з х а н. Безнең егет әйбәт. Шәп егет! Кулыннан килмәгән эш юк. Үз көче белән шундый дәрәҗәләргә иреште. Кызыгыз да безгә бик ошады. Пар килгәннәр. Икеләнеп торырга кирәкми, ризалык бирегез, Мөслимә ханым, кушылсыннар.

М ө с л и м ә. Ни әйтергә дә белмим инде, хәзрәт. Туганыбыз белән киңәшергә кирәк. Ул ни әйтер? Бик зур урында эшли. Начарга әйтмәс.

Ч ы н г ы з х а н. Анысы шулай. Ләкин бу эштә кеше киңәшенә караганда йөрәккә колак салырга кирәк. Кыз белән егетнең йөрәге бер-берсенә тартыла бит, күрмисеңмени, Мөслимә?

М ө с л и м ә. Йөрәк кушканча гына йөреп булмый шул.

Ч ы н г ы з х а н. Ятим үссә дә, Таймас энебез хәлле кеше, йоланы белә. Менә калымның бер өлешен алып килдек. *(Кесәсеннән акча чыгарып күмәч өстенә куя.)*

*Гөлназ йөгереп керә.*

Г ө л н а з. Килде!

М ө с л и м ә *(тәрәзә янына килеп)*. Килде... Ай эре дә соң... Машинадан төшүен кара... *(Таймаска.)* Машинасы да синекенә охшаган. Әйтәм бит, зур нәчәлник ул. Гөлназ, апаңны каршы ал!

*Гөлназ чыга. Таймас тәрәзә янына килә. Йөзе агара. Йөгереп чыгып китә.*

Ч ы н г ы з х а н. Таймас! Син кая...

М ө с л и м ә. Кунакны каршыларгадыр... Яшь булса да, бигрәк ипле инде. Тәртипне белә.

Ч ы н г ы з х а н. Ул шундый... Туганыгызга ошарга тиеш ул. Исеме ничек әле?

М ө с л и м ә. Илүсә. Илүсә Робертовна.

*Илүсә белән Гөлназ керә.*

И л ү с ә. Хәерле көн.

М ө с л и м ә. Хуш киләсен, туганым. Кадерле кунак булгач, көттереп киләсең.

И л ү с ә. Мулла да чакыргансыз икән *(Чыңгызханга.)* Сәлям алейкум.

Ч ы ң г ы з х а н. Вәгаләйкүм әссәлам. Утырышыгыз, дога кылып алыйк. Бисмиллаһи *(авыз эченнән мыгырдана.)*

*Утыралар, учлары белән бит сыпыралар.*

И л ү с ә. Вакытым бик тар. Кияү буласы егет кайда соң?

М ө с л и м ә. Гөлназ, ашны керт. *(Илүсәгә.)* Сине каршы алмадымыни ул?

И л ү с ә. Юк, күрмәдем. Жиңги, аш ашап тормам инде мин. Бер чынаяк чәй булса, шул җитәр.

М ө с л и м ә. Нәселдә булмаганны... Гомергә бер килеп... Утыр әле бераз. Көне бит шундый.

И л ү с ә. Анлыйм да соң...

*Гөлназ аш кертә. Бүлә башлый.*

М ө с л и м ә (Илүсәгә). Эш ул беркайчан да бетми. Дөнья булгач, ялы да кирәк.

И л ү с ә. Кирәк, кирәк... Таянырлык кешесе юк бит, җиңги. Гел берүзем. *(Чыңгызханга.)* Хәзрәт, син кайсы мәчеттән? Кол Шәрифтәнме? Аның мулласын бик телгә беткән дип сөйләделәр.

М ө с л и м ә. Буздәктән килгән ул. Кияүнең агасы.

И л ү с ә. Кияү, дисең... *(Күмәч өстендәге акчага ымлый.)* Сез инде миннән башка да хәл иткәнсез түгелме соң?

Ч ы н г ы з х а н. Юк, ярәшә генә башладык әле.

И л ү с ә. Гөлназ, кая югалды кияү?

М ө с л и м ә. Сина каршы йөгереп чыкты лабаса. Ходаем, кайда соң ул? Гөлназ, бар әле эзләп кер.

Г ө л н а з. Качкандыр...

Мөслимә. Бу ни дигән сүз инде? Бар, бар, алып кер. *(Илүсәгә.)* Бик оялчан, бик тыйнак егет.

*Гөлназ теләр-теләмәс кенә чыгып китә.*

Илүсә. Үзе бизнесменмы?

Мөслимә. Әйе. Бик зур фирманы житәкли.

Илүсә. Оялчан бизнесмен да була икән... Беренче тапкыр ишетүем.

Чыңгызхан. Безнең Таймас шундый.

Илүсә. Таймас?

Мөслимә. Әйе, Таймас. Исеме шундый.

Илүсә. Фамилиясе ничек?

*Гөлназ керә.*

Гөлназ. Бәдрәфкә бикләнгән ул.

Илүсә. Таймас... Таймас... Кеч-кенә генә буйлымы?

Мөслимә *(ошатмыйча).* Кеч-кенә дип... Кешедән ким түгел инде.

Илүсә. Гөлназ! Алып кер егетеңне! Күрим әле, нинди була икән оялчан бизнесмен!

*Таймас керә.*

Таймас. Исәнмесез, Илүсә Робертовна.

Мөслимә. Һи, сез танышлар икән бит! Иш ише белән йөри шул. Менә нинди шәп булды.

Гөлназ *(ирония белән).* Гаҗәп!

Илүсә. Таймас... *(Көлә.)* Мин бит сине бер атнадан бирле эзлим. Кая югалды дисәм... Югалырсын син! Минем сеңелкәш янына оялаган! Ай, жилкуык... *(Гөлназга игътибар белән карый.)* Сез бит инде бездән башка хәл иткәнсез. *(Бармак селкеп.)* Вәт юньсезләр! Бигрәк өлгер инде хәзерге яшьләр. Артык сизелми әле сизелүен...

Мөслимә. Нигә алай әйтәсен, Илүсә? Нишләп безнен кияү жилкуык булсын?

Илүсә. Ул үзе белә.

Гөлназ. Сүз әйтмәгез ана! *(Таймас янына килеп баса.)* Мин аны шул килеш тә яратам.

Илүсә. Ай-яй-яй *(башын чайкый.)* Хәзер инде яратмыйча ярамый да. Ай Таймас!

Мөслимә. Туктагыз әле, аңлатыгыз миңа! Хәзрәт, кода, ник эндәшмисең?

Чыңгызхан *(жилкәсен жыера).* Ни әйтим? Кыз үзе яратам дип торганда, безнең сүз нәрсәгә?

Гөлназ *(Таймаска).* Жаныем! Үзеңне әлләкем күрсәтеп, шыттырып йөрмәсән дә, яратам бит. *(Кочаклап елап жибәрә.)* Синең хыялый икәнеңне беләм ич мин.

Таймас. Беләсең? Белеп тә сиздермәдеңме?

Илүсә. Житте! Шундый көнне елап торырга... Утырышыгыз әле. Хәзрәт! Эшне бетерик тә, Таймасны мин алып китәм.

Гөлназ. Кая?

Илүсә. Әйтәм бит, мин аны бер атна эзлим инде. Австралиядән килгән эшкуар таптыра. Желегемә үтте. Контрактка Таймастан башка кул куймыйм, ди. Күп миллионлы контракт. Таймас! Кияү! Котлыйм сине *(килеп Гөлназ белән икесен кочаклый).* Икегезне дә котлыйм. Әйдәгез, утырышыйк. Бәйрәм бүген!

Мөслимә *(Чыңгызханга).* Кода, син бирәр нәрсә аңлыйсыңмы?

Чыңгызхан. Башыңны ватма, Мөслимә! Әйбәт бит! Табын түгәрәк, тиздән туй булачак. Жырларбыз, биербез. Рәхәтләнеп күңел ачарбыз. Күп кирәкмени безнең халыкка...

***Тәмам.***



Дания
Нәгыймуллина

# БӘХЕТЕМНЕ СИҢА БҮЛӘК ИТӘМ

## Хыялларсыз

**Балачакны кайтарыгыз димим,
Хыялларым кире кайтсыннар!
Хыял күлмәкләрен киеп карыйм:
Кайсы ертык инде, кайсы тар...**

**Балачакта җылыттылар алар
Ышанучан керсез күңелне.
Хыял белән яшәү авыр дисез,
Ә аларсыз тормыш җиңелме?!**

**Чыныктыра язмыш, оныттыра
Хыялларны, ябып ишекне...
Ә аларсыз көн дә тирбәткән күк
Баласыз буш, ятим бишекне.**

## Тынлыкта

**Юк, дәшмә!
Бозма син тынлыкны,
Ул синең бүләгең.
Кайчандыр
Шул тынлык эчендә калдырдың.
Бәлки мин урынсыз качамдыр
Кояштан,
Үземнән
Тынлыкка.
Хәтерем гөрселдәп аумады
Зәмхәрир кышларда туңып та.
Исемең йөрәктән яу алды,
Дәшәргә уңайсыз шуңадыр.
Гадәткә әйләнде –
Яшьләрем
Һәркөнне битемнән шуадыр.**

---

Дания НӘГЫЙМУЛЛИНА – *яшь шагыйрә; шигырьләре көндәлек матбугатта даими басылып килә. «Иделем акчарлагы» – 2011 бәйгесенең гран-при иясе. Казанда яши.*

Тынлыгым урлама –
Бүләгең,
Тырналган йөрәктән кубарма.
Барысы да яхшы!
Аз гына
Иреннәр чатнаган...
Су бармы?

## Син – тормышның хуҗасы

Син – тормышның тамадасы,
Син аның язучысы.
Син дирижер, сәясәтче,
Син көрәшче һәм сынчы.

Юлың күксел томан сарса,
Беркем маяк тергезмәс.
Начар гамәл кылсаң, беркем
Җаның юып кер элмәс.

Өметең карга әйләнеп
Ятса аяк астыңа,
Кисәк кенә шау-шу тулы
Сөенечле яз тына...

Ләкин мондый хәлгә берүк
Ялгышып та юл куйма!

Кояшлы таңны кемнәрдер
Күрсәләр кара итеп.
Гомерең нурсыз үтмәсен
Намусыңа тап тиеп.

Син – бизәкче, тамашачы,
Син фокусчы, очучы.
Тормышның яңгыр-кояшын
Үз җилкәңдә тоючы.

* * *

Җибәрәм, тоткарлый алмыймын –
Хакым юк.
Көтмимен. «Көт мине» дип язган
Хатың юк.

Күтәрәм башымны, кояшка
Карыймын.
Мин аның нурында эрермен...
Ярыймы?..

Күзләрем кояштан чагыла –
Яшь түгел.
Туйдыра ятларга син диеп
Дәшү гел.

## Аңлый алмыйм

Иркен дибез дөнья... Чиксез дибез...
Чикле ләкин безнең мәрхәмәт.
Йөрәк тибешләрен тикшерегез,
Яши микән әле мәхәббәт?

Кулда каләм... Тырнап-тырнап яза –
Йөрәгемнең ясый сурәтен.
Мин тормышны һаман аңлый алмыйм...
Өйрәтегез, зинһар, җай-рәтен.

Ялантәпи йөрим төн эчендә...
Бәй, миндәйләр монда җитәрлек!
Бердәм булсак, көч тупланыр иде
Сүрән айны кояш итәрлек.

## Икебезгә бер бәхет

Мин шимбәне икебезгә бүләм:
Көне — сиңа, миңа исә төн.
Бәхетемне сиңа бүләк итәм,
Алам, ләкин, нәни кисәген.

Мин төннәрдә калырга да риза,
Янып торсаң күктә ай булып.
Сукмакларны җепләр белән бәйлик –
Китмәсеннәр юллар аерылып.

Бәхет кисәкләрен бергә кушыйк –
Бәхет берләштерсен җаннарны.
Ләкин үрнәк итеп алмыйк, сулар
Кушылдырмый торган ярларны.

## Вакыт сорыйм

Фонарь яктысында урам буйлап
Эзләп йөрдем кичен эзеңне.
Кипми калган яшькә тап булдым мин
Һәм утырдым кочып теземне.

Мин үзгәрдем, әллә заманамы?
Дучар булам тирән уйларга...
Чүл салкыны биләп ала җанны,
Чарасызлык – хәлсез колларда.

Ничә еллар хыял аша сине
Иртә саен эшкә озатам.
Ташка йөзем белән төшкән кебек,
Әрнү хисен һаман кузгатам.

Татлы сагыш дусты итте мине,
Усал эткә бирдем хыялны.
Караңгылык чолгап алган җанга
Йолдыз нуры инде сыярмы?

Күз күлмәгән салмый киям хәзер,
Йөзем охшаш яфрак төсенә.
Кайтмаска дип киткәнеңә уйчан
Учак очкыны да төшенә.

Оч-кырыйсыз күктә очар урын
Таба алмый күңел интегә.
Бүген сине оныта алмадым мин,
Насыйп булыр бәлки иртәгә.

Яшен тизлегенә тиңдәш булган
Вакыт сорыйм сине күрергә.
Кемгә сөю юлламасын бирер
Яңа салган мәрҗән күпергә?



Марат
Әмирханов

# УТЛЫ КАМЧЫ

ХИКӘЯ

*Була күрмә башка һичкемнеке.*
«Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан.

Букча эчендә телефон өзгәләнепме-өзгәләнә. Азга гына тынып ала да янә чырылдарга тотына, март мәчеләрен бер якта торсын!

Дамирәнен генә исе китми. Йомшак кәнәфидә йокымсыраулы ләззәткә талган. Ара-тирә иренеп кенә вак-вак йотым белән сыра эчеп куйгалый, озын бармаклары арасына эленгән сигаретыннан төтен алкалары очыртып ала.

Телефонның да бирешергә исәбе юк. Барыбер үзенекен итте. Кыз, ниһаять, шәмәхә тырнаклы нәфис ак кулын букча авызына шудырды.

Экранда дусты Рәхимә иде. Авызы турсайган, йөзе үпкәле.

– Ә-ә, син икәнсең әле, кызый, сәлам, мин бит Хәниф мүкләк дип торам, – дип акланды Дамирә, – тәмам җилегемә төште.

– Син инде бигрәк, берәү армияга китә...

– Бу хакта сөйләшмибез, бер аягың анда, бер аягың монда, оч минем янга, кәеф корып утырырбыз.

– Мин эштә ич.

– Эшләп кем баеган, берәр калын кесәне йөгәнләргә вакыт.

– Шунын өчен түземсезләнеп шылтыратам да инде, подруга, бер бай абзый тагылды бит әле монда. «Ажаганда» очрашыйк, таныштырырмын.

– Беләсең ич инде, мин төнге клубларны өнәмим.

– Алайса кафеда. Безнең «Чулман су»ыбыз да бар бит әле. Син яраткан милли төплекәй, син яраткан милли музыка...

– Сөйләштек!

Тутый кошларына жим сипкәндә Дамирәнен күзләре тәрәзәгә төште. Һәм шунда ук читкә тайпылды: ишек алдындагы балалар мәйданчыгында сакчы гаскәридәй Хәниф арлы-бирле йөренә иде. Еш-еш сәгатенә текәлеп ала, вакыты тар иде булса кирәк.

– Мүкләк, – дип пышылдады кызның иреннәре, – Альбертка житәме сон?

Хәниф дөрестән дә ашыга иде, нәүмизләнеп янә бер тәрәзәгә карап алды да йөгерә-атлый китеп барды.

---

Марат ӘМИРХАНОВ (1933) — *прозаик; «Таш һәйкәл», «Тәкъдир», «И кылган догам минем», «Дөя муены» һ.б. китаплар авторы. Журнал укучыларына ул тарихи темага язылган «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг» романнары белән таныш. Казанда яши.*

Алар авылда таныштылар. Дамирә җәйге каникулны әнисенең туган авылында үткәрә иде. Әбисенә булыша, каз бәпкәләренә күз-колак була, бәрәңге бакчасындагы чүп үләннәрен утый, су ташый. Эшсез тормый.

Узган ел дустына ияреп Хәниф тә Күзкәйгә кайтты. Бик тиз аралашып киттеләр. Икесенең дә кулында аттестат, икесе дә институтка гариза биргән. Баллары, шөкер, югары. ЕГЭ дигән сират күперен хәвеф-хәтәрсез генә үттеләр.

Кызлар, кагыйдә буларак озын буйлы, пумала чәчле, күперек мускуллы егетләрне үз итә. Мондый егет кәмәшенең сүз кушуы, игътибар салуы үзе бер дәрәҗә. Хәниф нәкъ менә шундый иде. Өстәвенә, күзләре зәңгәр. Бусы да зур плюс.

Дамирә бер сирпелүдә яңа танышына унай бәя бирде. Әлбәттә, егет имидән аерылмаган бозау урынына тагылачак. Монысы да көн кебек ачык. Чөнки аңа һәммәсе кармак салып карый, Хәниф кенә башка камырдан изелмәгәндер, шәт.

Дамирә үзенең әһле тылсым көчен бик яхшы белә иде. Чибәрлеге егылып китәрдәй түгел, анысы хак. Әмма искиткеч мөлаем: каен яфрагыдай озынча-түгәрәк күзләре мөлаем, бөрлегәндәй мәмрәп торган алсу иреннәре мөлаем, ияк уртасындагы мәхәббәт уемы мөлаем, нур тулы йөзе мөлаем. Әсир төшкәненне сизми дә каласың.

Көтмәгәндә Хәниф кызны хафага салды. Әйе, әйе. Ник дисәң, кая гыйшык-мыйшык, таянмаганга сөйкәлмә булып, читләтеп кенә йөри.

Исәнмесез, хушыгыз – шуның белән шул. Озату, очрашу турында ләм-мим. Мүкләкнең мүкләге.

Бу гаделсезлеккә ничек түзмәк кирәк?

Көннәрдән бер көнне егет чырылдаган телефон тавышына уянып китте.

– Вакытсыз борчуыма гафу ит, бер үтенечем бар иде...

– Кем сөйли, нинди үтенеч? – дип бүлде шылтыратучыны Хәниф.

– Дамирә иде бу, ярый инде, кирәкми, башка ярдәмче эзләргә кала...

– Дамирә?!

Хәниф ятагыннан очып кына төште.

– Нинди үтенеч, Дамирә?

– Әбиемнең басымы күтәрелде, дарулары беткән икән. Аптека район үзәгендә, велигың белән шунда алып барып кайтмассыңмы дигән идем.

– Көт, хәзер килеп житәм.

Дүрт чакрым ара нәрсә ул. Выжылдап кына бер тында барып та җиттеләр. Аптека әле ачылмаган да иде, 10-15 минут чамасы көтеп торырга туры килде.

– Олы жанлы, миһербанлы кеше икәнсең, Хәниф, рәхмәт, – дип, кайткач Дамирә капка төбендә егетнең бит очыннан әп итеп алды.

– Син инде бигрәк, – диде Хәниф, – нәрсәсе бар инде аның.

Ул куштәгәрмәченә атланмак иткән иде дә Дамирәнең ишарәсен күреп тукталып калды.

– Әллә тагын берәр йомышың бармы, Дамирә?

– Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый, ди, – кыз керфекләрен жиргә чәнчеп кенә, – булгач булсын инде, бәлки, Ак тирәк атавына су коенырга да алып барырсың? Үзең дә Ньютон биномнарыннан беразга арынып торыр идең. Сине математикага мөкиббән диләр...

– Бик рәхәтләнеп, математикага коену комачауламый, ул һәрвакыт үзем белән.

– Иртәгә әбәттән соң, ярыймы?

– Сөйләштек.

Иртәнге якта шаулап-гөрләп явып алган шифалы яңгырдан соң дөнья ничектер кинәеп киткән иде. Аръяктагы имәнлек тә, әнә, йөзен ачты. Агачларның карасу-көрән кәүсәләренә кадәр аермачык күренә, кулыңны сузсаң капшап та булыр иде, шәт.

Дамирә куышта киемен алыштырган арада Хәниф шушы манзараны күзәтеп торды.

– Син күлмәкчән генә кызынмакчымы әллә? – дип тавыш бирде кыз, – борчылма, кеше ашый торган гадәтем юк, чишен.

Хәниф әле һаман табигать хозурында иде.

– Ак тирәк атавы диден, кая соң тирәге?

– Анысын бабайлардан сора инде.

Дамирәнең буй-сыны мәшһүр Микеланджело кулыннан төшкән грек шаһинәсенең мәрмәр сынын хәтерләтә иде. Егет бер сирпеп карауда шундый нәтиҗә чыгарды. Ләкин бу оялтырлык караш иде, шундук күзләрен читкә борды.

Чибәркәй дә сизде аның хәл-халәтен. Шуңа күрә ашыкмыйча гына, сол белән генә купальнигын рәтләгәндәй итенде.

– Сөн монда бөтенләй үзгә икән, күр, ничек каракучкыллы, – дип, Хәниф сүзне баштагы эзенә кертеп җибәрде.

– Заманында бу урында уникe ташлы тегермән булган, – диде Дамирә.

– Син аяклы тарих икән, авылны бөтен нечкәлекләренә кадәр беләсең, – диде Хәниф гаҗәпле кыяфәттә, – Ак тирәк атавы, тегермән...

– Мин бит шушы авылда тудым, ә ул тегермәндә әниемнең бабасы идарәче вазифасын башкарган, – диде кыз.

– Уникe ташы ни-нәрсәне аңлата инде?

– Бу хактагы лекцияне калдырып торыйк, хөрмәтле математик, әйдә, минем арттан калма!

Дамирә кулларын алга сузып суга сикерде. Тыны озын икән, башы елга уртасында гына калкып чыкты.

Хәниф тә төшеп калганнардан түгел, сылукайны ике катлы сальто-мортале мәтәлчеге белән шаккатырды.

– Шәп! – дип кычкырды Дамирә.

Иске тегермән чоңгылларының чишмәләре иртәнге чык сыман салкынча иде. Үзенне су өстендәге каз мамыгыдай тоясын. Хәниф бертуктамый ярдан-ярга Сөнне ике-өч әйләнде.

– О-о, баттерфляй! – дип сокланды кыз.

– Ә син брасс остасы икән, – диде егет, – аякларың искиткеч синхрон!

– Мин берара йөзү секциясенә йөреп алган идем бит, тик музыка мәктәбе барыбер җиңде. Һәм үкенмим.

Алар елга кочагында үрдәк бәбкәләредәй кичкә кадәр чупылдаштылар.

– Бу искиткеч көн өчен сиңа зу-у-р рәхмәт, – диде Хәниф, – мин аны кайтара алмамдыр, мөгаен, шуңа күрә алдан ук гафу үтенеп куям.

Дамирәнең уенда бөтенләй башка мәсләк иде.

– Синең сөяркәң кем исемле? – дип, әңгәмәне астан өскә әйләндереп ташлады.

Егет бу көтелмәгән сораудан югалып калды.

– Сө-яр-кәң?!

– Сөйгән кызың инде алайса...

– Ә-ә.., юк... мин кызлардан оялам...

– Анысын үзем дә күреп торам, – диде кыз иреннәрен кыйшайтып, – минем белән өч метрдан торып сөйләшәсең ич әнә.

– Синнән отыры оялам, син үтә матур.

Дамирә серле генә елмаеп куйды.

– Мин җавап көтәм, Хәниф.

– Институтка кереп, ике-өч курс тәмамламый гыйшык-мыйшык уеннары белән шөгыльләнмәскә карар иттем мин, – диде егет кыюсыз гына, – дәресрәге, әниемнең киңәшен тотам. Ул минем чын акыл иясе.

– Ә-ә, мамкин сынок!

Дамирә егетне хуплавын белдергәндәй йөгенү ясап, чүгеп куйды. Аннан әйтте: «Мамкин сынок, әйдә, куышка кереп ял итеп алыйк, – диде, – зинһар өчен, катып торма инде, судан чыгарга булыш, курыкма, йогышлы чирем юк».

Хәниф кызны күтәреп алды, шундук муенына ефәк тасмадай нәфис куллар уралды. Бөтен тәнен җилкендереп, барча күзәнәкләренә кадәр ләззәтле дулкын таралды. Тамак төбендә моңарчы татып карамаган ниндидер искиткеч татлы тәм...

– Рәхмәт, – диде Дамирә куыш авызына җиткәч, – булдырдың.

Ул үзе белән ширбәт тә алган икән, кабымлыклар да. Кара-каршы утырып сыйландылар.

– Минем бурычларым геометрик прогрессиядә арта бара, – диде Хәниф батыраеп, – ничек бәхилләтергә булыр.

– Белмим инде...

Дамирә сүз уртасында ничектер янтаеп китте дә суы Хәнифнең өстенә чәчрәде.

– Гафу ит, зинһар!

Кыз гөрелди-гөрелди Хәнифнең юешен корытырга тотынды.

– Аполлон, мускулларың әнә ничек бүртенгән, миңа шундый тыгыз балтырлы егетләр ошый...

Өттергеч йомшак куллар җайлап кына плавки эченә шуып керде.

– Аһ!

Тестостерон тулышкан яшь тәннәр бер-берсенә беректе. Дөньялар онытылды.

Зилзиләдән соң иң беренче Дамирә телгә килде.

– Кичер, мамкин сынок, әниеннең киңәшен боздырдым, – диде.

– Мин сиңа өйләнергә тиеш, – диде Хәниф җитди кыяфәттә, – борчылма, минем өчен намус беренче урында. Монысы да әниемнең сабагы.

– Тиле, – диде Дамирә, – күзләреңне ач, егерме беренче гасыр бу, иректә секс заманы, түгел карагруһ «Печән базары» чоры. Син генә ул адашкан ак чәүкә, мамкин сынок...

***

Моннан җитмеш бер ел элек тә июль аеның җиденче көне шушындый ук кояшлы, шушындый ук хозур вә галибәнә якты иде. Әрәмәләрдә кошлар сайраша, болыннар аллы-гөлле чәчәккә төренгән. Кая карама, купшылык, гүзәллек. Әйтерсең лә җиһанны салават күперенә индереп алганнар, балкыпмы-балкый.

Әфкан Шәмсиянең чишмә суына китеп барганын шәйләп алган иде. Атларын җир башына чыгарып, кызның урап кайтканын куак ышыгында сагалап торды.

Күренүгә каршысына йөгереп чыкты да такмакларга кереште:

Мәүри кыз хитрый,
Җилкәсендә кош йөри.
Огына сырлан сарган,
Сыргасы төшеп калган...

Кыз кәжә бәтиедәй читкә тайпылды.

— Абау, нәмә кеше куркытып җөрисен монда, котымны алдын, — диде, — суымны түктереп бетерә яздын бит.

— Сез шул яшелчә бакчасында чишмә суы эчеп кенә ятасыгыз ахры, ярты җәй үтте, сынар кыяр да күрсәткәнегез юк.

— Үзегезне бел, Хөрәсән ялкаулары, стена гәҗитенә бригадыгыз белән ташбакага атландырып төшергәннәр бит, ыстырам.

Егет хатасын төзәтергә ашыкты, анын нияте бөтенләй башка иде ләбаса. Кызны ошатып йөри ул. Ошатмаслыкмы сон, авылда бер ич. Озын чәч толымнарын ак алъяпкычы өстеннән калку күкрәгенә салып җибәрсә, тыннар кысыла, валлаһи. Ул атлаулары. Сөннән су ташыганын күзәтеп тору үзе бер тамаша. Күл камышыдай нәфис сыны, аккошныкы сыман озын төз муены гүя бер җепкә тартылган, көянтәгә эленгән мөлдерәмә тулы чиләкләрдән ник бер тамчы су өзелеп төшсен.

— Күрегез, берәү эшкә дә базар оегы гына киеп йөри, — диде Әфкан.

— Абау, тәүфыйксыз, аякка бакма, — диде кыз, — мине кетәләр анда, кит жулымнан.

— Шулай инде, безненише чабаталы сабанчыга тел әрәм итеп тора димени тәти кыз?! — Егет үпкәләгәндәй итте.

Шәмсиянен йөзенә кояш кунды.

— Әллә минем чабата сина эржинкә булып күренәме?

> Ак матур – чак матур,
> Кара матур – бик матур.

Егетнен бу тезмәсе дә нәкъ урынына ятты. Чибәркәй кетер-кетер көләкөлә куак арасына кереп югалды. Артыннан: «Мина әрмисләр ошай» дигән җөмләсе генә ишетелеп калды.

Әфканнын кәефе кырылды. Чөнки армия анын төзәлмәс ярасы иде. Яшьтәшләренен солдат гимнастеркасы киюенә бер ел үтеп китте. Кәртечкәләре Уку йортында эленеп тора. Ә аны алмадылар, бракка чыгардылар. Имеш, аю табаны. Югыйсә, кеше йөргән җирдән йөри, кеше ашаганны ашый. Калхузда да исемле. Һаман атлы эштә. Берәр зары булса иде — юк алар. Былтыр әнә, авыл сабан туенда батыр калды, җилкәсенә тәкә асып җыен әйләнде.

Бер көенсән, бер тиенерсен ди, ай үтмәде, Әфканнын да чәчен кыркыдылар. Сугыш аю табаннардан да йөз чөермәде. Җиенырга нибары бер тәүлек вакыт бирделәр. Кичен ул тыкрык ышыгында Шәмсиянен эштән кайтуын сагалап торды.

— Менә Шәмсия, мин дә әрмис булдым, — диде авызын ерып, иртәгә парахут белән Сарапулга китәбез, аннан эшалонга төйиләр...

— Җарай ла, син барып житкәләгәнче сугыш бетеп куймаса, — дип шаяртты кыз.

— Нимес качып-посып кына чикне үтеп кергән бит, — диде Әфкан белдекле рәвештә, — сугышнын бер-ике айга сузылуы да бик ихтимал.

Шәмсия фикерен җыр белән җиткерде:

> Карлыгачлар ояда,
> Оялары пыяла;
> Кызыл гаскәр жиналмаслык
> Бер дошман юк дөньяда.

— Бүген кич чык әле, Шәмсия, сүләшәсе сүзләр бар ие, — дип, егет әнгәмәне үз ягына борып җибәрде.

— Әткәй рөхсәт итмәс шул, — диде кыз, — аның кич чыгып җөрүләрне җаны сөймәй.

— Мин сезгә күршебез Сәмиганы җибәрермен, — диде Әфкан үз табышына үзе шатланып, — ул сине утырмага чакырыр. Берәр кул эшеңне аласың да...

— Диуана, — дип көлде кыз, — җәен нинди утырма, төн чыбыркы сабыннан да кыскарак бит.

— Ә-ә...

Шулай да алар очраштылар. Ана йөрәге сизгер, ирен ул ризалаштырды.

— Җарар, сеңлесе Рабига белән җәт кенә урап кайтсыннар, — диде әти кеше.

Рабига апасының кулына талпан урынына ябышкан, бер генә минутка да җибәреп тормый. Егет, аяк астындагы балчык кантарларын типкәләгән атлы булып, сөйгәненә орынып-орынып алды алуын. Тик кызчык ошбу хәйләгә дә чик куйды.

— Тилебәрән орлыгы ашадыңмы әллә, тач кортлы кәҗә булдың, — дип, апасын үзенә таба тартты.

Күзгә күз төшәр,
Күзгә күнел төшәр.

Шөкер, күзләр иректә. Ә йөрәкнең сере — күзләрдә. Әфканның күзләре дә сөю-ярату хисләренә төренгән. Ул күзләрнең теле булса, һичшиксез, мин сина үлеп гашыйк, дип күнел төпкелендәге илаһи тойгысын ачып салыр иде. Хәер, кызның да күзләре мөлдерәмә, аның да йөзендә нур чаткылары кабынып-кабынып ала.

— Хатыма җавап язарсыңмы? — дип сорады Әфкан.

— Белмәем шул, — диде кыз оялчан гына, — җегетләргә хат язганым юк минем.

Янә киеренке тынлык урнашты, ком гарәбе булып араларына Рабига кергәнгәме, сүзләре һич тә ялганмый.

— Ярар, җитте, минем сыерны кичке көтүгә алып чыгасым бар, — дип кызчык очрашуга нокта да куйды.

— Исән йөреп, сау кайт, — диде Шәмсия, — бу соңгысы булмас әле, күрешербез...

Әфкан: «Мине көтәрсеңме?» дип сорамак иткән иде дә кыймады, нияте эчендә йотылып калды.

Алар авылдан өчәү иде. Зурлап озату да оештырмадылар. Чөнки уттай эш өсте, һәр минут исәптә. Аннан соң, бу сугышның нинди афәтләр, нинди кайгы-югалтулар китерәсе билгесез иде әле. Кызыл Армиянең тиз арада дошманны тар-мар итеп ташлавы берәүдә дә икеләнү уятмый иде. Әнә, Фин сугышын сизми дә калдылар ич. Немеснең кабыргасын санау да авыр булмас.

***

Дамирә Хәнифтән бик тиз ялыкты. Бәйләнчеклеген ошатмады. Һаман мете-мете бер сүз: «хатаны төзәтик, хатаны төзәтик». Йөдәтте тәмам. Шуңа күрәме, гыйшкы дөрләп китә алмады, Сөн суында йотылып калды.

Шәһәрдә янасы көтеп торган икән.

Урамда сары яфраклы көз иде. Кулчатырын да алмыйча җинелдән генә кузгалган иде. Көтмәгәндә биек йортлар артыннан мескен бүрек кадәре генә болыт кисәге бүселеп чыкты да ишә башлады. Чиләкләп коя. Мизгел эчендә Дамирәнең модный прическасы таралды да төште.

Нишләргә белми торганда, янына ак төстәге джип килеп туктады.

– О-о, детка, тебя же как промакашку развезло, – диде машина иясе, – поехали ко мне, обсушишься.

Дамирә итәкләрен тарткалый-тарткалый сузмак булып караган иде дә, бәбәй бәбәй инде ул, аны ничек озынайтмак кирәк.

Шул арада ул рульдәге кешене дә энә күзеннән үткәрергә өлгерде.

Конгырт чәчле, армут җимешенә тартым озынчарак йөзле азамат ирегет. Тегәрҗеп калынлыгындагы тар мыегы да үзенә килешеп тора. Әйтерең бармы, фартавай.

– Рәхмәт, янгыр хәзер үтә ул, – диде Дамирә.

– Хочешь восполение заработать? Залезай быстрее, пока не передумал.

Дамирә ачык ишектән машина эченә шуды.

Альберт ике бүлмәле заманча җиһазланган фатирда үзе генә яши икән. Бар җирдә тәртип, һич тә буйдак ир куышына охшамаган. Җыештыручы тотадыр, дип уйлап куйды кыз. Ә юынып, киемен алыштырып чыккач, бу камил тәртипнең хуҗа кулы икәненә төшенде. Ник дисәң, мондый югары зәвык белән әзерләнгән табынны кыйммәтле рестораннарда гына күрергә мөмкин ләбаса!

– Мин сезне әүвәл врач дип уйлаган идем, ялгышканмын, мөгаен, ресторан тотасыздыр, – диде.

Альберт көлеп җибәрде.

– Вот, не угадала, детка, я – программист. Притом очень успешный программист.

– Вау! Ә менә нигәдер русча гына сөйләшәсез, сез бит татар кешесе, – дип төпченүендә булды Дамирә.

– Это болезнь современного технократного поколения, – диде Альберт, – понимать понимаю, но говорить стесняюсь.

– Берәр чын татар кызына гашыйк булсагыз, ул сезне бик тиз өйрәтер, – дип көлде Дамирә.

Егет янә башын чөйде.

– Пожалуйста, вам карты в руки...

Хәзер кочып алачак, дигән уй йөгереп узды кызның башыннан, чөйне шул якка суга.

Ни гаҗәп, Альберт ана кагылмады. Кызыл шәраб тәкъдим итте, мәтрүшкәле чәй эчерде, әмма кулларын уйнатмады. Төпле кеше димәк ки.

– Мин риза, – диде Дамирә, – кайчан башлыйбыз.

– Хоть сейчас, чего ждать?

***

Берникадәр вакыттан соң аны Хәниф эзләп тапты.

– Шылтыратуыма җавап бирмисең, очрашулардан качасың, – диде үпкәсен белдереп, – ни уйларга да белмим.

– Монда уйлыйсы-нитәсе юк, – дип кырт кисте Дамирә, – мин башка кешене яратам. Моннан ары бимазалап, аяк астында чуалып йөрмә.

Әйтәсен әйтте дә, тырт-тырт басып китеп тә барды.

– Дамирә туктале, без соң... Дамирә...

– Ахмак!

Альберт телгә дә сәләтле булып чыкты. Әти-әнисе дә читләшкән туган телен ипилек-тозлык кына түгел, чын асылына төшеп өйрәнергә тырышты.

Алар инде бик якынайдылар. Дөрес, Альберт күнел капкасын ачып салырга бик ашыкмый, дистанция тота. Дамирә исә хатын-кызларга гына

хас төпченүләрен шаярту биләвенә биләп, акрын-акрын мәсләгенә ирешә бара. Кичә дә Альбертның: «Мин синең бүгенгедәй һаман шулай яшь, чибәр булып калуыңны телим», — дигән комплиментын бик оста гына үз ягына әйләндереп куйды.

— Рәхмәт, әлбәттә, — диде керфекләрен җилпештереп кенә, — тик бу балта сораганда шөшле тоттыругарак охшый түгелме?

— Менә-менә, — дип элеп алды Альберт, — мин бу очракта «Күп белсәң, тиз картаерсың» дигән мәкальне исемдә тоттым. Мөгаллимәсе нинди, шәкерте шундый, бигайбә.

— Төлке, — дип егетнең куенына сарылды кыз, — өйрәтүләремнең үз башыма төшәсен белсәмме?

— Нишләр иден?

— Фатир ачкычыңны барыбер кесәмдә генә йөртер идем.

***

Хәниф сөйгәненең сүзләрен чынга алмады. Ничек инде шундый илаһи якынлыктан соң башка кешене яратырга мөмкин? Чибәр кызлар вакыт-вакыт чыгымчылап ала ди бит. Шуңа күрә бернигә карамый тауга каршы таш тәгәрәткән Сизиф үҗәтлеге белән үз сиксәнен алга сөрде.

Ул әнисе тәрбиясендә, сыңар канатлы гаиләдә үсте. Матди хәлләре чамалы иде. Һәр нәрсәгә фәкать шәхси тырышлыгы белән генә иреште. Аның өчен иҗтиһад максатка ирешүнең бердәнбер юлы иде. Тик гыйшкый хис мәсьәләсендә әлеге теория көчсез булып чыкты. Дамирә ераклаша гына барды. Альберт белән сөйләшү дә файда бирмәде.

— Мәхәббәтне теләнеп алмыйлар, — дип, көндәше иреннәрен генә кыйшайтты.

Тора-бара әлеге тискәре үҗәтлек күңел ярасы, рухи төшенкелек, сагыш вә үкенеч тойгылары белән алышынды. Әнисе дә:

— Улым, төпченеп тормыйм, егет бул, җебеп төшмә, — дип кисәтте.

Хәниф айнып китте, хак, аның хәләте шул «җебеп төшү»гә барып тоташа лабаса! Әйе, әйе. Әгәр Ак тирәк атавында җебеп төшмәгән булса, бу кимсетелүләргә юлыкмый иде ул.

Шулаен-шулай. Ә ләззәтле хыялларны, сөешү назларын кая куясың? Хак, гыйшык белән газап — икесе бертуган. Французларның мәшһүр мәхәббәт романнарында бу ике полюслы бердәмлек бик оста тасвирлана. Кагыйдә буларак, аларда бәхеткә әһле хис газаплары сукмак сала. Берәүнең гыйшкы икенче затка гыйшык китерә. Хәнифнең гыйшкы исә шытым бирмәде, коры туфракка төшкән орлык кебек бөрешеп кипте. Инде өмет тә юк.

Ангыра бәрәндәй кая барып сугылырга белмичә изаланып йөргәндә ул солдатларга тап булды. Шахмат тактасындагы сыннар кебек тигез сафка тезелешеп, урам уртасыннан баралар. Аяк атлаулары бер, кул селтәүләре бер, сулышлары бер, әйтерсең лә электрон адәмнәр.

— Доп-доп, доп-доп!

Хәнифнең башында нидер келт итте, гүя мәрт йокысыннан уянды.

Ошбу хәрби оешмасыз калада каян килеп пәйда булган иде колонна, анысы билгесез, бәлки хыялының кыйшаеп китүе генәдер, әмма ул аны җиргә кайтарды. Шул ук көнне Дамирәне эзләп тапты да, искәртмәстән генә каршысына килеп басты. Тегесе читкә тайпылмак иткән иде итүен, ирек бирмәде, кулларыннан тотып алды.

— Бер генә минутка, Дамирә!

— Җибәр!

— Борчылма, мине башка күрмәячәксең, — диде Хәниф кызның чәбәләнүенә игътибар итмичә, — армияга китәм!

***

— О-о, берьюлы ике хат, иптәш сержант, — диде почтальон авызын ерып, — икесе дә Татарстанга, без почти якташлар икән, ич, үзем Уфа каласыннан.

— Мин аларны хәтсездән язган идем инде, җибәрергә җае чыкмый торды. Барып кына җитсеннәр, югыйсә, элеккеләренә дә җавап алмадым, кулларына кермәде ахры.

— Боларының да язмышы кыл өстендә, якташ, — диде почтальон, — ярый ла, камалыш боҗрасын өзә алсак...

Ул сүзен тәгәлләгәнче әмер яңгырады.

— Атакага әзерләнергә!

Ә дигәнче атлар авызлыкланды, куллар кынысларга ятты.

— Беренче отделение әзер! — дип җавап кайтарды сержант Әфкан Мортазин.

— Ватан өчен, Сталин өчен, алга!

Урман авызыннан 79нчы аерым кавалерия дивизиясе карамагындагы бу тәмам өтәләнеп беткән 233нче полкның ничарадан-бичара зәгыйфь атакасын немецларның ак тәреле танклары каршы алды.

Читтән караганда бу Дон Кихотның сөңге белән җил тегермәннәренә ябырылуын хәтерләтә иде. Нишләмәк кирәк, чолганыштан чыгуның бердәнбер юлы шушы.

— Ур-р-а-а! Ур-р-а-а...

Комиссарның карлыккан тавышы снаряд шавы эчендә йомылып калды. Үзе дә аты-ние белән йомычка урынына чәрдәкләнде.

Җир убыла, атлар кешни, яралылар ыңгыраша. Мәхшәр.

Атака, башлануга тончыкты, тәртипсез рәвештә чигенү башланды. Исән калган кавалеристлар Дон елгасы куенына сырышты. Хәлбуки, аръяк та дошман кулында иде инде. Каршында тәмуг уты дөрләгәндә бу хакта уйлап торыргамы соң?

Әфкан да шулар арасында. Тик аты чыгымчылый, каһәр, куркып калды ахры.

— Йолдыз, киреләнмә, Йолдыз...

Ул арада яр кырыенда гына снаряд ярылды да, дулкыны аларны елгага эшереп төшерде. Вулкандай кайнап торган упкынлы дәрья икесен тин үзенә йотты. Бетүем шушы икән, дип сызланды Әфкан, нинди үкенечле үлем.

Йолдызның балыкларга азык буласы килми иде, күрәсең, бар көченә өскә талпынды.

Агым бөтергәләпме-бөтергәли, төпкә суыра, рәхмәт, бахбай бирешми, ярга ыргыла. Шөкер, елганың яртысына җиттеләр бугай инде.

Хәерчегә җил каршы дигәндәй, шул вакыт баш өстендә ач козгын өередәй аэропланнар пәйда булды. Немец штурмовиклары шулай искәрмәстән җиргә ятып кына килеп чыгалар да әйләнә-тулгана үлем уты чәчәргә керешәләр. Күз уңнарына электенме, котылырмын димә. Берсе, әнә, Әфканны да абайлап алды. Алар шулай берәмтекләп чукудан ямь таба, ди. Ау котырыгы, әйтерең бармы. Чылбырдан ычкынган үгез кебек маңгайга-маңгай килә, иблис. Тәүге пулялары колак төбеннән генә сызгырып үтте. Шөкер, тимәде. Немец моны үзе дә күреп торды, билгеле. Шуна күрә икенче ыргымга әзерләнде. Хәзер әйләнеп киләчәк тә...

Әфкан атының муен астына керергә өлгереп калды, Йолдыз һөҗүмне үзенә алды.

— Бәхил бул, бахбай!

Төркемне икенче көнне көн уртасында эләктерделәр. Төркем дисән, хәтерең калыр, бу мәхшәрдән нибары тугыз кеше исән калган иде.

***

Дала кояшы мәрхәмәтсез. Кыздырыпмы-кыздыра. Болай да хәлдән тайган арык солдатларның кыл өзәрлек тә көче калмады. Иләмсез ябыктылар.

— Егетләр, колакка чишмә челтерәгән тавыш керде, — диде старшина, — валлаһи, әйдәгез, калкулыкның аргы ягына чыгыйк әле.

— Саташасың гына, чүл бит бу, нинди чишмә? — диде Әфкан.

— Валлаһи...

Чыктылар. Ә анда немец патруле иде.

Әфканның өч елга сузылган әсирлек тормышы менә шулай башланды. Аларны исеме җисеменә туры килми торган ниндидер «Мария» атлы вакытлы лагерьга китереп яптылар. Әсир өстенә әсир. Әйтерсең лә бөтен Кызыл Армияне шушында куып кертkәннәр.

Берәр таныш-белешне очратмаммы дип йөренгәндә Әфкан аяклары аннан-моннан гына иске салам белән каплаштырылган бер солдатка тап булды. Немецлар, гадәттә, чирлеләрне тотмыйлар, атып кына үтерәләр. Бу яңа этаптан булса кирәк, куллары җитмәгәнгә охшый.

Яралының баш очында кечкенә генә кесә китабы ята иде. Коръән!

— Әссәламегаләйкум, кардәш, — дип сәлам бирде Әфкан.

— Су! — диде яралы саф татар телендә, — су!

Әфкан су эзләп китте. Кухняда эшләүче әсир хәленә керде, рәхмәт. Тик ул әйләнеп килгәндә татар кардәшенең күзләре керәчләнгән иде инде.

Коръән китабы аның кесәсенә күчте.

Икенче көнне әсирләрне сафка тезеп бастырдылар.

— Коммунистлар, еврейлар бер адым алга!

Плацта кабер тынлыгы урнашты, берәү дә үзен таныттырга теләмәде. Немецлар үзләре эшкә кереште. Әфканны да сафтан сөйрәп чыгардылар.

— Еврей?

— Ман мөселман! — дип кычкырды ул.

— Ә нигә күзең зәңгәр, чәчең сары?

— Ман мөселман!

— Ни белән исбатлыйсың?

— Гер офицер, менә Коръәнем.

— Ду религиозен ман?

Әфкан кычкырып бала чакта әбисе өйрәткән догаларны укый башлады.

— Гуд, ферштейн, — дип кайтып төште офицер, — урыныңа бас.

Немецлар тәкъвә әсирләргә миһербанлырак карыйлар иде. Чөнки СССРда дин тыелган. Дин тота икән кеше — димәк, Советка каршы. Шуңа күрә легионнар оештырыла башлагач та исемлеккә Әфканны беренчеләрдән теркәп куйдылар.

Коръәнле әсирнең язмышы гына немецлар тәгаенләгән юлдан китмәде. Берлиндагы Тегель төрмәсендә ул Михаил Иконников дигән власовчы, полк комиссары белән танышкан иде. Көннәрдән бер көнне отбой алдыннан күлмәк итәге астыннан гына бер төргәк сузды яна танышы.

— Иртәгәгә кадәр мендәр астында тот әле, сине тентемиләр, — дип пышылдады, — выручай.

— Нәрсә бар соң аның эчендә? — дип төпченде Әфкан, — ул-бу булмасмы?

— Курыкма, бомба түгел.

— Ярар, калдыр.

Комиссар иртән төргәкне Әфканнын үз алдында сүтте. Ә анда иске гәҗит кисәкләре генә иде.

Иконников бу хәлне шәрехләп тормады, «Мин сине Гайнан Курмашев

дигән милләттәшең белән таныштырам, әзер бул», — дип китеп барды. Гайнан исә аны татар легионерларының яшерен оешмасына тартты.

Лагерь җитәкчелегенең ышанычлы кешесе буларак, ана иң четерекле, иң җаваплы вазифа — листовкаларны саклау һәм тарату вазифасы йөкләнде. Ышанычны аклады, бер провал да ясамады.

Бервакыт кичке якта ниндидер йомыш белән Гайнан янына барып чыккан иде.

— Коръәнле легионерыбыз шушы инде, таныш бул, — дип тәкъдим итте аны дусты, янындагы кешегә, — исеме Әфкан.

— Ә мин Гумеров булам, — диде тегесе күз очлары белән генә көлемсерәп, — танышуыма шатмын.

— Син сабантуйларда мәйдан тотканСын булыр, — диде Әфкан, — кулын каты, тоткан җирдән өзә торган, бәдәнең дә таза күренә, андыйлар бил бирмәй.

— Психолог икәнсең, — диде Гумеров көлемсерәве аша, — тик куеныңда Коръән йөрүне генә аңламыйм, Совет кешесе ләбаса син.

— Туган ил белән Коръән — икесе бер тамырдан, якташ.

Гумеров нидер әйтмәкче булып кулларын аның җилкәсенә салган гына иде, отбой сиренасы яңгырады. Лагерьда тәртип педант немецларның үзләре кебек үк катгый. Су сипкәндәй шундук таралышып та беттеләр. Алай да Гайнан колагына пышылдарга өлгерде:

— Муса Җәлил шушы инде, — диде.

Кызганыч, шагыйрь белән башка очрашу насыйп булмады.

Татар-башкорт легионындагы дүрт батальонның берсе дә үзебезнең гаскәрләргә каршы корал күтәрмәде. Әфканны исә сугыш өермәсе Франция таш-таулары арасына илтеп җиткерде. Шөкер, җәза операцияләрендә катнашырга туры килмәде. Юлда ук Тюрнус дигән станциягә җитәрәк деголльчылар эшелонга һөҗүм итте.

Бу форсатны кулдан ычкындырырга ярыймы соң? Атыштан файдаланып, легионерларның булдыра алганнары бөҗәкләр кебек төрлесе төрле якка сибелде. Немецлар «хальт» та «хальт» кычкырыша.

Бераздан барысы да тынды. Эшелон да китеп барды.

Бу ирек иде.

— Ир-е-ек!

Ирегең ирек, өстә бит немец формасы. Французлар өчен алар дошман. Янә төрмә, янә тикшерү.

— Яшермә, син бит монда махсус җибәрелгән немец шпионы, — диде зур өркәч борынлы, какча гәүдәле сорау алучы.

— Мин татар легионеры, әсир, яшерен оешма әгъзасы, — диде Әфкан немец телен вата-җимерә, — лагерьда листовкалар тарату белән шөгыльләндем.

— Безнең отрядта да легионер татар бар, хәзер барысын да ачыкларбыз, — диде партизан, — листовкалар тараткансыңмы, әллә шымчы булып кешеләр өстеннән торгансыңмы?

— Коръән тотып ант итә алам.

— Әфкан кабалана-кабалана кесәсенә тыгылды. Коръән юк иде. Ыгы-зыгы вакытында төшеп калган, күрәсең. Ләкин немецлардан үзгә буларак, французга Коръән сүзе бөртек тә тәэсир итмәде.

Аларда дин түгел, сөю-сөешү кәсафәте алдан йөри икән.

— Шеф-сержантны чакырыгыз! — диде тикшерүче.

Күп тә үтми, бүлмәгә озын буйлы, ыспай гәүдәле кеше килеп керде. Билендә киң каеш, башында зәңгәр беретка.

Йөзе таныш, атлаулары таныш, карашы таныш.

Артист! Артист ич бу! Гадәттәгечә кашлары жыерулы, күзлеген керфек очына гына элгән. Лагерьда оештырылган музыкаль капеллада жырчы да, биюче дә, декламатор да иде. Бераздан юкка чыкты. Башка жиргә күчергәннәр дип сөйләгәннәр иде. Ә ул качып киткән булган икән, француз партизаннарына кушылган.

Әфкан таныды. Ә менә Гарәф Фәхретдинов танырмы? Күренеп тора, Гарәф французларда үз кеше. Командир. Дөнья хәлен белеп булмый.

Таныды.

— Әфкан, якташ!

Коръәнен югалтып, Әфкан дустын тапты.

Сугыш инде тәгәлләнү ягына борылган иде. Генерал де Голль регуляр армия оештыра башлады. Ә армиядә хезмәт итәр өчен француз гражданины булу зарур.

— Сөн буйларын, сөйгәнем Шәмсияне Франциягә алыштыра алмаем, — диде Әфкан, комиссарның гражданлык турындагы тәкъдимен кабул итмәде, —мин Ватаныма кайтам.

Ватан ул — сулаган һаваң, эчкән суың, ашаган икмәгең, яшәгән йортың, әтиең-әниең, сөйгән ярың, шатлыгың-куанычың, күз яшьләрең... Ватан барысыннан да газиз. Ватансыз кеше — бакчасыз сандугач.

Ватан үз баласы Әфканга үги иде — контрразведкасының вак иләгеннән үтә алмады...

Немец төрмәсендә утырды, Француз төрмәсендә утырды, чират, ниһаять, Совет төрмәсенә житте.

***

Ишек кыңгыравы шылтырады. Дамирә өйдә үзе генә иде. Битараф кына:

— Кем бар анда, ни кирәк? — дип сорады.

— Почтальон.

— Безнең тартма бар, корреспонденцияләрне шунда сал, — диде кыз ризасызлыгын белдереп, — юкка бимазалама.

— Ач әле, ач, бу хатны кулдан-кулга бирү зарур.

Мүкләк, китәргә дә өлгермәде, инде заказной хатлары белән интектерә башлады, дип Дамирә эченнән генә Хәнифне сүгеп ташлады.

Почтальон кәгазь-язулары иске кердәй унып беткән өчпочмак рәвешендәге конвертсыз ике хат тапшырды, нindiдер белешмәгә имза салдырды.

Аңлашыла, Хәнифнең бу сәер хатларга бернинди катнашы да юк. Мондый хатларны Дамирәнең музейда гына күргәне бар иде. Икенче бөтендөнья сугышы чоры хатлары. Әтисе сораткандыр мөгаен, жыен искемоскыга ул мөкиббән бит, тарих белән кызыксына, эзтабар.

Зиннур, чыннан да, хатларны күргәч бик дулкынланды, кызын күтәреп алып, бүлмә буенча бөтергәләп йөртте.

— Сөенче, нинди кадерле сөенче!

— Инде кешечә аңлат, әтием, сүз нинди сөенеч турында бара? — дип сорады Дамирә атасының кочагыннан арынгач.

— Нинди зур табыш, кызым, нинди зур табыш! Болар сон минем бабам, синең карт бабаң сержант Әфкан Мортазинның сугыштан язган хатлары. Тапшырылмаган хатлар. Жә, Ходай!

Зиннур әле бик озак тынычлана алмыйча хис-тойгыларын чәчте.

Ахыр чиктә шул мәгълүм булды: Киев Бөек Ватан сугышы музее үзләрендә саклаган солдат хатларын мирас ияләренә жибәрү кебек үтә дә игелекле эш башлап жибәргән икән. Рәсәйгә кагылышлысы — 1186

хат. Шуларның берсе Татарстанга адресланган. Төгәле: ТАССР, Актаныш районы, Күзкәй авылы: берсе Мифтахов Габдуллага, икенчесе Ибраһимова Шәмсиягә. Эчтәлекләре гап-гади. Хәлем яхшы, сезнең өчен генә кайгырам, дигән. Бәрәңгене тирән базга күмегез, черемәсен, сыерны сата күрмәгез, дигән. Шәмсиягә исә, әтән-инәнә тишә тор, кайтуга яучы җибәрәм, дигән. Теге вакыттагы шикелле исәрләнә күрмәсеннәр, үзен дә нык тор, дигән. Җиңү турында ләм-мим.

– Датасын кара әле, кайчан язылган? – дип сорады Дамирә.

– 1942 елның 17 июле. Татарстандагы БВС музей-мемориалы аша килгән. Директоры, эзтабар Черепановка рәхмәт, кемнең кем икәнен дә ачыклаган, адресын да тапкан.

– О-о, җитмеш ел, – дип сузды Дамирә, – кызганыч, мин карт бабамны да, карт әбиемне дә күреп белмим.

– Бабамны мин үзем дә әткәй сөйләгәннән генә беләм, – диде Зиннур, – сугыш, төрмәләр аның сәламәтлеген бик нык какшаткан, иллесен дә тутырмый үлеп киткән. Шәмсия әбием җитмеш яшендә, син туган елны вафат булды.

– Карт бабам сугыштан кайчан кайткан, алар ничек өйләнешкән?

– Бу үзе бер мавыктыргыч тарих, кызым, – диде Зиннур, – Шәмсия әбием сөйләгәннәрне язып та алдым.

– Мин дә танышып чыгыйм әле, әтием.

– Нәкъ вакыты, кызым, мә, рәхим ит.

Немецлар искиткеч төгәл вә җаваплы халык. Һәр адымнарын теркәп барганнар. Катлаулы шартларда да документларны күз карасыдай саклаганнар. 1942 елның 17 июлендә камалышта һәлак булган хәрби почтальонның сумкасындагы хатларны да алып рәсмиләштергәннәр, әнә. Хәтта Гитлер почтасы хезмәткәренең исем-аты да теркәлгән – доктор Ольштегер.

Сугыштан соң ул хатларны Украина музеена тапшырганнар.

Менә бу почта, менә бу тәртип!

***

Дамирә бүлмәсенә кереп бикләнде дә әтисе биргән катыргы тышлы дәфтәрне кулына алып, уйга калды. Ул карт әбисенең буй-сынын, килешкилбәтен күз алдына китерергә тырышып карады. Аның үзенә, мисал өчен, унтугыз яшь. Шәмсия кыз нинди булды икән бу яшьтә?

Мөгаен... хәер... истәлекләрендә әлеге сорауларга да җавап бардыр әле, бәлкем.

Истәлекләрдән битәр, бу чын мәгънәсендә интервью иде. Күр, әтисе нинди оста, журналистлардан ким түгел. Ә карт әбисе искиткеч һиммәтле зат булган, олы шәхес. Тәвәккәллегенә сокланырлык. Һәрвакыт бәхет белән ләхет чигендә йөргән. Шуларга өстәп, җор телле, тапкыр. Сүзе тамагына утырмый, үлчәп тә тормый, очыра гына.

Укучым, мин дә әлеге әңгәмәне дәфтәрдәгечә тәкъдим итәм.

– Карт инәй, атаеңны бик коры, таякны тоткан җиреннән сындыра торган кеше булган, сине хатыны үлгән бер адәмгә кияүгә бирергә дә талпынып караган, дип сөйлиләр. Бу дөресме?

– Дөрес тә, дөрес тә түгел, бәгырь. Элеккеге дәвердә бер җегеткә җәмсез кәләш туры килгән, дие. Кыз-хатын чытлыклана бит инде ул. Җәш киленебез дә сырпаланып кына: «Җөзем белән кемнәргә күренсәм җарай?» – диеп сораган, дие. Кияү әйткән: «Миннән башка кемгә күренсәң дә җарай», – дигән. Без үскәндә әле мин сүләгән нәмә юк иде инде. Сәүит чорында буй җиткердек бит, әнәтрәк. Алай да җегет-кыркын белән ихахай-михахай

килеп жөрү жук иде. Карт әтәң белән дә мәхәббәт сүзләре әйтешмәдек, әнәтрәк. Сугыштан килгән бердәнбер хатындагы җыруыннан гына миңа чын-чынлап өмет итүен төшендем.

Кызыл-кызыл бөрлегән
Күл читенә тезелгән.
Булмас инде минем күек
Синең өчен өзелгән.

Үзем дә ризалыгыма ишарә белән җавап хатыма җыру сырладым.

Уйсу җирләр, уйсу җирләр,
Уйсу җирләрдә күлләр;
Электрдан җакты булыр
Безнең киләчәк көннәр.

Укый гына алмаган бәгырь, бу вакытта инде ул плен төшкән булган.

Әткәй коры ие, хак, үземә тиң түгел кияүгә дә бирергә тырышып карады. Ләкин дә революция җилләре анардан көчлерәк ие шул инде. Чебен никадәр генә дуламасын, тәрәзәне вата алмай бит, әнәтрәк.

– Кызларның да, егетләрнең дә күзе иң элек матурга төшә. Карт әтәй сине кайсы ягы белән үзенә каратты?

– И, бәгырь, без дә җырлап үстек андый җыруларны.

Матур матурга карай,
Безгә матуры кирәкмәй,
Әп итә белсә җарай.

Минем үземне чибәрләр рәтендә җөртәләр ие. Гәүдәм калку, чыраем күркәм, авылда иң озын чәч толымы да минеке ие. Тырт-тырт кына басып җөримен. Артымнан борылып карап калалар ие, әнәтрәк.

Әфканны «Минзәлә» дип түбәнсетәләр ие. Инәсен бик авыр хәлдә Минзәләгә алып киткәннәр. Баласын җарып алганнар, әнәтрәк. Каладан чәтерәннәп торган зәңгәр күзле, аксыл-сары чәчле малай алып кайткан. Алыштырганнар диеп тә гайбәт саталар ие. Монысы бәла тагу гына булгандыр диеп уйлаймын, нәселләрендә аксыл керфекле адәмнәр бер Әфкан гына түгел ие. Карга көтүендә чәүкә булып үсте Әфкан. Без җырудагы күек «Бер матурга бер җәмсез» булып кавыштык. Ходай шулай язган, күрәсең, Ходайдан узмыш җук бит.

– Ә тәвәккәллегең каян килгән?

– Анысы торфтан, бәгырь, торфтан. Мине торф кеше итте. Авылдан разнарядка белән җоммай түктереп чыгарып җибәргәннәр ие, җыл җарымнан җакалы куфайкалардан гына чын ясау булып кайтып төштем. Бөтен авыл шаккатты.

Маржалар бригадасына туры килдем бит мин. Өстемнән торып елата-елата русчага өйрәттеләр. Соныннан үземә дә ошап китте, әнәтрәк. Су кебек эчә башладым, бозусыз-нисез сүләшәм мин ул телдә. Ә менә казанлылар татар телемнән көлә ие, хәтта ки «Нәмәкәй бичә» дигән кушамат та тагып куйдылар.

Балчык эше авыр бит ул, бәгырь. Шулай да авылда үскәчтен чырышлык бар, умырам гына. Бер айда да премиясез калмадым, шөкер.

Каширда торфчылар өчен татар телендә гәҗит басыла ие. Тәмле телле, исле сабын кабындагы сылукай сурәтеннән дә чибәррәк Мәрҗәм Дибаева дигән корреспондент мине берничә тапкыр мактап та язды.

Баштагы мәлне көнләштеләр анысы, яшереп булмай. Әрләштек тә. Нәмәгә дисән, әле көрәк сабын сындырып куялар, әле ломны жәшерәләр, әле хәрәмләшеп, ин сулы ал бирдерттерәләр.

Тукта, мәйтәм, болай жарамай, араны көйләргә кирәк. Аларны начарлык белән жинәм димә, чөнки дә ишлеләр. Аннан китереп, каланыкылар, заводтан жибәргәннәр. Грамотныйлар.

Әмәлен таптым тәки. Күз күремендә генә бер авыл бар ие. Барышып-килешеп жөри иек. Жал көнгә туры китереп, Серафима исемле солдаткадан мунча жактырдым да кызларны шунда алып киттем. Чыгуларына токмачлы аш әзерләдем, кабак бәлеше салдым. Көмешкә дә жүннәттем. Ансыз булмай ие.

Ис-акыллары китте бәгырькәйләремнең. Бөртекләп жыйган акчам бетсә бетте, әнәтрәк, әмма да кызлар белән анлаштык, чын дуслар булып жәшәдек. Алар мине күп нәмәгә үрәтте, кыюлыкка да, чослыкка да, хәйләгә дә. Ифрат та шомарган кызлар ие, әйе.

– Аннан Себергә кияү эзләп киттен инде...

– Әстәгъфирулла, алай турыдан бәрмә инде, бәгырь. Анысы бит анын сугыш беткәч булган хәл, әнәтрәк.

Сугыш бетте, авыл аксак-туксак солдат белән тулды. Бәгъзе берәве чыбылдык эченә дә кертмәк иткән ие. Үзем дә риза була язган ием, бәгырь. Барыбер күнел тартмады. Уйда һаман шул сары чәчле Әфкан утыра бит, каһәр, бармак жанай. Ә үзенен ни хаты, ни хәбәре дигәндәй. Кайтасы кеше кайтып бетте, ул жук та жук. Утырып та каласы килмәй бит, бәгырь.

Бердәнбер көнне авылда жаман хәбәр таралды. Имеш, Әфканны сөргенгә сөргәннәр, илен саткан, имеш, хыянәт иткән. Үзләренә дә барып белештем. Чыннан да, өстеннән язу килгән икән. Пособие түләүне туктату турында хәбәр иткәннәр, улыгыз хәрби антын бозды, дигәннәр.

Төн жокыларым качты, бәгырь. Бу бит үтә дә жаман жинаять. Чүп өстенә чүмәлә, авылда бер зәнгәр погонлы кгбшник та пәйда булды. Әфканнын әти-әнисен, туган-тумачасын, таныш-белешләрен чакырта башлады бу. Авыл умарта кортыдай гөжләй. Мине дә басуда эшләгән жирдән жилтерәтеп алып кайттылар.

– Син сатлык жан Әфкан Мортазин белән хат алышкансын, – дип өстәлгә китереп сукты Погон, – тәрәзә пыялалары зынлап торды, бәгырь. Гомер булмаганны коелдым да төштем, телем анкауга жабышты, сүземне дә әйтә алмаем.

– Жә!

– Бер хаты килгән ие, иптәш...

– Алып кил! – дип акырды Погон, – тиз!

Ул көнне Әфкан жанашым да төшкә керде. Капка баганасы артыннан башын сузып, текәлеп карап тора, бәгырь. Йөзе ачулы. «Нигә минем хатны чит кешегә бирден?» – диеп бармак жанай. Йөрәгемә ачыташ кырып салдылармыни, шул кадәр хәсрәтләндем, чыдарлыгым чистый төкәнде.

Тиз-тиз генә жыендым да Норильски дигәннәренә юл тоттым.

Тәмуг газапларына тин михнәт-нужалар турында сүләп тормаем, бәгырь, китапка да сыймас авырлыклар кичердем. Әмма дә сүземне сүз иттем, ярты ел дигәндә эзләп таптым мин ул лагерьны. Торфка рәхмәт, анда алган сабаклар бик тә булышты, әнәтрәк.

Лагерь ашханәсенә табак-савыт юучы булып эшкә дә урнаштым. Кешеләре житмәй икән, ике куллап алдылар.

Лагерьда халык мыж. Ата улны, ана кызны белерлек түгел. Танышынны табу кибәннән энә эзләү белән бер. Шулай да жаен таптым бит, бәгырь. Директордан агач аударучыларга әбәт ташу төркеменә күчерүен үтендем. Каршы килмәде.

Күнелем белеп сизенгән икән, ай ярымнан Әфкан белән дә очраштык.

Лагерь тормышы бик катлаулы ул, бәгырь. Анда законнар бөтенләй башка. «Вортухайлар» лагерьның эчке эшенә, яшәешенә тыгылмай. Тоткыннар белән Пахан идарә итә. Ул нәрсә әйтсә, шул була. Үтер ди икән, үтерәләр, чишендер дия икән, чишендерәләр. Килгән посылкаларны да беренче булып ул ача. Берәү дә каршы килә алмай.

Кичен Әфкан белән Пахан катына киттек. Кабак башлы, төптән җуан адәм икән. Каш астыннан чекерәеп, ярдәмчеләре аша гына сөйләшә.

– Белешегез, мужикмы, сукамы?

– Мужик.

Ачыклап китәем әле, 58 нче статья белән хөкем ителгән сәяси тоткыннарны «Мужик» диеп җөртәләр ие, калганнар – «Сука». Мужикларны барысы да хөрмәт итә ие.

– Сора, ни жомыш?

– Кәләшем белән никах укытып, лагерьда яшәп каласы ие, – диде Әфкан, – кәләшем вольнонаемная.

– Рөхсәт!

Бер чичен мулласы никах укыды, баракның аулак почмагында урын әтмәлләдек. Шунда ир хатыны булдым. Ике ел Әфкан белән сөрген тормышын бүлештем, бәгырь. Властька Хрущев килгәч, әүвәл поселениегә чыгардылар, аннан бөтенләй җарлыкадылар Әфканны.

***

Әңгәмә шушы урында өзелә. Дамирә аннан соңгы хәлләрдән хәбәрдар иде инде. Әфкан гаиләсе белән Себер якларында төпләнеп кала. Улы Мирзаян да шунда туа. КамАЗ төзелә башлагач кына Чаллыга кайта. Зиннур дөньяга Татарстанда аваз сала. Дамирә Әфканлыларның автоградтагы икенче буыны.

Шәмсия ире вафатыннан соң тол килеш егерме дүрт ел буе ярканат булып яши. Балалары ничек кенә кыстамасын, туган ягына әйләнеп кайтмый.

– Мин аны ташлап калдыру өчен эзләп тапмадым, – дип кырт кисә.

– Йосыф-Зөләйхалар мисалында туган «Ерактагы якын мәхәббәт» гыйбарәсе чын дөреслекне чагылдыра дигән сүз бит бу, кызым, – диде Зиннур гадәттән тыш илһамлану белән, – аны Шәмсия сылу кебек асыл ярлар яшәтә. Әнә, Зөләйха Йосыфка төшендә күреп гашыйк була. Мәхәббәтен көтә-көтә карт әбигә әверелә, сукырая.

Ошбу риваятьнең нигезе булганмы-юкмы, анысын әйтә алмыйм, әтием, ләкин дә романтик мәхәббәт заманнары үтте инде. Без интернет, менеджмент, прагматизм чорында яшибез. Барысын да кирәклек, зарурилык, ихтыяж билгели.

– Ә мәхәббәт, хис-тойгы?

– Мәхәббәт тә музей экспонаты хәзер, әтием. Син бу хат-хатирәләрне музейга тапшыр. Аларның урыны шунда.

***

Телевизордан концерт тапшыралар. Ашкынулы җинел көйләр ритмында Дамирә көзге каршында бөтерелә. Башта миллиметрга-миллиметр тәнсынын тикшереп чыкты. Муенын ошатмады, ул ана кыскарак сыман тоелды. Ияк асты да салынкыбрак тора кебек. Чәбәкләп-сыпыргалап та алды, ләкин ана карап, май бизләре кечерәймәде. Ахыр чиктә бу файдасыз гамәлдән ваз кичеп, игътибарын бил-янбашы-аяк тирәләренә юнәлтте. Ошбу тарафта тәртип иде. Күнеле күтәрелеп китте. Чөнки белә, ир-егетләрнең күзе иң элек шунда төшә.

Вәйт!

Дамирә көзгедәге сурәтенә телен чыгарып күрсәтте.

— Карагыз, ләззәтләнегез!

Шул күтәренкелек белән Дамирә коену костюмнарына күчте. Алар бихисап. Һәрберсен киеп карады. Яртысыннан артыгын читкә бәрде. Чөнки аны кисәттеләр, Канарда игътибар үзегендә буласын килсә, тәненне ача да бел, уйната да бел, диделәр.

Ә кайсы чибәркәйнен күз өстендә каш буласы килми?

Альбертка рәхмәт, чын ир-егет.

— Сине сюрприз көтә, әзер бул, — диде беркөнне.

Дамирә сюрпризны туй балдагына юрады. Үзе дә вакыт житте дип саный иде. Рәхимәләр, әнә, эшне кызу тоттылар, инде бәби көтәләр.

Альбертнын сюрпризы исә Канарга ял сәяхәте булып чыкты. Дамирә шатланды гына. Чөнки экзотик төбәктә ясалган тәкъдим күпкә тылсымлырак лабаса. Анын шулай булачагына ул бөртек тә шикләнми иде.

Телевизордан жирле хәбәрләр тапшыра башладылар. Студиядә Солдат аналары комитеты рәисе пәйда булды. Шәһәрдә аны белмәгән кеше юктыр, мөгаен. Бик булдыклы ханым. Чыгышларын көтеп алалар.

Дамирәнен дә колаклары сагайды.

— Шәһәребезгә тагын бер хәвефле хәбәр килеп ирешге, — диде рәис ханым, — Норильскида урнашкан хәрби частьларнын берсендә язгы чакырылышта үз теләге белән армияга киткән студент якташыбыз Шәйхетдинов Хәниф дедовщина афәтенә юлыккан. Шовинистлар ерткычларча кыйнап имгәткәннәр. Без бу коточкыч хәлне ишетүгә, республикабыз президентына мөрәҗәгать иттек, Мәскәүгә, оборона министрына хат юлладык. Башка чаралар да күрелә.

Хәниф?! И, мескен. Иртә унмаган кич унмас, кич унмаган һич унмас, ди.

Дамирәнен күз алдында Сөн буйлары, Ак тирәк атавы, куыш мизгелләре биешеп алды. Тик болар мәгънә егәрен югалткан буш хатирәләр генә иде инде. Шуна күрә ул алардан тизрәк арыну ягын карады, кабаланып пульт төймәләренә баскаларга тотынды. Сайлана торгач, табигать турындагы тапшыруда туктады. Ләкин анда да кадрлар алмашынып кына торды, күп тә үтми экранны Себер кышы күренешләре биләп алды.

Себер! Норильски дигәннәре шул Себер ич инде.

Дамирә телевизорнын шнурын йолкып сүндерде.

Бу халәттән аны телефон шылтыравы коткарды.

— Альбертым минем, жанашым, Альбертым...

— Ни булды сина, бик дулкынлангансын? — дип сүз кыстырды егет, ниһаять.

— Сагындым, кил!

— Нинди килү, без бүген төнлә Канарга очабыз бит, әллә онытып жибәрденме? Мәшәкать муеннан.

— Алайса үземне көт!

Дамирә сумкасын жилкәсенә элде дә фатирдан чыгып йөгерде. Машинасы гына ни сәбәпледер Альберт яшәгән йорт яныннан выжылдап кына үтеп китте. Тормозларга ул Солдат аналары комитеты урнашкан админстратив бина каршында басты. Анда рәис белән очрашты.

Дамирә кояш баеганда поездда иде инде. Кузгалып китүгә, Альбертка SMS-хәбәр жибәрде: «Мин Хәниф янына киттем. Барысы өчен дә рәхмәт. Хуш!»

*Васильево иҗат йорты.*
*01.07.2013.*

# Хәйдәр

## ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Гөлжиһан әби буявы унган, инде купшып коела башлаган рәшәткәгә сөялеп, беравык торды да авылга таба атлады. «Алтын йөгерткәнмени үзләренә. Яфрак коярга да өлгермәгәннәр», — дип уйлады ул, зираттагы агачларга карап. Алтынсу яфраклар исә: «Бөтен дөнья саргайган мәлдә каян килгән яшеллек бу?» — дип, карчыкның яшел яулыгыннан көнләшкәндәй, шыбырдашып куйдылар.

Гөлжиһан әби үзе моны сизмәде дә. Уйлары тынгылык бирми иде ана. «И, раббым! Дөньялыкта күрешергә насыйп булмагандыр инде... Кыямәт көннәрендә генә теләгемә ирештерерсең микәнни?..»

Зиратның теге дөньяга алып чыгучы капка түгеллеген бик яхшы белә ул. Теге дөнья дигәннәре әллә бар, әллә юк дигәндәй... Кем барып күргән дә, кем әйләнеп кайткан аннан. Кыямәт көннәре дип, болай гына әйтә инде... Дөньялыкта күрешүгә ни житкән?! Зираттагы агачларга сокланып йөрүе дә теге дөньяга ашыгудан түгел. Алай юрамый Гөлжиһан әби. Аннары, үлгән кеше белән кавышырга жыенмый бит ул. Исән кеше белән!

Тракторлар гөрелтесен тынлый-тынлый кайтты Гөлжиһан әби. Игеннәрне жыеп алгач, тунга сөрәләр. Тавышлары көчле булса да, күнелгә шом салмый бит, әй! Әллә улы Хәлим тракторда эшләгәнгәме икән? Алай дисәң, элек тә колакка ятышсыз тоелмый иде. Жанга нининдер якын аваз, моңлы аваз чыгаралар бит, кара инде, ә...

Тракторлар кыр ягыннан тырышып-тырышып киләсе ел унышы турында хәбәр салалар иде.

«Дөньялар үзгәрде. Мондый да имин елларда нишләп исән булмасын?! — дип уйлады Гөлжиһан әби. — Чегәннәр дә исән диделәр бит!»

Чегәннәр багуын берәүгә дә сөйләгәне юк иде әле аның. Дөрестерме-юктырмы «күрәзә» дигәннәре, анысын белсә, ахирәте Фатыйма гына белә инде. Сугылып чыгарга кирәк әле Фатыйма күршегә, нишләп ята икән? Хәлимнең кырдан эшен бетереп кайтырына да шактый вакыт бар. Оныклары да өйдә түгелләр. Кояш әнә төшкелектән авышты гына.

...Сугыш башланган елны Гөлжиһан белән Кави өйләнешкәннәр генә иде әле. Аларның гаиләсе бик бәхетле булырга тиеш иде югыйсә. Шулай булмыймы соң?! Алар бер-берсен яраталар иде бит. Кави да Гөлжиһанга теләп өйләнде, Гөлжиһан да Кавига теләп кияүгә чыккан иде. Түп-түгәрәк бәхет бер яктан кителә, диләр... Халык арасында таралган әйтемдәге хакыйкать Кави белән Гөлжиһанны урап узарга тиеш иде кебек. Аларның

бәхете бер яктан түгәрәк тоелса да, каралты-куралары, мал-туарлары әлегә юк иде. Бердәнбер дүрт почмаклы йорт. Аннары, гаилә бәхете бит ул бала булганда гына түгәрәкләнә...

Аларны кинәт башланган сугыш мәңгелеккә аерды да куйды... Егерме икенче июнь таңында сугыш башлану хәбәре Иштирәк авылына да килеп ирешТЕ.

1914 елгы Герман сугышын айкап кайтучылар бу сугышның тагын да шәфкатьсез булачагын, күп гаиләләрнең җимереләчәген сизенәләр иде, мөгаен; яшь егетләрнең сугышка җыенуларын күреп, алар лапас асларында яшеренеп сыгыла-сыгыла яшь түктеләр. Кеше алдында күз яше чыгармаска тырыштылар. Киресенчә, егетләрнең күңелләрен үстерергә теләптер, юату сүзләрен кызганмадылар.

— Сез ул мәлгуньнәрнең муеннарын тиз борырсыз, — диделәр алар. — Уракка төшкәнче кайтып житәргә тырышыгыз!

Күбесе Германия белән сугышуның ничек булачагын күз алдына да китерми иде. Ни төсле була ул сугыш? Тиктомалга ни өчен сугышып мәшәкатьләнергә соң әле? Шуңа күрә дә алар сугыш башлану хәбәрен тыныч кабул иттеләр. Бу хәбәр Кавины да артык борчымады.

— Кайту юк инде безгә... Күрешүләр насыйп булмас инде... — дип, башкалар елаша-елаша хушлашканны Кави үз хатынына күрсәтергә теләмәде.

Басу капкасын чыккач, Гөлжиһанны чаукалык буенарак алып китте дә култыклап алды.

— Мин, — диде ул, — исән кайтам. Шулхәтле кан коешырга нимес тә жүләр түгелдер әле. Син миннән үлде дигән хәбәр көтмә. Исәнлегем турында хәбәр килмәсә дә, кайгырма: барыбер кайтырмын.

Жигүле атлар район үзәгенә таба юл алдылар. «Вараксин» гармуннары өзгәләнеп «Шахта» көен башлап җибәрде. Ир-егетләр гармунга кушылып сузып-сузып җырлыйлар. Мәңгегә аерылышу ачысын шушы бер җыр үзенә ничек туплап бетерә алды икән?.. Кем чыгарды икән бу җырны? Мөгаен, дөньяның иң бәхетсез кешесе булгандыр ул... Бәхетле кешедән мондый үзәк өзгеч моңны көтәргә ярамый.

Сөйләшер сүзләре күп булса да, Кави белән Гөлжиһан эндәшмичә генә атладылар. Икесенең дә күңеле тулган иде. Аерылышуның никадәр авыр булуын икесе дә менә хәзер генә белделәр кебек.

— Печән чабармын дигән идем быел...

Моңа хәтле еламыйча түзеп барган Гөлжиһан ике кулы белән битен каплады да сукмак буена чүгәләде. Тавышсыз гына сулыга-сулыга елый иде ул.

— Йә инде, — диде, ни әйтергә дә белмәгән Кави. — Сабыр бул инде...

Гөлжиһанның күңеленә җыелып килгән барлык ачыргалануы тышка бәреп чыкты.

— Китмә, Кави! — дип, чирәмгә капланып илерә-илерә үкседе ул. — Ташлап китмә!..

Яраткан кешесенең шулай ярдәм сорап үксүен карап тору кызганыч иде. Никләр сугыш башлаган ул немец, кем уйлап чыгарган бу сугышны?! Кави иренен тешләде, үзе дә елап җибәрүдән чак-чак тыелып, Гөлжиһанны жирдән күтәреп торгызды.

— Сабыр бул... — дип әйтүдән башка сүз эзләп таба алмады. «Их, нигә дип төркемнән аерылырга иде!.. Кешеләр белән калса, аерылышуны җиңелрәк үткәрер иде», — дип үз-үзен битәрләде ул.

Алар култыклашкан килеш озатучылар төркеменә таба киттеләр.

Ичмасам, җырламасыннар иде, аерылышу да бу хәтле үк моңсу булмас иде.

— Нигә печән чабар идем диден, Кави?

Гөлҗиһан һаман да сулкылдый, тамак төбенә утырган төер аңа һич кенә дә сөйләшергә ирек бирми иде әле.

— Нигә дип... — Кави үзенең ниятен кычкырып әйтергә базмады. — Сабыр бул, Гөлҗиһан...

Кавинын ниятләре бик тә матур иде. Печән әзерләп, көзгә башмак тана сатып алмакчы иде ул. Балалары була-нитә калса, сөт кирәк бит! Моны Гөлҗиһанга әйтсән, тагын капланып елаячак инде...

Сөйләшер сүзләр инде беткән, түгеләсе яшьләр түгелгән. Гармун да «Шахта» көен сузмый, җыр белән күнелләрен басарга теләүчеләр дә тынып калган.

— Йә, ашыгырга кирәк! — дип кычкырды колхоз председателе. — Военкоматта көтәләр.

— Ие шул, — дип күтәреп алдылар ирләр анын сүзен. — Мәңгегә аерылышмыйбыз бит! Тиз генә барып кайтыйк та...

Янәшәсендә басып торган Фатыймага Гөлҗиһан шунда гына игътибар итте: бер баласы итәгенә асылынган, берсен кулына күтәргән. Гөлҗиһаннын, ичмасам, баласы да юк бит! Бер ялгызы кала... Ичмасам, Кавинын төсе итеп үстерер иде. Анын күз төбен тагын яшь каплады... Ул башын күтәреп Кави киткән якка карады: сугышка китүчеләр төркеме күз яшьләре аша әллә нинди шомлы булып күренде.

Шул китүдән Кавинын хәбәр-хәтере булмады.

Хат ташучыны ул көн дә көтеп ала торганга гадәтләнде. Кырга эшкә киткәндә күршеләренә әйтеп калдыра иде:

— Мин кайтып өлгермәсәм, хат килсә, югала күрмәсен.

Юк, Кавидан хат килмәде.

Көзге көннәрнен берсендә Фатыймага ире үлү турында кайгылы хат китерделәр. Бу хәбәрне ишетүгә, Гөлҗиһан ахирәте янына ашыкты.

Ике баласы сәке читендә утыра. Аларнын йөзләренә ятимлек төсмере инәргә өлгергән. Фатыйма инде елап арыган, озак елаудан күз төпләре шешенеп беткән, өзек-өзек сулкылдап кына куя.

— Кайгырма инде, Фатыйма,— диде ни әйтергә белмәгән Гөлҗиһан,— минә минекенен дә хәбәр-хәтере юк бит әле...

Фатыйма бер ноктага караган килеш озак утырды. Ахырда:

— Синен үле хәбәре килмәде, ичмаса, — дип, сәкегә капланып үксергә кереште. Өлкәннәрнен сәерлекләрен карап утырган балалар да ана кушылдылар...

Ул көнне Гөлҗиһан Фатыймаларда гына кунды.

Менә хәзер алар әйтерсен лә әле генә йокыдан торганнар. Кайгыдан елашып утырулары да гүя кичә генә булган. Тик ни өчендер танымаслык булып үзгәргәннәр генә: битләрендәге җыерчык араларына бетмәс-төкәнмәс сагыш-моң сенеп калган...

— Кайтмадылар шул...

Гөлҗиһан карчыкнын тавышында һаман да өмет чагыла иде. Кайтырга вәгъдә итеп тә соңга калганнар диярсен...

— Синен, ичмасам, үле хәбәре килмәде. Ходай биреп кайтып та төшәр әле, — дип, Фатыйма карчык анын күнелен тагын да алгысытып җибәрде. Чегәннәр турында сорашырга ин унайлы чак иде. Чәй эчкән арада, Гөлҗиһан әби җайлап кына узганнарны кузгатырга кереште.

— Карале, Фатыйма, элгәре авылга чегәннәр килерие. Хәтерлисеңдер инде?..

— Хәтерләмимме соң! — Фатыйма әби бал белән майны ахирәтенәрәк этәрде.

— Хәзер бер дә күзгә-башка чалынмыйлар. Кем биздергәндер мескенкәйләрне.

— Шәһәрдә ди алар. Авылга килеп чыкмыйлар шул менә.

— Яңалык була торганые шуларның күренеп китүе. — Яңалык булмый ни! Башка халык бит инде. Киенүләренә хәтле.

— Башка халык та соң... Безнеңчә дә беләләрие бит алар.

— Әйтмә! Каян өйрәнгәннәр диген, әй.

— Берсе хәтеремнән һаман да чыкмый. — Ахирәтеннән җавап сүзе ишетмәгәч, Гөлҗиһан әби тагын өстәп куйды:

— Берсе хәтеремнән һаман да чыкмый. Күңелгә өмет салды да... — һәм яшел яулыгының почмагына күз яшьләрен сөртеп алды.

Фатыйма әби эндәшмәде. Авырткан җиренә кагылырмын дип курыкты бугай.

— Чегәннәрен дә әйтерием. Күңелгә өмет салдылар да... Шуннан бирле күренмиләр.

...Сугыштан соңгы еллар иде бу. Кызу печән өсте.

Авылга чегәннәр якынлашуын малай-шалай әллә каян ук шәйләде: «Киләләр! Тегеләр!..»

Бу сүздә кызыксыну чагылса да, хәвефләнү дә бар иде. Ничек хәвефләнмисең инде. Чит-ят кеше ни кылмас. Ходай белсен. Нинди ният белән киләләрдер бит әле?.. Ярый ла бәла-казалы булмасалар. Мона хәтле дә күренгәләгәннәре бар иде, анысы. Кайберләре өй борынча хәер сорашып йөриләр. Шунысы кызык: ипи сыныкларына да, бәрәңгегә дә, оңга да — һәммәсенә аерым капчык тота андыйлары. Каян табып бетергәннәрдер шулхәтле капчыкны, ничек көчләре җитәдер күтәрергә. Урлап алмагач, рәхмәт инде. Кайсылары вак-төяк белән сату итә. Берсен дә гаепләрлек түгел — тамак туйдырырга кирәк бит. Нишләтәсең инде — тир түгәргә өйрәнмәгән халык шул. Бар белгәннәре җыр да бию, күңел ачу.

Болары нинди хикмәтләр күрсәтер тагын. Эшкә яраклы бөтен кеше болында. Авылда карт-коры, бала-чагадан гайре адәм заты да юк, ичмасам.

Чегәннәр килүен ишетүчеләр капка төбенә чыгып басты. Кулларын каш өстенә куйдылар да басу капкасы тарафын күзәтергә тотындылар.

— Күче белән киләләр.

— Ир-атлары юкмы?

— Әллә балаларын да ияртkәннәр инде.

— Ир-атлары белән йөрми бит алар.

— Нигә икән?

— Үзләреннән сора, Мәхүбҗамал җиңги. — Монысын чуар Рәис әйтте.

— Әйбер-фәләнгә кагылмыйлардыр бит?

— Соныннан әйтермен, Мәхүбҗамал җиңги.

— Ходай сакласын...

Бу сүзләрне ишетүгә, малай-шалай җитдиләнеп китте. Алар хуҗа ич авылга! Бер-бер хәл була калса... Олылар күзне дә ачырмас. «Куркаклар икәнсез», — диярләр. «Сезгә моннан ары ышаныч бетте», — диярләр.

— Минем янга! — дип кычкырды арада бер башка калкурак Хәлим.

Малайлар гаярьләнделәр. Аннары дәррәү кубып басу капкасына элдерделәр.

— Кертмәскә кирәк аларны.

— Капканы бикләргә.
— Таш белән куабыз.
— Кире борылсыннар!
— Ә сина, — диде Хәлим Чуар Рәискә, — эләгер әле...
Ләкин малайларның планы барып чыкмады.
Тегеләр әкрен генә киләләр дә киләләр. Бер чегән малае бозау кадәрле эт житәкләгән. Юк, мондый бурзайга каршы торырлык эт юк авылда. Торса, тегермәнче Микулайныкы гына каршы торыр. Әмма тегермәнче эте малайларның кан дошманы иде шул.
Ә чегәннәр әкрен генә якынаялар. Үзара сөйләшәләр.
Шул вакыт алгарак йөгереп чыккан кечкенә кызыйлары борыны белән юл тузанына капланмасынмы! Чуар Рәис түзмәде, көлеп жибәрде. Көлүе — көчек ләнгелдәвемени... Бу авазга чегәннәр бурзае колагын шомрайтты һәм кинәт, хужасын өстерәп, малайларга ыргылды. Көчек бар дип белде, ахрысы.
Малайлардан жилләр исте.
Чегәннәр авылга озын итәкләре белән тузан туздырып килеп керделәр.
Аларның өй борынча йөрүен малайлар башта читтән генә карап тордылар. Бераздан кыюлыклары артты. Чегәннәр керәсе йортның ишегалдына кереп тулдылар да капканы бикләп куйдылар. Чиләкләргә, чүмечләргә су тутырып, койма янына барып бастылар.
— Өсләренә сибик, — дип сүз куештылар. Койма ярыгыннан карый-карый чегәннәрне көттеләр.
Менә өлкән генә бер чегән хатыны капка келәсен шакылдатып алды. Ул да булмады, койма өстендә малайларның башлары күренде. Бурзай, аларны күреп, буыла-буыла өрергә тотынды. Котлары очты малайларның, берәм-берәм жиргә сибелештеләр. Акырышкан, чиләк-чүмеч шалтыраган авазларны ишеткәч, чегәннәр, сукрана-сукрана, икенче йортка күчтеләр.
Гөлжиһан апа печән жыюдан кайтып килә иде. Койма ярыгыннан әнисен күргәч, Хәлимгә жан керде.
— Әнкәй! — дип кычкырды ул.
— Кайда син? — дип, Гөлжиһан апа башын боргалады. Койма өстеннән Хәлимнең башы калыкты.
— Нишләп йөрисең анда, чит кеше каралтысында?
— Чегәннәрдән качтык.
— Нигә качасың? Нигә куркасың? Алар кешегә тими бит.
— Тимәс! Бурзайларын гына кара син аларның.
— Әйдә, улым, кайтабыз.
Атаманнары киткәч, бүтән малайлар да әкрен генә таралыштылар.
Хәлим күргәннәрен энәсеннән жебенә чаклы әнисенә сөйләп бирде.
— Шул Чуар көлеп жибәрмәсә, — диде ул, — чегәннәр бурзае кумыйдырые да безне.
— Гомерләре озын булыр боларның. Әнә безгә дә керәләр, — диде Гөлжиһан апа.
Чынлап та, кап-кара чәчле, жәйге челлә булуга карамастан, шактый ук керләнгән калын яулык бәйләгән, чәчәкле озын күлмәк кигән бер чегән хатыны жилкапканы ишегалды ягыннан ябарга азаплана иде. Бу халыктан бик шикләнмәсә дә, Гөлжиһан апа аны өйгә кертергә теләмәде — каршысына чыкты.
Чегән хатыны керешли авыз эченнән нидер мыгырдана, ялт-йолт тирә-ягына карангалый иде. Гөлжиһан апаны күргәч, кулын сузды да

анлашылмаган телдә нидер сөйләргә тотынды. Гөлжиһан апаның сәерсенеп торуын күргәч, татарчага күчте:

— Синең чәчең коела икән. Чәчеңне жыеп йөр. Бозганнар сине, коелган чәченне табып алып сихерләгәннәр.

Гөлжиһан апа тораташ булды. Әйе шул, чәче коела. Каян белә ул аны?..

— Кара менә бу көзгегә, әйбәтләбрәк кара. Ике дошманың бар синең, шуларны күрерсең!

Монысын ук көтмәгән иде Гөлжиһан апа. Чит кеше була торып, каян белә диген. Бигрәкләр туры китерә бит!

— Син курыкма, — дип тынычландырды чегән хатыны, — курыкма миннән. Мин сиңа бәхет юрыйм бит.

Гөлжиһан апа чигенә-чигенә өйгә керде. Телен әйләндереп сынар сүз әйтергә өлгермәде, чегән хатыны бөтен ипи сорап алды. Һәм ипигә тиз-тиз ниләрдер сызгаларга кереште.

— Ирең сугышта булган икән. Ул исән. Кайтачак. Аны дошманнарың бозган. Кабат чәчеңне жыеп йөр. Ныклабрак кара, әнә ипи дә читлек күрсәтә, — дип сөйләнде чегән хатыны, үзе сызган аркылы-торкылы сызыкларга ишарәли-ишарәли. — Котылыр ирең. Тик ипи миндә булырга тиеш.

Аңлаштылар. Әллә нинди сызыклар сызгаласа да, мондый яхшы күнелле күрәзәчегә түгел, гап-гади хәерчегә дә бирерсең ипиеңне.

— Ал! — диде Гөлжиһан апа. — Кайтсын гына берүк.

Чегән хатыны югалды.

Өмет калды.

Әлеге өмет һаман да сулмый, һаман да саргаймыйча яши бирә.

Кайтачак, кайтачак! Улы да көтә бит аны. Хәлим исемле улы барлыгын да белми бит әле этисе. Кайларда йөридер шул гомер?!

Гөлжиһанның ире сугышта булуын, аның исән калуын каян белгән диген чегән хатыны? Дусларын, дошманнарын каян белгән?

Фатыйма әби сүзсез генә утырды. Гөлжиһанның ире сугышка китүен дә, дусларын-дошманнарын да чегәннәргә ул сөйләгән иде... Фатыймадан сорашканнар иде. Әмма исән калуын бераү дә белми. Исән калуы — чегәннәр күнелгә салып киткән өметтә генә. Алар бераүгә дә начарны юрамый шул.

Гөлжиһан әби чыгып китте. Фатыйма әби серне ачмады, өнсез генә карап калды. Өй каршындагы саргайган юкә агачы да Гөлжиһан әбинең яшел яулыгына карап калды... Күпме күз яшьләре дә уңдыра алмаган, кайчандыр ире туй бүләге итеп биргән, иренең төсе буларак сакланган яшел яулык...

1978

Наил
Шәрифуллин

# МЕҢ ТИЛЕНЕҢ КҮМӘК АКЫЛЫ
## яки
# ГЫЙЛЕМЛЕЛЕК «ЗАРАРЫ» ХАКЫНДА

«Күп белсәң, тиз картаерсың». Һәр шаяртуда азмы-күпме дөреслек бар дисәләр дә, бу очракта ул нәкъ киресенчә. Күп белү, мәгълүмат кабул итеп, аны «эшкәртеп» тору, китап белән дус булу, акыл хезмәте, кыскасы, башны даими эшләтеп яшәүнең гомерне озынайтканлыгы билгеле. Ягъни эштәге тимер тутыкмый. Әмма ки кемнәргәдер без күгәргән килеш тә бик ярап торабыз икән бит әле. Россиядә наданлыкка янә бер адым ясалу ихтималы юк түгел. Ул да булса, илдәге урта белем бирү системасын түләүле итү турында сүзләр әледән-әле куергалап ала.

«Күп белсәң, тиз картаерсың». Татарчага «тәрҗемә иткәндә» надан озын гомерле була дигән сүз бит инде бу. Ягъни Марсель Гали яратып һәм үз итеп, «наданым» дип дәшкәннәр, барысы да, кем дигәндә сиксән-туксанны тутырмыйча Ходай хозурына китмәячәкләр дию. Әмма ки наданлыклары аркасында микән? Ошбу сүз белән ул урам себерүчеләргә түгел, ә каләм тибрәтергә алынган акыл хезмәтендәге халыкка дәшә булыр. Ә соңгыларының, алда китерелгән дәлилләрне дә истә тотып, озак яшәргә шанслары җитәрлек.

Тик, гомумән алганда һәм җитди сөйләшкәндә, рустан кергән мондый әйтем, «Эш тилене ярата ул» («Работа дураков любит»), «Гомереӊ буе укы — дивана булып үләрсең» («Век живи, век учись, все равно дураком помрешь») кебек мантыйксыз башка әйтем-мәкальләр белән бергә, бары юләрләр иле Россиядә генә ярала һәм яши аладыр. Электән килгән үзенчәлекле психология, аң-белемгә, хезмәткә булган аңлаешсыз һәм кире мөнәсәбәт, рациональлектән, акылдан ерак яткан ниндидер очсызлы кыйммәтләр. Биредә син артык акыллы, гыйлемле булма, уңышка түгел, киресенчә, бәхетсезлеккә, бәлагә таруың бар. Данлыклы «Акыллылык бәласе» дә башка ил-җирләрдә түгел, шушында — Россиядә туган бит. Үзеңә дә, башкаларга да, инде килеп бигрәк тә төрле дәрәҗәдәге башлык-түрәләргә синең тилемсәрәк халәтең, мокытлыгың мәслихәт. Бары биредә генә элек-электән, төрле «блаженный»ларны изгегә санап, алар хөрмәтенә олы чиркәүләр салганнар. Бары монда гына мич башыннан да төшмәгән ярымдивана һәм ялкау Емеляларның патша кызын алуы турындагы һәм башка шундый әкиятләрне хәзер дә исләре китеп тыңлыйлар. Менталитет шундый инде ул!

Ярар, наданлык белән юләрлек, шуларга ияргән ялкаулык һәм булдыксызлылык, бу илдә һаман модада калып, консервацияләнеп тә килсен ди. Ә гомер-гомергә гыйлем эстәргә яраткан, белемле затка олы хөрмәт белән караган, китапны өйнең иң түрендә тоткан татар нишләргә тиеш булып чыга? Без бит, ни кызганыч, шушы Идел-Чулман төбәгендәге җирләребезне күтәреп Айга менеп китә, гыйлем системасын анда үзебез дигәнчә корып, үзебезчә укый-укыта, гыйлемгә хиреслекне шул рәвешчә канәгатьләндерә алмыйбыз. Шушы гөнаһлы җирдә, Россия уртасында кала киләбез. Гыйлем бирү юнәлешендә Мәскәү безне болай да стенага китереп терәде инде. Тик анысы турында соңрак.

Түләүле урта белем ни дигән сүз соң ул? Очын-очка кыенлык белән генә ялгап килгән бик күп ата-аналар өчен балаларны укытмау, надан калдыру дигән сүз. Уй сөрешен дәвам иткәндә бүген халыктан өстәмә акча савып, иртәгә, илнең киләчәгенә балта чабу...

Дөнья кызу темплар белән үзгәрә, алга бара. «Туганыбызның» мәкаль-әйтемнәре тормышны үзләренчә сукаласалар да, егерме беренче гасырда аларга ияреп, элекке холык-фигыль белән әлләни ерак китеп булмаячак. Заманнан артта калмау, белемлелекнең милләт өчен бөек хәзинә икәнен аңлау ифрат та зарур. Белем белән мәгълүмат — бүгенге дөньяның беренче кыйммәтләре. Тик юк — биредә һаман да үз туксаннары туксан. Гыйлемгә аңлаешсыз караш Россиядә урта белемгә булган яки булачак мөнәсәбәт белән генә һич чикләнми. Узган ел азагында «Мәгариф турында закон» дип аталган закон проектын тикшергәндә Дума трибунасыннан Владимир Жириновский ясаган чыгышны сүзгә-сүз китерәсем килә. «В любом законе об образовании заложена революция. Чем больше высокообразованной молодежи, тем она опаснее для нас. Они будут свергать власть каждые 10 лет. Надо сдерживать образование, если мы хотим стабильности. Все правильно делал Николай I — на каторгу декабристов. Слишком образованные были русские офицеры».

Менә моннан соң күп нәрсә яңадан үз урынына баса да куя. Чикләвек һаман да юкәдә икән бит. Без, заманга ияреп, гыйлемне алгарыш синонимы итеп кабул итәбез, үзгәрешләр көтәбез тагын. Традицияләрне сакларга — мәгарифне, гыйлемне дәүләт дәрәҗәсендә тыеп торырга, авызлыкта тотарга кирәк икән ич. Дума депутаты гына түгел, вице-спикер һәм сан ягыннан илдә өченче урынны биләгән сәяси партия җитәкчесенең сүзләре бит бу. Эш бит бер «юрист улында» гына да түгел, эш тирәндәрәк. Айныкның уендагы — исерекнең телендә диләрме әле. Хакимият уйлаганны, кылырга җыенганны баш либерал-демократның югары мөнбәрләрдән беренче белдерүе, киртәгә менгән әтәч кебек, бер бүген генә сөрән салуы түгел.

Түләүле урта белем кертүнең томаналар ишәйтүдә янә бер адым булачагын исбатларга кирәкми. Ишәйсеннәр, тагын да кыргыйлансыннар, ник шунда маймылга әйләнеп агач башына менеп китмиләр. Өстәгеләр иминлегенә генә җил-давыл тимәсен. Ни соң бу? Хакимияттә калу, үзләренә кулай бүгенге вәзгыятьне саклау өчен иң мәгънәсез юллардан да баш тартмау, җирәнмәүме? Әллә егерме беренче гасыр инквизициясеме? Караңгылыкның хакимият тарафыннан хуплануына хәтта ышанасы да килми. Тик утсыз төтен булмый. Наданнар белән идарә итү күпкә җиңелрәк шул. Зиһен йокысы албастылар тудыра дигән кебек, караңгы халык караңгы җитәкчелекне тудыра. Җитәкчелек, үз чиратында, ул караңгылыкны тагын да куерту ягында. Россия дигән дәүләт бүген, өстенлекле титул милләт — русларны гына түгел, алардан да бигрәк ил бөтенлегенә һәрдаим «олы куркыныч тудырып торган» милли азчылыкларны да җитәкләп, шул йомык әйләнә буенча йөри дә инде...

Без татарларга ул әйләнәне ничек булса да ертып чыгарга кирәктер. Башкача булмый. Гыйлемлелек, бигрәк тә милли аң һәм белем – исәнлегебез гарантиясе ул. Мәгарифтәге һава торышы һәрчак Мәскәүдә яралып, бу юнәлештә безне моңа кадәр җитәрлек кактылар һәм суктылар. Безнең милләткә киләчәктә, бигрәк тә гыйлем сәясәтендә, һәрдаим сукырларча Мәскәү фарватерында бару өҗәлгә тиң. Чигенүнең дә чиге була. Миңа калса, без ул чиккә килеп терәлдек тә инде. Барысы да булды. Татар-төрек лицейларын ябудан, җанга тигән 309нчы кануннан, БДИны татарча бирдертмәүләрдән башлап, Гуманитар институтны бетерү, Милли университетны ачтырмауга кадәр. Болар ни өчен эшләнә соң? Россия җитәкчелеге шушы XXI гасырда да колониаль стандартлардан аерыла алмый интегә. Колония гыйлем ягыннан метрополия белән тигезләшсә, яки аны узып китсә империя белән ни-нәрсә буласы билгеле.

Милләтнең гыйлем дәрәҗәсе, аңы бүгенге дөньяда бик күп нәрсәне, шул исәптән аның киләчәк язмышын – бәхете белән бәхетсезлеген, ирекле яки ирексезлеген, башка халыклар арасындагы урынын билгеләп килә. Һәм

киресенчә, ирексезлек аша халыкны наданлыкта тотып була. Шушы принципны бик яхшы аңлаган Мәскәү чын федерациягә юл ачтырмаган кебек, Татарстанга да Россия белән берләшкән суверен дәүләт булу мөмкинлеге бирелмәде. Әмма Татарстан барыбер ул форматка тартылмый, үз дигәнен эшләргә, үз сүзен әйтергә тырышмый дип тә бик әйтеп булмыйдыр. Республикабыз, авторитар дәүләттә, каты хакимият вертикале шартларында, шикле закон кырында, биредә булдырганның ким дигәндә дүрттән өч өлеше Үзәккә алынып торганда да тырыша, эшли, таба, яши. Ул гына да түгел, санаулы донор-регионнар белән бергә ул Россия дигән алагаем илне локомотив урынына тартып. Шулай булгач, хәлиткеч мәсьәләләрдә үз сүзебезне әйтергә безнең тулы хакыбыз бар булып чыга. Әйтергә генә түгел, үз дигәнебезчә эшләргә дә.

Икътисадта без үз юлыбызны таптык кебек. Икътисади уңышларны ипләп кенә милли-сәяси казанышларга әверелдерә, милли проблемаларның уңай чишелешенә ирешә башласак, инкыйраз куркынычын бетерсәк – бу, аз да түгел, күп тә түгел, яңа, әле тарихыбызда күрелмәгән яңарыш, татар күпме гасырлар хыялында йөрткән Яңа татар ренессансы булыр иде.

Россия белән мөнәсәбәтләр, икътисад турында сүз чыкканда кайберәүләрнең Татарстан моделе Россияне дә үзгәртергә тиеш дияселәре килә. Без каршы булмас идек тә. Ләкин «состав» артык зур, менталитет кире. Тәгәрмәчләргә тыгылган таяклар... Күпме генә булдыклы, гыйлемле, эшчән, тырыш булсак та, бер Татарстан гына Россияне хәзерге аңлаешсыз, ипсез халәтеннән, мәгарифтәге кыеклыклардан, бөекдержавачылыкның яман чирләре – милли азчылыкларны ирексезләүдән, гаделсез һәм мәгънәсез «ясак» системасыннан, чималчылыктан, гиперүзәкләштерү аркасында туган икътисади һәм социаль деформация-гариплекләрдән, законлаштырылган наданлыктан колагыннан тартып чыгара, коткара алмаячак. Әмма тамчы тама-тама ташны тишә. Татарстанның илгә йогынтысы булды һәм бар. Вакыт та алга бара. Россиянең дә, бөтенләй юкка чыгасы килмәгәндә, кыйбласы, холык-фигыле, хәл-әхвәле, гыйлем дәрәҗәсе иртәме-соңмы барыбер үзгәрәчәк, караңгылыгы, тарихи артталыгы, империячел традицияләре дә, киму ягына юнәләчәк, «караңгы урта гасырлары» тарихта калачак дип ышанасы килә. Әмма яхшы «һава торышын» көтеп кул кушырып утыру да — булдыксызлар шөгыле. Әлегә, сәясәттән читтәрәк торып, күбрәк икътисад белән, Казанның меңьеллыгы, Универсиада кебек глобаль проектлар белән шөгыльләнсәк тә (алар да бик кирәк), без, татарлар, үзебезне саклауга, исәнлеккә генә түгел, әйткәнебезчә, яңарыш-үсешкә дә ышаныч тотып яшәргә тиешбез. Шул исәптән яңача, заманча куелган, куелачак милли гыйлем системасы аша да.

Мегапроектларга киткән көчнең бер өлешен безгә милләтнең белемен, милли аңын үстерү ягына ныклап бору кирәктер. Моның өчен, беренче чиратта, үз белем стандартларыбызны (мәсәлән, шул ук татарча БДИ, ВУЗларда татарча укытуны җайга салу, Милли университет) булдыру зарур. Моңа омтылыш юк түгел. Тик тагын да шул Мәскәү куйган киртәләр. Дәүләт Советының бу тармакта актив эшләп килүче комитетына югары җитәкчеләребезнең ныклы теләктәшлеге җитенкерәми кебек. Гражданнарыбызның булышлыгын инде әйткән дә юк. Әлеге юнәлештә, бәлки, бер кечкенә «бунт», Мәскәү белән якалашып алу кирәктер? Аларның тамагын туйдырып торып, ни өчен әле без һаман да дәшмәскә, үзсүзләнмәскә тиеш ди? Толерантлык, тыйнаклык, койрыкны бот арасында тоту бер дә безнең файдага эшләми. Кирәк булганда сыртны кабартырга өйрәнмәсәк, безнең белән беркем дә исәпләшмәячәк. Үзебезгә, үзебезнең көчкә ышанганда гына без башкаларны да ышандыра, аларның кәкре юлда икәнен исбатлый алачакбыз. Эчке энергетика, Гумилевча билгеләгәндә, пассионарлык бар әле татарда. Без – «ташлар басып» та исән калган, чыныккан милләт бит. Тик без һәрчак ниндидер импульс, этәргеч, яшен яшьнәгәнен көтәбез. Милли аспектта эзлекле көндәлек эшләр майтарырга өйрәнәсе, ташны тишүче тамчы буласы иде безгә. Ә болай «безнең көннәр ташу кебек шаулап килер» диярге иртәрәк әле.

Россиядә җылы җилләр исә башлаганын, демократик үзгәрешләр көтеп без, дөресен әйткәндә, арыдык инде. Тотрыклылык, стабильлек дигән булып, дистә ярым ел буе Россия бер урында таптануын дәвам итә. Наданлык стабильләшеп кенә калмый, куера да тора. Наданлык тудырган караңгылык исә — режимны

саклап калуның беренче гарантиясе. Әмма ки, хакимият шамакае — баш либерал-демократ барыбер белеп кыбырсый: XIX гасырда Европада «коммунизм шәүләсе» йөргән кебек, күптин-күп гаделсезлекләр күзгә төртелеп торган Россиядә соңгы елларда чыннан да инкыйлаб шәүләсе йөри. Ул «төсле революция» рәвешендә, яисә гарәп фетнәләре кебек буламы, әлегә билгесез. Шунысы ачык, давыл килсә, бүгенге хакимияттән кол өемнәре генә калырга мөмкин. Власть моны аңлый. Ни өчен бүген Көч структураларындагы сары авыз — лейтенант 25 еллык эш стажы булган укытучыдан ике-өч тапкыр күбрәк хезмәт хакы ала дип беләсез? Инкыйлаб өрәге Россиядәге иң югары хакимиятне гыйлемгә, фәнгә, алдынгы икътисад белән сәнәгатькә (промышленность) таянасы урында шушы заманда да көчкә — армия белән полициягә таяндыра. Ә бу хәл Россияне хурлыклы режим — полиция дәүләте итеп кенә калмый, илне тагын да бер йомык әйләнә эченә кертә. Һәм казыкка бәйләгән кәҗә тәкәсен йөрткән кебек, шунда миңгерәүләтеп әйләндереп йөртә.

«Алтын бозау», акча культы болай да халкының акылын, зиһенен томалаган чорда, штыклар гына тоткан империядә, урта белем бушка калып килгән нисбәттә дә, властьларның кире, булдыксыз һәм куркак сәясәте аркасында гыйлемлелек соңгы ике дистә елда күрелмәгән девальвация, ягъни очсызлану кичерә килә. Шушы җәһәттән югары белемнең бүген ни дәрәҗәдә югары булуын күпмедер ачыклап китү дә артык булмастыр.

## Ялган укымышлылык

Пәйгамбәребез безгә гыйлемгә бишектән алып ләхеткә кадәр омтылырга кушкан. Бу бик аңлашыла. Аң-белемле, мәгърифәтле булудан да күркәмрәк сыйфат бар микән адәм баласы өчен. Ул гына да түгел, миңа калса, кеше, үзе яшәгән җиһанны чын-чынлап аңларга тели икән, белемне бер юнәлештә, тар белгечлек кысаларында гына түгел, булдыра алган чаклы киң, энциклопедик масштабта да үзләштерергә омтылырга тиеш. Шулай булганда дөнья да яктырак, офыклар да киңрәк, җирдә яшәүләре күпкә күркәмрәк, кызыграк, кеше үзе дә чистарак, кешелеклерәк булыр иде. Әмма, кызганыч ки, акча бизгәге дер селкеткән, шомалык, мутлык тантана иткән җәмгыятебездә, Россия дип аталган илдә, төпле, фундаменталь югары белем урынына псевдобелемлелек, псевдодипломнар, ягъни укымышлы булып кылану шаукымы модада.

...Кайчандыр кызым белән бергә мәктәпне тәмамлаган укучыларнең сиксән-туксан проценты ВУЗ студентлары булып алдылар. Кайсылары — бетерү белән, икенче берләре бер-ике ел соңрак. Кемдер (дүрт-биш бала) бюджет группаларында «энә белән кое казыды», башкалар (күпчелек) шул ук көндезге бүлекләрдә, ләкин түләп сабак алды. Акча түлә дә, шуңа өстәп көн саен укуга да барып йөр диептер инде, иренеп, читтән торып кына гыйлемле буласы килүчеләр дә шактый иде. Инде ашыгып, укып мәшәкатьләнмичә генә, дүрт ел үтәр-үтмәстән ук, диплом сатып алганнары турында да сүзләр ишетелгәләде. Бер сыйныф мисалында гына да менә шундый хәлләр. Сыйныф кынамы соң, аң-белемнең иң югарысына «сусау», инде ике дистә еллап булыр, ил масштабында гөрләп чәчәк ата шикелле. «Белем бумы». Мәктәпләрдә отличниклар, яхшы укучылар егерме, утыз процентттан артмаганда ул сиксән-туксан процентның күпчелегенә белем түгел, бары диплом гына кирәк. Һәм алар аны алып та киләләр.

Бер фикер иясе әйтмешли, мең тиленең күмәк акылы бер акыллы кешенең ипле акылы белән тиңләшә алмый. Безнең очракта «тиле» сүзен «надан»га алыштырганда да ярар иде. Тик хикмәт анда түгел. Россиядә болар — тиңдәш сыйфатлар. Биредәге кавем тилемсә булганга надан, надан булганга тилемсә бит. Французлар bien ou rien, ягъни, булса яхшы булсын, яхшы булмаса — гел булмасын, диләр. Сан түгел, сыйфат кирәк бит! Ә сыйфат юк һәм көтелми дә. Бүгенге кайбер югары уку йортлары өләшкән диплом совет чорындагы техникум, ПТУ дипломыннан да кайтышрак. Мәктәптәге чыгарылыш имтиханнарын көчкә «өчле»гә биргән, ПТУ көткән булачак потенциаль сантехникларга, ташчы, штукатур-малярларга ВУЗ дипломнары өләшеп дәүләт тә, җәмгыять тә бик нык оттыра. Иманым камил, чын белемне хәзер дәүләт карамагындагы ВУЗларга кереп, сәләтләре һәм тырышлыклары аркасында андагы бюджет группаларына эләгеп,

«белем гранитын» үзләрен укыткан укытучыларны ришвәткә ымсындырмаслык итеп «кимерүче» шактый аз санлы контингент кына алып килә булыр. Андыйларның җитмеш-сиксән проценты — бай булмаган гаиләләрдән чыккан, акчаның тылсымлы көченә өйрәнмәгән балалар. Авыл балалары да күбрәк шундыйлар арасында. Әлеге аз санлылар илнең киләчәге, аз-маз өмете дияр идем. Булачак сәләтле инженерлар, табиблар, укытучылар, галимнәр — киләчәктә туачак яңа техника, технология, яңача дәвалау һәм белем бирү, яңа ачыш авторлары. Әмма, кызганыч ки, бюджет группалары кимүгә юнәлтелгән. Икенчедән, тырышлык әҗере көннән-көн кимеп, гыйлемлелек бәясе дә, хәл үзгәрмәгәндә, бетүгә таба бара. Бераздан чын диплом иясе, үз юнәлешен камил белгән квалификацияле белгечләр Россиядә бөтенләй калмаска да мөмкин. Узган ел әйдәп баручы техник ВУЗларга кергән беренче курс студентларының математика буенча белем дәрәҗәсен тикшергәннәрен язганнар иде. Нәтиҗәләр шаккатмалы. Студентларның 70 проценты «икеле», 20 проценты «өчле» алган. Ә бит бер 20-25 еллар элек мондыйлар урта белем турындагы аттестатны да ала алмаган булырлар иде.

Илдә нинди дер тоташ күз буяу, имитация, чынны ялган белән алыштыру, җиңелне эзләү шаукымы. Мәктәпне бетергәндә үзеннән бигрәк әтисенең кесәсенә ышанып, шул кесә ярдәмендә түләүле төркемгә кергән, анда «акча түләнгән, дипломны барыбер бирми калмаячаклар» дип элкен-селкен йөрүчеләрнең хәтсез өлеше, «белгеч» булып алгач та, бүген башка, үзенчәлекле юлны сайларга, карьерада да «ат йөреше» ясарга тырышалар. Табадан төшү белән дигәндәй, «майлап-җайлап» начальниклеккә омтылган һәм булган, әле шуның өстенә чын белгечләр белән җитәкчелек итә башлаган кичәге «блатной» студентлар җитештерү өлкәсендә дә, башка даирәләрдә дә очрап тора. Имтиханнарны, дипломны сатып алган кебек алар җылы урынны, кәнәфине дә сатып алалар. Россиядәге бозыкбашлылык шул дәрәҗәдә ки – биредә парламент депутаты урыныннан башлап теләсә нинди кәнәфине сатып алырга була. Кесәң генә калын булсын.

Бүген яшәсә, Ленинннан «кадрлар барысын да хәл итә» дигән гыйбарә калыр иде микән? Кадрлар алар белгечләр генә түгел, шулук җитәкчеләр дә бит. Ришвәт биреп урнашкан надан башлыктан да начары бар микән? Надан белгеч җәмгыять өчен бер бәла булса, надан җитәкче — биш бәла. Миңа калса, илдәге проблемаларның бер өлеше төрле рангтагы профессиональлек, гыйлем, кешелеклелек җитмәгән шул башлыклардан, аларның наданлыгы тудырган мәгънәсез дуамаллыклардан килеп чыга. Ун сыйныф белемле, сатып алынган дипломлы бер таныш башлык, мәгълүм мәкальне үзгәртеп, «Белеме булган берне егар, акчасы булган меңне егар» дияргә ярата. Заман өчен, Россия өчен дөрес сүзләр бу.

Белгеч һәм эш. Илдәге статистика ВУЗ бетереп чыккан белгечләрнең яртысыннан күбесенең үз белгечлекләре буенча эшләмәүләрен искәртә. Бу да аңлашыла. Халыктан акча имүне генә күздә тоткан, гыйлем бирү икенче планда торган «эшкуар» институтлар өчен кичәге студент эш тапты ни дә, тапмады ни, барыбер. Монысы — беренчедән. Икенчедән, «белгеч»нең үзенә дә, үз юнәешендә белгәннәре сайлыгын истә тотып, икенче, дипломга бөтенләй катнашы булмаган эштә эшләү кулайрак. Һәрхәлдә, наданлыгы алай ук кычкырып тормый. Ягъни белемсезлек һәм аннан-моннан йолкынган белем наданлыкның дилетантлык, һәвәскәрлек дип аталучы вариантларын тудыра.

Псевдодиплом иясенә белгечлеге буенча эшләргә белем сайлыгы комачауласа, эшче булырга югары белем турындагы «катыргы»сы киртә. Ул бит үзенең дипломлы надан икәнен барыбер белештерми. Үзе теләгәндә дә аңардан квалификацияле эшче чыкмаячак инде. Аны боздылар – диплом белән мин-минлек, амбиция бирделәр, ә белгеч итмәделәр. Шунлыктан үзенә урын, эш таба алмый гаҗизләнгән, укыгандагы кебек, хезмәттә дә «халява» эзләгән, көткән, башка ил-җирләрдә булмаган, күрелмәгән мондый яңа төр белдексез һәм булдыксыз белгечләр белән хәзер ярты ил тулган. «АиФ» атналык газетасы Россиядә югары белемле кешеләр саны Франция белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк дип яза. Ягъни һәр йөз кешегә ВУЗ тәмамлаганнар бездә ике тапкыр күбрәк булып чыга. Тик аңа карап кына Россия Европа була алмый. Чөнки биредә диплом белән чын гыйлем арасында упкын ята. Ә бит, «кәҗәсе кыйммәт түгел, мәзәге кыйммәт» дигән төсле, мәгънәле җәмгыятьтә, ипле илдә

белем дипломнан кирәгрәк. Диплом ул — бер формальлек, кешенең теге яки бу өлкәдә гыйлем алганлыгына белешмә генә. Белешмә кешене укымышлы итми. Мондый күз буяулардан кемдер отышта калса да, ил икътисады, аның белән бергә булган абсолют күпчелек — оттырышта.

Заманында мин тәмамлаган техник ВУЗның икътисад бүлеген (мондый сүз тезмәсен язарга кул бармый, акча дип дәрәҗәсен төшергән өчен газиз уку йортыма ачу кабара) читтән торып ерып чыккан берәү, мин житештерүдә тир түккәндә, технолог булып эшләп йөрде. Башка бер урында икътисадчылык барып чыкмагач, әтисе, техникум дипломы барлыгын искә алып, танышлык белән урнаштырган иде үзен. Технологлылыгы да ташка үлчим, икътисадчы да түгел. Әллә кем иде ул шунда. Ә шул ук вакытта станоклар артына басарга кеше житми. Предприятиедә гади эшчеләрнең уртача яше кырыктан артып киткәндә яшьләргә чиста эш «подавай», чөнки кесәләрендә диплом. Мәктәптә «икеле» белән «өчле» арасында адашып йөргәннәрен алар инде онытканнар.

Без институтларда укыган заманнарда түләүле төркемнәр, «шабашка» эшләү өчен генә оешкан институтлар юк иде анысы. Ләкин югары белем бирү системасында күңелгә хуш килеп бетмәгән күренешләр ул вакытларда да күренгәли иде. Шуның берсе — читтән торып уку тәртибе. Аны кем уйлап чыгарган булгандыр? Өч дистә елдан артык житештерүдә эшләп, читтән торып институт бетергәннәр арасында яхшы белгечләрне күрмәдем мин. (Шунысын да искәртергә кирәк, үзләрен ихтирам иткән институтлар аның ише эш белән шөгыльләнмәделәр дә). Чөнки андый белем системасында да бүгенге параллельләр ята: диплом бар, белем — чамалы. Ул вакытларда ук, андыйларның имтихан бирергә бидоны белән бал, каз түшкәләре төяп йөргәннәре хәтердә. Ахыр чиктә уку, белемле булу аларга да кирәк түгел иде. Алар, нәкъ хәзерге псевдодиплом ияләре кебек, тизрәк диплом алып, карьера баскычында югарырак күтәрелергә тырыштылар. Ә безнең системада әрсез, шома, телчән кешегә, чи надан булса да, житәкчелек итү әлләни кыен түгел.

Мин балачактан белгән, «өчле», «дүртле»гә мәктәпне ерып чыккан берәү, башта читтән торып, Хазанов әйтмешли, бер «калинарный» техникум, соңрак, бүләк ташып, елына ике тапкыр барып институт тәмамлаган иде. Техникумны бетереп, бер кичкенә генә начальник булып алгач ук, Гарвардны тәмамлаган кебек һавалы, тәкәббер кыланып, кеше белән өч бармак белән генә исәнләшеп йөрде. Үземнең күптән күргәнем юк, сөйләүләренчә, хәзер шундый кәпрәйгән, «важный»ланган ки, кыланмышлары, цех башлыгы гына булса да, министрнрыкыннан ким түгел икән. Әйтәсе килгән сүзем шул, «диплом» белән беркетелгән наданлык гади наданлыктан күпкә начаррак. Ул андый затка һавалылык, мин-минлек кенә түгел, акылсызлык та өсти.

Бүгенге Россия. Мең тиленең бер акыллы кешенең камил акылына тормаган суммар акылы. Яки акылсызлыгы. Тилелек бу очракта – психоневрология бүлегендә исәптә тору түгел, ә тар карашлылык, гап-гади наданлык аркасында тамак белән тамашадан башканы белмәү һәм белергә теләмәү. Караңгы, каргалган ил. Гавамның шушы көнгә кадәр сакланган караңгылыгы – Россиядәге михнәтләрнең дәвам итүе дә бит ул. Караңгылык биредә һәрчак беренчел. Акыллылар, чын гыйлемлеләр, гыйлемле булырга теләүчеләр биредә шул ук Европа белән чагыштырганда элек-электән чамасыз аз булып, тиләрнең, наданнарның – «күп белеп тиз картаясы килмәгәннәрнең» чагыштырмача куелыгы, химия терминологиясе кулланып әйткәндә – концентрациясе, киресенчә, һаман әле югары кимәлдә. Гыйлемгә омтылуны биредә җиңел, ансат килгәнгә, ягъни, «өлкән туган»ның үз сүзе белән әйткәндә, «халява»га өмет итү әле бүген дә ега да сала.

## «Потенциаль» һәм «кинетик» энергия

Мәсьәләнең әле тагын бер ягы бар. Гыйлемсез, фәнсез, алдынгы сәнәгатьсез теләсә-нинди илнең киләчәге бер – банан республикасы. Россиядә банан үсми, ә нефть чыга. Нефть чыгару, суырту ни-нәрсә соң ул? Бу шул ук «халява» инде. Ул балык тоту, аучылык кебек үк промысел, ягъни примитив табучылык, җыючылыкның

бер төре, охшашлыкны дәвам иткәндә – акылда, гыйлемдә бик алга китмәгәннәр шөгыле. Ягъни ул сәнәгать, җитештерү, булмаганны булдыру, ясау түгел. Сәүдә, коммерция, «купи-продай» булдыру да түгел. Коммерция дигәнебез – кайдадыр, кемдер тырышып, башын эшләтеп ясаганны әвеш-тәвеш китереп акча ясау. Сәүдәгәргә, әзерне сатучыга да, промыселчы-табучы кебек үк, җитештерүче белгәнне, фәнне, технологияне белү, аның осталыгына ирешү гел дә кирәкми. Алыпсатарга шомалык, тапкырлык, товарны җитештерүчедән мөмкин кадәр азрак бәягә алып, кыйммәткә сатып җибәрү мөһим. Артык гыйлем аңа — арбадагы бишенче тәгәрмәч. Ә менә акча бермә-бер күбрәк тамарга мөмкин. Нигә баш катырып, мәсәлән, шул ук инженерлыкка укырга да, аннан соң җитәр-җитмәс хезмәт хакына мескенләнеп эшләп йөрергә ди? Россиядәге гавамнең белем дәрәҗәсен, аңын, сыйфатын шушы сорау-җавап җитәрлек ачып сала булса кирәк.

Россия гомер-гомергә җитештерүнең иң гади төрен – иген игүне үз иткән ил, аграр дәүләт булган. Сталин индустриализациясе кебек сәнәгать алгарышы да аңа көчләп, таяк һәм камчы белән иңдерелгән. Алар белән бергә — фән һәм гыйлем дә. Ул индустрияләшү, инерция рәвешендә, узган гасырның сиксәненче елларына чаклы барды. Дәүләттә фәнгә, белемгә чагыштырмача яхшы мөнәсәбәт тә, аңа ияреп, шул елларга чаклы килде һәм болганчык еллар җиткәч бик тиз юкка чыкты. Бу җәһәттән Икътисади үсеш министрлыгының 2030 елда Россия дөньяда иң шәп икътисадлы булачак дигән тилемсә прогнозлары да наданлыктан, вәзгыятьне бөтенләй күрмәүдән түгелме икән?..

Татарның күпмедер булган пассионарлыгы, энергетикасы, исәнлеге безнең милләтнең элек-электән укуга, китапка, аң-белемгә битараф булмаганлыгыбыз белән дә аңлатылуын әйттек инде. Гыйлемгә битараф булмау — безнең канда ул. Бу күркәм сыйфатның үзен, шулай ук әҗер-дивидендларын киләчәктә тагын да нәтиҗәлерәк файдаланасы иде. Россия, үзенең гыйлем системасын, фәнне җимергәндә, әллә аңлап, әллә аңламыйча, үзенең бәйсезлеген, суверенитетын да акрын гына юкка чыгарып маташа. «Банан республикасы» белән исәпләшүчеләр булмаячак. «Бөеклек» тә плинтус биеклегендә калырга мөмкин. Ә без татарлар, теләгәндә, киресен эшли, ягъни суверенитетка тоташ гыйлемлелек аша юл сала алыр идек. Икътисади уңышлар да кирәктер. Милли яңарышка омтылуда, милләтчелектә без һаман да «җепшеклек»не, һава торышының җылынуын, яз килүне көткән, чәчәк атарга тилмергән бутон, бөре халәтендә калып киләбез. Бездәге зыялылык та яралгы рәвешендәге, һаман җитлекмәүче, чын-чынлап яралмаучы зыялылык. Болар барысы да, төптән уйлаганда, гыйлемлелек яратып, аңа тартылып та, ул бездә җитмәү, тиешле дәрәҗәдә булмау бәласе түгелме икән?

Яһүд милләтеннән булган бар халыкның 65 проценты югары белемле икәнлеге мәгълүм. Гыйлемлелек турында «мәгълүматлы» түгел, нәкъ менә гыйлемле. Татарда бу сан 20 процент тирәсе диләр. Ягъни, гыйлем ярату белән мактанган хәлдә дә, Моисей улларына караганда без 3 тапкыр наданрак булып чыгабыз. 65 процентлы югары белемлелек — милләтнең ифрат та олы потениаль энергиясе ул. Бу — су запасы миллионлаган куб метрлар белән үлчәнүче, олы басым тудырырга сәләтле алагаем буа-плотина. Физиклар белә: потенциаль энергиядән, әгәр дә ул һәрдаим кинетик, яки башка төр энергиягә әверелеп тормаса, әлләни файда юк. Буа буып кына эш бармый. Су басымы хәрәкәткә, кинетик рәвешкә күчеп, зур-зур турбиналарны әйләндерергә тиеш. Яһүдләр үзләрендәге гыйлем потенциалын ифрат та яхшы куллана лар – аларның турбиналары тулы көчкә әйләнде һәм әйләнә. Биредә Нобель премиясе лауреатларының абсолют күпчелеге яһүд милләтеннән икәнен искә төшерү дә җитәр иде. Белемнең бәясен, кыйммәтен алардан да яхшырак белүчеләр, кулланучылар тагын бар микән? Шунысын да әйтергә кирәк, белемнең, хәзерлекнең урта-һөнәри дигәне һич тә алар өчен түгел. Яһүдләр үзләренә планка куя беләләр. Станок артында торган, төзелештә эшләгән яһүдне очрату җәй уртасында кар табуга тиң. Хәтта гади инженер да яһүдләрдә юк диярлек. Инженер ни инде ул — алдынгы илләрдәге, дөньядагы финанс рычагларының да күпчелеге алар кулында булганда. Ә акчалы булу йогынтылылык һәм абруй гына түгел, икътисади һәм, барыннан да бигрәк, сәяси бәйсезлек дигән сүз

дә. Шул акча һәм йогынты аларга 1948 елны ук үз дәүләтләрен булдырырга ярдәм итте дә инде. Менә сезгә гыйлемлелекнең һәм булганлыкның ахыр килеп бәйсезлеккә трансформациясе, әверелеше.

Белемнең, куллана, файдалана белгәндә, көч-гайрәткә, байлык-муллыкка әверелеп килүе бер яһүдләрдә генә түгел. Шул ук Америка ни өчен дөньяның иң нык алга киткән, иң көчле икътисадлы иле? Америка университетларының бюджеты Европадагы атаклы Сорбонна, Оксфорд университетларыныкыннан да бернична тапкыр артык. Россиядәге төп югары уку йортлары исә соңгылар белән чагыштырганда 10-15 тапкыр азрак финанслана. Кая монда провинциональ ВУЗларга акча? Америкада фән һәм гыйлем системасына ил бюджетының 3 проценты тотылса, Россиядә бу сан 0,1 процент кына. АКШ үзе генә дә дөньяга 180 Нобель премиясе иясен бирган ил. Тикмәгә генә Америка икътисады Россиянекеннән 8 тапкыр (!) көчлерәк түгел ул.

Шулай булуга да карамастан, Россиядәге эшем ияләре (аларны капиталистлар дип атарга тел әйләнми), алар белән бергә урыннардагы хакимиятләр дә, мөмкинлекләре булса, киресенчә, белемсезлекне, наданлыкны тулы хутка кулланып, хәтта коллыкка, крепостное правога кире кайтырга да бик риза булырлар иде кебек. Бирелә мигрантлар хезмәте елдан-ел киңрәк кулланыла. Ни өчен эш бирүчеләрнең зур өлешенә үзебезнең халыктан бигрәк мигрантлар, ягъни гастарбайтерлар кирәгрәк? Хокуксыз һәм надан булганга. Белемле кеше үзен яклый белсә, гастарбайтер – ярымкол. Аңа күпме түләсәң, яки бөтенләй түләмәсәң дә ул берни дә эшли алмый. Россиянең бөтен халкы шундый булса, бирелдәге буржуйларның шатлыгы чиктән ашар иде.

Университет дигәннән. Законнар күпмедер үзгәрде, Татарстанда Милли университет мәсьәләсен, миңа калса, янәдән күтәреп чыгарга кирәк. Андый уку йорты булдырмый торып татар «турбиналары» әйләнеп китмәячәк. Чөнки потенциаль энергиябез шактый чамалы әле безнең. Милли университет Мәскәүдәге «колониаль администрация» уйлаганча, берничек тә үзе үк фетнә, булачак милли революция оясы түгел. Ул—безнең исән-саулыгыбыз гарантиясе, милли «сәламәтлек саклауда» иң йогынтылы профилактика чарасы булыр иде.

Әлегә республика зурдан кубып спорт белән мавыга. «Спорт башкаласы» статусы татар мәркәзенә алай ук кирәк микән соң? Спортның милли дивидендларны күп түгел. Эш беткәч, уйнарга ярый дигән кебек, милләт өчен беренчел, үзәк проблемаларны хәл иткәннән соң да спортка баштанаяк чумарга җитешер идек югыйсә. «Рубин»ны Европада белүдән татарга файда күпме инде? Футбол белән хоккей – республикага йөзләрчә миллион долларга төшүче спорт спектакльләрен акырып-бакырып карап, күңел ачучыларны күрсәткәндә күз алдына тарихи ассоциация-охшашлыклар — Рим империясе, бүгенге алагаем стадионнарның борынгы «бабасы» булган Колизей, андагы гладиатор сугышлары килә. Тамашалы спорт – халыкка аз гына да сәламәтлек бирми торган баналь күңел ачу ул. Аның рухияткә тәэсире берничек тә уңай була алмый. Игътибарны милли проблемалардан читкә җәлеп итү генә ул. Җыеп әйткәндә, спорт милләтебезне яклый да, аның потенциаль энергиясен арттыра да алмый.

...Наданлык – фәкыйрьлекнең иң яманы, дигәннәр борынгылар. Жириновскийны, ярар, шамакай дип кабул итик. Тик ил халкының гыйлемлелеге өчен башы белән җавап бирергә тиешле рәсми зат, әле күптән түгел генә Россиянең фән һәм мәгариф министры булган Фурсенко сүзләрен искә төшерик. «Совет гыйлем системасының төп җитешсезлеге — ул иҗат кешесе булдыру өчен тырышты, шуның өстендә эшләде. Бүгенге максат – квалификацияле кулланучыны, башкалар иҗат иткәнне уңышлы үзләштерә белүчене тудыру һәм үстерү». Ягъни артыгын уйлама, укыма, белмә, корсак ягын гына кайгырт. Бу коточкыч сүзләргә комментарийләр кирәк микән? Бары үз халкына каршы белем геноциды оештырырга җыенган һәм оештырган кеше генә шулай дип әйтә аладыр.

# ЯРУЛЛИННАР ЙОЛДЫЗЛЫГЫ

Бу елның декабрендә халык композиторы, «Тукай маршы» авторы Заһидулла Яруллинның тууына 125, киләсе елның гыйнварында (2014) «Шүрәле» балеты авторы Фәрит Яруллинның тууына 100 ел. Түгәрәк даталар. Әлеге уңайдан кайбер фикерләрне милләттәшләр белән уртаклашып, вакыйгаларны хәтердә яңартып китү урынлы булыр.



*Заһидулла Яруллин кече улы Мирсәет белән. 1951 ел.*

Заһидулла Яруллин 1888 елда Мамадыш өязенең Кече Сөн авылында туа. Малай биш яшеннән тома ятим кала, төрле гаиләләрдә тәрбияләнә. Үсә төшкәч, Чистай, Сембер, Уфа, Самара, Оренбург шәһәрләрен гизеп, 1908 елны Казан каласына аяк баса. Тукай белән «Болгар» номерларында еш очрашалар. Сәйдәш, Шиһап Әхмәров, Фатих Әмирхан, Солтан Гәбәши кебек затлар белән аралашып яшәгән. Бу чорда ул күп кенә җырлар иҗат итә. Әлбәттә ана дан китергән әсәрләрнең берсе — «Тукай маршы».

Халык рухының зурлыгын, бөеклеген әйтеп бирү өчен сәнгатьтә кайчак бер әсәр дә җитә. Тукай вафатыннан соң андый әсәрне Заһидуллан Яруллин иҗат итә. Ул халкыбыз күңелендә мәңгелеккә үз урынын алды.

...Дәрья сулары кайный, кояш-йолдызлары белән бөтен җиһан чайкала. Һәрбер үлән, агач, яфрак елый. Кылган эшләрен дөньяның кайсы да булса җирен яктыртырмы? Адәм баласы — көньяшәр күбәләк түгел. Ул тәне белән дә, рухы белән дә көчле, үлем каршында тезләнүне белми. Үлем — яшәүнең халык күңеленә көчә баруның башы гына. Үзеңдәге зурлыкның намен югары тот, Кешем!

«Тукай маршы»ның моңнары әнә шулай дип инри.

Кече улы Мирсәет Яруллин белән очрашуларның берсендә мин аңарга шундый сорау биргән идем: «Әтиегез Заһидулланы ничегрәк хәтерлисез?» Ул болай дип җавап бирде:

— Әтием вафат булганда миңа 26 яшь иде инде. Соңгы елларда гаиләсе белән шәһәрдә яшәде. Ләкин, май айлары җитүгә, әни белән авылга торырга кайтып китәләр иде. Ул 1964 елның көзендә туган авылы Кече Сөндә дөнья куйды. Хәле бик авыр иде, ара-тирә генә аңына килгәләде. Кызганыч, васыять-мазар әйтергә дә мөмкинлеге булмады... Ничегрәк хәтерлимме? Ул бар табигате белән йомшак күңелле кеше иде. Радиодан бер-бер матур музыка, моң ишетелә башласа, тәмам мөкиббән китә, сихерләнә, хәтта кайчакны күзләреннән яшь чыга. Үзе ясаган гармуннарда озын көйләрне, халык җырларын еш уйный иде. Яхшы сыйфатлы күн, жиз чыбык, почмак калайларын, гармун телләрен музпрокаттагы дусларыннан алып кайта иде... Безнең Мамадыш якларына артистлар килеп чыктымы, эти янына керми калмаслар иде. Гармунчы Туишев, композиторлардан

Сара Садыйкова, Фәтхерахман Әхмәдиев һәм тагын күпләр истә калган. Фольклорчы Хәмит ага Ярми килгәннән соң әтинен Тукай белән шәхсән очрашулары хакында сөйләгәннәре истә. Бик тә озаклап сөйләде, тик мин, балык кыздыру белән мәшгуль булганлыктан, күп өлешен ишетмичәрәк калдым *(Искәрмә: әлеге магнитофон тасмасы Татарстан Фәннәр Академиясенең әдәбият-сәнгать бүлегендә сакланган булырга тиеш).*

З.Яруллин — фаҗигаи язмышлы кеше. Анын улы Фәрит Яруллин үзенен «Шүрәле» балетын сәхнәләрдә күрмичә кала, аны тиз арада сугышка алалар. 1943 елнын көзендә әтисенә «хәбәрсез югалды» дигән кара пичәтле кәгазь кисәге генә килә. Фәритнен каберен, күп эзләнүләр нәтиҗәсендә, 40 елдан соң гына (!) табу һәм ачыклау мөмкин булды. Мин боларны өйрәнеп һәм тәфсилләп ЖЗЛ сериясеннән «Ут һәм җир» романында яздым инде, кабатланасы килми *(Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2000 ел. Тиражы – 3 мең данә).*

Ә хәзер Фәрит Яруллин тормышында һәм иҗатында кайбер хәлләрне күздән кичерик.

***

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә «Шүрәле» балеты бара...

Күгелҗем-яшькелт декорация. Рампа утлары. Кордебалет. Оркестр ярсый, елый, ынгыраша. Музыка давылы эчендә әле скрипкалар ансамбле өстенлек итә, әле барабан һәм кларнетлар авазы ашыга-ашыга өскә күтәрелә дә кисәтүле оран булып дөньяга чан кага. Сәхнәдә музыка һәм биючеләр патшалык итә. Биючеләрнен кул-аяк, гәүдә хәрәкәтеннән тирә-якка әллә ничаклы сер, мәгънә, ашкыну дулкыннары түгелә. Шул тиклем дә сыгылмалы бу хәрәкәтләр ни анлата? Тән һәм рух берлеге ничек шулай сәнгати гүзәллек тудыра ала? Әсәрне тамаша кылу гына түгел, ихтыярсыз рәвештә күнелдән энә шундый сорауларга да җавап эзлим... Без яшибез. Бездәге дәрт һәм яшьлек — матурлыкнын бер өлеше генә. Тормышнын, яшәүнен, матурлыкнын гомерен озайтырга, кадерен белергә бер-беребездән өйрәник без. Җирдә әле яманлык дигән нәрсә дә бар. Ул тормышны карангылый, күнелләрне рәнҗетә. Ана каршы бергәләп көрәшик. Матурлык кешегә алга бару, биеккәрәк күтәрелү өчен кирәк. Ул һәркемнен йөрәге аша узарга тиеш. Матурлыкнын яшәр урыны — Ватан, кешеләр, табигать...



Фәрит Яруллин. 1940 ел.

Биючеләрнен ни әйтергә теләгәнен мин әнә шулайрак анладым. Шушы мәгънәләрне музыка тагын да көчәйтә, тирәнәйтә, күнел кылларын киеренкегамьле халәттә тота. Ак һәм кара. Мәхәббәт һәм нәфрәт. Менә шуларнын үзара тартышы, кискен бәхәсе тылсымлы музыкага әверелгән дә матурлыкнын дөньяны коткарырга тиешлеген раслап бәргәләнә, өнди, алга чакыра. Андый чакта күнелнен тормыш-яшәешваклыкларыннан биеккәрәк күтәрелүе гаҗәпмени! Көн һәм төн, ай һәм ел дигән төшенчәләр кинәт юкка чыга. Гомернен һәм кыска, һәм мәнгелек икәнлеген тоясын. Шуны анлаудан күнелдә бер хис мөлдерәп тула: үзенә бирелгән шушы гомердә тормышны мөмкин кадәр матурлап, бизәп китә алсан икән!

Сәхнәнен бәрхет пәрдәләре ябыла. Зал гөмбәзендәге бәллүр люстра, көчле алкышлардан сискәнеп, камелия чәчәгедәй салмак кына ачыла, яктыра башлый. Театрнын имән ишекләрен ачып урамга чыгасын. Дөньяда никадәрле үзгәреш! Күкләр тагын да биегәйгән, шәһәрнен йортлары, урамнары, кешеләре, җилләре һәм чәчәкләре өр-яна мәгънә белән каршына агылып килә. Ә мәгънәсе бик гади: сөй, шатлан, яшә, ләкин җиргә күнел матурлыгы бүләк итәргә тиешлегенне онытма, кешем!

Композитор иҗат иткән музыка минем тын гына агып яткан тормышымны, уй-фикерләү рәвешемне әнә шулай төптән үзгәртеп ташлый, табигать биргән чын асылыма кайтара.

Балетның төп геройлары — гаделлек сөйгән тәвәккәл егет Былтыр, Шаян һәм шул ук вакытта хәйләкәр Шүрәле, саф мәхәббәт өчен яратылган гүзәл зат Сөембикә. Бер-берсенә охшамаган бу затларга композитор психологик характеристика бирү, аларның күңел халәтен тулырак ачу өчен музыка һәм оркестр чараларының барлык арсеналыннан уңышлы файдаланган.

Табигатьнең зирәклегеме, әллә саранлыгымы — кешегә гомер дигәнең бик тә чикле, үлчәп кенә бирелгән. Ул менә шушы вакыт арасына сыярга, үзеннән билгеле бер өлеш — күңел хәзинәсен калдырып китәргә тиеш. Заманның нинди генә чоңгылларына эләкмәсен, кагыйдә буларак, зур шәхесләр үзләренә тигән гомердә әйтәсе сүзләрен әйтеп өлгерәләр. Гаҗәп хәл: Тукайга моның өчен нибары егерме жиде ел вакыт җиткән.



*Утырганнар: Хамит Ярми (сулда), Заһидулла Яруллин, басканнар: Мирсәет Яруллин (сулда), Әнвәр Бакиров. 1958 ел.*

Фәрит Яруллин яхшылык һәм яманлык, тагын да төгәлрәк әйтсәк, гуманизм һәм фашизм дуэлендә үтерелде. Үлем аны асылда тән көрәшендә генә җиңде. Ромен Ролланның иҗат эше турында бик тә мәгънәле сүзләре бар: «Иҗат итү, димәк, үлемне үтерү». Әйе, Фәрит Яруллин үзенең иҗаты белән үлемнән өстенрәк калды. «Шүрәле» балеты моңнары, илебезнең төрле почмакларына гына түгел, хәтта Азия, Европа, Америка кыйтгаларына кадәр барып җитте. Аның бүгенге көндә дә сәхнәләрдән төшми уйналуы Фәрит Яруллинның һаман да безнең арада яшәве, музыкасының озын гомерле булуы турында сөйли.

«Язган әйберләремнән эзләгез сез мине...» Антуан де Сент-Экзюпери әйтеп калдырган бу сүзләр теләсә кайсы иҗатчының язмышын аңлауда тылсымлы ачкыч булып тора. Ватан сугышы кырларында ятып калган Фәрит Яруллин бер генә әсәре белән дә метеор кук балкып, атылып узды. Метеор атыла да сүнә, ә менә талантлы композитор үзенең «Шүрәле»се белән кешеләрнең күңел күгендә мәңгелек эз калдырды. Йә, гаҗәп хәл түгелмени бу?!

Сугышта Яруллин ике ил, ике дөнья бәрелешкән утлы гарасат уртасына килеп эләкте. Композитор өчен гражданлык намусы һәм иҗади фаҗига әнә шулай ут эчендә төенләнә. Мондый көрәш кырында кешенең шәхесе, иҗтимагый кыйммәте тагын да зурая. Гомумән, гади бер кешеме, әллә даһимы — бу дөньяның һәр кешесендә нинидер сер яшеренеп ята. Фәрит Яруллин үзенең иртә үлеме һәм яраткан «Шүрәле»сен үзе бөтенләй күрми китүе белән безнең арадан зур бер серне дә алып китте. Шул серне аңларга тырышу теләге безне каядыр еракка чакыра, тәгәри киткән йомгак шикелле үзенә ияртә.

Фәрит Яруллинның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләгәндә без күп кенә сорауларга җавапны аның балачагыннан, ул яшәгән чордан, композиторның шәхесеннән эзләргә тиеш булабыз. Ләкин болары инде бүтән тарих, кыска гына мәкаләдә барысын да сөйләп бетереп булмый.

Инде, ниһаять, йолдызлык дигәнбез икән, композитор, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе Мирсәет Яруллин турында да беркадәр сүз әйтүне кирәк дип саныйм.

Тагын алда әйтелгән әңгәмәбезгә әйләнеп кайтыйк булмаса. Мин ул чакта Мирсәет абыйдан әтисе турында гына түгел, Фәрит абый турында да сораштым. Аның сөйләгәннәре булачак роман-хроника өчен бик кыйммәтле җим булды.

— Никадәр кызганыч, абыең сугышка китеп баргач. Сез аның белән очрашмый калгансыз икән. Язмышның аяусызлыгыдыр инде...

— Әйе шулай да без аның белән бер тапкыр «очрашып» калганбыз. Ләкин бу — беренче һәм соңгы очрашу булган икән. Фәрит абый Мәскәү консерваториясендә укыган чакта, төгәлрәге 1938 елның җәендә, Кече Сөнгә эти янына кайтып төшә. Бишектә яткан нәни сабыйны энә шул чакта күрә ул. Кем белә, бәлки тирбәтеп тә алгандыр әле (Мирсәет абый бу урында көлемсерәп куя).

Фәрит Яруллинга кагылышлы хатлар, хәрби кәгазьләрне, каберен ачыклауда ул зур тырышлык, сабырлык күрсәтте. Озак еллар Татарстан композиторлар берлеген җитәкләде, Казан дәүләт консерваториясендә декан булып эшләде. «Кеше» дигән ораториясе өчен ул республикабызның М.Җәлил исемендәге премиясе белән бүләкләнде.

1990 елда Кече Сөндә Яруллиннарга багышланган музей ачылды.

**Рашат НИЗАМИ**

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# ТӨРКИ ДӨНЬЯ ХӘЗИНӘЛӘРЕ

XIX – XX гасыр башында Казан иң күренекле шәрыкшенаслык (ориенталистик), шул исәптән тюркологик үзәкләрнең берсе була. Анда һәм өлешчә Оренбург, Өфе калаларында басылган китаплар бөтен төрки-мөселман дөньясында, хәтта Госманлы империясендә дә киң таралыш таба. Казан նаширлары төрки кардәшләребезнең басма сүзгә ихтыяҗларын канәгатьләндерүне дә үзләренең бурычы дип саный. Идел-йорт нәшриятларында казакъ, үзбәк, кыргыз, төрекмән һәм кайбер башка телләрдә китапларның дөнья күрүе – моның ачык дәлиле. Казан галимнәре Шәрык, җөмләдән төрки кавемнәрнең тарихын, мәдәниятен, көнкүрешен, рухи мирасын өйрәнүгә дә үзләреннән зур өлеш кертә. Совет чорында исә Казан (Оренбургны инде әйтәсе дә юк) төрки дөньяда үзенең әйдаманлык ролен җуя; нигездә, автономияле җөмһүрият кысаларында гына гамәл кылырга мәҗбүр ителә. Союздаш статусына ия булган төрки республикаларда төп игътибар үзләренең эчке, милли ихтыяҗларына юнәлтелә. Үткән гасырда Төркиядә исә, гомумтөрки мәнфәгатьләрен күздә тотып, шактый гына эшләр башкарыла. Әмма, кызганыч ки, ике арада «тимер пәрдә» булу аркасында Истанбул, Анкара басмалары безгә килеп ирешмәде диярлек. Хәтта XX–XXI гасырлар аралыгында "Ататөрек Культура Мәркәзе" тарафыннан Төркиядә басылган 33 томлык төрки әдәбиятлар тарихы, антологиясе, энциклопедиясе кебек житди хезмәтнең дә бары тик берничә томы гына Казанга килеп житте.

СССР таркалганнан соң мөстәкыйльлек алган мәмләкәтләр арасында Казакъстан гомумтөрки мәнфәгатьләрен кайгыртуга житди игътибар бирә башлады. Моның объектив сәбәпләре дә булып, бу ил үзенең зурлыгы, географик урыны, табигый байлыкларга муллыгы, совет чорында икътисади һәм мәдәни яктан шактый нык үсеше, күпмилләтлеге белән сыйфатлана. Россия һәм Кытай составындагы төрки җөмһүриятләр һәм кавемнәр дә ана бик якын урнашкан. Шулай ук Казакъстан житәкчелегенең евразиячелек идеясенә тугрылыгы да аның халыкара абруен күтәрүгә ярдәм итә.

Соңгы елларда Казакъстан шәһәрләрендә, югары уку йортларында, гыйльми һәм мәдәни үзәкләрендә гомумтөрки планда шактый мөһим эшләр башкарылды. Бу аеруча илнең башкаласы Астанадагы Төрки академия мисалында ачык күренә (президенты – күренекле тюрколог Шакир Ибраев). Илбашы Н.Назарбаев фәрманы белән оештырылып, 2010 елның маенда рәсми рәвештә эшли башлаган бу мәркәзи оешма (Казакъстан һәм Төркия президентлары катнашкан тантаналы ачылышында без фәкыйрегезгә булырга туры килде) кыска гына вакыт эчендә тюркологик тикшеренүләрне оештыру, координацияләү, белгечләрне барлау һәм тарту юнәлешендә зур һәм игелекле гамәлләр кылырга өлгерде. Шунысы мөһим: Төрки академия татар тематикасына, галимнәребезне уртак проектларга тартуга житди игътибар итә. Аның ярдәмендә Казан тюркологларының дистәләгән монографияләре, мәкалә-хезмәтләре басылып чыкты.

Бу язмада мин Төрки академия житәкчелегендә 2012-2013 елларда әзерләнгән һәм нәшир ителгән ике антологиягә һәм ике альманахка тукталып китәсем килә. Аларның һәрберсе гаять күләмле (хәтта кайберләре уртача 4 кг авырлыкта, 100 басма табактан, мең биттән артып китә), затлы, полиграфиянең соңгы казанышларын исәпкә алып эшләнгән. Иллюстратив материалларга искиткеч бай. Күбесе төсле рәсемнәр белән баетылган. Һәр дүрт китапның да үзәгендә – төрки тематика, аның үткәненә, бүгенгесенә, асылына, төрки кавемнәрнең дөнья тарихында

тоткан урынына мөнәсәбәтле материаллар. Бу басмалар, ин беренче чиратта, төрки галимнәрнен уртак тырышлыгы ярдәмендә әзерләнгән. Алар белән бергә, альманахтагы авторлар арасында төрки булмаган ил, халык вәкилләренен дә төркигә мөнәсәбәтле язмалары шактый (Д.Васильев, Мәскәү; Х.Янковски, Польша; К.Райхл, Германия; Генг Шиминь, Кытай; П.Гольден, АКШ; М.Хоппал, Венгрия; Г.Лаказе, Франция; А.Саг, Голландия һ.б.).

Төрки академия әзерләгән альманах һәм антологиянен 2012 елгы басмалары хакында мина матбугатта, радио-телевидение аша кайбер фикерләр әйтергә туры килгән иде. Аерым зыялыларыбыз алар белән таныш та. Шунысы гыйбрәтле: Төрки академия бу төр басмаларны үз хисабына Татарстан Фәннәр Академиясенә, Казан федераль университетына, Милли китапханәгә җибәреп тора. Аларнын электрон вариантларын сайттан табарга була.

2013 елнын 26-27 сентябрендә Астанада урнашкан Төрки академиядә төрки әдәбиятлар тарихын чорларга бүлү мәсьәләсенә багышланган халыкара семинар булып узды. Анын эшендә без фәкыйрегезгә катнашып, доклад-чыгышлар ясарга туры килде. 2013 елгы альманах һәм антологияне шушы сәфәрем вакытында Казанга алып кайттым. (Астанада сонгы булуымда мин Казакъстандагы татар-башкорт ассоциациясе җитәкчеләре Ринат Абдулхаликов һәм Тәүфыйк Кәримов белән очраштым. Икесе дә билгеле шәхес, җәмәгать эшлеклесе. Ринат әфәнде – продюсер, күп кенә көй һәм җыр авторы, 1993 елдан чыгып килүче «Фикер» газите мөхәррире. Тәүфыйк әфәнде – Казакъстан президенты аппараты һәм «Нур Отан» партиясе хезмәткәре, әдип, публицист, урыс, татар, казакъ, инглиз телләрендә басылган берничә китап авторы. Аларнын өчесен («... И все цвета радуги», 2000, 320 с.; «Татарстан, татары и спорт», 2012, 134 с.; «Төсләр балкышы», 2009, 271 б.) мина да бүләк итте. Рәхмәт үзенә).

«Төрки дөньясы» дип исемләнгән альманахнын (Астана, 2012, 724 б.) төзелеш-структурасы, эчтәлеге чын мәгънәсендә анын исеменә туры килешле. Ул хәзерге төрки дәүләтләр хакында аерым-аерым белешмә-мәгълүматлар бирүдән башланып китә. Шунда ук сонгы дәвер төрки дөньясынын Ататөрек, Нурсолтан Назарбаев, Хәйдәр Алиев, Чынгыз Айтматов кебек күренекле затлары хакында язмалар урнаштырылган. Эртегин Сәламзадә (Азәрбайҗан) мәкаләсендә төрки дөньянын дәүләти символлары тарихи планда яктыртыла. Анда Россия составындагы хәзерге төрки җөмһүриятләрнен әләмнәре дә анализлана. Альманахнын төп өлешендә төрки дөньянын төрле тармаклары (тарихы, мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате, фольклоры, архитектурасы, теле, мәгарифе, этнографиясе һ.б.) комплекслы планда тикшерелә. Болар арасында турыдан-туры безнен халыкка мөнәсәбәтле һәм татар галимнәре язган хезмәтләр дә бар. Мәсәлән, тарих фәннәре докторы Дархан Кыдырәли (Астана) мәкаләсендә Ш.Мәрҗани (1818-1889) белән Абай (1845-1904) эшчәнлекләре үзара мөнәсәбәттә карала, татар мәгърифәтчесенен казакъ шагыйренә шифалы тәэсире ассызыклана. Уфадагы милләттәшебез Алмаз Шәйхулов төрки-татар мәгърифәтчелек хәрәкәтен Исмәгыйль Гаспралы һәм җәдитчелек мисалында яктырта. Мирфатыйх Зәкиев язмасында Казан төрки лингвистик мәктәбенен оешуы, үсеше хакында сүз бара. Хатыйп Миннегуловнын «О письменной культуре городов Поволжья в период Золотой Орды» дип исемләнгән мәкаләсендә куелган проблема тарихи, мәдәни, рухи яссылыкларда карала.

Төрки альманахнын (Алматы, 836 б.) 2013 елгы саны күләм ягыннан гына түгел, ә төзелеш, эчтәлек җәһәтеннән дә тулылана, камилләшә төшкән. Ул хәзерге төрки мәмләкәтләр һәм кавемнәр арасындагы интеграция, үзара аралашу, хезмәттәшлек кебек мәсьәләләрне яктырту белән башлана. Алга таба төркиләрнен гыйлем-мәгърифәте, теле, әдәбияты, эпиграфикасы турындагы материаллар килә. Болар арасында Казан галимнәре Хатыйп Миннегуловнын «Татар китабы тарихыннан», Дания Заһидуллинанын «Неклассический тип культуры» в татарской литературе: теоретические вопросы» исемле язмалары да бар.

Мәскәү галимнәре А.Васильев, А.Карамасов мәкаләсендә 1926 елда Бакуда узган Беренче Бөтенсоюз тюркологлар съезды архив материалларына нигезләнеп яктыртыла, анын үзенчәлекләре, тарихи роле күрсәтелә. (Шунысын да искәртик: алдагы елларда, бәлкем, 2014 елнын көзендә, Астанада Бөтендөнья тюркологлары

корылтаен уздыру хакында да сүз алып бара). Еркин Ауғалинен (Пекин) «Кытай тюркологиясе: үткәне һәм бүгенгесе» дигән язмасы урын алган.

Мифлар теләсә нинди кавемнең, шул исәптән төркиләрнең дә рухи тормышында зур роль уйный. Бу хакыйкатьне күздә тотып, җыентыкның быелгы санында мифологиягә зур урын бирелгән. Берничә мәкаләдә аерым-аерым казакъ, төрек, кыргыз, үзбәк, хакас, дагыстан мифлары карала, тәңречелек хакында да кызыклы фикерләр әйтелә. Берничә төрки кавемнең мифларыннан үрнәкләр дә бирелгән.

Хәзерге рухи-мәдәни яшәешебезне музейлардан башка күз алдына китереп булмый. Алар – үткәнебезне, бүгенгебезне, табигатьне, тирә-юньне күрмә (визуаль), күрсәтмә рәвештә, үтемле итеп җиткерүче чара. Әгәр дә альманахның 2012 елгы санында музей тематикасына аз гына урын бирелсә, 2013 елгы җыентыкта исә музейлар мәсьәләсе 15 мәкаләне үз эченә алган махсус рубрикада карала. Альманахның бу кисәге гаҗәеп төрле, матур, мәгънәле, төсле рәсем-иллюстрацияләр белән бизәлгән. Аларга карап төрки кавемнәрнең тарихын, көнкүрешен, үсеш-тәрәккыят дәрәҗәсен, сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен шактый тулы күзалларга мөмкин. Язмаларда төрки җөмһүриятләрдәге күп кенә музейларның хәзинәләре, эшчәнлеге яктыртыла, рәсем сәнгате, зәркәнчелек (ювелирлык), архитектура, этнография хакында мөһим фикерләр әйтелә, кызыклы факт-мәгълүматлар китерелә. Гөлчәчәк Нәҗипова язмасында Татарстан Милли музееның тарихы, төзелеше, эшчәнлеге турында сүз бара. Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты хезмәткәре Светлана Суслованың «Татарский костюм в музейных собраниях России и Украины» дип аталган мәкаләсе укучыларга халкыбызның кием-салымы хакында күрсәтмәле рәвештә бик күп төрле мәгълүматлар бирә.



Төркиләрнең күпгасырлык тарихы, яшәеше, көнкүреше ат белән тыгыз бәйле. «Ир-ат» дип әйтү үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Альманахның «Төркиләрнең җылкы (елкы, ат) мәдәнияте» дип исемләнгән кисәгендә сүз төркиләрдә ат культы, аның төрләре, тормыштагы роле, мифологиядә, фольклорда, әдәбиятта, сәнгатьтә чагылышы тикшерелә, ат белән бәйләнешле йолалар яктыртыла. Кызганыч ки, татар фәнендә ат тематикасы бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Югыйсә бит безнең фольклорда, язма әдәбиятта, аерым әдипләр иҗатында ат мотивы, ат образы зур урынны били, төрле идея-эстетик вазифа үти.

2013 елгы альманахта төрки дөньяның күренекле шәхесләре хакында юбилей уңае белән язмалар бирү дәвам иттерелә. Болар арасында Бәкер Чубанзадә (тууына 120 ел), Магжан Жумабаев (120 ел), милләттәшебез Әкъдәс Нигъмәт Курат (110 ел), Мирфатыйх Зәкиев (85 яшь), Гайсә Хөсәенов (85 яшь) һәм безгә билгеле булган кайбер башка затлар бар.

Альманахның соңгы рубрикасында Алтайга, Кытайга (нигездә, Уйгырстан вилаятенә), Кыргызстанга оештырылган палеографик, этнографик, археографик экспедицияләрнең материаллары урнаштырылган. Шушында ук сары уйгырларның авыз әдәбиятыннан аерым үрнәкләр дә укучыларга тәкъдим ителгән.

Һәр ике альманахтагы язмалар 6 телдә (казакъ, азәрбайҗан, төрек, кыргыз, урыс, инглиз) телләрендә бирелгән. Шунысын да искәртик: казакъның дистәләгән галиме үз язмаларын инглиз телендә тәкъдим иткән.

Антология дип күпчелек очракта төрле авторларның әсәрләрен туплаган җыентыкка әйтәләр. Төрки академия әзерләп чыгарган 2012 елгы басма (Астана, 568 б.), нигездә, антологиянең без күнеккән мәгънәсенә туры килә. Ул төрки дөньяда VIII гасырдан алып XX йөзнең 30-40 елларына кадәр иҗат ителгән күренекле ядкарьләрне үз эченә ала. Күпчелеге шигъри, чәчмә әсәрләр. Фәнни-публицистик

язмалар, фольклор үрнәкләре дә бар. Кагыйдә буларак, Борынгы һәм Урта гасыр язма истәлекләренең оригиналдагы, ягъни рун, уйгур, гарәп язуындагы күчермәләре дә өлешчә бирелә. Әүвәл һәрбер истәлек, автор, нигездә, казакъча язылган 1-2 битлек белешмә белән тәэмин ителгән. Әдәби текстлар латинча транскрипциясендә һәм янәшәдә кирилл хәрефләре белән бирелә. Авыррак әсәрләрнең, бигрәк тә борынгырак дәвергә караганнарның хәзерге казакъ теленә тәрҗемәләре дә бар. Китап Шакир Ибраев тарафыннан казакъ һәм инглиз телләрендә язылган гомуми кереш сүз («Алгы сүз») белән башлана.

Антологиянең беренче бүлеге (дөресрәге, рубрикасы, кисәге) VIII гасырга мөнәсәбәтле Күлтәгин, Таникук, Билгә каган каберташ язмаларын, ягъни борынгы төрки рун истәлекләрен үз эченә ала. Алга таба «Төрки дастаннары» дип исемләнгән бүлек килә. Бирелә «Коркыт Ата китабы»ннан, «Угызнамә»дән, кыргыз халык эпосы «Манас»тан үрнәкләр бирелә. «Урта гасыр» дип аталган бүлек Әл-Фәрәбинең (870–950) – аны еш кына «Шәрык Аристусы» (Аристотеле) дип тә йөртәләр – «Дәүләт хакындагы рисаләсе» белән ачыла. Алдагы битләрдә Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» китабындагы (1072–1074) шигырьләр, мәкаль-әйтемнәр һәм атлас (карта) урнаштырылган. Төрки шигъриятенең «Шаһ китабы» – Йосыф Баласагунлының «Котадгу билик» әсәре дә (1069) антологиядә үзенә лаеклы урынны алган. Жыентыкны Әхмәд Йүгнәкинең (XII) «Һибәтел-хакаик» дастаны һәм мәшһүр Әхмәд Ясәвинең (1166 елда үлә) «Диване хикмәте»ндәге шигырьләр дә бизәп тора. Янәшәдә үк Низаминың (1141–1209) «Жиде гүзәл» дастаныннан өзекләр урнаштырылган. Әмма, ни сәбәптәндер, бу шагыйрьнең фарсыча язуы искәртелмәгән. Төп текст азәрбайжанча һәм казакъчага тәрҗемәдә бирелгән. Алга таба Алтын Урдада яшәгән һәм иҗат иткән Рабгузи, Харәзми, Мәхмүд... әс-Сараи, Котб, Сәйф Сараи әсәрләре тәкъдим ителгән. Әмма алар хакындагы белешмәләрдә бәхәсле яклар, төгәлсезлекләр дә җибәрелгән. Әдипләрнең урнаштырылышында хронологик принцип сакланмаган. Сәйф Сараи 1391 елда үлгән дип күрсәтелгән (323–326 б.). Югыйсә, әле бу шагыйрь 1393–1394 елларда үзенең «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанын иҗат итә. Фәндә аның үлеме 1396 елда дип карала. Котбны Харәземгә нисбәт итү дә бик бәхәсле. «Нәһҗел-фәрадис» (1358) авторының исемен дә Мәхмүд... әс-Сараи әл-Болгари дип бирү дөресрәк булыр иде. Кыскасы, Алтын Урда чоры әдипләре хакындагы белешмәләрдә кайбер искергән карашлар бәян ителә, соңгы чор гыйльми казанышлары тиешенчә исәпкә алынмый.

«Урта гасыр» төрки әдәбияты кысаларында «Кажы Бекташ Валинең «Макалат»ыннан өзекләр тәкъдим ителгән. 1303 елда Сарай шәһәрендә төзелгән «Кодекс куманикус» сүзлегеннән китерелгән табышмаклар, шигъри текстлар да унай тәэсир калдыра.

Галишер Нәваиның (1441–1501) «Искәндәр дивар»ыннан өзекләр, Физулиның (1494–1556) газәлләре һәм «Ләйлә вә Мәҗнүн»еннән үрнәкләр, Заһиреддин Бабурның (1483–1530) «Бабурнамә»се антологияне бизәп тора. «Урта гасыр» бүлегенең ахырында Кадыйргали Жалаерлының (Кадыйр Галибәк) «Жәмигъ эт-тәварих» (1602) язмасыннан өзекләр китерелә. Әмма автор хакындагы белешмә шактый искергән. Әсәрне «казакъ телендә» язылган дип әйтү дә бәхәсле (394 б.). Касыйм ханлыгында иҗат ителгән бу әсәр чынлыкта иске татар телендә.

2012 елгы антологиянең XVIII – XX гасыр башын үз эченә алган соңгы бүлеге (рубрикасы) «Яңа дәвер» («Modern Period») дип исемләнгән. Анда Мәхтүмколый (XVIII), Молланепес (1810–1861), Акмулла (1831–1895), Абай (1845–1904), Исмәгыйль Гаспралы (1851–1914), Фитрәт (1885–1938), Зыя Гөкалып (1876–1924), Хөсәен Жәвид (1882–1941), Токтагул Сатылганов (1864–1933), Магжан Жумабаев (1893-1938), Тукай (1886–1913) кебек төрекмән, казакъ, үзбәк, кыргыз һәм кайбер башка халык шагыйрьләренең классик әсәрләре урнаштырылган. Тукай язмаларын жыентык өчен без фәкыйрегез хәзерләде. 16 шигырь арасында «Туган тел», «Пар ат», «Шүрәле» әсәрләре дә урын алган. Соңгы бүлеккә карата бер-ике тәнкыйть фикерем дә бар. Исмәгыйль Гаспралы – төрки дөньяның мәшһүр заты. Әмма аның Кырым татары булуы телгә алынмаган. Г.Хөсәенов хезмәтенә таянып язылган Акмулла турындагы белешмәдә (426–427 б.) бу затның «башкорт шагыйре» булуы гына искәртелә. Хакыйкатьтә ул өч халыкның – татар, башкорт һәм казакъның уртак шагыйре.

2012 елгы антология, гәрчә аерым бәхәсле яклары, кимчелекләре булса да, гомумән унай тәэсир калдыра. Бирегә тупланган әсәрләр «төрки дөньясы» әдәбиятынын байлыгын, төрлелеген, озын тарихлы булуын янә бер мәртәбә раслап тора. Мәгълүм ки, төрки-татар шагыйре Кол Галинен «Кыйссаи Йосыф» дастаны – Урта гасырнын күренекле ядкаре. Ул, ни сәбәптәндер (бәлкем, очраклы рәвештә) антологиядән читтә калган.

«Төрки тәрбия» («Түрки тәрбие» –Turkic upbringing ) дип исемләнгән 2013 елгы антология (Алматы, 1004 б.) – Төрки академия әзерләп чыгарган китапларнын иң күләмлесе (5 кг тирәсе) һәм саллысы. Ул, гомумән, төзелеш-структурасы һәм эчтәлеге белән, мөгаен, уникаль күренештер. Бу аңлашыла да, чөнки ул элек тә, бүген дә бик әһәмиятле булган тәрбия, аеруча милли, төркилек мәсьәләләренә багышланган. Бу антологиягә бәйле проектны гамәлгә ашырып, татарга мөнәсәбәтле материаллар (алар 600 биттән артып китте) минем тарафтан тупланды, сайланды һәм тәртипкә салынды. Аларга кереш рәвешендә язылган мәкалә «Әби-бабаларыбызнын гыйбрәтле сабаклары» исеме астында «Чын мирас» журналынын 2013 елгы 8 нче санында басылып чыкты. Шунысын да әйтим: бу проект буенча эшләү миңа күп нәрсә бирде. Баксаң, татарнын теге яки бу дәрәҗәдә үзенә хас булган тәрбия элементлары, чаралары шактый икән. Аларны бары куллана белергә генә кирәк. Шулай ук татарда башка төрки кавемнәргә якын, кайберләре хәтта уртак материаллар да бар. Аерым әкият-дастаннар, мисал өчен, «Нәүрүз» бәйрәмнәре, «Яр-яр» җырлары һ. б. – әнә шундыйлардан.

Бу антология – чын мәгънәсендә төрки галимнәрнең үзара хезмәттәшлек кылып эшләү нәтиҗәсе. Мәсәлән, аны төзүдә Азәрбайҗаннан А.Гулиев, Казакъстаннан К.Кадашева, Төркиядән М.Екижи, Кыргызстаннан С.Кайыпов, Үзбәкстаннан Ж.Эшонкул һәм башка галимнәр катнашты. Гаять күләмле материалларны сайлауда-эшкәртүдә, системалаштыруда, транскрипцияләүдә, тәрҗемә итүдә Төрки академия хезмәткәрләре фидакарьләрчә эшләде.

«Төрки тәрбия» исемендәге бу антология нәрсәдән гыйбарәт сон? Анын төп өлеше тәрбия процессынын һәм гомумән инсан яшәешенең үзәк мәсьәләләрен үз эченә алган берничә зур бүлектән (рубрикадан) гыйбарәт: 1. Бишек тәрбиясе; 2. Гадәт-йолалар; 3. Әхлак тәрбиясе; 4. Патриотик, ирлек тәрбиясе; 5. Хезмәт тәрбиясе; 6. Акыл тәрбиясе; 7. Дини тәрбия; 8. Эстетик тәрбия. 9. Матурлыкка, зифалыкка күнектерү аша тәрбияләү. 10. Физик һәм экологик тәрбия һ. б. Бу төр мәсьәләләр үз эчендә тагын да кечерәк өлешләргә аерыла. Төрки академия төзегән бу план-проспектны андагы тәрбия пунктларына туры китереп материаллар белән тәэмин итү бурычы куелды. Алар халык иҗатыннан, мифологиядән, матур әдәбияттан, тарихи, педагогик, дини, әхлакый китаплардан, мәдәниятнең төрле тармакларыннан тупланды. Алынган текст-мәгълүматларнын чыганаклары антология ахырында һәр кавемнеке аерым-аерым күрсәтелде.

Антологиядә 6 төрки кавем алынган: азәрбайҗан, казакъ, кыргыз, татар, төрек, үзбәк. Бу халыкларга мөнәсәбәтле текстлар оригиналдагыча бирелде, ягъни кыргызныкы кыргызча, татарныкы татарча, казакъныкы казакъча. Бу кавемнәр хәзер кирилл язуын куллана. Шуңа күрә алардан алынган әсәрләр янәшәдә латин графикасында да бирелә. Ә инде хәзер латин хәрефләрен кулланучы төрек, азәрбайҗан, үзбәк текстлары шул килеш кенә калдырылган. Китапка гомуми кереш, тәрбия төрләре алдыннан бирелгән мәкаләләр казакъча һәм инглизчә бирелә. Күренекле шәхесләр турындагы белешмәләр әүвәл милли телдә (казакъныкы казакъча...), аннан инглизчә языла. Ә инде 6 төрки кавемнең тәрбияви материалларына күзәтү, анализ ясаган мәкаләләр оригиналдагыча бирелә (төрекнеке төрекчә, үзбәкнеке үзбәкчә...). Шунысы мөһим: китап һәм бүлек башларындагы мәкаләләрдә чагыштырма тикшерүнең дә матур үрнәкләре бар.

Әйткәнебезчә, Нәүрүз күпчелек төркиләр өчен хас. Анын йолалары, бу бәйрәмдә әйтелә торган сүзләр тәрбиянең башка төрләре белән табигый керешеп китә. Шулай да Нәүрүз аерып, махсус рубрика астында бирелә, алты төрки кавемнән дә анын үрнәкләре тәкъдим ителә. Татар өлеше дә шактый бай: Нәүрүз, анда әйтелә торган теләкләр, «Нәүрүз мөбарәкбад» такмаклары урнаштырылган. Татарларда Нәүрүз бәйрәмен үткәрү үзенчәлекләрен яктырткан мәкалә дә бирелгән.

Китапта төркиләрнең тотемнары (бүре, бөркет, ташбака...) хакында да кечерәк бүлекчә бар.

Антологиянең өчтән бер өлешен диярлек төркиләр тарихында мөһим роль уйнаган шәхесләр, аларның тәрбияви характердагы фикерләре, язмалары алып тора. Бу төр исемлек антик дәвер чыганакларында еш телгә алынган Томирис – Түмар-Ханша (яна эрага кадәр 570–520 еллар) белән башланып китә, ана мөнәсәбәтле берничә легенда-риваять китерелә. Алга таба Күлтәгин (684–731), Коркыт (VIII–IX), Әл-Фәрәби (870–950), Әхмәд Ясәви (1093–1166) турында белешмәләр, аларның иҗатларыннан үрнәкләр тәкъдим ителә. Аннан соң шул рәвешчә Низами, Йунус Әмрә, Нәваи, Абай һәм башкалар урнаштырылган. Болар арасында Магжан Жумабаев, Мохтар Ауэзов, Чыңгыз Айтматов кебек яңа дәвер әдипләре һәм аларның тәрбия турындагы кызыклы язмалары да бар. Татар әдәбиятыннан М.Гафури (10 шигыре: «Ана», «Нәсихәт», «Татар жегетенә», «Кошларга»...), Г.Тукай (20 шигырь: «Су анасы», «Пар ат», «Туган җиремә», «Китмибез», «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Эш беткәч, уйнарга ярый», «Ата илә бала», «Театр» һ. б.), Г.Ибраһимов («Алмачуар») укучыларга тәкъдим ителә.

Антологиянең татар халкы тәрбиясенә караган өлеше шактый бай. Текстлар 46 исемдәге китаптан сайлап алынды. Фольклор җыентыкларыннан тыш, алар арасында гыйльми, әдәби, тарихи китаплар, элеккеге һәм хәзерге чор авторларының да әсәрләре бар. Күп кенә мисаллар Г.Тукай, М.Гафури, К.Насыйри, Р.Фәхреддин, Утыз Имәни, Мөхәммәдьяр, С.Сараи әсәрләреннән алынды. Бала тәрбияләү өлешендә Г.Исхакыйның «Кәҗүл читек» хикәясе тәкъдим ителде. «Идегәй», «Чура батыр», «Камыр батыр» һәм башка билгеле әсәрләрдән дә өзекләр урнаштырылды. Антологиядә халкыбызның күп кенә мәкаль-әйтемнәре, җырлары, бәетләре, милли уеннары да бирелде. Шунысы гыйбрәтле: антологияне төзүчеләр һәр алты халыкка да мөмкин кадәр тигез урын бирергә омтылган. Бу – бик тә әйбәт, гадел күренеш. Китапта күренекле шәхесләрнең рәсемнәре, аерым әсәрләргә, темаларга мөнәсәбәтле иллюстрацияләр дә шактый. Бизәлеш, полиграфик як искиткеч камил.

2013 елгы антологиягә карата бер теләгем бар. Әйткәнебезчә, җыентыкта шактый гына җыр текстлары очрый. Әгәр дә һәр халыкның бер-ике җыры (мәсәлән, татарның «Туган тел»е, «Карурман»ы) ноталар белән бирелгән булса, нур өстенә нур гына өстәлер иде. Шунысын да искә төшерик: бу альманах төрки дәүләт җитәкчеләренең Азәрбайҗанда уздырылган Саммитында (16.08.2013) югары бәягә лаек булды.

* * *

Үзенең этник тамырлары белән борынгы һун, скиф-сармат, татар һәм кайбер башка кавемнәргә тоташкан төркиләр, гәрчә аларны төрлечә түбәнсетергә, мыскылларга тырышсалар да, чынлыкта данлы һәм драматик, вакыты белән фаҗигале дә юл үткән, гаҗәеп бай матди һәм рухи хәзинә тудырып, үзенең барлыгын, телен, моның саклап бүгенге көнгә килеп җиткән. Төрки дөнья тарихын, мәдәни байлыкларын гыйльми нигездә өйрәнү, бүгенге буынга җиткерү, әби-бабаларыбызның гасырлар буена туплаган тормыш тәҗрибәсен көндәлек гамәлгә кертү – мөһим бурычларның берсе. Астанадагы Төрки академия тарафыннан чыгарылган китаплар шул бурычларны гамәлгә ашыруда матур башлангыч. Алар төрки кавемнәр арасындагы бәйләнешләрне көчәйтүдә, төрки дөньяны җиһан халкына танытуда гаять әһәмиятле. Бу басмалар белән танышу, алардагы фикер-күзәтүләрне, байлыкны үзебезнең күңел хәзинәсенә әйләндерү безнең фәнебезне күтәрүгә, миллилекне саклауга һәм үстерүгә ярдәм итәчәк.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*КФУ профессоры*

# «ЯН СИН, ЙӨРӘК»

## ӘНВӘР ДАВЫДОВ ИҖАТЫНДА ЗАМАНА СУРӘТЕ

*Ә сез, бәлки, һәр кич-иртән*
*Үткәрерсез*
*Мине искә алып,*
*Мине сагынып...*
*Ә мин — хәйләкәр —*
*Бер дә кайтмам инде...*
*Чөнки шундук*
*Мине искә алудан*
*Туктар идегез, кайтсам мин әгәр.*
Ә.Давыдов. «Мин дингезче түгел...»

Замана таләпләрен тоеп, үзен хөрмәт итеп яшәгән кеше кебек үк, шигърият тә эчтәлеген, тышкы бизәлешен, «киемен» янартып тормаса, укучысын да, җәмгыятьтәге абруен да югалтырга мөмкин. Шуңа күрә һәр тарихи чорның сүз сәнгате үз арасыннан шундый ихтыяҗны сиземләгән, фәнчәрәк әйтсәк, реформаторларын үстерә, алга чыгара тора. Әйтик, XX йөз башында татар поэзиясенең халык тормышына, рухи эзләнүләренә якынаю, дөнья әдәбияты казанышларына күтәрелү сәгате җиткәнне аңлаган даһи Тукай күтәрелә, шул ук янарыш юлына Дәрдемәнд, С.Рәмиев кебек каләм осталары чыга. 1917 ел борылышыннан соң татар шигыренең мәгънәви һәм шәкли ачышлары Такташ, Туфан исемнәре, иҗатлары белән билгеләнә. 1941-1945 еллар афәте М.Җәлил, Ф.Кәрим кебек шигъри йолдызларыбызны суырып алгач, татар поэзиясе урында таптанмаса да, Тукай әйтмешли, чупансыз (житәкчесез, көтүчесез) кала. Фронт низагларының бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә татыган, исән калуларына шатланып бетә алмаган С.Хәким, Н.Арсланов, С.Баттал, Ш.Мөдәррис, Ә.Давыдов, З.Мансур, Г.Хужи, З.Нури, Ә.Маликов, М.Хөсәеннәр, табигый сәләтләре мөмкинлек биргән тәкъдирдә, үз «мин»нәрен сакларга тырышып, сүз сәнгатебезгә ихластан, намус белән хезмәт иттеләр.

Кызганыч ки, ике гасыр кисешкән чорда, төрле сәбәпләр аркасында, бигрәк тә «фронтовик шагыйрьләр»нең беришесенең әдәбиятта иң мөһиме тематика, замана рухы, ә сәнгатьчелек, профессионализм икенчел, вәзен белән кафия булса шул житкән, диебрәк санаулары нәтиҗәсендә, бигрәк тә мираслары турында кайгыртучылары булмаганнарының исемнәре сирәк чыга торган әдәбият тарихы битләрендә генә телгә алынып, мәҗмугалары китап киштәләрендә күренми башлады (Тыныч тормышта озаграк яшәү бәхетенә ирешкән С.Хәким, Н.Арсланов, С.Батталлар, сугыш чоры шагыйрьләре иҗатына хас мондый берьяклылыкны җиңеп, татар поэзиясен үлмәс әсәрләре белән баета алдылар).

Шул гомуми вәзгыятьне истә тотканда, тынгысыз «фронтовик шагыйрьләр»нең берсе — Ә.Давыдовның «Безнең чорда» *(Татар.кит.нәшр., 2011. 156 б.)* исемле җыентыгы басылып чыгуы унай күренеш итеп бәяләнергә тиеш. Берничә ел элек шагыйрьнең тәрҗемәләрен җәмәгатьчелеккә аерым китап итеп ирештергән якын туганнары — Альберт Нарбеков белән Алсу Абдульянова бу җыентыкны да, үсеш чорларын үзәккә алып, проза, драма, публицистикасыннан да үрнәкләр биреп («Түгәрәк бәхет» повестеннан мәгънәсезрәк өзекне керткәнче, шигъри романы белән ныграк таныштырсалар, «сайланма» ота төшәр иде), кыскартуларны эчтәлеккә зыян китермәслек итеп, китапны зәвык белән төзегәннәр.

Төрле унай белән Ә.Давыдов иҗатына, шәхесенә мөнәсәбәтләрен белдергән С.Хәким, Х.Камалов, К.Миңлебаев, Ш.Маннанов, Г.Рәхим, Н.Юзиев, якташы

Р.Мингалимнәр әдипне Такташ белән Туфанның 20-нче еллар тәҗрибәләрен, ачышларын, фольклор кыйммәтләрен, бигрәк тә аның шартлы алымнарын, символларын, мәкаль-әйтем фәлсәфәсен маяк итеп алып, шуларга таянып, мәгәр бер очракта да әзерне кабатлаучы пишкадәм дәрәҗәсенә төшмичә, үзфикерле, образларны, ритмик рәсемне, композицияне үзенә коручы сүз остасы булып үсеп китүенә игътибар итәләр. Остазлар турында сүз чыкканда, шул хакыйкатьне искәртү дә мөһим: башка каләмдәшләренең казанышларына таянса да аның өчен иң югары һәм буй житмәслек абруй булып Тукай һәм аның мирасы тора.

Яшь язучыларга юллаган «Ярдәмең берлә синең» (1966) исемле мәкаләсендә ул бу хакта сендереп әйтә: «Бүгенге татар поэзиясе күпкырлы булып үсә. Үзләренең шигъри алымнары, стильләре белән аерылып торган төрле-төрле талантлар килә... Шигъри юлларын бик җентекләп, тәртип белән төзүче чын «кануни» шагыйрьме яки рифма, ритм, үлчәм дигән нәрсәләрне «иң мөмкин булмаган» төстә кулланучы «новатор»мы — туган телнең шигъри мөмкинлекләрен гаҗәеп куәткә туплап оештырып калдырган Тукайдан башка алар берсе дә булмас иде». Җыентыкка исем биргән иң соңгы шигырьләренең берсен ул Тукайның фикерләү рәвешенә охшатырга тырышып, үзе сорау куеп, үзе үк җавабын эзләп («Ни бар? Ни юк? Бармы чын «Бар», Бармы чын «Юк» дөньяда?»), антитеза алымы аша нәтиҗәгә килеп, бердәнбер шигырен 15-15 ле иҗек белән яза.

Үз чиратында аңардан соңрак килгән Ә.Баянов, М.Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, Р.Мингалим һәм яшь шагыйрәләрдән Й.Миннуллина, Э.Һадиеваларның ритмиканы төрләндерү, юлларны бүлгәләү, риторик эндәш, сорау алымнарын шигъри тукымада «эретүдә» Ә.Давыдов тәҗрибәләре мәгълүм йогынты ясады һәм ясый дип уйлыйм.

Таләпчән каләмдәшләре Ә.Давыдовның үсеш авырлыкларына, өслүбенең четерекле якларына игътибар итеп, шигыренең камилләшүенә «булышып» торалар. Күренекле тәнкыйтьче Н.Юзиев Ә.Давыдов «...шигырьләренең беренче карашка кытыршы булып» күренүләренә игътибар итә («Нурлы поэзия»). С.Хәким таләпләрне арттыра төшә: «...Давыдов шигырьләре шома түгел, тигез түгел. Ул моны яхшы белә. Шигырь юллары кайчакта публицистика белән аралаша, кайчакта шагыйрь прозаизмнардан да качмый. Кайчакта иҗекләр юллардан артык чыга». Поэзиясенең бу үзенчәлеген Әнвәр ага, күңелемдәге хисләремне әйтеп калырга ашыгам, «Шуна күрә... Тигез төшми юллар шигырьдә», — дип аңлата («Никтер бу көз сагышлы...»).

Чыннан да аның шигыре «җырлап», көйгә салуны сорап тормый, чөнки ул, хисси башлангычны кире какмыйча (шуннан башка шигырь була алмый), татар сүз сәнгатенең акыл, зиһен эшчәнлегенә, фикергә өстенлек биргән канатына якын шагыйрь.

Сугышка чаклы катлаулы тормыш юлы үткән булачак шагыйрь, әүвәл гади укчы, аннан сержант дәрәҗәсендә фронт низагларының башыннан алып җиңү көненә кадәр үз җилкәсендә татыса да, кайбер каләмдәшләреннән аермалы буларак, җир өсте җәһәннәмендә күргәннәре турында күп язмый, онытырга тырыша. Әмма сугышчан дуслары — шагыйрьләрнең тормыштан иртә китүләренә ул битараф кала алмый, кемнеңдер бәхете, билгесез идеаллар өчен атакага күтәрелгән чорлары исенә төшеп, күңеле сыкрана, рәнҗи («Шәрәф Мөдәррис», «Зыя Мансурга»). «Кинәт телде йөрәкне Шомлы хәбәр: «Үлгән...» Бар чынлаулар өстендә җан өзгеч: «Шәрәф». Мәгәр үзенең дә гомере озын булмый, күп өлеше сәнгати кыйммәтен югалтмаган мирас калдырып, фани дөньяны кырык тугыз яшендә ташлап китә.

Ә.Давыдов иҗатка иртә килә, сугышка чаклы ук Камышлыда төбәк газетасында беренче шигырьләре күренә башлый, рус, татар, үзбәк телендә чыга торган вакытлы матбугатта журналист вазифаларын башкара. Сугыштан соңгы ике унъеллыкта фикерләү киңлеге, тасвир чараларының төрлелеге, мәүзуг киңлеге белән аерылып торган Ә.Давыдов каләменнән дистәләгән поэмалар, йөзләгән шигырьләр, проза, драма әсәрләре төшә. Бу чорда аның шигъриятендә өч тематик һәм мәгънәви юнәлеш ачык төсмерләнә. Кырыгынчы еллар ахырында, аллагы унъеллыкта,

гомуми агымга иярепме (ул чорда бөтен жанрда авыл, колхоз мәүзугы өстенлек итә), әллә сугыш калдырган яраларын, авыр хатирәләрен тизрәк оныту турында хыялланыпмы, күмәк хужалыклар тормышына, хезмәткәрләренә багышланган вакыйгалы сюжетлы, эшне мәхәббәт мажаралары, табигать яме белән бизәгән бер бәйләм поэма ижат итә. «Янгырлы таң» (1948) (беренче басмасы «Коммунизм таңы колхозында») «Алтын көз» (1949), «Ферма кызы» (1952), «Тыныч мәхәббәт» (1954), «Ташу» (1955), шигъри новелла дип аталган «Су юлы» (1960) кебек эпик оеткылы, яшәгән жирне, аның кешеләрен ярату хисләре белән сугарылган күләмле әсәрләрендә шагыйрь халыкны иркенрәк яшәтү өчен үзләрен кызганмыйча, көне-төне эшләгән замандашының эчке матурлыгын, рухи дөньясын ачуга омтыла. Бу поэмаларында шигырь тәнәмәгән прозаизмнар, тәфсилле сөйләмнәр, эзлекле сурәтләүләр, конфликтны жинел, шомартып чишү, тормышны бизәбрәк сурәтләү, аларның эстетик янгырашын чикләсә дә, ил белән бергә татар халкы узган тормыш баскычларын күрсәтү яссылыгыннан килеп бәяләгәндә, Ә.Давыдов поэмалары танып-белү әһәмиятләрен югалтмыйлар.

Үзәккә алынган теманың нечкә якларын тотып алып, вакыйга-хәлләргә үзенчә бәя бирә белү сәләте Ә.Давыдовның 60-нчы елларда шәһәр тормышына, төзелешләргә, фән-техника өлкәсендәге ачышларга багышланган урбанистик поэма-шигырьләрендә дә саклана. «Чорлар чатында», «Дәверләр диалогы», «Себер трактында квартал» кебек замана яңалыкларына багышланган әсәрләрендә текә ритмнар (-Тук-тук! — Дан, дон-дон!), кинодагы шикелле тиз алышынып торган күренешләр аша бу үзгәрешләрнең шәхес тормышына, язмышына, рухи дөньясына тәэсирен ачарга ниятли.

Ижатының югары үрләренең берсе — «Чорлар чатында» (1959) поэмасы шәхес культы фаш ителгәч, жәмгыять әхлакый кыйммәтләр, киләчәк, һәр кешенең тормыштагы урыны турында житди уйлана башлаган вакытта язылa.

Ирекле агышлы композициянең үзәгендә «Беләсеңме, бәхет ул нәрсә?» кебек фәлсәфи-этик сораулар һәм аларга бергәләшеп жавап эзләү ята. Шагыйрь мондый соальләрнең берәүне дә битараф калдыра алмасын белеп, анлап сүзне алып бара һәм жавабы белән дә ашыкмый. Көндәлек һәм мәңгелек мәшәкатьләре белән мәшгуль олы дөньяны лирик каһарман образы аркылы кабул итәбез һәм анлыйбыз. Бәхет яңа туачак ал таңнардан, бер-берсенең кадерен белеп яшәгән олы мәхәббәттән башка була алмый, дигән беренче нәтижәсенә килә шагыйрь.

*Бу минутта безнең бакчаларда*
*Күпме сөю чәчәк атадыр.*
*Кайдадыр бер кушылган пар*
*Сөенә-сөенә өенә кайтадыр.*

Тулаем алганда, «катырак» күңелле булып күренергә тырышкан, балавыз сыгуны өнәмәгән, мәгърур ритмнар шагыйре, гашыйкларның мәңгелек юлдашы, традицион образ — ай белән очрашкач, бар «эрелеген» онытып, «боламык» Мәжнүнгә әйләнә дә куя.

*Күпме еллар,*
*Күпме чорлар*
*Моң сипте, ай,*
*Синең нурлар.*
*Егет башын*
*Кайгы басса,*
*Хәсрәттән качса,*
*Жырлый иде*
*Сиңа карап,*
*Тик юк иде*
*Синнән жавап.*

Алдагы юлларда лирик герой белән ай арасында «ышанычлы» әңгәмә булып ала, символның экспрессив мәгънәсе кинәя төшә. Ул чорда кабул ителгәнчә, айның «сагыш-моңын» кире кагып, «чакыру нуры н алгы нәүбәткә чыгара.

Күләме белән җыйнак поэманың архитектоникасы, фикер агышы, хис катламы шактый катлаулы. Шагыйрь табигать матурлыгын интеллект, зиһен казанышы белән янәшә куеп, чорны инләргә, сугыш, «Җир хурлыгы коллык!» кебек олы вакыйгаларга игътибарны юнәлтә. Шуңа күрә поэмада сурәтлелек чарасы, кинаяле тасвир алымы буларак метафора зур әһәмияткә ия.

*Урманда — чык. Далада рәшә.*
*Иярченнәр күктә серләшә.*
*Елга белән елга берләшә.*

Поэманың сонында автор гомере буена эзләгән «Беләсенме, бәхет ул нәрсә? — дигән соаленә тулырак җавап бирә.

*Беләсеңме, бәхет ул нәрсә? —*
*Юлда битеңә талгын җил бәрсә!*
*..................................................*
*Беләсеңме, бәхет ул нәрсә? —*
*Кеше сиңа рәхмәтен әйтсә!*
*Беләсеңме, бәхет ул нәрсә? —*
*Эзең калсын, үлсәң дә гәрчә!*

Бу фаразлар искерде, кыйммәтен югалтты, дип әйтергә кемнен теле әйләнер икән.

Ә.Давыдов иҗатының өченче һәм, әйтергә кирәк, төп юнәлешен күнел лирикасы тәшкил итә. Галәмнәргә, ерак гасырларга хатлар язган әдип, «аңына» килеп, гөнаһлы җиргә төшә һәм бәйнәлмиләл битлеген-маскасын салып, табигать фасыллары, рухи дөнья матурлыгы, мәхәббәт, сөю-сәгадәт сагышы турында ихласи шигырьләрен яза, укучысына ин саф йөрәк серләрен ышанып тапшыра, һәр мизгелнең кыйммәтен белеп яшәгән ихласи шәхес булып. «Шатлык өчен күп кирәкме кешегә?», «Җәен төннәр аяз чагында», «Уздылар байтак гомерләр», «Язгы төшләр» кебек кеше тормышының мәгънәсе, тарихи барыш, яшәү белән үлем турында уйланган, лирик затның эчке кичерешләрен үзәккә алган медитатив шигырьләрен укыганда, кая китте теге барабан кагулар, дәртле гимннар, күк җисемнәренә кизәнүләр дип гаҗәпләнеп, аптырап, ахыр сөенеп утырасың. Ин мөһиме канәгатьсезлек хисе, эчке сызланулары, гаҗизлеге белән сурәткә шагыйрь үзе килеп керә.

*Бер язам да бер сызамын,*
*көн утә, укып карап.*
*Уйланам, эчтән сызланам*
*бар эшем, дим, юккарак —*
(«Бер язам да...»)

«Никтер бу күз бик сагышлы мина...», «Шәһәрдә болытлы ямьсез көн...», «Язлар миңа хәстәрләмәс инде...», «Бөтен язган җырларымны...», «Үләр өчен кеше урын...» кебек заманында төшенкелеккә, өметсезлеккә бирелә, дип битәрләнгән шигырьләре эчкерсез өзгәләнүләре белән җаны бар кешене битараф калдыра алмыйлар.

*Никтер бу күз бик сагышлы миңа,*
*Ахры, үзенекен итә чир.*
*Бөдрә чәчем белән шаярмый да,*
*Күкрәккә моң салып китә җил.*

*Төннәрендә башка әллә нинди,*
*Тәнкыйтьчеләр рөхсәт итмәгән*
*Уйлар кила: «Вакыты җиткәч үлем*
*Беркемне дә җәлләп үтмәгән».*

(«Никтер бу көз бик сагышлы миңа...»)

Бу төр шигырьләрендә яшь, башы иҗади хыяллар белән тулы кешене урында сыкранып ятарга мәҗбүр иткән сугыш яралары, аннан соңгы авыр еллар, ачлык, хәерчелек, киләчәк өчен яшибез дигән тормышка ашмас вәгъдәләр кебек күренешләргә тәнкыйди караш, юл араларында яшертен оппозиция сизелә.

*Үләр өчен кеше урын*
*Сайлый алмый алдан ук.*
*Тормыш биргән вәгъдәләргә*
*Йөри әле ул алданып.*

(«Үләр өчен кеше...»).

Ә.Давыдов иҗатында иҗтимагый лирика өстенлек итсә дә, рухи дөньясының байлыгы мәхәббәт мизгелләренең төрле чагылышларын үзәккә алган шигырьләрендә тулырак ачыла. Сөю-сөелү, ләззәтләнү, сыкрану, уйлану, сызлану кебек хисләр турында язганда, шагыйрь натурализм ярларына төшмичә, кешеләр арасында мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгын саклык белән сурәтләргә тырыша. Күңеленә ингән матурлык нурын ачуда аның юлдашлары — ай, кояш, җил, чәчәк, болыт, тал кебек традицион сурәтләр.

*Нишлим икән,ниләр генә итим?*
*Күңелем һаман сине сагына.*
*Таң алдыннан чыгам су буена,*
*Тик анда да ялгыз тал гына.*

(«Тал»)

Табигать күрке тал лирик затның ялгызлыгын, хәсрәтен «бүлешә» сыман. Ана мәхәббәтнең яшен уты кебек ялтырап алган һәр мизгеле кадерле һәм газиз.

*Бәлки, артык сине мин очратмам.*
*Бер күрдем дә, күздән югалдың.*
*Елмайдың да миңа бик ерактан*
*Көнге мәшәкатькә чолгандың.*

(«Бәлки, артык сине...»)

Ә.Давыдовның лирик каһарманы женси азгынлыкны, кемгәдер бәйләнеп, кадерсезләнеп йөрүне күз алдына да китерә алмый. Яхшы мәгънәсендәге аскетизм сагынырлык, сокланырлык. Шашып сөеп, йөрәгеннән кан тамганда да, ул үзен тыеп кала белә. «Ян син, йөрәк. Шул бит тормыш!», — дип тәмамланган шигырендә, ул мәхәббәтнең илаһи көчен күпертү алымы аша сурәтли.

*Мәхәббәтнең тәмуг газапларын*
*Кем күбрәк миннән татыган?*
*Йөрәгемнең ал кан тамчылары*
*Эземә тамып килде артымнан.*

(«Мәхәббәтнең тәмуг...»)

Сөю хисе өермәдәй, җир тетрәведәй көчле булса да, ул упкынга ташланмый, аның бар курыкканы кадерлесенен үзен дөрес анламавы.

*Сиңа хисләремне күңелемдә*
*Һаман кадерләбрәк тотамын.*
*Аңламас дип сүзем сөюемне,*
*Торган саен күбрәк куркамын.*

(«Моңсуланма, иркәм...»).

Ә.Давыдовның шигъри һәм публицистик мирасында туган халкының язмышы, теленең киләчәге турында уйланып, борчылып язылган әсәрләр аерым урын тота. «Халык» белән «татар» сүзләре аның өчен изге һәм газиз төшенчәләрнең билгеләре (ул чорда әле милләт сүзен авыз тутырып әйтү куркыныч иде). «Халкым минем яшерә алмыйм...» шигырендә ул халкы алдында кылган гамәлләре өчен хисап тота:

*Кыен минем нәни эшләр белән*
*Үрелү синең бөек буеңа.*

Икенче бер шигырендә мактауларга алданып, үсенеп китkән якын кешесенә хакыйкатьне, дөреслекне кайсы тарафлардан эзләү кирәклекне исенә төшерә: «дустым, ялган шөһрәттән» сакланып калуның ышанычлы юлы — «Халык дигән бөек төркем» фикеренә, бәясенә таяну, ди шагыйрь. («Саклан, дустым, ялган шөһрәттән»).

Милләтенең хокукларын, дөнья халыклары харитәсендәге лаеклы урынын, татарлыгын яклаганда, шагыйрьнең тавышы кырыслана, анарда кан кардәшләрен рәнжетергә, кимсетергә җөрьәт иткән теләсә кем белән бәйгегә чыгарга әзер, Волхов, Ленинград, Балтыйк буе канлы бәрелешләрендә чыныккан гаярь сугышчы рухы уяна. Бу җәһәттән аның «Тарихка карата» (1959) памфлеты белән «Рус теле» шигырендә, татар лөгатенә тибеп узган, шул чор совет поэзиясенең күренекле вәкиле Ярослав Смеляковка, үлеменә бер ел калгач, каты авыру хәлендә язган ачык хаты (1967) әдипнең тормыш позициясен, миллилеген аңлау өчен гаять әһәмиятле ядкарьләр.

*Тикшермәдем, мин тарихчы түгел,*
*Минем ата-бабам йөреткән*
*Татар исем ялгыш исем, диләр.*
*Без — болгарлар, диләр, электән.*

(Ә.Давыдов. «Тарихка карата»)

Шагыйрьне бу очракта үзебезнең арада яшәүче коткы таратучыларның, бер күзәнәкле сәясәтчеләрнең халыкның аңын бутап, татарның катлаулы үсешен болгарчылыкка гына кайтарып калдырулары кебек үк, рәсми тарихның монголлар кылган явызлыкларны хәзерге татар милләтенә сылап, үткәнне бозып аңлатуы ярсыта. СССРны саклап Днепрда һәлак булган атаның улы дәреслектән «явыз татар» дигән яланы ятлап утырырга мәҗбүр. «Купмый миндә татар дигән сүз», дип, халкының көченә, киләчәгенә тирән ышанычын белдерә:

*Татар, татар, син бүген дә юлда,*
*Көчең әле тора бөркелеп.*

(Ә.Давыдов. «Тарихка карата»)

Татар телен «он итү» хисабына рус телен «баетырга» алынган шагыйрьгә мөрәҗәгате телебезне «яңа дәрәҗәдә» кысу башланган безнең көннәрдә аеруча мөһим янгырый. «Яшермим, дип яза Ә.Давыдов шигырегезне беренче кат укыганда, минем телемне мыскыл итүегез өчен генә күнелем рәнҗеде. Ә кат-кат укыгач — бөек рус теле өчен, сезнең шәхси поэтик телегез өчен дә күнелгә бик кыен булды. Нинди дә булса бер телне он итү хисабына гына баеган тел тарихта юк...» Үткәннән мәгълүматлары сыек рус шагыйренә хат авторы иренмичә аңлатмасын

да бирә. «Истә тотыгыз: татар теле басып алучы монголлар теле түгел... Ул телне басып алучы монголлар да, Грозный басымы да он итә алмады. Ул тел һаман үсте, баеды, башка халыкларга да унай йогынты ясады», — ди Ә.Давыдов публицист, күрәшче.

Милли идеологияне камилләштерү, заманага җайлаштыру турында кискен бәхәсләр барган XXI гасыр башында Ә.Давыдовның бер фикере аеруча игътибарга лаеклы. «Халык көчләүләргә дучар булган саен, үз теленә сакчыллык-кайгыртучанлык белән карый», — дигән җөмләсе милли сәясәтебезнең нигез баганасы булырга хаклы. Халкыбыз бик акыллы алып барылган астыртын көчләүне аңлап, пассионарлык куәтен уятсын, телен саклау өчен күтәрелә алсын иде!

Соңыннан ачыкланганча, җирдәге тормышының соң көннәрен Ә.Давыдов олы эпик әсәр — шигъри роман иҗат итүгә багышлый. «Каләмдәш дусның соңгы әсәре «Йокысыз төннән соң» дип атала. Бу шигырь белән язылган роман. Соңгы әсәр, — дип яза С.Хәким һәм аны оста корылган конфликтлы поэмаларының «синтезы» буларак бәяли. Архивында табылган «Йокысыз төннән соң» шигъри романы эпик сюжетны лиризм белән бизәп алып баруга, ил тормышын Гайни, Гөлзада, Наталья кебек шәхес язмышлары аша күрсәтүгә осталыгын, текә борылыш елларында үз урыныңны, кыйблаңны табу авырлыгын психологик күзәтүләр, тасвир чаралары гаммасы ярдәмендә ачу сәләте үсүенә дә дәлил булып тора. «Бер тәүлеккәчә тыгызланган бер гомер. Бер күңелгә тыгызланып тулган безнең чор» эпиграфы шагыйрьнең алдына куйган максатын аңлауга ачкыч булып тора.

С.Батталның «Чирмешән ярларында» исемле шигъри романы кебек үк, Ә.Давыдовның бу олы эпик әсәре татар поэзиясенең офыгын киңәйтеп, телебезнең мөмкинлекләре чикләнмәгән булуны янә бер кат исбатлады. Шул традицияләр җирлегендә, яңа гасыр башында, Р.Харисның «Исемсезләр» шигырь романы пәйда булды.

Шул рәвешле, тормыш чынбарлыгын хыял көче белән үреп баруга ирешкән, кирәк чакта шаярта да белгән («Хуҗа Насретдин турында җырлар») Ә.Давыдов мирасы ул яшәгән һәм иҗат иткән чорның шигъри сынын тудырып калдыруы белән кадерле. Татар һәм башка әдәбиятларның казанышларын иҗади үзләштереп, Ә.Давыдов шигъриятебезне үзенчәлекле чигешле поэмалары, публицистикасы һәм самими, эчкерсез шигырьләре белән баетты. Чал тарихлы татар поэзиясенең сугышта да, иҗади бәйгедә дә үз «высотасын» бирмәгән, шул ук вакытта «даһилыкка» дәгъва итмичә, татар сүз сәнгатенә ихластан хезмәт иткән, гайрәтле Әнвәр Давыдовы бар! Аның мирасы, алдагы елда чыккан китабы, галим сүзе барлык «фронтовик шагыйрьләр»ебез рухына дога булып ирешсен!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Мәмсә

Мәмсә авылы район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән 35 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Ташкичү авылыннан – 1, Казаннан 101 чакрым ераклыкта урнашкан.

Д.А.Корсаков белешмәсендә (XVIII йөз) Мәмсә авылы Мәмсә суы ярына утырган Байчура пүчинкәсе, Мәмсә исемнәре белән искә алына. Анда 78 йомышлы, 1 керәшен татары яшәгән Укше елгасы ярындагы Укше пүчинкәсендә 76 ясак түләүче татар көн иткән. 1859 ел мәгълүматларын эченә алган белешмәдә авыл Байчура пүчинкәсе дип искә алына. Ашыт суы ярына утырган бу авылның 76 хужалыгында 295 ир-ат һәм 316 хатын-кыз көн иткән, мәчет эшләгән.

1878 елда басылып чыккан тарихи белешмәдә күрсәтелгәнчә, Байчура пүчинкәсе Байчура авылы жәмгыятенә кергән. Пүчинкәдәге 223 хужалыкта 515 ир-ат һәм 472 хатын-кыз көн иткән. Анда агач мәчет, мәктәп, 3 кибет, су тегермәне эшләгән.

Нажия апа Борһанова мәгълүматлары күрсәтүенчә, Мәмсә авылы халкы май аеның ахырында күршедәге Иске Ашыт, Иске Кенәр, Печмәнтау, Сөрде, Ташкичү, Иске Тазлар авыллары белән Ашыт жыены үткәргәннәр. Ул жыен икенче төрле Ашыт каршы яисә катык жыены дип йөртелгән.

Мәмсә авылы зиратында XIX йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташы билгеләнгән.

Олылар сөйләве буенча, авылга нигез XVII гасыр ахырларында салына. Авыл яныннан Ашыт суы ага. Ана Мәмсә суы килеп кушыла. Авыл янында зур булмаган күл бар. Аны Бака күле дип әйтәләр. Чишмәләр бик күп түгел. Мәмсә суында элек тегермән буасы булган һәм анда су тегермәне эшләгән. Берничә кичү урыны бар. Аларның берсе Кәрәкә дип атала. Авылның үзәк урамнарында электән үк таштан юл салынган булган. Авыл уртасында таш күпер бар.

Мәмсә таулы урынга утырган. Ул урынны Хәтимә әби тавы диләр.

Икенче гильдия сәүдәгәре Мөхәммәтсафа Галикәев (1822-90) чыгышы белән Казан өязенең Мәмсә авылыннан була. Ул Казанда үзенең сабын заводы житештергән әйберләр белән сәүдә иткән, 1880 елда Ш.Мәржанигә мәдрәсә («Мәржания») төзүдә зур матди ярдәм күрсәткән. Сәүдәгәрнең Мәскәү урамындагы корылмасы табыш йорты (доходный дом) булган, заманында бирелә Г.В.Майзельснын дару кибете, Я.А.Кравернын аптекасы, Х.М.Сәлимовнын бакалея кибете һ.б. урнашкан була. М.Галикәевнын вафатыннан соң 20000 сумлык дип бәяләнгән әлеге хужалык анын варислары милкенә күчкән. Соңгылары аны 1916 елда «Мәржани» мәчетенә бүләк иткәннәр.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

## Мүлмә

Мүлмә авылы Биектау районында, район үзәге Биектау тимер юл станциясеннән – 27, Казан шәһәреннән 60 чакрым ераклыкта утырган.

Мүлмә авылы тарихи чыганакларда телгә алына. Ул Казан ханлыгы чорында ук булган.

Н.Н.Вечеслав (XIX йөз) китабында Мүлмә авылы искә алына. Авылдагы 131 хуҗалыкта 347 ир-ат һәм 862 хатын-кыз исәпләнгән. Авылда волость идарәсе һәм бер агач мәчет булган.

1866-67 еллар белән авыл исеме тарихи хезмәттә теркәлеп калган. И.А.Износков Мүлмә авылының татарча исеме Мулла Иле дип күрсәтә. Себер элемтә юлының сул ягына утырган бу авылның мулла тарафыннан нигезләнүе турында ул легендага таянып яза. Элек Мүлмә авылы даирәсенә аерым торак пункт булып исәпләнгән Мулла Иле пүчинкәсе дә кергән. Бу пүчинкәне Тәтеш районы Алабирде авылыннан килгән мулла оештырган. Үзе үлгәннән соң монда аның оныклары яшәп кала. Авылда элек 110 хуҗалык булып, анда ислам динен тотучы 423 ир-ат һәм 431 хатын-кыз яшәгән. Халык он тарту һәм умартачылык белән шөгыльләнгән. Тирә-юньдә яшәгән авыл аксакаллары Мүлмәнең икенче төрле Мулла Иле дип тә йөртелүен һәм анда муллалар укытылган булуын сөйләделәр. 1898 елгы хезмәттә Мүлмә һәм аның пүчинкәсе искә алына, анда татарлар яшәгәнлеге әйтелә. К.П.Берстель җыентыгында күрсәтелгәнчә, Мүлмә авылында барлыгы 962 татар кешесе исәпләнгән.

Мүлмә авылы халкы Иске Җөлби, Яңа Җөлби, Комыргуҗа, Олыяз, Сасмак авыллары белән бергә июньнең икенче декадасында Кызыл Яр җыены бәйрәм иткән. Ул икенче төрле Җөлби җыены яисә Сасмак җыены дип тә йөртелгән.

Мүлмә авылы табигатьнең бик матур, күркәм бер җиренә урнашкан. Аның бер ягында таулар, икенче ягында зур куе урман (Чыпчык урманы турында сүз бара). Авыл яшеллеккә күмелеп утыра.

Мүлмә авылы янынннан Кызылсу елгасы агып үтә, ул Казансуга коя. Кызылсуның суы чиста, ләкин ул хәзер бик саеккан. Аның Әртил асты дигән урынында өлкәннәр атлар коендырганнар. Инешнең тирә-ягында ямь-яшел булып тал агачлары үсеп утыра. Кызылсу Әтнә районының Яңа Җөлби авылы янындагы бәләкәй чишмәләрдән башлана. Елганың башланган урынында ярлары биек һәм кызыл балчыктан гына тора. Инешнең суы гел кызыл төстә, бара-бара гына бераз чистара. Ул юлында 7 авыл аша үтә. Иң тирән урыны булып Сасмак авылы тирәсеннән узган өлеше исәпләнә.

Мулла елгасы исә – коры елга. Элек аның үзәнендә печән шәп үскән, аны мулла чапкан. Кар сулары язын аның буенча Кызылсуга төшәләр. Колачы елгасы да Казансуга кушыла. Бу елганың кайбер урыннарында су бар. Ә урыны белән ул бөтенләй коры.

Авыл янындагы таулар бик биек түгелләр, ләкин үзләренә күрә исемнәре бар: Зират тавы, Аргы як тавы, Станция тавы. Моннан башка тагын Үләксә чокыры, Мулла җире, Олыбай басуы атамалары халык телендә актив кулланыла. Юл атамалары да шактый. Авыл башында Чүкмәч юлы сузылып киткән. Анда Чүкмәч кушаматлы кеше торган.

Халык авыл урамнарын үзенчә атый: Ахирәт урамы, Таш урам, Аскы урам. Зират башы урамы, Кибет урамы, Аргы як урам, Авыл башы урамы, Шамайлар урамы, Алты өйле урам — хәзерге исеме Түбән урам, Котылдык урамы (яңа барлыкка килгән, әти-әниләреннән аерылып чыгып, өй салып чыгучы яшьләр урамы).

Авыл халкы эшчән һәм иманлы. Авыл йортлары һәм каралты-куралар нык, таза. Авыл яшьләре читкә китми, шушында төпләнеп калалар. Кем белә, бәлки Мулла Иле авылында киләчәктә мәдрәсә ачылып, ул иман нуры чәчә торган бер үзәк булып китәр.

Мүлмә авылында 300гә якын хуҗалык исәпләнә. Анда мәктәп, мәдәният йорты, китапханә, балалар бакчасы, ике кибет бар.

Авылда мәчет эшли. Теләгән кеше анда гыйбадәт кылырга йөри.

## Наласа

Наласа авылы Арча районына керә, ул район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән – 9, Казаннан 75 чакрым ераклыкта урнашкан.

Наласа авылы Казан ханлыгы чорында да булган.

Эпиграфист Һарун Йосыпов Наласа авылы зиратында XVI йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташы язмалары тапкан. Археологлар да Наласа зиратында XVI йөзнең беренче яртысына мөнәсәбәтле кабер ташы язмаларын билгеләгәннәр.

Д.А.Корсаков хезмәтендә (XVIII йөз) авылда 314 йомышлы татар яшәгәнлеге күрсәтелә.

1898 елгы җыентыкта авылда татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. К.П.Берстель хезмәтеннән күренгәнчә, Наласа авылында барлыгы 1647 татар кешесе яшәгән.

Наласа авылы халкы күршедәге Югары Аты, Урта Аты, Түбән Аты, Яна Аты халкы белән бергә июнь ахырында һәм июль башында Наласа исемле җыен бәйрәме үткәргән.

Өлкән буын кешеләре сөйләвенә караганда, авыл тирәсе элек калын урманнар белән капланып алынган булган.

Наласаның тирә-юне матур, урамнарында яшеллек күп. Авыл янынннан Наласа суы агып үтә. Халык телендә икенче төрле ул Утай асты елгасы дип тә атала. Наласа башы елгасы Наласа суына кушыла. Заманасында ул суын Утай асты елгасына китергән. Коры елганың хәзер суы беткән, яз көне генә була. Аның тирә-юне кызыл балчыклы. Бурсык елгасы янында элек бурсыклар яшәгәнлеген аңлыйбыз.

Авыл эчендә һәм тирәсендә матур гына чишмә-кизләүләр бар. Бурсык елгасының түбән итәгендәге Рәбига чишмәсен шул исемдәге хатын-кыз кадерләп карап торган. Бу чишмә турында авыл өлкәннәре болай сөйли: «Авылдагы Рәбига бик тырыш хатын иде. Басуда урак урганда ул чишмә таба һәм аны карап, тәрбияләп тора. Ул вафат булганнан соң халык чишмәне аның хөрмәтенә Рәбига чишмәсе дип атый». Тагын Балтай чишмәсе бар. Ташчишмә ташлы урыннан ага, Утай асты суына кушыла. Үләт елгасы астындагы чишмәне Сазлык чишмәсе дип йөртәләр. Таҗи тегермәне янындагы чишмә Таҗи тегермәне чишмәсе дип аталган. Элек Наласа яисә Утай асты елгасында Җанкуат, Пума (Фома), Таҗиныкылар һәм Мөхәммәтвәли тегермәннәре эшләгән. Тегермән буалары нәтиҗәсендә елга-инешләрдә су да мул булган. Хәзер тегермәннәр дә юк, чишмәләр дә чистартылмый, сулары да бетү алдында тора.

Арча районында Наласа зур авыл санала. Анда 250дән артык хуҗалык бар. Авылда балалар бакчасы, элемтә бүлеге, китапханә, мәдәният йорты һәм урта мәктәп эшли. Юлларга асфальт салынган.

Наласа авылына багышланган халык җыры һәммәбезгә таныш:

*Өздереп гармун уйныйлар*
*Наласа авылында.*
*Йөрәгемә утлар яктың,*
*Янам мин ялкынында...*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Р

**РИСАЛӘ** (гарәп) — юллама, хат, трактат) Урта гасыр гарәп, фарсы, төрки әдәбиятлары жанры. Мөстәкыйль жанр булып гарәпләрдә 8 гасырда сәяси яки фәлсәфи эчтәлекле кыска юллама, трактат буларак формалаша. Төрки-татар әдәбиятында да Р. жанрында әсәрләр языла (Ялчыголның «Рисаләи Газизә» һ.б.). 19 — 20 йөз башында татар әдәбиятында «Р» атамасы б-н теләсә нинди аз күләмле чәчмә әдәби, фәнни-популяр, публицистик әсәрне атаганнар. Хәзерге заманда сирәк кулланыла.

Әдәб.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**РОБАГЫЙ** (гарәп. — дүртләтелгән), Шәрекъ халыклары шигъриятендә лирик жанр; ааба, аерым очракларда аааа рәвешендә рифмалаша торган, тәмамланган дүртьюллык. Аерым очракларда рәдиф урын ала. Лирик кичерешләрне, фәлсәфи уйлануларны белдерү өчен кулланыла. Тарихы фарсы фольклорына барып тоташа. Язма рәвештә 9-10 гасырлардан бирле билгеле. Борынгы төрки язма әдәбиятында Р. остасы булып фарсы шагыйре һәм галиме Гомәр Хәйям санала. Татар әдәбиятында Р. жанрына Сәйф Сараи, Акмулла, Г.Тукай, М.Гафури, Дәрдемәнд, Ш.Бабич, Х.Туфан, Ә.Исхак, Н.Арсланов, З.Мансур, Р.Гатауллин һ.б. мөрәҗәгать итә.

Әдәб.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**РОМАН** (франц. roman), аерым кешенең язмышын, аның тирәлек б-н каршылыкларын һәм шул вакыттагы эчке кичерешләрен, характеры һәм үзаны үсүен, шәхси тормышның иҗтимагый мәгънәсен күрсәтеп хикәяләү, әдәби жанр, зур күләмле эпик әсәр. Жанр авторга геройлар рухи дөньясының үсеш-үзгәрешен озак вакыт дәвамында күзәтергә, аларның характерлары формалашу һәм үсү шартларын анализларга мөмкинлек бирә. Мөстәкыйль хикәяләү жанры буларак Р. татар әдәбиятында 19 йөзнең 2 нче яртысында пәйда була. Башта мәгърифәтчел әдәбиятка хас булганча, үгет-нәсихәт бирүгә, сюжет төзелешен билгеле бер тезисны раслау яки кире кагуга, персонажлар системасына автор идеяләрен йөрткән геройларны кертүгә корылган Р.нар языла (М.Акъегетнең «Хисаметдин менла», З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә», «Гөнаһе кәбаир» әсәрләре). Р.ның жанр буларак барлыкка килүе татар әдәбиятының Көнбатышка йөз тотуы нәтиҗәсе генә түгел, ә бәлки авторларның уку-укыту системасын яңартырга һәм камилләштерергә омтылуына да бәйле. Жанрның төрләре татар җәмгыяте тормышын сәнгати яктан тулаем күрсәтергә мөмкинлек бирә. Әйтик, Г.Исхакый иҗтимагый-психологик «Теләнче кызы» Р.ында татар хатын-кызының милләт киләчәге өчен көрәш юлына басуын күрсәтә; социаль тигезлек мәсьәләсен күтәрә; «Тормышмы бу?» психологик Р.ында яшь буынны тәрбияләү мөһимлеген һәм укытуда искергән дини кануннар һәм ышануларга сукырларча иярүнең фаҗигасен ача; иҗтимагый-тарихи «Мулла бабай» Р.ында татар җәмгыятендә ислам традицияләренең ролен яктырта. Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» Р.ны б-н бергә татар әдәбиятында мөстәкыйль сәнгати юнәлеш булып романтизм формалаша. Ф.Әмирханның «Урталыкта» Р.ны 20 йөз башы татар зыялыларының рухи эзләнүләрен бәяләве ягыннан үзенчәлекле.

1920 еллар уртасыннан Р. жанры үсеш кичерә. Авторлар иске тормыш тәртипләренең җимерелүен, яңалары тууын, аларның кеше аңына һәм язмышына ясаган фаҗигале тәэсирен эстетик яктан аңлатырга омтылалар. Бу чорның күренекле әсәре булып Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» Р.ны (эчтәлеге б-н иҗтимагый-революцион, формасы б-н детектив) тора. Бу тенденция Ш.Камалның «Таң атканда» һәм «Матур туганда» героик-революцион, М.Галәүнең «Кабулсай» Р.нарында дәвам иттерелә. Милли традицияләрне гәүдәләндерү һәм саклап калуга

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынан басылып килә.*

омтылу М.Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр», Г.Ибраһимовның «Казакъ кызы» Р.ры язылуга сәбәп була. Берникадәр тукталып торганнан соң, 1950 елларда Р. янарыш чорын кичерә һәм әдәбиятны яңа типтагы әсәрләр б-н баета: Г.Әпсәләмовның героик-романтик «Алтын йолдыз»ы, К.Нәҗминең героик-революцион «Язгы җилләр»е, Ф.Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы», Г.Әпсәләмовның биографик «Газинур»ы, И.Газиның «Онытылмас еллар»ы, Ә.Фәйзинең «Тукай»ы, Г.Бәшировның иҗтимагый-психологик «Намус»ы, М.Әмирнең «Саф күңел»е шундыйлардан. Р. жанры, дөреслеккә хилафлык китермичә, тарихи үзгәрешләр чоры вакыйгаларын бөтен нечкәлекләре б-н кабатлап тасвирларга, кешенең эчке дөньясындагы тирбәлешләрне күзәтергә мөмкинлек бирде. Бөек Ватан сугышы темасы Г.Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше», Ш.Маннурның «Муса» документаль Р.рында дәвам иттерелде. Аларда сугыш натуралистик пландагы кансыз көрәнешләр һәм совет идеологиясе патетикасы бердәмлегендә тасвирлана. Авторлар авыр сугыш шартларында һәм әсирлеккә юлыккан кешеләрнең психологиясен сурәтләүгә игътибар бирә башлый: Ш.Рәкыйповның «Йолдызлы төннәр», Х.Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» Р.ры.

Г.Ахуновның «Хәзинә», Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», И.Газиның «Гади кешеләр» һ.б. производство романнарында төп герой бәхетен хезмәттә таба, хезмәт шәхесне, аның аңын, фикерен, карашларын камилләштерү чарасы кебек бәяләнә. 1960-70 нче елларда тарихи һәм иҗтимагый-психологик яссылыкларны тоташтырган романнар языла. Тарихи җирлек Гражданнар сугышы елларында татар җәмгыятендә барган үзгәрешләрне (С.Батталның «Чирмешән ярларында» шигъри Р.ны), В.И.Ленинның революцион эшчәнлеген (Г.Әпсәләмовның «Күк күкрәр» Р.ны) колачлый, шәхескә мөнәсәбәт иҗтимагый-психологик планда совет идеологиясе позициясеннән чыгып аңлатыла. Ләкин 1960 елларның 2нче яртысыннан башлап татар әдәбиятында героик тенденциягә тискәре мөнәсәбәт урнаша һәм беренче планга әхлакый бурыч, сайлау мәсьәләсе килеп баса. Җәмгыятьтәге әхлакый тупаслану, акрынлап милли тамырларны югалта бару язучыларны бу күренешләрнең сәбәпләре турында уйланырга, аларны «эчтән», кеше психологиясеннән эзләргә этәрә. Тәүбә-истигъфар проза, беренче чиратта Р. материалында, рухи торгынлыктан чыгу юлларын барлый, бер үк вакытта совет җәмгыяте нигезләрен, кешенең әхлакый түбән тәгәрәвен тәнкыйди бәяләү башлана (Г.Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр»е, А.Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын»ы, А.Расихның «Ике буйдак»ы, «Сынау»ы). Авторлар көнкүрештәге кимчелекләрне бөтен нечкәлекләре б-н, «эчтән», бюрократик каршылыкларга, яхшылык һәм хакыйкать төшенчәләренең бозып аңланылуына, әхлакый нигезләрнең җимерелүенә тап булган кешеләр күзлегеннән тасвирларга омтыла.

Хакыйкать эзләп, язучылар халыкның үткәненә мөрәҗәгать итәләр. Нәкъ менә тарихи Р.да татар әдәбиятының идея-эстетик юнәлеше алмашына (Н.Фәттахның «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар», М.Хәбибуллинның «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный», Р.Батулланың «Сөембикә», Ф.Латыйфиның «Хыянәт» Р.ры).

1920-30нчы, 1930-50нчы еллар вакыйгаларының асылын аңларга омтылып, язучылар аерым бер кеше язмышына карата рәхимсез чорны каршылыклы вакыт буларак тергезәләр. Г.Ахуновның «Идел кызы», Г.Бәшировның «Гыйбрәт» Р.рында әдипләр үзләре шаһит булган фаҗигале вакыйгалар турында бәян итә, әхлакый кыйммәтләрнең алмашынуы, рухи югалтулар тарихы сурәтләнә. Кырыс иҗтимагый сынауларга каршы торырлык бердәнбер көч итеп кешеләр арасындагы җылы мөнәсәбәтләр күрсәтелә, туганлык, бердәмлек, туган илгә мәхәббәт кебек кыйммәтләрнең мөһимлеге раслана. Кайбер Р.да табигать кешедәге рухи ярлылыкка каршы куела, әхлакый тамырларга кире кайтырга өндәү яңгырый (Г.Бәшировның «Җидегән чишмә»се). Шигъри Р.ның яңалан торгызылуы традицияләрне яңарту кебек кабул ителә (Ә.Давыдовның «Йокысыз төннән соң», Р.Харисның «Исемсезләр» әсәрләре).

1980-90нчы елларда Р.да фәлсәфи яктан чишелеш тапкан төп темаларның берсе — тоталитар шартларда зыялыларның фаҗигасе, шул китереп чыгарган коточкыч әхлакый нәтиҗәләр булды (А.Гыйләҗевнең «Балта кем кулында?», Ф.Сафинның «Саташып аткан таң»). Бу әсәрләрдә заман конкрет-тарихи (совет идеологиясе) һәм символик (шәхеснең тапталуы) яктан чагылдырыла. «Лагерь прозасында» (Г.Тавлинның «Афәт», Р.Мөхәммәдиевнең «Сират күпере», А.Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!») геройларның әхлакый потенциалын авторлар аларның яшәү һәм үлемгә мөнәсәбәтеннән чыгып билгели. Шәхес культы чоры — га-

заплар юлы, тормыш хакыйкатенә төшенү, революция елларында туган өметләрнең чәлпәрәмә килүе буларак тасвирлана.

20-21нче гасырлар чиге атмосферасы Р. жанрының юнәлешен кабат алмаштырды: ул социаль гаделсезлеккә каршы тору формасына әйләнде, тормышка фәлсәфи һәм әхлакый карашны тамырдан үзгәртергә мәҗбүр итте. Ф.Садриевның «Таң җиле», Ф.Латыйфиның «Ишелеп төшкән бәхет» Р.рында ялганга нигезләнгән совет чынбарлыгының ирекне бууы тасвирлана, әхлакый традицияләрне, милли үзенчәлекне югалту, милли үзбилгеләнү зарурлыгы ачыклана. Җәмгыятьнең генә түгел, бәлки яшәеш кануннарының камил түгеллеге язучы борчылуына сәбәп була. Ф.Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» Р.-трилогиясендә совет идеология системасы шәхесне — массага әйләндерүче буларак карала, автор үзгәртеп кору чорын элекке режимның дәвамы итеп күзаллый. Т.Галиуллинның «Сәет Сакманов» Р.-трилогиясендә үзгәртеп корулар чоры соң чиккә җиткән кансызлык, җинаятьчеләр һәм җинаятьләр дәвере буларак тасвирлана. Унай геройларның булмавы рухи торгынлык чорында гомумкешелек кыйммәтләренең югала бару күрсәткеченә әверелә. Ф.Бәйрәмованың тоталитар режим шартларында татар милләте язмышы темасын дәвам иткән «Караболак» Р.да (Чиләбе өлкәсендәге шул исемдәге татар авылының радиацион катастрофа кичерү вакыйгалары сурәтләнә) үз халкына каршы юнәлтелгән идеологияне явызлык дип бәяләүче тәнкыйди башлангыч б-н документаль башлангыч берләштерелә. З.Хәкимнең «Гөнаһ» Р.да «гөнаһ» — «җәза» — «чистарыну» төшенчәләренең үзара бәйләнеше ачыклана. Җәмгыять, аерым алган һәр кеше сыман, тәүбәгә килергә тиеш дигән фикер әсәрнең идеясен тәшкил итә. З.Хәкимнең «Агымсуда ни булмас» социаль антиутопиясендә сатирик төстә бүгенге авыл, анда яшәүчеләр тасвирлана. Мондый әсәрләрдә совет чорын һәм үзгәртеп корулар вакытын сатирик бәяләү алга чыга. Мажаралы әсәр итеп уйланылган Т.Миннуллинның «Минһаҗ мажаралары» Р.ны 19 йөзнең ахырыннан башлап Николай II хакимлек иткән чорга кадәр милли тарихны киң масштаблы пародия рәвешендә тергезә. Төп геройның 20 гасырның танылган сәясәтчеләре б-н егерме бер тапкыр очрашуы — авторның ил тарихын идеологик мифлардан арындыру омтылышы турында сөйли.

Татар әдәбиятында Р.ны сюжетка корылган дискуссияләр, карашлар төрлелеге кисешкән модель, төрле дәверләр идеологияләре пәрәвезе, кеше психикасындагы аң һәм аң төпкеленә мөрәҗәгать итү кебек файдалану бу жанрда интеллектуаль башлангычның көчәюенә китерә. Разил Вәлиевнең «Мирас» Р.да 20 йөзнең төрле чорларына хас көнкүреш һәм сәяси билгеләрнең бер текст эчендә очрашуы күпкатламлы шәрехләүгә мөмкинлек бирә. Г.Гыйльмановның «Албастылар» Р.да мифка йөз тоту кешене яшәү мәгънәсен эзләүче зат буларак тәкъдим итә. Автор күптөрле параллель дөньяларны тасвирлый һәм бу фонда яшәү мәгънәсе үз «мин»ен, асылын танып белү аша раслана. Р.Сибатның «Ялгызак» Р.да әхлак мәсьәләләре хакыйкатьне фәлсәфи эзләү б-н тоташа; кеше концепциясе «йомык» дөнья кебек күзаллана. Милли характер мәсьәләсен хәл итүне ул шәхсилекне раслауда күрә.

20-21 гасырлар киселешендә, яңа иҗтимагый-идеологик шартларда, татар әдәбиятында ислам кануннары һәм гореф-гадәтләре б-н таныштыручы, диннең мөһимлеген исбатлаучы, эчтәлеге б-н дидактик-мәгърифәтчел, шулай ук иҗтимагый фикернең әхлакый-фәлсәфи эзләнүләрен бер төенгә укмаштырган Р.нар языла. Үзенең «Соңгы дога» Р.да Ф.Бәйрәмова иманга китергән юлны тасвирлый, аны бердәнбер яшәеш хакыйкате дип билгели.

Әдәб.: Рымарь Н.Т. Поэтика романа. Куйбышев, 1990; Эсалнек А.Я. Типология романа (Теоретические и историко-литературные аспекты). М., 1991; Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика. К., 1993; Эпик жанрлар. К., 1973; Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы. К., 2002; Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында. К., 2006.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# 2014 елда дини бәйрәмнәр<br>һәм истәлекле көннәр

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1435-1436 ҺИҖРИ ЕЛЛАР

**13 гыйнвар** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе — Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

**30 апрель** — мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаж, гомрә хажы кылына.

**2 май** — Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич — Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**21 май** — Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**26 май** — Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә — Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраж уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**13 июнь** — Бәраәт кичәсе, ягъни "ләйләтул-Бәраәт". Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**28 июнь** — чират изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә — Кадер кичәсе. (23 июль)

**28 июль** — Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**3 октябрь** — Гарәфә көне. Хаж кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**4 октябрь** — Гайдел-Әдхә, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**5, 6, 7 октябрь** — Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

**25 октябрь** — 1436 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**3 ноябрь** — Гашура бәйрәме. Сөнниләр Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнне мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**19 декабрь** – Сәфәр ае башланган көн.

*Тәзүче-мөхәррир*
**Хаҗи АБДУЛЛА ДУБИН**



*Язучылар берлеге бүлмәсендә. Сулдан уңга – Нәби Дәүли, Равил Фәйзуллин, Марс Шабаев, Рөстәм Мингалим, Ренат Харис. 1971 ел. Бауман урамындагы Матбугат йорты.*



*Галим әдип Фатих Урманче.*



*Язучы Фаил Шәфигуллин (алгы рәттә, сулдан беренче) якташлары белән. 1959 ел. Яшел Үзән, Карашәм авылы.*



*Шәүкәт Галиев (сулдан икенче), Фатих Хөсни (уртада) Зөя буенда. Апас районы. 1974 ел.*



*Язучы Вакыйф Нуруллин. Туган якка кайтып барыш. 2000 ел.*



*Язучылар Кукмара районының Чарлы авылы мәктәбендә. Рашат Низамиев, Рәфыйк Рәуфов (колхоз рәисе), Шаһинур Мостафин, Илдар Юзеев. 1998 ел.*

Рәсим
Хәбибулла

# СЫНАУ...

Талия Талибны армиягә озатып калганда әле тугызынчы сыйныфта гына укый иде. Авылда житкән кызлар күп булса да, егет шушы кызга гашыйк булды да куйды. Кызның сөйкемле сөяге булгандырмы, башка төрле сәбәбе булдымы, үзенең сабакташлары арасыннан да, өлкән сыйныф кызлары арасыннан да Талибны үзләренә каратырга теләп карадылар, әмма Талиб аларга борылып та карамады. Ул унбердә, Талия сигездә укый, алар әйтерсең лә абыйлы-сеңелле, мәктәпкә дә бергә баралар, бергә кайталар. Кичләрен авыл клубына киногa да, биергә дә бергә йөрделәр. Әйтерсең лә бөтен дөньяда алар үзләре генә! Юк, алар онытылып исәрләнеп йөрмәделәр, кешелек кысаларыннан чыкмадылар, икесе дә мәктәптә яхшы укыйлар, җәмгыяви эшләрдә дә актив катнашалар. Авылда кайберәүләр аларны мактап туя алмасалар, икенче берәүләр чүбек урынына чәйнәделәр. Ә яшьләрнең халык теленә колак саласылары килмәде, аларның торган саен бер-берсенә карата булган ихтирамнары, мәрхәмәтлелекләре артканнан-арта барып, ихлас мәхәббәткә әверелде.

Әти-әниләре дә кеше сүзенә карап яшьләрне бер-берсеннән биздерергә уйламадылар, чөнки егет белән кызның азып-тузып йөргәннәре булмады. Аларга күрше-күләннәре төрле «киңәш» белән әйткән сүзләренә җаваплары:

— Вакыт күрсәтер әле, яшьлек юләрлеге белән йөрсәләр, үз вакыты житкәч узып китәр, мәхәббәтләре чын булса, бергә булырлар, — дип кенә җавап бирә тордылар.

Көн арты көн уза торды, Талиб мәктәпне тәмамлап, көз көне армия сафларына китәргә чакыру кәгазе алды. Саубуллашу кичәсеннән соң егет кызны өенә озатып куйгач, болай диде:

— Талия, мәхәббәтем, берданберем, мине көтеп алачаксыңмы, башкаларга алмаштырмассыңмы?

— Талибым, алтын таулары вәгъдә итсәләр дә, сине беркемгә дә алмаштырмаячакмын. Хәтта клубка да чыкмаячакмын, өй — мәктәп булачак йөргән юлларым.

Талибның хатлары авылга көн саен булмаса да, атнасына ике хат килеп торды.

Чыннан да Талия сүзендә торды. Талиб хезмәтен тутырып кайтканчы кичләрен танца-манцаларга йөрмәде, егетләргә күз салмады. Өйдә әнисенә булышты, мәктәптә дә яхшы укыды.

Талиб авылга житлеккән ир-егет булып, кырып ясаган кебек төз сынлы, чибәр ир-егеткә әверелеп кайтып та житте. Аны зарыгып көткән Талиясе каршы алды. Талибның исән-имин хезмәт итеп кайтуына әти-әнисе һәм туганнары гына түгел, Талиянең дә әнисе бик шатланды, чөнки ул кызының егетен ничек зарыгып көткәнен белде, ә әтисе

Талия өченче сыйныфта укыганда ук юл һәлакәтенә очрап һәлак булган иде.

Талиб озын-озак ял итеп, киләп сарып йөрмәде. Талия мәктәпне укып чыккач та өйләнешергә сүз куешып, ул Чаллыга китеп эшкә урнашты.

Вәгъдәләшкән вакыт та озак көттермәде, алар 1991 елның август аенда гөрләтеп туй ясадылар. Ике яшь йөрәкнең бер-берсен яратышып, кызның егеткә биргән вәгъдәсенә тугры калып көтеп алулары авыл халкының кин күңелле кешеләрендә горурлык хисләре уятты, кияү белән кәләшнең бер-берсенә шулчаклы пар килүләренә сокланып туя алмадылар. Көнчел бәндәләр төрле гайбәтләр сөйләп карасалар да, авыл халкы аларның сүзләрен игътибарга алмады. Алар яшьләргә ихлас күңелдән бәхетле һәм шатлыклы озын гомер теләделәр.

Бу елларда Чаллыда эш табуы шактый кыенлашкан булса да, икесе дә КамАЗ заводына эшкә, Чаллы институтына читтән торып укырга да керделәр. Башта кеше фатирында тордылар, аннары Талиб белән Талияне шатландырып дөньяга Алия исемле кызлары тугач, заводтан бер бүлмә бирделәр.

Көн арты көн уза торды, яшьләрнең тормышлары үзләренең тырышлыклары белән һаман да җайлаша, һаман да яхшыга таба алга бара. Инде Алияләре туып ике ел узуга әтисенең ярдәмчесе һәм нәсел дәвамчысы – малайлары да дөньяга аваз салды. Талибның тырышлыгы һәм уңганлыгы, Талиянең ирен эштән тәмле ашлар пешереп көтеп каршы алулары белән тормыш авырлыгы сизелмичә, вакыт һаман алга шуды, инде ике бүлмәле фатирлы да булдылар. Аларның тормышларына сокланмаган кеше калмады. Җае чыккан саен авылларына кайтып ике як әти-әниләренә ярдәм итәргә дә онытмадылар. Талиб бигрәк тә Талиянең әнисе – әбисенә ярдәмне ныграк күрсәтергә тырышты, чөнки ялгыз хатынга тормыш алып баруы кыен икәнен яхшы аңлый иде ул.

Балалары Алия белән Алмаз туп кебек тәгәрәшеп үсәләр. Аларга инде ун һәм сигез яшь тулды. Тормыш түм-түгәрәк иде...

Беркөнне көтмәгәндә аяз көнне яшен суккан кебек, Талия ире Талибка:

— Талиб, әйдә без аерылыйк әле, минем синең белән яшисем килми башлады, — диде.

Әлбәттә Талиб хатынының бу сүзләрен бер шаярту итеп кенә кабул итте:

— Нәрсә, алтыным, әллә миннән яхшыракны таптыңмы, ә?! – дип, килеп бит очыннан үбеп алды.

— Юк, Талиб, мин шаярмыйм... үзем дә аңламыйм, нәрсә булды миңа... синең белән яшисем килми... бер ир белән дә яшисем килми минем... зинһар мине кичер... мин балаларны алып авылга, әни янына кайтып китим. Синең...

— Тукта әле, Талия... матурым... сөеклем... син заводта театр түгәрәгенә язылмагансыңдыр бит? Нинди роль уйнарга бирделәр сиңа? Аңлатып сөйлә әле!

— Юк, Талиб, беркем дә бернинди роль уйнарга бирмәде... мин инде заводтан увольняться итеп кайттым. Мин сиңа берни дә аңлата алмыйм... әллә нәрсә булды миңа.... син минем күземә сөйкемсез кеше булып күренә башладың. Беләм, синең гаебең юк, әни дә... сине үлеп ярата... «киявем», дип кенә тора.

Талиб, чыннан да яшен суккан кебек, катып калды, тамагына төер тыгылды... Үбеп озатып калучы һәм елмаеп каршы алучы Талиясе

сөйлиме соң бу сүзләрне? Аны сигезенче сыйныфта укыганнан алып үлеп яратучы, хезмәтен тәмамлап кайтканын зарыгып көтеп алучы, ниһаять, үзләренең томрап торган кызы белән улларының әнисе сөйлиме бу сүзләрне?

— Талия, жаныем, әйдә врачка барып карыйк әле, бәлки врач бирәр киңәш бирер, ә? − диде ул гажизләнеп.

— Юк, Талиб, минем бер төшем дә авыртмый, врачка бит авырулар гына йөриләр. Минем өчен... син борчылма, Талиб.. гафу итә күр... без балалар белән авылга китик инде... син балалар янына һәрчак кайтып йөрерсең.

Гаиләсенең бер мизгелдә чәлпәрәмә киләсен башына да китереп караганы булмады. Үзе эчеп-исереп йөрми, хатыны беркайчан чит ирләргә күз атмады. Нәрсә булды соң Талиягә? Сәбәбе нәрсәдә? Бу сорауларга Талиб түгел, Талия үзе дә жавап бирә алмый. Бәлкем Талибның фикере дөрестер, кем дә булса бозым ясаган булса кирәк.

Чынлыкта исә соңгы арада Талиб үзе дә Талияне элеккеге кебек ярата алмый иде. Ул үзенең Талиягә суынуын тормыш мәшәкате басудан күрә иде.

Алар ике көн хәтта аерым, ачуланышмыйча гына, оршышмыйча гына икесе ике бүлмәдә йоклдылар. Талиб каяндыр өшкерүче белешеп, адресын табып, әби белән дә сөйләшеп кайтты. Ул бергә килергә кушып жибәрде:

— Ярар, улым, иртәгә хатының белән икәү килегез, өшкереп карарбыз, Аллаһы насыйп итсә.

— Ярар, әби, иртәгә без хатын белән килербез, ярдәм ит инде, тормышыбыз жимерелә бит, — дип, ялвара-ялвара әллә әбигә әйтте, әллә үз-үзе белән сөйләште.

Өйгә кайткач, балалар ишетмәсен өчен, хәләлен йокы бүлмәсенә чакырып алды да:

— Талия, мин бер өшкерүче әбине таптым, иртәгә килергә кушты, иртән шунда барырбыз, ярыймы?

— Талиб, мин врачлар янына да, өшкерүче әбиләр янына да барып йөрмим. Мине балалар белән авылга кайтарып куй... Әнигә аерылу турында әйтми торырбыз... Сиңа «развод» кәгазе кирәксә, үзең судка гариза бирерсең, мин кул куярмын... Минем авылда... яшисем...килә...синең белән яшисем килми, нигә икәнен үзем дә белмим.

— Акыллым... Талиям... син бит мине үтмәс пычак белән суясың... балалар турында уйла... аларны тере әтиләре була торып та ятим, бәхетсез итикме? Әйдә инде өшкерүче әби янына барып карыйк... тормышыбызны, гөрләп торган гаиләбезне саклап калыйк инде... минем бит... Талиям...сине югалтасым килмии..и..и..., — дип, көч-хәл белән сүзләрен әйтеп бетерде дә, ир булганнан алып беренче тапкыр күзләреннән яшь тамчылары тәгәрәп төштеләр.

— Талиб, син мине шушында бәреп үтерсәң дә, беркая да барып йөрисем килми. Кайтар... зинһар, безне...авылга. Балаларның жәйге каникуллары... балалар белән авылга ял итәргә кайткан шикелле генә итеп кайтар инде... зинһар...

Талиб аларны авылга, әбиләренә кайтарды.

***

Аерылуларына ике ел үтте. Ул балаларын күрергә, әти-әнисенә ярдәм итәргә кайтып йөрде. Көннәрдән бер көнне аның юлында бер кыз кул күтәреп тора иде. Монарчы юлда очраучыларны утыртканы булмаса да, «бераз уйлар таралыр» дип, туктап кызны утыртты.

— Красавица, вам куда? Айда, садись, довезу.

— Абый, мин Чаллыга бара идем, аласызмы? — дип татарча эндәште сылукай.

— Үзебезнең татар кызы икән әле, әйдә утыр, сенелем.

Кызый, Чаллы институтын тәмамлаган егерме биш яшьлек Эльвира, бик ачык йөзле, матур итеп татарча сөйләшә, Талибларның күрше авылында туып-үскән булып чыкты. Сүз арты сүз китеп, шактый якыннан таныштылар. Талиб Эльвираны өенә чаклы илтеп куйды.

— Талиб абый, сезгә бик зур рәхмәт яусын, мин монда фатир снимать итеп торам, әгәр дә ашыкмасагыз, чәй эчереп җибәрәм, ашыксагыз, менә телефон номерым... — дип, Талибка визиткасын сузды. Ул карап тормыйча гына, визитканы түш кесәсенә шудырды.

— Сенелем, мин, чәй эчәсе килгәч, сина шылтыратырмын әле, ярыймы? Хәзергә сау булып тор.

— Пока-пока, Талиб абый, исән-имин йөрегез! — дип, сәер генә елмаеп кул болгап калды.

Талиб ике көн буе уйланып йөрде. Талия белән балалары хакында да, Эльвира хакында да. Каян килеп чыкты бу кызый. Ни өчендер аны күрәсе килеп күнел ашкына. Мин бит инде ике бала атасы. Бу — кыз кеше, аралар да тугыз яшь.

— Туктале, нәрсә хыялланып утырам соң?! — дип уйларыннан арынырга уйлады ул.

Икенче көнне тагын шул Эльвира исенә килеп төште. Костюм кесәсеннән алып, визиткасын карады: «Валиуллина Эльвира Карамовна, менеджер по маркетингу, магазин «Эдельвейс». Тел. 8-917-... ...».

Талиб хәтер йомгагын сүтә башлады: «Тукта әле, күрше авылның Вәлиуллин Фәтих исемле кешесе элек районда райпо мөдире булып эшли иде. Анын бер малае Кәрам исемле иде түгелме? Шулай бугай. Димәк Эльвира Фәтих абзыйның малае — Кәрамның кызы булып чыга...» — дип, бик озак уйланып торды. Ул сәгатенә карады, эш сәгате тәмамланмаган, бигрәк тә кибет сонга чаклы эшли, шалтыратып тормыйча гына кызны кибеттә очратырга уйлады.

Ни хикмәт, Талиб кибеткә килеп керүгә, Эльвираны очратып катып калды. Ә тегесе авызын ерып:

— Нихәл, Талиб абый, әллә мине эштән каршы алырга килденме? — диде.

— Нихәл, Эльвира сенелем, әллә син монда эшлисен?

— Шаяртма инде, Талиб абый, мин сина визиткамны биреп калдырдым бит.

— Шулай иде шул, кая тыктым икән мин аны? Әле бит визитка карарга вакыт та булмады.

— Костюмынның тышкы түш кесәсенә тыккан иден...

— Кара. Чыннан да монда икән, менә хәтер диген инде, — дип, Талиб визитканы беренче караган кебек кыланып алды. — Тәк, Валиуллина Эльвира Карамовна, менедж... Кара әле, Эльвира, синен бабан...

— Әйе, минем бабай Фәтих, элеккеге райпо мөдире.

— Син, сылукай, минем нәрсә сорыйсымны да белеп торасын икән...

— Әйе... мин әле синен бүген киләсенне төшемдә дә күрдем.

— Кызык, ә нәрсә алырга килгәнне дә әйтеп бирмәссенме?

— Бер әйбер дә алырга килмәден, мине күрергә дип килден.

— Мин шалтыратмыйча гына килмәс идем инде, сенелем, — нәрсә дә булса алырга кирәклеген уйлап торды да, болай дип өстәде: — Мин менә бер дустымның туган көненә фотоаппарат бүләк итәргә исәпләгән идем, шуны карарга килдем, ошаганы булса — алырга исәп.

— Әйдә, фотоаппаратлар сата торган бүлеккә алып барам үзеңне, алайса...

Аннары алар кафега керделәр.

— Кияүгә чыгарга жыенмыйсыңмы соң әле, сеңелем? — дип сорап куйды Талиб, үзе дә ни өчен сораганын аңламыйча.

— Мин жыену беләнмени, Талиб абый, син бит миңа «предложение» ясамадың әле...

— Мин бит ике бала атасы, хатын аерган кеше, сеңелем. Сиңа «предложение» ясасам, кимсетү булыр иде. Аннары синнән күпкә олы да... Мин синең йөргән, вәгъдәләшкән егетең бармы соң дип кенә сорамакчы идем...

— Тугыз яшь аерма зур түгел инде, әнә, минем белән бергә институтта укыган иптәш кызым үзеннән ун яшькә олы иргә чыкты әле, әйбәт кенә яшәп яталар. Хәзер егетләрнең күбесе дегет кебек инде, кайсысы борынын югары чөйгән була, кайсысы — айныр-айнымас.

— Эльвира сеңелем, миңа синең тәкъдим ясавың түгелме бу?

— Юк, Талиб абы-ы-ый, үзеңне иртә картайтып куйма, дип әйтүем генә.

— Мина кияүгә чык әле, дисәм, чыгарсыңмы?

— «Дисәм»е булмаса... чыгар идем.

— Син бит мине бөтенләй белмисен дә...

— Бөтенләй белмим дип әйтмәс идем, синең турыда күп ишеткәнем, сезнең туй фотогызны да күргәнем бар хәтта...

— Туктале, сеңелем, безнең туй фотосы күзеңә ничек чалынды?

— Сабакташын Әлфира апа безгә туган тиешле кеше, ул күрсәткән иде, әле ул сине үзенә каратырга да уйлаган булган... шулаймы?

— Әлфира исемле сабакташым бар иде шул. Мине кемнәр үзләренә каратырга тырышканнарын барысын да хәтерләмим инде. Мин бит Талияне нык яраттым, беркемгә дә күз салганым булмады.

— Талия үзе синнән киткән бит. Ә мин синнән үзем китмәячәкмен!

Авылда бермәл гел сезнең турыда сөйләделәр: «Таһир белән Зөһрә кебек яратышып өйләнешкән иделәр, тоттылар да аерылыштылар»... — диләр.

— Кызык... бик кызык...

— Нәрсәсе кызык инде, кешеләр теленә бер эләксәң, чәйнәп аталар инде.

— Ә син үзең дә кешеләр теленә эләгүдән курыкмыйсыңмы?

— «Эт өрә тора, бүре йөри тора», диме әле халык мәкале, кеше сүзеннән курыксан, туасы да, яшисе дә түгел инде.

— Яшьләрнең халык мәкале белән сөйләшкәннәрен ишеткәнем юк иде әле..

— Талиб абый, мин бит авылда үскән бала!

— Эльвира сеңелем, син миңа чыннан да ошыйсың, әмма өйләнәм икән, колагына киртләп куй, балаларымны ташламаячакмын, аларга алиментны түләп, кайтып хәлләрен белеп, туган көннәренә бүләкләр алып торачакмын, шулай булгач мин синең өчен «койрыклы» ир булачакмын, уйлап бетер.

— Чын ата шундый булырга тиеш тә инде... Та-лии-бб аб-бый. Балалар бит гаепле түгелләр.

Алар шушы чәй эчүдән соң ике ай гына очрашкалап алдылар да, өйләнешеп тә куйдылар. Никахны да авылга кайтып тормыйча, Чаллының бер мәчетендә укыттылар. Авылга кайтып гайбәткә «азык» әзерләп йөрмәскә булдылар.Никахтан соң Эльвира инде Талибның фатирына тулы хокуклы хуҗабикә булып кайтты. Зөфаф кичендә Эльвираның сафлыгын җуймаган булуы Талибны тагы гаҗәпкә калдырды. Ул инде «Эльвира бик кыю һәм чая,

ирләрне күп күргәндер, менә хәзер кияүгә чыгарга да вакыт житкәнлектән хатын аерган иргә чыгарга да атлыгып торгандыр», дип уйлаган иде. Туйны зурдан кубып ясамадылар, кыз да иптәшләрен генә чакырып ресторанда утыруны хуп күрде.

Никахтан соң тугыз ай узуга дөньяга тагын бер малай аваз салды. Аны мәчеткә алып барып Таһир дип исем куштырдылар.

Талиб, яңа гаилә корып жибәргәч, Талияне сирәк исенә төшерергә тырышты, шулай да балалары янына еш кайтып йөрде. Ул балалары өчен җаваплылыкны ныгытып үзенә бурыч итеп йөкләп куйды. Алия белән Алмаз да һәрвакыт әтиләрен көтеп алып кочаклап каршы алдылар. Талия Талибны күргән вакытта да: «Нихәл, Талиб?» —дип әйтүдән ары узмый иде. Талиянең әнисе генә Талибны күргәч:

— Әй, балалар, нәрсә генә булды сезгә? Гөрләп торган тормышыгызны җимердегез бит... — дия иде.

— Әй әби, үзем дә аңламыйм, ничек болай килеп чыкканын, без Талия белән бер-беребезне нык яратышып өйләнешкән идек, мин бит ничә тапкырлар кайтып Талия белән сөйләшеп карадым, үзең күреп тордың бит, әби... Өшкертеп карарга да теләдем, һәрвакыт катгый каршы килде, беркая барырга да ризалык бирмәде.

— Шулай, Талиб балам, шулай... Сине ачуланмыйм, әле хәзер дә ярдәмеңнән ташламыйсың, Аллаһының рәхмәте булсын. Әнә күр, бакчи, Талия балакай суырылып төште, әз сөйләшә, үзе: «бер төшем дә авыртмый», ди балакай, — дип, елап та җибәргәли Гөлҗинан апа.

Яшь хатын Таһирны тапкач, Талибның балалары янына кайтуы сирәгәйде, юк, ул бер генә минутка да аларны исеннән чыгармады. Ул балаларына компьютер да алып бирде, икесенә дә кесә телефоны бүләк итте. Хәзер алар телефон аша да сөйләшкәләп торалар. Әтиләре озаграк кайтмый торса, исенә төшереп торалар, әмма артыгын борчымыйлар, әбиләре һәм әниләре янында инсафлы, олыларга мәрхәмәтле булып, тәрбияле үсәләр.

Талиб, эштән кайтып керүгә үк башта улы Таһирны кулына алып сөяргә, аннары гына ашарга утырырга гадәтләнеп китте. Инде сабый тәпи йөри башлагач бигрәк тә, ишектә ачкыч тавышы чыгуга, малай әтисен каршы алырга ишек каршына килеп басарга өйрәнде. Шулай әтисенең тезенә иркәләнеп ике яшен тутыргач, Таһирны балалар бакчасына бирделәр. Ул анда төрле һөнәрләргә өйрәнеп кайтып әти-әнисен көлдерә вә сөендерә башлады.

Беркөнне Талиб эштә чакта аңа кызы Алия елый-елый кайгылы хәбәр әйтте — әниләре Талия үлгән.

Ирнең күкрәгеннән нәрсәдер өзелеп төшкән кебек булды, тын алуы авырлашты, һава җитми башлады. Ул галстугын салып ташлады, кесәсендәге машина ачкычларын барлады. Телефоннан Эльвирага шалтыратып, Талиянең үлгәнен, авылга китәчәген хәбәр итте дә, хатынының җавабын да көтеп тормыйча, телефонын кесәсенә салып, машинасына йөгерде...

Талияне үзе ләхеткә төшерешге. Аны җирләгәч балалары Алия һәм Алмаз белән Гөлҗинан апа янына кайттылар. Бүлмәдә тынлык. Тынлыкны бозып, карчык мышкылдап елап җибәрде:

— Бу... бу балаларны... хәзер кем карый... кем кеше итәр... Талиб, улым... минем дә исәнлегем юк... синең хәзер яңа гаиләң бар...

— Әби, бер дә борчылма, мин балаларны үзем карап, үзем аларны укытып кеше итәрмен.

— Әй улым,.. шулай дисең дә бит... синең бит әле хатының бар, ул синең

бу балаларыңны кабул итәрме икән? Хәзерге яшьләр бит ирнең балаларын кабул итәргә ашкынып тормыйлар.

— Әби, Эльвира кабул итәчәк, ул яхшы хатын. Мин Алия белән Алмазны сентябрьдә укырга Чаллыга алып китәрмен. Башта Чаллыдагы кайсы мәктәп яхшырак буласын белешеп, сөйләшермен дә, киләсе атнада тагы кайтып китәрмен.

Талиб Эльвираны Гөлҗинан апага ашыгыбрак мактаган булып чыкты. Кайткач та хатынына балаларын үзләренә алып кайтачагы хакында әйткән иде, әйтерсен лә Эльвираны җен алыштырды:

— Нәрсә??? Нәрсә дисең... Талиб? Син үз акылыңдамы? Син башта минем белән сөйләштеңме? Мин... мин...Талиянең балаларын карарга тиешме? Ә?

Талиб һич кенә дә хатыныннан мондый сүзләр ишетермен дип уйламаган иде. Бервакытта да каршы сүз дәшкәне юк иде аңа Эльвирасы. Ул үзен кулга алып, мөмкин кадәр тыныч, сабыр тавыш белән болай диде:

— Эльвира, беренчедән, балалар минекеләр, ә Талия инде вафат, аның турында начар сүз әйтергә хакыбыз юк. Икенчедән, хәтерләсәң, сиңа чәй эчәргә кергәч, мин үземнең ике бала атасы, балаларны ташламаячагымны әйткән идем. Син оныттыңмы ничек җавап биргәнеңне? Ә син: «Миннән сорадыңмы?» — дисең. Исән әтиләре була торып, аларны хәзер балалар йортына бирер дип уйлыйсыңмы?

— Аларның әбисе бар... карасын!

— Гөлҗинан апа үзе дә чирле, без, матурым, әйдә бозылышмыйк, балалар минем өстә, мин алар өчен җаваплы. Һәм без синең белән аларны карап кеше итәргә бурычлыбыз...

— Җитте! Башка балаларың турында ишетәсем дә килми. Талия балаларын күземә күрсәтмә! Әллә Таһир синеке түгелме?! Үзем исән чакта бусагадан да атлатмыйм мин аларны! Ишетәсеңме?! Моннан ары балаларыңны күзем дә күрмәсен, колагым да ишетмәсен...

Талиб, мондый ук сүзләр ишеткәч, катып калды. Юк, ул балаларын ташламаячак! Ләкин ничек итеп килеп туган четерекле мәсьәләне хәл итәргә? Менә сиңа яхшы хатын, әби, сизенеп, чамалап дөрес әйткән булып чыга. Аерылсаң, тагы кемгә өйләнәсең дә, нинди хатын туры килә? Балаларны балигъ иткәнче барыбер үзем карарга тиешмен. Аларга аерым фатир сатып алыргамы?!

— Эльвира, бу сүзләрне мин ишетмәдем, син әйтмәдең, әгәр риза булмасаң, безгә аерылырга туры киләчәк.

— Юк, мин әйттем! Син дә бик яхшы ишеттең! Кабатлап әйтәм, балаларыңны күрәсем дә, ишетәсем дә килми. Син минем белән аерыла алмыйсың. Мин сиңа Талия балалары карар өчен кияүгә чыкмадым. Яптык бу теманы, ишетәсеңме, үзем исән чакта шушы бусагадан да атлап кермәячәкләр.

— Ярый, дөнья үзе күрсәтер, Эльвира, мин сине аңладым. Башка сүзем юк, мин эшкә киттем, — дип киенеп чыгып китте ир.

Талиб эшкә бармады, ул татар телле мәктәпләр һәм фатир бәяләре белешеп йөрде. Фатир бәяләрен белешкәч: «Әгәр дә эштән бер биш йөз мең сум белән ярдәм итсәләр, ике бүлмәле фатир алырга була икән», — дигән нәтиҗә ясады. Ул бер атна буе эштән соң өенә кайтканчы белдерүләр буенча фатирлар карап йөрде. Бер фатир аңа бик ошады, ул сайлаган мәктәп тә ерак түгел, балаларга җәяү дә йөрешле. Уйларын Эльвирага сөйләп тормады. Шулай янә бер-ике көн үтте, балаларына шалтыратып бу атнада кайтып булмасын әйтте.

Бер көнне эшендә акча белән ярдәм итәчәкләрен ишеткәч, шатланып

өенә кайткан иде, ишек аша улы Таһирнын кычкырып елаганын ишетте. Ул тиз генә ишекне ачып керсә, хатыны идәндә хәрәкәтсез ята иде. Иелеп жилкәсеннән селеккәч, хатын ынгырашып куйды. Талиб тиз генә ашыгыч ярдәм машинасы чакыртты...

Врачлар Эльвираны жентекләп тикшерделәр. Аны көчле инсульт бәргән. Талибка әйттеләр:

— Хатынын әле өч-дүрт ел яшәячәк, әмма күзләре күрмәячәк, колагы начар ишетәчәк. Без башка төрле ярдәм күрсәтә алмыйбыз, ана тынычлык, яхшы тәрбия кирәк, без хәлебездән килгәнне эшләдек.

— Карагыз әле, анын күзенә операция ясап та булмыймы?

— Гаеп күздә түгел, баш миендәге күрү өчен жаваплы күзәнәкләр үлгән, бүгенге медицинанын көче житми, анлагыз, Талиб Хабибрахманович, без кулыбыздан килгәннен барысын да эшләдек. Гафу итегез, ана өйдә яхшы тәрбия кирәк, үз хажәтен стенага тотынып барып үти алачак, башта ярдәм кирәгер, тора-бара үзе дә өйрәнер.

«Менә тагын бер мәсьәлә килеп туды, Талиб, түз генә», — дип уйлап куйды. Ул аны хастаханәдән житәкләп алып чыгып машинасына утыртты да кайтып китте. Хатынын урын жәеп яткыргач, телефоннан кызы Алиягә шалтыратып хәлне анлатты. Кыз әтисенә:

— Әти, борчылма, без сина ярдәм итәчәкбез, безне алырга кайт, без жыена торабыз, — диде.

— Ярар, кызым, бер сәгатьтән кайтып житәрмен.

— Әти, ашыгып йөрмә, юлларны карап йөри күр, без сине яратабыз.

***

Талибнын балаларын авылдан алып килеп яши башладылар. Хәзер алар биш кеше булдылар. Эшеннән ярдәм иткән акчаны да, үзенен жыйганын һәм ике бүлмәле фатирын да сатып, яхшы, зур, дүрт бүлмәле заманча фатирга күчтеләр. Бер бүлмәдә сукыр һәм ярым чукрак Эльвира ята, берсендә житкән кыз — унбиш яшьлек Алия, берсендә ике яшьлек Таһир белән унөч яшьлек Алмаз урнаштылар. Талиб үзенә урынны залда жайлады. Таһир баштарак әнисенен бүлмәдә берүзе торганына аптырап, «әни, әйдә бу бүлмәдән чыгабыз», — дип кулыннан тарткалап карады, тик әнисенен каядыр төбәлгән күзләреннән яшь акканын гына күрде. Әнисе аны кочаклап нәрсәдер әйтергә тели, тик әйткән сүзләре анлашылмый.

Эльвира апаларын Алия белән Алмаз яхшы карыйлар, тик Эльвира апалары аларны күрүдән дә, ныгытып ишетүдән дә, сөйләшүдән дә мәхрүм. Ул кайбер гозерләрен, сукыр булса да, кәгазьгә язып анлата. Талия балалары бусаганы атлап керәләр, атлап чыгып китеп укырга баралар. «Бусагадан да кертмим» — дигән хатынны Талия балалары ашаталар, туалетка йөртәләр, ваннада юындыралар. Нәкъ Эльвира үзе теләгәнчә,күзләре аларны күрә алмый, колагы бик начар ишетә. Әйе, бу чирне ул үзе сорап алды. Хәзер урын өстендә яткан хатын шулай икәнен анлады, әмма берсен дә кире кайтарып булмый иде инде.

Дүрт бүлмәле өйнен өчесендә тормыш кайный. Алмаз Таһирны балалар бакчасына йөртә — укырга барганда алып бара, кайту унаена алып кайта. Алия ашарга пешерә, өйне жыештыра, әтисенен урын өстендә яткан хатынын карый, укырга да өлгерә. Ә әтиләре тормыш алып барыр өчен мал таба, акча эшли.

Талибка кызы Талиянен мәктәп елларын хәтерләтә, көлүләре дә, шуклыгы да, кыюлыгы да, йөзе белән дә әнисенә охшаган. Ул Талия белән йөри башлаганда нәкъ Алия кебек иде. Вакыт дигәнен сизелми дә бер жайга

ага да ага. «Инде Раббым, кызым Алиянең язмышын әнисенеке кебек бәхетсез итә күрмә! — дип, эченнән уйлады ул. — Тукта, мин Раббымны искә алдым түгелме? Ә Раббым риза булырдай нәрсәләр эшләдем соң әле?» — дип, Талиб үз-үзен сүзендә тотты да,үзен ачуланып алды. Инде малаена исем куштырганнан бирле мәчет ишеген дә ачып кергәне юк икәнен исенә төшерде...

— Хәзрәт, минем сезнең белән утырып сөйләшәсе дә бар, мәчеткә дип хәер дә китергән идем, вафат булган хатыным рухына дога кылдырырга дип тә килгән идем, вакытыгыз булмасмы? — дип, үзе яшьләрендәге имамга мөрәҗәгать итте ир, малаена исем куштырган мәчеткә килгәч.

— Хатыныгыз вафат булдымы? Әле ике еллар чамасы гына малаегызга исем кушкан идек түгелме? Хатыныгыз бик яшь иде, дип истә калган.

— Малайга исем куштырырга бергә килгән хатын, ул минем икенчесе инде. Беренче хатын вафат булды, без аның белән аерылган идек инде, шулай да мин аны ташламадым, ярдәм итеп тордым.

— Бик күркәм сыйфат, кем, Талиб туган. Күркәм, мөселманнарга хас сыйфат...

— Менә, хәзрәт, кайгы өстенә кайгы, дигәндәй, шул яшь хатынны да инсульт сукты бит әле.

— Аллаһы Тәгаләнең сынавы инде бу, Талиб туган, сынавы. Төрле кешене төрлечә сыный инде...

Талиб туган, менә минем сина киңәшем шушындый: үз күз алдында Аллаһы Тәгалә хатынына җәза биргән. Инде киләчәктә тормышың яхшы, балаларың бәхетле булсыннар дисәң, мәчеткә ешрак йөрергә тырыш, хәер бирергә димим, намазга басып, җомга намазларына йөрергә кирәк сиңа. Бүгенге гамәлне иртәгә калдырганны яратмый Хак Тәгалә. Син әкертенләп өйрән намазны. Башта эшкә киткәнче иртәнге намаз укып китәргә тырыш, аннары Раббыбыз Үзе ярдәмен бирәчәк. Менә сиңа шушы кечкенә генә китапларны бүләк итеп бирәм, намазга бассаң, күңелеңә тынычлык табарсың, иншаллаһ!

Талиб мәчеттән чыккач үзен җилкәсеннән тау төшкән кебек хис итте. «Әйе, хәзрәт хаклы, дөнья куабыз дип, Аллаһыны онытабыз, намазга басарга кирәк, һичшиксез басарга, әнә бит хәзрәт минем яшьләр чамасында гына булса да, нинди дөрес киңәш бирде», — дип юл буе уйланып кайтты.

***

Эльвираның урын өстенә ятканына өч ел булды, Алия инде унберенче сыйныфта укый, тиздән унсигез яшь тулачак, Алмазга уналты яшь, ә Таһирга биш, өч бала атасы Талибка — кырык яшь. Бу яшь ир-атның көч һәм акыл туплап тормыш итәр өчен иң куәтле һәм дәртле чагы. Әмма Талибның намазга баскач күңеленә күпмедер тынычлык инсә дә, яшь хатынның урын өстендә ятуы, үзенең ни өйләнә алмавы, ни тулы гаилә булып яшәр өчен утырып сөйләшергә хатыны булмавы эчтән тырнап, эчтән сызып, өч бала хакына дип кенә эшкә йөрүе аны алҗыта иде. Күпме генә уйланса да, ни өчен Талиянең кинәт кенә анардан читләшүенә җавап таба алмады. Эльвираның да кинәт кенә юлда очрап, үзе теләп хатыны булырга ризалык бирүендә дә нindидер анлашылмаган сорау ятканын тоемлый ул.

— Әти, бүген Эльвира апаның хәле начарланды, ашыгыч ярдәм чакырган идек, ярдәм итә алмыйбыз, гомере озак калмаган диделәр, — дип, Алия әтисен эштән каршы алды. — Бүген ризык та капмады, чәйне дә ярты йомры гына эчте.

— Кызым, ни язган булса шул инде, сезгә рәхмәт, яхшы карадыгыз, тәрбия кылдыгыз, мине дә аңладыгыз, сез булмасагыз мин нәрсә эшләгән булыр идем? — дип, Талибның күзләре яшьләнде.

— Әти, син үзең нык борчылма инде, син бит дөньяда иң-иң яхшы кеше. Әни белән аерылуыгызда синең гаебең юк, Гөлҗинан әби шулай дип үстерде безне. Хәзер дә кайткан саен: «Әтиегезне хөрмәт итегез!» — дип әйтми калмый.

— Әбиегез дә бик яхшы кеше, әниегез дә бик яхшы хатын һәм әни булды, ни өчен кинәт миңа күнеле сүрелгәненә генә җавап таба алмадым, кызым, урыны җәннәттә булса иде.

Беркөнне Алия мәктәптән кайткач Эльвира апасының хәлен белергә керде, башын, аякларын тотып карады, аяклары суык иде. Хатын кырыенда кеше барлыгын аңлап, күрмәгән күзләрен ачты да, кулы белән ишарәләп кәгазь белән ручка сорады. Алия тәрәзә төбендә генә хәзерләп куелган махсус җайланмага кыстырылган кәгазь белән ручканы алып бирде, шулвакыт Алмаз белән Таһир да кайтып керделәр. Алар да чирле хатын бүлмәсенә уздылар. Барысы да тын калып, Эльвираның язганын көттеләр. Калтыраган куллары белән бик озак язды да, ручкасы кулыннан төшеп китте. Алия белән Алмаз кәгазьдәге язуга күз салдылар, анда: «Сезгә рәхмәт, балалар, мине карадыгыз.... Әтиегез белән әниегезне чуаш карчыгыннан бозым ясаттырып аерттырдым. Үзем кияүгә чыктым... сөйдергеч ясаттым... Хушыгыз, кичерә....», — дип язылган иде. Көч-хәл белән аркылы-торкылы булган хәрефләрне кушып укып чыгып хатынга карасалар, аның инде йөзе саргайган, аңа мәет төсе кергән иде...

— Алмаз, бу язуны әти күрергә тиеш түгел, аңладыңмы? — диде Алия, елый-елый.

— Юк, аңламадым... Ни өчен? — Алмазның да күзләре яшькә тыгылган.

— Әгәр бу язуны...әгәр бу язуны әти... әти күрсә, без әтисез дә калабыз, — диде апасы үксүен баса алмыйча. Бераз тынычлана төшкәч:

— Ул болай да әнинең үлгәненә үзен гаепләп йөри. Әгәр бу язуны әти укыса, хатынын үтерүче дошманына өйләнгәнен кичерә алмыйча йөрәге шартлавы бар. Аңладыңмы хәзер?

— Хәзер аңладым, без әтине сакларга тиешбез.

— Димәк язуның эчтәлеген син һәм мин генә беләбез, өченче кеше белергә тиеш түгел, өченче кеше белсә, әтигә дә ишетеләчәк, — дип, язуны ваклап чүп чиләгенә салды да Алия әтисенә шалтыратты:

— Әти... Эльвира апа... үлде...кайт...

# КАЗАН, ИСЕМЕҢ МАТУР...

Казан атамасы турында күп фаразлар бар. Шуларның берсе —«алтын казан» турындагы легенда. Имеш, хан кызы су алганда алтын казанын елгага төшереп җибәргән. Шуна шәһәрне Казан дип атаганнар. Бу легенда күптән түгел сәхнәдә куелган музыкаль әсәрнен үзәгендә тора. Гомумән, Кабан күле төбендәге алтын, Сөембикәнең манарадан ташлануы кебек мифларга корылган әсәрләр белән артык мавыгу сизелә. Асылда алар сәнгатебезгә дә, чын тарихны белүебезгә дә житди яналык өстәми. Күп еллар дәвамында безне юлдан яздырган уйдырмалар, мифлар тегермәненә су коя.

Манараның авышлыгын да туристларга тулы аңлату күптән сорала. 1552 елда Казан Кремленен диварлары ике тапкыр махсус казып шартлатыла. Бу турыда рус елъязмаларында шул заманның шаһитләре «жир селкенеп торды» дип язган. Жир тетрәүгә тин шартлаулар нәтиҗәсендә, әлеге манара-төрбә, нигезе ком һәм акшарлы таш (йомшак таш) катламнарында булу сәбәпле, бер якка авыша, утыра, әмма жимерелми. Геологлар тикшереп, манара нигезенә сыек цемент куылса да, авышу дәвам итә. Чөнки Казан Кремле йомшак таш катламнарында тора. Шартлатуның берсе хәзерге Фәннәр Академиясе каршысындагы кечкенә чиркәү урынында булган. Шартлау урыны, жир селкенү дулкыны һәм манара авышлыгы да әлеге фикерне куәтлиләр. Бу шартлаулар, Казанның Большая һәм Малая Проломная урамнары атамалары булып, тарихка кергән.

Казан атамасын да фәнни нигездә ачу бик кирәк эш. Мәгълүм булганча, авыллар, шәһәрләр сулы, чыганаклы урыннарны сайлап корылган. Суны изгеләштерү дә мөһим урын алып торган. Табигать күренешләрен кешегә охшату (елга култыгы, яр кашы, тау бите, Кама Тамагы) һәм чагыштырулар борынгы заманнарда аеруча тирән көчкә ия булган. Кешеләр табигатькә жанлы нәрсә дип караганнар. Чыганакларны изгеләштерү хәзерге заманда да сизелеп тора.

Казан атамасы да әлеге тарихларга һәм тел закончалыкларына бәйле. Сүзлекләрне ачыйк. АНАК сүзе элекке заманнарда «күз яше» дигән мәгънәне аңлаткан. ЧЫГАНАК сүзен ЧЫГА/АНАК (ЧЫГА ЯШЬ) дип әйтеп һәм укып була. Бу инде борынгы бабаларыбызның жир өстенә бәреп чыккан кадерле, саф, изге суны кеше күзеннән бәреп чыккан яшькә тинләве, охшатуы, изгеләштерүе.

Күп тарихларны хәтерләүчән (шуна туган тел кадерле һәм тирән белүгә лаек) ана телебездә КҮЗ дигән өлеше дә бар икән. Мамадыш шәһәрендә ПУЗАНКА дигән күп сулы һәм бик борынгы чыганак бар. Ул инде, текә ярлар ясап, ПУЗАНКА тавы атамасын да барлыкка китергән. Саф суын Вятка (Нократ) елгасына коя. Ихтимал, әлеге чыганак та борынгы заманнарда бу урында авыл төзелүгә сәбәп булгандыр.

Бу сүзнең ПУЗ өлешен КҮЗ дип укый алабыз, ПУЗ=ПҮЗ=КҮЗ. Чөнки тарихи фонетикада расланганча, борынгы телебездә аеруча П-К-Т-Х-Ф кебек тартык авазлар көчәмлелеге еш күзәтелә. Хәзер дә хатын-катын, чишен-тишен, кели-тели, Казанлы-Хузангай дип сөйләшү яши. Соңгы мисал чуаш теленә ишарә.

КАЗАН=ХУЗАН=ПУЗАН\КА\ сүзләре якынлыгы, АНАКның кыскара бару табигатен дә искә алсак, күп нәрсәне ачыклый. Фәндә расланганча, борынгы татар-болгарларның кайбер кабиләләре теле чуаш теленә якын булган. Димәк, әлеге атамалар — ерак төрки бабаларыбыз сүзләре. Бу дәлил Казанның тарихы мен ел белән чикләнмәвен дә раслый. Хәзер күпләргә аңлашылмый торган АНАК сүзе жирне жанлантыру фәлсәфәсе гасырына карый — Мәжүсилек гасырларына!

ПУЗАНКАның (КҮЗАНАКның) икенче өлеше АНКА. Моны АНАК дип укый алабыз. Чөнки (КА=АК) бирелә телдә авазлар күчү күренеше бар. КА русча әйтелеш нәтиҗәсе дә. ПУЗАНКА, КА\Ү\ЗАНКА кебек сүзләр руслар белән яшәүнең өстәмә үзгәрешләре дә. Асылда әлеге ике сүз «күз яше чыга» дип, чыганакларны атаудан

ясалган. КҮЗАНАКтан (кыскара барып) КАЗАН шәһәре атамасы барлыкка килгән. Урал ягында бер чыганакның ПЛАКСУН (ЕЛАК) дигән атамасы да бар.

Ихтимал, шәһәр туачак мәйданда чыганаклар күп булу да, КҮЗАНАКлы һәм Идел белән элекке Казансу кушылган (хәзерге елга техникумы янында) бу урынның бик мөһим географик, икътисади һәм хәрби-стратегик үзенчәлекләре дә тора-бара кала-кирмәннең табигый үсешенә үз өлешләрен керткән. Әлеге урын (авыл) калкулыгы да һәм элекке Казансу тамагы калкулыгы да (Казандагы ин беренче монастырь калкулыгы) отышлы ил сагы, таможня вазифасын башкарган булулары бик мөмкин.

Борынгы Жукәтау, Тубылгытау, Калатау кебек шәһәрләребез дә шундый калку урыннарда үсеп чыкканнар бит. 16 гасыр рус язмаларында (Писцовая книга) Казансу тамагындагы калкулык ИЛАНТОВ (Илантов монастырь) дип атала. 17 гасырда гына ул Зилантов дип языла. Диалектларыбызда сакланган АНД\Т\АУ=АНДАУ сүзе көтеп, күзәтеп, саклап тору мәгънәләрен белдерә.

Татарстандагы Карашай-Саклау, Саклау, Саклубаш, Карамыш, Урсак авылларының, нигездә, калкулыкта булулары да шуны раслый. Сакта кизү торулар Кизүләү һәм Кизләү дигән авыл атамаларын барлыкка китергән. А.Х.Халиков «Кыз тау» дигән атаманы да «Күз тау», «Күзәтү тавы», «Илнен күзе» дип анлау кирәклеген язган иде. Димәк, ИЛ+АНДАУ (ил сагы, бу очракта—елга сагы, набережный дозор) борынгы дәүләтчелегебез сүзеннән ясалган. Халыкның чиксез фантазиясе (этимологиясе) аны Е\И\ЛАН+Т\Д\АУ=З\Ж\ИЛАН\Т\ дип үзгәрткән. Чөнки ЕЛАН=ЖЫЛАН=ЗИЛАН\Т\ сүзләрендә авазлар вариациясе күзәтелә.

ИЛАНД\Т\АУ, Е\И\ЛАН Т\Д\АУ атамалары шул рәвештә башка урыннарда да саклану төрки дәүләтнең ил чикләре һәм житди ил сагы системасы турында сөйли. Башкортстанның Илеш районында Агыйдел белән Базы елгалары кушылган урындагы тауны «Елан тау» диләр. Алабуга шәһәрендә сакланган Чулманны күзәтү корылмасын («Еланнар шәһәре» дигәндәй) «Чертово городище» дип атыйлар. Чиләбе шәһәре янындагы скифларга нисбәтле курган-тауның хәзерге атамасы—ИЛАНТ\Д\АУ! Анда 1999 елда граниттан эшләнгән, шлем кигән хатын-кыз статуясы һәм кеше сөякләре табылган. Мондый атамаларны картада билгеләп чыксак, халыкның тарихы яна төсмер алачак.

Казан урынындагы авыл тарихы ил сакчылары һәм аларны тәэмин итеп торучы кешеләр тарихлары белән бәйле. Ил сакчыларының кизү торулары, «эш урыннары» элекке Казансу тамагындагы калкулыкта (хәзерге иске монастырь тирәсендә) булуы ихтимал. Аннан тирә-як бик ачык күренә, Иделгә дә якын. Андагы сакчылар—Казансуга керү йозагы.

Мондый зур хәрби-стратегик һәм икътисади әһәмияткә ия булган авылның тора-бара калага әверелүе табигый күренеш. Иске Казанда (борынгы атамасы БОЛГАР ӘЛЖӘДИД) изгеләштерелгән чыганак булуны. Казанда изге чыганак хәзер дә хөрмәт ителүне искә алсак, ЧЫГАНАК сүзенен борынгы авыл һәм тора-бара шәһәр атамаларына да кучүе гажәп түгел. Тел һәрвакыт кыскаруга омтыла. Бу серле атама да гасырлар дәвамында кыскара барган. Нәтижәдә ЧЫГАНАК=КҮЗАНАК=КАЗАНАК=КАЗАН=КАЗАН\КА\ туган.

Ихтимал, Арча ягындагы Иске Казан урынында да ниндидер борынгы кирмән-авыл булып, ул да ЯНА БОЛГАР каласына нигез вазифасын үтәгән. Хәзерге Казаныбызның ерак тарихлары ачыкланмаган заманнарда, аны Иске Казан дип атаганнар.

Күренә ки, Казаныбызның тарихы мифлар белән генә чикләнми. Ул гажәеп шигъриятле, тылсымлы. Тел мирасыбыз — тугандаш халыклар тарихларына да алтын ачкыч. Казанның тетрәндергеч сәхифәләре күп. Аларны халыкка житкерү, сәхнәгә күтәрү, мәдәни мирасыбыз итү — безнең изге бурычыбыз. Ышанам, борынгы Казан турында нәфис кинофильмнар да, рәссамнарыбызның «Казансу дозоры» дигән әсәрләре дә туар. Әйе, Казан, исемен матур, кемнәр куйган...

**Назыйм ХАНЗАФАРОВ,**
*филология фәннәре докторы*

# ҺӘРКАЙДА ҮЗ КЕШЕ

МАРСЕЛЬ БАКИРОВКА 80 ЯШЬ

Һәр төр фәнни һәм әдәби иҗат шәхеснең рухи дөньясы, тормыш-яшәешне күзаллавы, хыял-омтылышлары белән тыгыз бәйле булып, аның табигый сәләтенә, тырышлыгына, максатчанлыгына нисбәтле дөнья күрә, укучыга килеп ирешә, танылу ала. Ә инде хезмәт нәтиҗәсенең ил-халык тормышына аваздашлыгы, җәмгыятьтә алган яңгырашы автор үзе сайлаган, эшләгән өлкәгә алып килгән яңалыгы, казанышлары белән билгеләнә. Әлеге уйланулар артында замандашыбыз, Казан федераль университеты профессоры, филология фәннәре докторы, ТР атказанган фән эшлеклесе Марсель Хәернас улы Бакировның шәхесен, фәнни һәм педагогик эшчәнлеген күзаллау, барлау, нәтиҗәләр ясау омтылышы ята. Галим һәм педагог, публицист һәм тәнкыйтьче, шулай ук бик күпләрнең остазы буларак Марсель ага Татарстанның әдәби һәм фәнни җәмәгатьчелегенә яхшы таныш. Аның күпсанлы хезмәтләре фәнни нигезе, һәр өлкәдәге соңгы казанышларга таянуы, киң колачлы булуы, яшәп килгән караш-фикерләр белән бәхәс-дискуссия алып баруы, киләчәккә юнәлтелгән булуы, иң мөһиме, новаторлык рухы белән беркемне дә битараф калдырмый.



Татарстанның Мөслим төбәгендә туып-үскән Марсель Хәернас улы урта мәктәптә, аннары Казан дәүләт университетының татар бүлегендә укыганда үзен әдәби-публицистик иҗатка һәм фәнни эзләнүләргә сәләтле итеп күрсәтә. Хезмәт юлын Уфада чыга торган «Кызыл таң» газетасында журналист буларак башлый. Иманым камил, бу өлкәдә дә югалып калмас, үзен шәхес буларак һәм эзләнүчән журналист, иҗат кешесе итеп танытыр иде. Ә инде остазлары, бигрәк тә Хатип ага Госман уку-укыту һәм фән юлын тәкъдим иткәч, Марсель абый бөтен сәләтен, гомерен шуңа багышлый һәм хезмәттәге бәхетен дә шунда таба. Бүген без аны татар шигырь төзелешен, халык авыз иҗатын, гомумтөрки поэзиянең генезис-башлангычын өйрәнүче танылган галим дип беләбез. Фән дөньясында үз урынынны табу, фәнни мәктәбенне булдыру җинел түгел. Моңа ул, бер яктан, остазлары Х.Госман, Л.Җәләй, Я.Агишев, М.Габдрахманов, И.Нуруллин, Д.Тумашева кебек остазлары ярдәме, аларның ышанычын тою белән, икенче яктан, хезмәт ярату, тырышлык, горурлык белән үрелгән үҗәтлек, үз-үзенә ышану, ихтыяр көче аша ирешә. М.Бакиров сайлаган өлкәләр – шигырь төзелеше һәм фольклор – галимнән тирән белем, киң күзаллау, аналитик фикерләү, даими эзләнү, татар-төрки халыкларының гына түгел, бәлки рус-Европа халыкларының да телен, әдәбиятын, фольклорын, киң планда мәдәниятен яхшы белүне таләп итә. Галим фәнни эзләнүләренең концептуаль үзенчәлеге булып мәсьәләгә тәнкыйди якын килү, теоретик карашларын гамәли сынап карау, билгеле фактларны анализлау-синтезлау аша яңадан-яңа сыйфат-билгеләрен ачу, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау тора. Ул өйрәнү объектына җитди әзерлек белән килә һәм вак кебек тоелган мәсьәләләрне дә тикшерү аша үткәрә, еш кына моңа кадәр читтә калып килгән үзенчәлекләрне ачуга ирешә. Шуңа да аның хезмәтләре Татарстан чикләрен үтеп, төрки дөньяда, гомумән, тюркология фәнендә яңалык буларак кабул ителде.

М.Бакировның фәнни кызыксынулары төрле булса да, ул җитди казанышларга ирешкән өлкәләрнең берсе булып татар-төрки шигъриятенең төзелеше, гомумтөрки поэзиянең формалашу һәм үсеше тора. Аспирант елларында башланган эзләнүләре

нәтиҗәсе буларак күпсанлы фәнни мәкаләләре һәм «Төрки-татар шигыренең үсеш баскычлары» (1973), «Шигърият дөньясына сәяхәт» (1999) кебек монографияләре дөнья күрә. Ул шигырь төзелеше мәсьәләләренең иҗат процессындагы урынын, әһәмиятен тирән аңлап эш итә, чөнки «ритмик-интонацион үзенчәлекләреннән башка поэтик әсәрнең формасын да, телен дә, стилен дә, образлар системасын да тулы итеп күз алдына китереп булмый». Болар исә, үз чиратында, рифма һәм строфа композициясе, метрика, шигырьнең эчке структурасы, силлабик системанын ритмик үзенчәлекләре, цезура кебек мәсьәләләрне калкытып куюны, алар буенча җентекле тикшеренүләр алып баруны, үз караш-фикерләренне ачык белдерүне таләп итә. М.Бакиров төрки һәм татар шигыренең ритмик закончалыкларын мөмкин кадәр бергә кушып яки чагыштырып өйрәнүне алга куя. Катлаулы мәсьәләләрне ачыклау өчен, бер яктан, төрки халыкларнын иң борынгы ядкәрләренә һәм алардагы иң борынгы уртак (төрки) шигырь төзелешенә нигезләнсә, икенче яктан, үзара кардәш төрки халыклар шигъриятендәге ритмик-интонацион уртаклыкка таяна.

«Шигърият дөньясына сәяхәт» монографиясе үзенең фәнни-теоретик нигезе белән генә түгел, бәлки полемик характерда булуы, бәхәсле булып саналган мәсьәләләргә галимнең кыю рәвештә үз мөнәсәбәтен белдерүе белән дә зур кызыксыну уята. Хезмәттә житди урынны гарузнын килеп чыгуын һәм табигатен аңлату алып тора. Әдәбият белемендә гаруз гарәпләрдә барлыкка килеп, аның теоретик нигезләре VIII гасырда Хәлил ибн Әхмәт тарафыннан эшләнгән диган фикер яши. Ә инде IX гасырда ул фарсыларга үтеп кергән. Гарәп-фарсы метры төркиләрдә XI гасырда кулланыла башлаган дип исәпләнә һәм анын уңышлы үрнәге булып Й.Баласагунлының «Котадгу белек» әсәре тора. Шулай да төрки әдәбиятларда аеруча киң таралыш алган чоры XV гасырга туры килә. Аңлашылганча, шәрык әдәбиятынын көчле йогынтысы күз алдында. Автор язганча, «төрки шагыйрьләрнең иң югары шигърият булып исәпләнгән көнчыгыш поэзиясеннән үрнәк алулары, алар иҗатында гарәп-фарсы әсәрләре йогынтысында гаруз метрларынын формалашуы һич тә гаҗәп хәл түгел».

М.Бакиров тикшеренүләренең тагын бер мөһим өлкәсе төрки гарузнын үзенчәлекләре белән бәйле. Мәсьәләнең катлаулылыгын искә алып, автор төрки гарузга хас сыйфатларны гарәп-фарсы гарузы белән чагыштыру аша ачыклый һәм әлеге аерымлыкнын өч яссылыкта булуын билгели: 1) төрки гарузнын язылышы төгәл тәртипкә һәм билгеле бер сандагы хәрефләргә нигезләнмәү; 2) озын-кыска иҗекләрнең үзара ярашуы, билгеле бер санда һәм тәртиптә килүе саклану; 3) төрки шигырьдә орфография белән укылыш арасында аерма булу. Бу исә уртак закончалыклар булса да, төрки гарузнын гарәп-фарсы гарузыннан билгеле бер дәрәҗәдә аерылуы турында сөйли. Шулай итеп, «татар шигырен монарчы кабул ителгәнчә, сүз аралы (цезуралы) һәм ачык иҗекле төрләргә генә бүлеп йөртү житми икән, чөнки алар үзара кушылган хәлдә дә очрыйлар, ягъни бу ике төр кысасыннан читкә чыгалар. Икенчедән, монысы аеруча мөһим, ачык иҗекле шигырьләр үзләре дә икегә бүленә: төрки гаруз һәм көчәйтелгән басымлы шигырь». Галимнең бу яңалыгы татар шигырь теориясен бермә-бер баетуы белән аны яңа баскычка күтәрә һәм яңа тикшеренүләргә юл сала.

Уртак мирас булган гомумтөрки поэзиянең башлангычына караган сораулар гаять катлаулы булып, галимнәрнең игътибарын даими җәлеп итеп килә. Шуңа да М.Бакировның гомумтөрки поэзиянең генезисы-яралуы һәм иң борынгы формалары турында тикшеренүләрен үз эченә алган «Шигърият бишеге: Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» (2001) диган монографиясе татар әдәбият белемендә үзенчәлекле вакыйга буларак бәяләнде. Борынгы поэзиянең яралгысы хезмәт процессындагы эндәшләрдән, эмоциональ кабатлаулардан үсеп чыгуы, гомуми атамаларнын акрынлап конкрет эчтәлекле сүзләр белән алышынуы һәм вакытлар үтү белән сүз-текстнын тотрыклы хәлгә килү процессы эзлекле күзәтелеп, хезмәт һәм поэзия синкретизмы таркалу нигезендә поэтик мөстәкыйльлек башлангычына юл ачылу билгеләнә. М.Бакиров мифологияне иң борынгы иҗтимагый аң формасы буларак борынгы ыруглар чорында бердәнбер идеология һәм дөньяга караш формасы дип күрсәтә һәм аны дөньяны поэтик үзләштерүнең беренче баскычы булу турында

нәтиҗә ясый. Мифология һәм поэзиянең үзара катлаулы мөнәсәбәтен ачыклаганда мимесис (ияру, охшату) һәм тел факторларына таяну кирәклеген искәртә.

М.Бакиров тикшеренүләренең тагын бер мөһим тармагы һуннарның (гун) поэтик сүз сәнгате нинди булуын ачыклау белән бәйле. Галим фикеренчә, ыру-кабилә коллективыннан әкренләп оештыручы – башлап йөрүче шәхес аерылып чыга һәм һун чорларыннан башлап шәхси иҗат һәм риторик сөйләм үрнәге буларак ораторлык сәнгате оеша. Гомумән, галимнең тикшеренү, бердән, сүз сәнгатенең башлангычын, мифология һәм фольклор белән үзара тыгыз бәйләнешен ачарга, икенчедән, гомумтөрки поэзиянең гасырлар дәвамында үсеш-үзгәреш эволюциясен тулырак күзалларга, өченчедән, күпгасырлык әдәбиятта урын алган архетипларның, мифологиядән, фольклордан килүче образларның, мотивларның, бай сурәт чараларының ерак тамырларын, төрле чор сүз сәнгатендә башкарган функцияләрен тирәнтен анларга ярдәм итә.

Марсель аганың эзлекле рәвештә өйрәнгән һәм житди фәнни казанышларга ирешкән өлкәсе халык авыз иҗаты белән бәйле. «Фольклор жанрларын системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе» (А.Яхин белән берлектә, 1981), «Татарский фольклор» (2012) монографияләрендә, «Татар фольклоры» (2008) дәреслегендә, күпсанлы мәкаләләрендә татар фольклоры жанрларының үсеш-үзгәрешен, поэтик үзенчәлекләрен, язма әдәбият белән бәйләнешен ачыклауда житди казанышларга ирешә. Бу өлкәдәге эзләнүләрен соңгы елларга кадәр дәвам итеп, гаилә-көнкүреш йола иҗатында гаять мөһим урынны алып торган өйләнешү-никах мәсьәләләрен тикшерүгә килә һәм нәтиҗә буларак «Котлы булсын туегыз» (2007) хезмәте дөнья күрә.

Әлеге хезмәтләр арасында рус телендәге «Татарский фольклор» китабы чын мәгънәсендә татар әдәбият фәнендәге казаныш булып тора. Монография рус телендә язылып, фольклористика фәнендәге яналыкларга нигезләнүе, татар халык авыз иҗатын ил, хәтта дөнья күләмендә танытуга хезмәт итүе белән дә кыйммәт. Әмма аның төп табыш-яналыгы концептуаль юнәлеше, фәнни-методологик нигезе, татар фольклорының борынгы чорлардагы һәм хәзерге барлык жанрларын фәнни бәяләве, сүз һәм фикернең диалектик бәйләнеше, төрле, беренче чиратта, төрки халыкларның мәдәниятләре аша татар халкының милли сыйфат-билгеләрен, киң планда менталитетын ачуы белән билгеләнә. Галим мона кадәр дөнья күргән хезмәтләргә бәя биреп, үзенең остазларына, каләмдәшләре эшчәнлегенә таянып, алга таба житди алгарыш ясый. Методологик планда герменевтикага, ягъни текстларны шәрехләү теориясенә, шулай ук рецептив поэтикага, фәлсәфи-милли эстетикага нигезләнү, тикшерелә торган мәсьәләләрне тарихилык, эзлеклелек, комплекслылык принципларына бәйле алып бару житди нәтиҗәләргә килү мөмкинлеге бирә. Хезмәтне милли рух, милли эчтәлек иңләп үтә. Шуның белән бергә, автор хаклы рәвештә төрки халыклар белән уртак сыйфат-билгеләргә, киң планда гомумкешелек кыйммәтләренә килеп чыга. Күпсанлы жанр төрләре белән үзара тыгыз бәйләнештә танышу, гаҗәеп төрле һәм бай мисалларга мөрәҗәгать итү әлеге системаны тулы бөтенлегендә күзаллауга һәм аңлауга китерә. Марсель Хәернас улының мона кадәр билгеле булган күпсанлы текстларны жентекле тикшерүе, аларны яна яктан ачарга, читтә калып килгән билгеләрен, үзенчәлекләрен күрергә мөмкинлек бирә. Гомумән, әлеге хезмәт фәнни, гамәли яналыгы белән аерылып тора һәм фольклористика, әдәбият белеме фәнендә татар халык авыз иҗатын әдәбият һәм сәнгатьнең башка төрләре, шулай ук төрле халыклар фольклоры белән чагыштырма планда киләчәк тикшеренүләргә ныклы жирлек әзерли.

Марсель Хәернас улы бүген дә безнең арада булып, яна иҗат планнары белән яши. Аның үз эшенә мөнәсәбәте, тырышлыгы, фәнни карашларының, фикерләренең житди уйланган, дәлилләнгән булуы яшь буынга үрнәк булып тора.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

**Редакциядән:**

*2013 елның 10 декабрендә үзенең 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче Марсель Хәернас улы Бакировка сәламәтлек, иҗат шатлыгы, хезмәт уңышлары теләп калабыз.*

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2014 елнын беренче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. «Казан утлары»нын индексы физик затлар өчен – **73210**; юридик затлар өчен – **16262**.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан, абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Әлеге квитанцияне кисеп алып, анда тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

90 еллык бай тарихы булган мәдәниятебез елъязмасы — «Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

---

Федеральное государственное унитарное предприятие " ПОЧТА РОССИИ" Ф. СП-1

Бланк заказа периодических изданий

**Ф.СП-1**

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

*«Казан утлары»* (наименование издания)

количество комплектов

На 2014 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому

Линия отреза

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА **73210** (индекс издания)

На ~~газету~~ журнал *«Казан утлары»* (наименование издания)

| Стоимость | | | Кол-во комплектов | |
|---|---|---|---|---|
| | подписки | руб. коп. | | |
| | каталожная | руб. коп. | | |
| | переадресовки | руб. коп. | | |

На 2014 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

почтовый индекс

город

село

область

район

код улицы

улица

дом

корпус

квартира

фамилия и. о.

# НИНДИ ҖИР УЛ СУСЛОНГЕР?

Сталинград өчен барган сугышларда 1942 елның җәй башларында каты яраландым. Казан госпиталендә өч ай буе дәваланырга туры килде. Шуннан соң безне, берничә кешене, Мари АССРның Суслонгер тимер юл станциясенең ике-өч чакрымлы урман эчендәге запас полкка җибәрделәр. Хәер, анда берничә полк булган икән.

Безне гаҗәпләндергәне шул: ни өчендер солдатлар кәефсез йөри. Үзләре бик ябык, хәлсезләр, барган җирләрендә сөртенеп егылалар. Килү белән 2нче батальонның 4нче ротасына беркеттеләр. Кичен яртылаш җир астына ингән ашханәгә алып бардылар. Ике такта кинлегендәге озын өстәлгә иллешәр кеше утырдык. Ун кешегә биш литр сыешлы кәстрүл белән кәбестә шулпасы, дөресрәге, кайнаган су, 200 грамм дип исәпләнсә дә 100 граммнан артмаган икмәк сыныгы — башка нәрсә юк. Бер рота солдатлык землянкага 240–250 кеше шыплап тутырыла. Иртәнге физзарядка дигәне: 3 чакрым йөгереп барып, берәр метр итеп киселгән ике утын пүләнен бил каешына бәйләп алып кайтасың. Кәбестә баландасыннан соң — тагын урманга. 3–4 километрга дүртәр тапкыр барабыз. Кайбер ротадагыларны 15–17 километрга да йөртәләр. Алты кеше бер бүрәнәгә ябышасың. Озынлыгы 6,5 метр, юанлыгы 25–30 сантиметрлы агачны инбашына күтәреп ташыйсың. Кешеләр барган җирдән егылып та үлә.




Ашау-эчү начар дигән идем. Без ит, май, шикәр ише әйбер күрмәдек. Икмәккә туймадык. Шул сәбәпле кырылды солдатлар. Иртә торышка землянкадан һәр көнне 4–5 мәет чыгарылды. Ә бит землянкалар саны 23 иде бугай. Димәк, көн саен йөздән артык кеше үлеп торган.

Моң-зарыбызга колак салмадылар. Ашханә янындагы черегән бәрәнге кабыгын җыеп ашаган өчен дә җәзалыйлар иде. Мондый гөнаһым өчен мине дә штабка алып кайтып, өч тәүлек гауптвахтада утырттылар. Хатларыбыз бик нык тикшерелеп кенә чыгарылды. Үзебезгә килгәннәрен дә энә күзеннән үткәределәр.

Шулай бервакыт безне урман эчендәге станциягә продуктлар бушатырга алып киттеләр. Бик куаныштык, тамак туяр дип өметләндек. Кая ул! Тимер әрҗәләргә, капчыкларга тутырылган әйбер брезент белән яхшылап томаланган. Алып та, эчендә ни барын белеп тә булмый. Үткен генә бер рус егете качып-посып кына капчыкны тешләп тишкән. Киптерелгән икмәк, ди. Кугәрә дә башлаган. Булдыра алганча тутыра бу сохариларны. Безне шуның белән сыйлады. Соңыннан солдатларга дигән әлеге сохарины җиргә күмделәр.

Мин үзем Суслонгер лагеренда 28 көн тордым. Әгәр тагын бераз яшәсәм, аяк сузган булыр идем. Сугышка дигәч, шатланып киттем. Юлда хәлсез солдатларны өстәмә паек биреп тергезделәр. Мәскәү янындагы урманлыкта унбиш көн буе өстәмә норма белән туклandырдылар. Шуннан соң гына Көнбатыш фронтка җибәрделәр.

Суслонгер турында соңыннан ишеткәләдем. Әгәр хак булса, анда К. Е. Ворошилов килгән икән. Чөнки лагерьда калган солдатлар безнең аша югарыгы оешмаларга хат язып җибәргәннәр иде. Комиссия шул нигездә килгән. Корткычлык булган икән. Күп офицерлар атылган. Ләкин бу чакта чутсыз гына солдатлар да якты дөнья белән

бәхилләшкәннәр иде шул инде... Исән калуыбызга куанып явыз дошманны ачу белән кыйнадык һәм җиңдек.

Шулай да Суслонгер хәлләре һич истән чыкмый. Дошманга сатылган явыз җаннар безнең халыкны күп кырды анда.

**Мөхәррәм ШӘРИПОВ**



*Сугыш фронтын да, тыл «фронтын» да исән кичә алган М.Шәрипов. Сугыштан соң төшкән фоторәсем.*

* * *

Бу тетрәндергеч хәлләрне сугыш ветераны кәгазьгә төшергән. Гомеренең төп өлешен Биектау районының Зур Көек авылында үткәргән Мөхәррәм агайны күп еллар дәвамында әлеге хәлләрнең сер булып кала килүе дә борчыган. «Төп әйтәсе килгән сүзем шул, Суслонгер вакыйгасын матбугат битләрендә кинрәк яктыртасы иде, — диган ул. — Андагы «сират күпере»н кичкән һәм исән калган солдатлар бүген дә бардыр бит әле? Аларның сүзен дә ишетәсе килә». Ошбу теләк Мөхәррәм агайның вафатыннан соң да мөһимлеген җуймагандыр.

Чыннан да, бу төбәктәге фронтка кадрлар әзерләү лагере турында мәгълүматларның рәсмиләре генә түгел, рәсми булмаганнары да бик аз икән шул.

Гаҗәп хәл, хәбәрсез югалган сугышчыларның язмышын, һәлак булганнарның күмелү урыннарын ачыклау, бу хакта аларның туганнарына хәбәр итү дәүләт органнарына бөтенләй кагылмый диярсең! Хәер, кешенең кадере булмаган, халкын йөзәрләп-меңнәрләп дәүләт үзе юк иткән илдә гаҗәп үк тә түгелдер.



*Суслонгер урманнары*

Шөкер, моның белән, бер катышлары да булмаган килеш, үзләре теләп шөгыльләнгән фидакарь затлар да бар әле. Михаил Черепанов кырык елдан артык бу эшнең башында тора. (Әлеге изге «чир»нең ана инде Казан университетының тарих-филология факультеты студенты чагында ук йокканын беләм.) Унбиш еллап элек Казан һәм Яшел Үзән фидакарьләреннән торган эзләнү төркеме Суслонгерга да килеп чыга. Михаил язганнардан *(«Отечество» журналы, 1999, № 3)* тәрҗемәдә берничә өзек китерик әле.

«Бу лагерь 1941 елның июленнән 1943 елның ноябренә кадәр генә эшли. Ачлыктан, суыктан, төрле чирләрдән меңнәрчә кеше үлә. Һәм алар хәзергәчә хәбәрсез югалганнар исәбендә... 1943 елның ноябрендә Суслонгерга инспекция белән К. Е. Ворошилов килә. Лагерьның шундый хәлдә булуына гаепле кешеләр каты җәзага тартыла, лагерь үзе исә бетерелә». «Лагерьның төп бурычлары пулемет взводы командирлары әзерләү һәм урыс булмаганнарны фронт өчен урыс теленә өйрәтү була. Шуна күрә лагерь курсантларының төп өлешен татарлар, башкортлар һәм Идел буеның башка халыклары тәшкил итә.» «Күршедәге (Кундыштагы һ. б.) шундый лагерьларда исә мондый хәлнең әсәре дә булмый.»

Шаккатмалы хәл! Совет солдатларын үтерү лагере (Сталин заманында!) 28 ай буена эшләп тора алсын әле! Ихтыярсыздан башка шундый бер уй килә: моның халыкка беркайчан да җиткерелмәячәк яшерен максаты булмады микән? Мәскәүнең үз сәясәтенә, ә бәлки, милли сәясәткә дә кагылышлы максат?

**Р.ЮНЫС**

# ХАЛЫККА ХЕЗМӘТТӘ ЯМЬ ДӘ, ТӘМ ДӘ БАР...

ШӘҺИД ӘХМӘДИЕВНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

XX йөз башында татар халкының иҗтимагый-рухи янарышында, әдәби-мәдәни күтәрелешендә язучы, журналист, публицист һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Шәһид Әхмәдиев мәгълүм роль уйный. Бу вакытта Казан татар милләтенең рухи-мәдәни мәркәзе булып торса да, Оренбург, Уфа, Җаек, Әстерхан шәһәрләрендә дә милли тормыш күренерлек төстә җанлану кичерә. Шул чорның әдәбият-сәнгать хәятенә, иҗтимагый хәрәкәтенә кинрәк күз ташласаң, һәр төбәкнең рухи юлбашчы ролен уйнаган әдәби-мәдәни даирәсе булуы ачыклана. Мәсәлән, Уфа шәһәрендә үзеген Г.Ибраһимов тәшкил иткән даирә барлыкка килә. Бу кинкырлы шәхес янында әдәби-эстетик омтылышлары, теләк-максатлары бер-берсенә якын булган Х.Искәндәрев, Х Кәримов, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Баттал туплана. Дөрес, бу даирәгә башка төбәкләрдән дә тартылганнар. Мәсәлән, алар белән Казаннан фәлсәфи эчтәлекле парчалары белән аерым урын тоткан язучы М.Кайбышевның хезмәттәшлек итүе мәгълүм. Бу зыялыларны шәхси дуслык кына берләштермәгән, алар бер-берсенең иҗади планнары белән уртаклашып торганнар, кирәк вакытта ярдәм кулларын сузганнар, татар матбугатында бер-берсенең иҗатларын пропагандалап, милли сүз сәнгатендә тиешле урын алуларына юл ачканнар.

Рухи көч-егәрлекләрен, сәләтләрен милләткә хезмәткә багышлаган шушы зыялы затлар арасында Шәһид Әхмәдиев тә бар. Ул 1888 елның 29 нчы декабрендә Чистай өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Чистай районы) Татар Ялтаны авылында туа. Башлангыч белемне шул авыл мәдрәсәсендә ала. Әти-әнисе вафат булып, бик иртә ятим кала. 11 яшьлек малай, туган авылыннан Оренбургка китеп, Вәли хәзрәт мәдрәсәсенә укырга керә һәм үз көнен үзе күрә башлый. Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә белем алганда Г.Ибраһимов белән таныша. Шушы көннән башлап, Ш.Әхмәдиев белән Г.Ибраһимов арасында дустанә, иҗади дуслык урнаша. Аларның биографиясенә күз салсак, уртак яклар шактый. Бер үк мәдрәсәләр, гасыр башында күтәрелгән шәкертләр хәрәкәтенә кушылып китүләре, мәдрәсә белән араны өзүләре, университетка укырга керү омтылышлары... Икесе дә социалист-революционерлар партиясенең идеяләрен яклый һәм соңыннан социал-демократлар, большевиклар фиркасенә кушылып китә. Октябрь борылышларыннан соң марксистик-ленинчыл идеяләргә чын күңелдән инанган Ш.Әхмәдиев тә, инкыйлаби үзгәртеп корулар белән рухланып, үзенең бөтен көчен һәм сәләтен Казан губернасында гына түгел, Урта Азиядә дә Совет властен урнаштыруга, халык мәгарифе эшләрен җайга салуга багышлый. 1930 елның августында каты авырудан соң 42 яшьлек Ш.Әхмәдиев Казанда вафат була.

Г.Ибраһимов Кара диңгез буенда урнашкан Гульрипши курортыннан Ш.Әхмәдиевкә язган хатында яшь чакларын болай искә ала: «...Беләсең, Шәһит, без синең белән уникe яшьтән, Оренбургта яланаяк чабучы малай чактан башлап, хәзергәчә күп план кордык. Моның байтагы тормышта гамәлгә куелды инде. Ләкин бөтенесен тәмамлау безгә насыйп булмас. Алдагы буын, бәлки, безнең балалар үзебез уйлап та ирешә алмаганнарны тормышта чынлап күрерләр» *(Гульрипши, 1926 ел, 29 ноябрь).*

Ш.Әхмәдиев кыска гомер юлында шактый катлаулы, авыр һәм үз заманы өчен олы, иҗтимагый идеалга буйсындырылган, мәгънәле тормыш юлы үтә. Ул иҗатка дөньяви мәктәпләрдә, югары уку йортларында белем алган яисә укуларын дәвам иттергән татар халкының күренекле зыялылары Г.Гобәйдуллин, Г.Рәхим,

Г.Кәрам, Н.Хәлфин, Ж.Вәлиди, Ш.Мөхәммәдъяровлар буыны белән, үзләренә татар дөньясында лаек урын дәгъва итеп, шаулап килеп керә.

Ш.Әхмәдиевнен иҗат гомере озын түгел, үз эченә 1912-1917 еллар аралыгын ала. Әдип кече проза жанрында яратып эшли: хикәя, нәсер, парча, очерк, хат, әдәби яктан эшкәртелгән әкиятләр, балалар өчен язылган әсәрләр һ.б. Ш.Әхмәдиев татар әдәбияты идея-эстетик эзләнүләр, яна сыйфат үзгәрешләре кичергән чорда яза башлый. Әдәби мирасында ул үз чорынын актуаль мәсьәләләрен күтәрә. Анын иҗаты, бер яктан, Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Г.Ибраһимов һәм башкаларнын әдәби-эстетик карашлары белән уртак. Икенче яктан, милли прозага 10 нчы елларда килгән Г.Сөнгати, М.Гали, М.Хәнәфи, Г.Рәфикый, З.Бәшири, Г.Рәхим, Г.Газиз, С.Җәләл, С.Рахманколый һ.б яшь буын әдипләре белән берлектә Ш.Әхмәдиев татар әдәбиятына яналык та алып килә. Шуна күрә әдип иҗатында үзенә кадәрге әдәби традицияләрне, XX йөз башы Янарыш чорынын үзенчәлекләрен, Рус-Европа әдәбиятларынын да йогынтысын күрергә мөмкин. Анын әдәби эшчәнлеге жанр байлыгы белән генә түгел, идея-тематик кинлеге, иҗат принциплары, сурәтләү алымнары, чараларынын төрлелеге белән дә аерылып тора. Милли әдәбиятта бай традицияле хатын-кыз темасын гәүдәләндергән «Суга баткан килен» (1912) хикәясе белән ул әдәбиятка килеп керә. Әсәрдә мәгърифәтчелек әдәбиятына хас ан-белем, тәрбия-әхлак, шәхес иреге, хатын-кыз мәсьәләләренә басым ясала. Татар тормышында хатын-кызнын хокуксызлыгы, Кәлимәнен комсыз, рәхимсез атанын корбаны булып биш йөз сумга сатып җибәрелүе, анын фаҗигале язмышын тасвирлау бу әсәрне Я.Вәлинен «Ачлык кушты», М.Гафуринын «Ачлык ел яки сатлык кыз», А.Таһировнын «Сатылган кыз» әсәрләренә авазлаш итә. Милли чынбарлыкта хатын-кыз хокукларын яклаган һәм шунын белән публицистик, тәнкыйди мәкаләләре белән керешеп киткән «Татар кызына» нәсере дә шушы темага багышлана. Романтик эстетика атрибутларыннан хатын-кыз, мәхәббәт культына бәйле геройларнын күнел дөньясын «Сүз истигъмал итмәдем» («Ышанычын акламау») хикәясе тасвирлый. «Шагыйрь моная» нәсерендә исә яшәүдән гайрәте чиккән, өметсезлеккә бирелгән ялгыз геройнын күнелсез хис-кичерешләре модерн әдәбиятына хас алымнар, сурәтләр ярдәмендә күрсәтелә.

Ш.Әхмәдиев иҗатында милли зыялылар тормышын сурәтләү кызыл җеп булып сузыла. Бу тема яшәүнен әхлакый һәм фәлсәфи мәгънәсен эзләү мәсьәләсе белән кушылып китә. Шушы юлда татар зыялыларынын төрле типлары тудырыла. Яшәү мәгънәсен, идеалын милләткә хезмәт итүдә тапкан, үз көч-энергияләрен, теләк-омтылышларын балалар укытуга, ач, фәкыйрь авыл балаларына белем бирүгә багышлаган мөгаллимнәр, мөгаллимәләр, халыкчы яшьләр тормышы, бу юлда аларны сагалаган авырлыклар, кимсетелүләр «Мөгаллим», «Хат һәм җаваплар» әсәрләрендә сурәтләнә. Мәсәлән, Ш.Әхмәдиев беренче хикәясендәге вакыйгаларны бәян итүчедән мондый сүзләр әйттерә: «Милләтебезнен истикъбале (киләчәге) сезнен кебек эшлекле, каһарман мөгаллим вә мөгаллимәләргә баглы икәнен хәтердән чыгармагыз; сезнен бөтен читенлеккә түзеп, сызганып эшләвегез генә безгә өмет бирә. Сез милләтнен мәгънәви тамыры: сез нык булсагыз, анын яфрагы яшел, чәчәге матур, җимеше татлы булыр. Яшәгез, татарга файдалы затлар!» — дип аларнын күнелләрен күтәрергә тырыштым». Әдип зыялы яшьләр арасында милләт файдасына кулыннан бер тиенлек эш килмәгәннәре барлыгына да ачынып, борчылып яза, аларны «сәрхушләр» дип атый.

Күренә ки, авторнын әсәрләрендә милли идеал мәсьәләсе яктыртыла, анын фәлсәфи һәм әхлакый нигезләре ачыклана. Тарихи темаларга мөрәҗәгать итеп «Хан кызы», «Сөенбикә» әсәрләрен иҗат итүе дә шушы мәсьәләнен башка яссылыкта чагылышы булып тора. «Хан кызы» повестенда Кара Идел, Чулман, Вятка, Агыйдел сулары буенда урнашкан, байлыгы, матурлыгы, халыкларынын яхшы тормышы, укымышлылыгы белән ерак илләргә, чит патшалыкларга даны таралган Болгар иле сурәтләнә. Анын сюжеты нигезенә тарихи хезмәтләрдә теркәлеп калган фактлар салынган. Шулай ук әдип Болгар дәүләтенен Ислам динен кабул итүен чагылдырган риваять һәм легендаларны да әдәби материал буларак файдаланган.

Ш.Әхмәдиев мабугат битләрендә үз чорынын актуаль иҗтимагый-социаль, милли проблемаларга багышланган публицистик рухтагы язмалары һәм тәнкыйть

мәкаләләре белән дә чыгыш ясый. Аның «Габдулла Тукаевны искә төшерү»(1914) дигән мәкаләсе шагыйрьнең вафатына бер ел тулу мөнәсәбәте белән язылa. Иҗтимагый-фәлсәфи планда язылган гуманистик яңгырашлы мәкаләнең башлам өлешендә автор тарафыннан Тукай татар милләтенә мәдәният мәйданында урын алырга күп көч сарыф иткән, «мәдәни милләтләрчә эш кыла башларга» юл ачкан шагыйрь буларак бәяләнә. Татарның кара бәхете өчен борчылган Тукайны әдип «татарның яшь мәдәни тарихына беркетелгән» «тарих әгъзасы» итеп саный.

Публицистик аһәң белән сугарылган «Шагыйребез Габдулла Тукаевның хатыннарга карашы»(1914) мәкаләсендә авторның бәя-хөкемнәре, уйланулары алдагы язмасы белән аваздаш. Ш.Әхмәдиев шагыйрьнең хатын-кыз мотивын, иҗтимагый-милли яссылыкта күчереп, конкрет-тарихи шартларга куеп гәүдәләндергән шигырьләренә таянып, Тукайның гамьнәре, күңел кичерешләре, гражданлык позициясе турында фикер йөртә. Автор бу язмаларда Г.Тукай иҗатының асыл хасиятләреннән икесен – татарлыкны һәм миллилекне аерып куя. Икенче мәкаләдән беркадәр соңрак басылган «Хатыннар хәле»(1914) дигән язмасында Ш.Әхмәдиев, Европа масштабыннан торып, милли чынбарлыкта татар хатын-кызларының хокуксыз хәле, хатын-кыз азатлыгы, гаиләдәге урыны хакында уйлана. Белем һәм һөнәр алу мөмкинлеге биреп, җирле шартларда бу мәсьәләне уңай якка үзгәртү юллары турындагы фикерләре кызыклы тәэсир калдыра.

Ш.Әхмәдиевләр буыны татар халкының яңарышын милли рамкалар белән генә чикләмичә, дөнья масштабында, Европа кимлекләрендә карый, татар әдәбиятының, сәнгатенең Гареб мәдәниятендә урын алуы, аны баетуы юнәлешендә хәрәкәт итә. XX гасыр башында матур әдәбият тизләтелгән үсеш юлына басып, дөнья орбитасына атыла. Мәдәни казаныш буларак сәхнә-театр сәнгате, аның тәнкыйте барлыкка килә. Татарның зыялы угыллары сәнгатьнең башка төрләрен дә үстерү юллары турында фикер йөртә башлый. Менә мисал итеп Әхмәтгәрәй Хәсәни мөхәррирлегендә нашир ителгән «Аң» «әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый, рәсемле журнал»ының эшчәнлеген күтәрү дә җитә. Ш Әхмәдиев тә бу юнәлештә актив хәрәкәт итә. Аның бер шәлкем язмалары сәнгатьнең төрле тармакларына багышланган. »Яшә, Зөбәйдә, яшим мин»(1914), «Тигезсезләр» пьесасы»(1915), «Г.Кариев бенефисы»(1915) – әнә шундыйлардан.

Тәнкыйтьче 1910 елларда сабый бала кебек кыюсыз гына тәүге адымнарын атлый башлаган җыр-музыка, рәсем сәнгатьләрен һәм дә аларның тәнкыйтьләрен барлыкка китерүгә, театр тәнкыйтен формалаштыруга үзеннән зур өлеш кертә. Фәлсәфи-эстетик яссылыкта язылган «Бездә сәнәигы нәфисә»(1914) мәкаләсендә Ш.Әхмәдиев матурлык эстетик категориясе, кешедә тән һәм җан берлеге, матди һәм рухи башлангычлар, кешелек җәмгыятенең төрле баскычларында рухи кыйммәтләрнең үсеш-үзгәреше хакында бәя-хөкемнәре белән уртаклаша. Аннан соң милли чынбарлыкта, татарларда нәфис сәнгать, дин-шәригать кануннарының рәссамлык, сынлы сәнгать, җыр-музыкага мөнәсәбәте хакында уйлануга күчә. Төрле чикләүләргә карамастан, җыр һәм театр сәнгатьләренең XX гасыр башында җитди адымнар ясавы ныклы дәлилләр белән расланa. Мәсәлән, ул җырчылардан милли-мәдәни тарихыбызда урын алган  Камил Мотыйгый, Фәттах Латыйпов, Солтан Рахманколый, актерлардан С.Гыйззәтуллина-Волжская, Г.Кариев, Мохтар Мутин һ.б.ларны атый. «Һәрхәлдә, сизгер, нечкә хисле, моңлы татар эченнән маһир композиторлар,чын рәссамнар, чын җырчылыр чыкмас диеп булмый» рәвешендә татар дөньясында  әлеге сәнгать төрләренең барлыкка килүенә өмет белдерелә.

Күзәтүләр Ш.Әхмәдиев рухи мирасының XX гасыр башы яңа татар әдәбиятын идея-эстетик яктан баетуда, стиль ягыннан төрлеләндерүдә, жанр мөмкинлекләрен киңәйтүдә билгеле бер роль уйнавын күрсәтә һәм автор стиленең үзенчәлеге, каләменең яңалыгы аның татар әдәбиятында үз юлын табуы турында сөйли. Публицист, журналист, тәнкыйтьче буларак та ул татар театр, музыка һәм рәсем сәнгатьләренең мөстәкыйль үсеш мәйданына чыгуына зур көч куя.

**Таһир ГЫЙЛАҖЕВ,**
*Казан федераль университеты доценты*

Шәһид
Әхмәдиев

# ШАГЫЙРЬ МОҢАЯ

Әллә кайда... еракта бер музыка уйный...

Ул җирдәге көйләрне уйнамый. Тик аның мәңге зарланганын гына аңлап була. Һәркем ул көйнең эчендә үзенең чиге-кырые булмаган өметсезлеген күрә. Шулай булса да, музыканың тукталуын ул шагыйрь бер дә теләми. Кем генә булса да, «аһ» белән «зинһар уйна, туктама, моңай!» дияргә хәзер тора...

Куе караңгылык бөтен дөньяны каплаган. Чиге бер дә күренмәгән су янында гына күркәм бакча. Ул төрле яшел агачлар һәм түтәл-түтәл булып торган күркәм чәчәкләр белән бизәлгән. Бүлмә. Аның ачык тәрәзәсе бакчага карап тора. Ак чәчәккә күмелгән киң яфраклы бер-юкә агачы нәкъ тәрәзә төбендә генә, хан кызы кебек елмаеп, бүлмә эченә карый. Бакчаның да һәм күзгә күренеп торган зур дәрьяның да исләре юк.

Музыка серле көен уйный. Шагыйрь нәкъ тәрәзә төбендә утыра. Ул музыканың моңына күмелә. Аның нәрсә уйнаганын ул шагыйрь аңламый. Ул үз гомерендә ишетмәгән бер көй тыңлый. Ул музыкадан элек тә «исемсез» кайгы белән кайгыра иде. Бу серле көйләрне тыңласа да, ул аның «исемсез» кайгысын бетерми. Тик ул шагыйрьгә бер иптәш кенә була ала. Шагыйрь аның зарында да исемсез, яшерен кайгы һәм сагыш күрә. Шагыйрь кайгыра. Ни өчен кайгырганына сәбәп эзләми. Уйлый да, уйлый. Уйның да ни икәнен аңламый: әнә ул бер ялгызы, иге-чиге бер дә күренмәгән диңгез өстендәге бер көймәдә бара. Кайдан утырганын, кайда барганын һәм ничек киткәнен белми. Көймәсенең канаты да һәм руле дә юк. Үзе бертуктамый бара. Артта да, алда да, янда да һәм тирә-якларда да ярлар бер дә күренми. Көчле дулкыннардан башка, күзгә бернәрсә дә күренми. Тик алар адашкан бер мөсафир белән исәнләшкән, хушлашкан төсле, көймәгә сугылып-сугылып китәләр.

Һавада аз гына сөрем бар. Вак кына һәм сиек кына болытлар сиздермәслек рәвештә генә кайдадыр агалар. Алар да кайдан чыкканнарын, канда барганнарын һәм ни эшләп калачакларын белмиләр. Шагыйрь аларга томырылып карый. Алар эчендә үз тәкъдирен күрә. Алар ана бер иптәш булып та күренәләр. Көймә дә мәгънәви язмышка буйсынып, диңгез өстендә йөзә генә бара. Исемсез көй туктый. Шагыйрь сискәнеп китә.

Юкә яфраклары да селкенешеп һәм кузгалып китәләр. Бик тәмле ис аңкып бакчадан бүлмәгә керә. Хәзер шагыйрь үз бүлмәсендә икәнен төшенә. Иге-чиге булмаган диңгез өстендә канатсыз һәм рульсез көймәне һәм адашкан болытларны оныта алмый. Тагын музыка уены янара. Бу көй дә исемсез. Ләкин элеккегә баш-башка. Шагыйрь тыңлый. Үзе моңая, кайгыра. Күзенә мохит[1] күренә: әнә үзеннән бер дә калмыйча йөргән дуслары, әнә һәммәсе... ул берсенә дә кул сузмый. Аларда ул ике йөз, кара йөрәк, ялган караш күрә. Гүя алар моны һәлак итәргә ау коралар.

[1] Мохит – дөнья, әйләнә-тирә.

Аның җан ачысы белән ләгънәт орып: «И хәйләле, мәкерле дуслар! Беләм мин сезнең эчегезне, мин бит сезне үтәдән-үтә күрәм. Ник соң болай ак пәрдә астында кара йөзегезне саклыйсыз. Моннан ни генә теләгегез бар. Мин барысын да беләм ич. Тәхкыйранә[2] карашыгызны, керле йөрәгегезне күреп тә, ничек мин сезгә ышаныйм. Ник соң мине сез дус дисез? Кайчанга чаклы сез үзегезне болай алдарсыз? Менә минем бергә яшәгән һәм яши торган дуслар. Шулар белән көл, уйна, шатлан һәм эш кыл...» диясе килә.

Ул уйлый-уйлый бераз дулкынланып китә. Шактый гына борчылып бераз торганнан соң янә барысын онытып, иске хәлгә килеп, исемсез кайгы белән кайгыра башлый. Бер генә, бер генә нәрсә дә аның күңеленә җиңеллек китерми. Үткән гомерен искә төшерә — аны да сагынмый. Ул анда да бернәрсә күрә алмый. Адәмнәрне сихерләгән алтыннар да һәм тәхетләр дә аны бер дә кызыксындырмый. Ләкин ул берөзлексез кайгыра. Шул «исемсезләр» кайгысыннан аерыласы бер дә килми. Чөнки ул үз кайгысында мәгънәви, илаһи һәм яшерен сер бар икәнен сизгәндәй була. Гүя шул кайгы эчендә үк анык шатлыгы яратылыр һәм булыр төсле...

Музыка һаман уйный. Аның соңгы көе бөтенләй башка. Гүя ул шагыйрь төпсез диңгезнең ярына килеп баскан. Гүя аны хәзер этәреп төшерәләр. Үкерә, елый, хушлаша. Кинәт шагыйрь үзендә бер үзгәреш сизә: җиңеләйгән дә һәм авырайган да төсле була. Ирексез аның күңеле тула. Әллә кай җиреннән авыр йөк күтәрелә башлаганын күрә. Гүя куе болыт эчендә янып кояш чыга... Елый... Аның күңелендә бөтен нәрсәгә мәхәббәт туа. Кемне, нәрсәнедер, бөтен җаны белән сөясе килә. Аның елавы да, тамган яшьләре дә бөтенләй башка. Ул уйлаган саен үзендә җиңеллек, шатлык һәм бәхет артканын сизә. Исемсез бер кайгысыннан аңа илаһи вәхи туа. Шигырьләре бөтен дөньяны мәхәббәт белән күмә. Бөтен дөньяда бер очкын дошманы калмый. Бөтен мохит һәм җир бик матур күренә. Әлеге кара йөзле, кер йөрәкле дусларын да якын күрә. Аларга да кул суза. Көймәсендә канатлар да, руль дә, һәм диңгезендә ярлар да күрә. Көлә, шатлана.

Таң ата. Шагыйрь йөрәге леп-леп тибә, йокыга китә алмый. Шул арада әлеге чәчәккә күмелгән юка агачына бер сандугач килеп куна. Шунда ук ул исемсез көйләрен сайрый һәм җырлый башлый. Бөтен агачлар, гөлләр һәм үләннәр бу сандугачка табыналар. Дәрья да авыр сулап кына һәм үз дәһшәтен онытып аны — сандугачны тынлый. Шагыйрь тынын да алмыйча, сандугачның яшерен һәм тирән серле бу көйләре моңына бирелә. Ләкин сандугачның ни әйтергә теләгәнен аңламый.

Гүя ул да кайгырган. Инде шатлыгыннан мәхәббәт көйләрен сайрый. Гүя ул да бөтен дөньяны сөя. Бу сандугач моңы һәм көе эчендә сагышлы шагыйрь уйлый-уйлый тирән йокыга китә. Сандугач тик сайравын көчәйтә генә һәм матурайта гына бара.

---

[2] Тәхкыйранә — хурлау белән тулган.

# КҮРЕНЕКЛЕ ТЕЛ ГАЛИМЕ

Г.АЛПАРОВНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Телебезнен үсеше, анын казанышлары шул өлкәдә эшләгән галимнәр хезмәтендә ачык күренә. Озак еллар буе армый-талмый тел күренешләрен жентекләп өйрәнеп, үзеннән соң шактый зур хезмәтләр калдырган галимнәребез арасында Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров аерым урын алып тора.

XX йөз башы, билгеле булганча, тарихи вакыйгаларга бик бай чор. Нәкъ менә шул еллардагы ижтимагый хәрәкәт халкыбызнын йөзек кашы булырдай вәкилләрен бөтен дөньяга танытты. Ул вакытта яшәгән башка бик күп чордашлары кебек үк Гыйбад Алпаров та башы-аягы белән мәгариф, журналистика һәм фән дөньясына чума, моңа, әлбәттә, анын ан-белемгә омтылуы, уку-язу, ижат һәм оештыру эшләре белән кызыксынуы, тынгысыз актив тормыш белән яшәве булышлык итми калмагандыр.

Архивларда сакланган мәгълүматларга караганда, Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров 1888 елнын 11 нче ноябрендә Уфа губернасынын Стәрлетамак өязенә караган Корманай авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Белем алу өчен, әтисе аны Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенә укырга жибәрә. Гыйбадулланы, беренче чиратта, дөньяви фәннәр кызыксындыра, шуна да ул укуын дәвам итү өчен, Казанга килә һәм Татар укытучылар мәктәбендә белем ала.

Октябрь инкыйлабы һәм аннан соңгы чорда Г.Алпаров төрле китапханәләрдә эшли, шул елларда татарча нәшир ителгән «Кызыл яу», «Кызыл армия», «Көрәш» һәм башка күп кенә газеталарда актив язышa. Әлеге эшләр белән бергә ул укытучылар һәм кызылармеецлар өчен оештырылган курсларда дәресләр алып бара, Уфа эшче-крестьян университетында да укыта. Шушындый актив, тынгысыз һәм кин кырлы эшчәнлек Г.Алпаровнын сәламәтлегенә зыян китерми калмый һәм ул Урта Азия якларына чыгып китәргә мәжбүр була. Анын төп максаты, дәваланып, сәламәтлеген ныгыту булса да, нәкъ менә шул чорда анын галимлек эшчәнлеге башлана.

Баштарак, ягъни 1921-24 елларда, Г.Алпаров Ташкент шәһәрендә чыга торган «Ак юл» («Ак жол») газетасында һәм «Чулпан» («Чолпан») басмаларында журналистлык хезмәтен дәвам итә, аннары Төркестан Халык мәгарифе комиссариатында фәнни хезмәткәр булып эшли. Урта Азия халыкларынын дәреслекләрен, орфографик нормаларын төзүдә актив катнаша, хәтта «Төрекмән теленен грамматикасы»н төзегән галимнәр төркеменә житәкчелек итә, шунда эшләү ана формаль нигезгә корылган беренче хезмәтне бастырырга ярдәм итә.

Аннан сон (1924-1926 елларда) Г.Алпаров Башкортстан Халык мәгарифе комиссариатында һәм Татарстан Халык мәгарифе комиссариатынын Академик үзәгендә эшли. Ул Беренче тюркология съездында делегат булып бара, гарәп графикасына нигезләнгән татар орфографиясе мәсьәләләренә караган чыгышлар ясый. Чыганаклардан күренгәнчә, Г.Алпаров бу елларда мәгариф һәм фән өлкәсенә караган вакыйгаларда бик актив катнаша. Югары белем алу теләге аны 1926 елда Ленинград Көнчыгыш институтына алып килә, шунда ук аспирантура да уза.

Укуын тәмамлагач, Г.Алпаров Казанга кайта һәм бөтен гомерен укытуга һәм фәнни эшкә багышлый: педагогика институтында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире булып эшли, башта доцент, аннары профессор дәрәжәсе ала.

Галимнең фәнни хезмәтләре арасында татар алфавиты, орфографиясе мәсьәләләрен яктырткannары шактый. Татар язуын латин графикасына күчерү белән килешмичә, Г.Алпаров вакытлы матбугатта үз фикерләрен бик дәлилләп язган күп кенә мәкаләләр белән дә чыгышлар ясый.

XX гасырның 20 нче елларыннан ук галим татар тел белеменә караган фәнни эзләнүләр алып бара башлый. Аның бу эшчәнлегендә философия фәненең йогынтысы, Н. Я.Марр фикерләре белән теләктәш булуы бик ачык күренә.

Г.Алпаров хезмәтләреннән «Әлифба тәртибе, имла кагыйдәләре, атамалар мәсьәләсе, халык әдәбиятын җыю турында инструкцияләр» (1926), «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926), «Татар теленең имла сүзлеге» (1927), «10 ел эчендә татар теле» (1927) һ.б. телебез үсешендә аерым урын алып тора. Алар арасында «Шәкли нигездә татар грамматикасы» татар теленең фәнни грамматикасына багышланган беренче җитди хезмәт дип саналырга хаклы. Анда галим татар телендәге сүз төркемнәренә, җөмлә төзелешенә һәм андагы кушымчаларга карата үзенең кыю фикерләрен әйтә. Тел берәмлекләрен тасвирлаганда, автор аларга башкача – формаль яктан чыгып, телебезнең эчке үзенчәлекләрен истә тотып якын килә. Шуна да бүгенге көн укучысында әлеге хезмәт каршылыклы фикерләр дә уятырга мөмкин. Тик шуны онытмаска кирәк: бу хезмәт – 100 ел чамасы элек язылып дөнья күргән грамматика – татар теленең эчке үзенчәлекләрен алгы планга куя, галим тарафыннан әйтелгән татар теле белеменең төп нигезен тәшкил итәрлек фикерләрне киләчәк буыннарга җиткерә.

Киң кырлы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе, фән, мәгариф һәм журналистика өлкәсендә үз сүзен әйткән шәхес – Гыйбад Алпаровның хезмәтләре татар телен фәнни яктан өйрәнүгә, аның үсешенә зур өлеш кертә; алар бүген дә үзләренең актуальлеген саклый һәм киләчәк буыннарга данлы еллар авазы булып килеп ирешә.

Бер булганнан бар да була, ди халык. Галимнең дәвамчысы – улы Үзбәк Гыйбад улы Алпаров исеме төзелеш һәм архитектура өлкәсендә эшләүчеләргә яхшы таныш. Ул – РСФСРның һәм Татарстанның атказанган төзүчесе, Казандагы проект оешмаларында җитәкче урыннарда эшли, 20 елга якын Татгражданпроект институты директоры була. Хезмәттәшләре аны сәләтле оештыручы һәм үз эшен камил дәрәҗәдә белгән җитәкче буларак хәтерлиләр. Ү.Г.Алпаров җитәкчелегендә эшләнгән проектлар буенча Казанда Болак елгасы буйлары, Кремль яңы янартыла, Үзәк стадион, Үзәк универмаг, Казан циркы, Яшьләр үзәге һәм башка күп кенә корылмалар төзелә. Ул башкалабыз үзәгендәге Болак елгасы ярларын - татар әдәбиятының күренекле вәкилләре Муса Җәлил һәм Тажи Гыйззәт исемнәре белән аталган урамнарны - тоташтырган күпер проектын эшләүчеләрнең дә берсе була.

Тел белеме өлкәсендә зур хезмәтләре белән билгеле булган галимнәребез арасында Г.Алпаровның үз урыны бар. Аның эшчәнлеге милли азатлык хәрәкәте башланган елларда үз юнәлешен таба. Аннан соңгы буыннар да галимнең хезмәтләрен онытмыйлар, аларны өйрәнәләр, үз эшләрендә аларга таяналар.

**Чулпан ХАРИСОВА**
*КФУ профессоры*

Ахир

# КАБУЛ ИТҮ БҮЛМӘСЕНДӘ

САТИРИК ПОЭМА

*Кайбер түрәләрләргә гозер юллап керү үлем газабы белән бер.*

Автор.

**Кайгы көен көйли–көйли,**
**Бик ямансу үтте көнем.**
**Ашыгыч эшен бүлеп бүген**
**Кабул итте**
**мине Үлем.**
**Аны күргәч, өнсез калдым,**
**Мин бит юкса тел бистәсе.**
**Ике чәшкә чәй китерде**
**Кизү торган фәрештәсе.**
**Әйтте Үлем көлемсерәп**
**(Итагатьле — йөзе кара!):**
**« Миңа кергән чакта, дускай,**
**Син беркайчан чират торма...**
**Бәреп кер син, һич тартынма –**
**Урның булыр һәрчак т(г)үрдән.**
**Хур кызлары каршыларлар —**
**Колач җәеп, төркем берлән...**
**Тыңлыйм!**
**Сүзең үлчәп сөйлә,**
**Кыска сөйлә,**
**вакытым тар.**
**Мине эштән бүлдерерлек**
**Әйт соң, нинди гозерең бар?**
**Әйтсәм әйтим, берәүне дә**
**Кабул итми идем бүген —**
**Югарыдан бер танышың**
**Шалтыраткач...**
**вәгъдә бирдем.**
**Ә ул сине, чын дусларча,**
**Якын күреп, хөрмәт итә, —**
**Гүр иясе булуыңны**
**Түземсезлек белән көтә...**

Бик тә башлы
(ярты кашлы!),
Иркен яши...Әлһәмдиллаһ!
Дер селкетә яраннарын,
Каршы дәшү аңар гөнаһ!
Тик шулай да төшермә син
Кереш сүздән күңелеңне,
Дикъкать белән тыңлыйм сине,
Сөйлә, дустым, гозереңне...»
Ләхет сыман
тын бүлмәдә
Янмый хәтта чыра уты...
Мин бит Үлем сорап килдем,
Ә сорауның юк ояты!
Мөнбәрләрдә —
караңгылык...
Алда — иблис,
чатта камин.
Телем эчкә ябышып каткан,
Сүземне һич башлый алмыйм.
Уен эшме?
Куркуымнан
Мин астыма сия яздым.
Инде кабат рөхсәт алгач,
Эндәшергә аңар баздым:

Көн–төн,
төн–көн уй эчендә
Яшим (инде илле биштә!)...
Үләрмен дигән идем лә
Шагыйрьләрчә... утыз яшьтә.
Яшьлегемдә эзләмәдем
Дан һәм шөһрәт.
(шундый холкым!)
Өметләндем, аңлар диеп
Җан ярамны газиз халкым.
Яндым–сүндем,
шуңар күндем,
Оча алмыйм күптән инде!
Кара еллар, таптый–таптый,
Хыялларым җиргә күмде.
Кыйбламны җуйдым күптән,
Калдым ике юл чатында.
Әсәрләнгән җаным оча
Күктә, җиденче катында!
Гарше җирдә яшәү уен
Кабул итми сынган күңлем.
Бу уй белән булмый яшәп! —,
Үлем сорыйм синнән, Үлем!

Әйтте Үлем көлемсерәп
(Итагатьле — йөзе кара!):
Тормыш шулай инде, дускай,
Кайгы белән үрелеп бара.
Әйтсәм әйтим — үтенечең
Минем өчен пүчтәк нәрсә,
Бисмилланы әйтеп иртән
Тавык чалган кебек кенә.

**Тик... карап, тикшереп тора**
**Черек күлнең яраннары,**
**Атна саен үзгәртелә**
**Госморгның карарлары.**
**Алдың– артың карау яхшы!**
**Миңа берүк тимәсеннәр —**
**Эш урнында ришвәт алып**
**Утыра икән, димәсеннәр.**
**Беләм, ярлы кеше бит син,**
**Юктыр коттежың һәм**
**дачаң...**
**Гомер буе шигырь сырлап,**
**Җитмәде инде синең акчаң.**
**Курку, дускай, безгә дә хас,**
**Газраил бар...**
**кыстати... кода.**
**Безне монда земельныйлар,**
**Санипидыстансы тикшереп тора.**
**Бу афәттән булмый безгә**
**Һичничек тә читтә калып.**
**«Сәлам хаты» килеп тора,**
**Үтерәләр штраф салып.**
**Каршы әйтеп карале син**
**Газраилга! —**
**күперенә!**
**Миллард сумлап акча китте**
**Соңгы сират күперенә.**
**Җәзалыйлар — урамнарда**
**Иясез этләр чабып йөрсә,**
**Теплоходлар батса суга,**
**Самолетлар егылып төшсә.**
**Кисәтүләр алам һәрчак,**
**Әгәр табыш эзләмәсәм,**
**Мең дә бер йөз персоналга**
**Хезмәт хакы түләмәсәм.**
**Бушка белем арттырулар –**
**Пычагыма кирәк димен!**
**Укыталар дәрес саен, —**
**«Үле җаннар»[1] һәм**
**«Хунвейбин»[2].**
**Шөкерана... әлегә тиклем**
**Исән йөрим, шуңа шатмын,**
**Мин бит әле коеп куйган**
**Менә диган депутатмын.**
**Җыен җыйнап әрвахларны**
**Үз артымнан ияртәмен...**
**Теләк изге:**
**үлсәм иде**
**Күңлен күреп сөяркәмнең!**
**Кичә генәк минем хатын**
**(Хатын түгел, чистый вандал!)**
**Ысымыскы табып алган**
**Телефоннан,**
**чыкты җәнҗал...**
**Аның уйлап–уйлавынча**
**Бар дөньясы бозык, азган.**

[1] Н.В.Гоголь романы
[2] А. Хәлим романы

**Сөяркәм дә әрсезләнеп:**
**«Сагындым соң...»— диеп язган.**
**Үлем белән сөешкәнен**
**Белми бит ул сөяркәмнең!**
**Әлегә өйдә, кулдале мин,**
**Уңда...**
**хатын иярләде...**
**Хатын нәрсә!**

**Метеорит**
**Хасил булган анда...**
**я-я-яман!**
**Безнең өскә төшеп килә,**
**Җитәр тиздән ахырзаман...»**

**Дикъкать белән тыңлап тордым**
**Иблиснең**
**моң вә зарын —**
**Күзгә карап алдашуның,**
**Сәясәтнең сиздем барын.**
**Белмим инде —**
**нигә шулай**
**минем янда мескенләнә!?**
**Үлүчеләр саны бездә**
**Үсә бара өстәвенә.**
**Җил-давыллар, кубарылып,**
**Үзгәрттеләр җирнең холкын,**
**Энцефалит,**
**грипп,**
**чума**
**Кыра җирдә дөнья халкын.**
**Ходай безне ташлаганмы?! —**
**Туа җанда шундый уйлар.**
**Без бит монда**
**лаборатор**
**Күселәрдер һәм дә коллар...**
**Кәккүк кенә санар безнең**
**Алда калган гомерләрне.**
**Тын бүлмәдә, җөрьәт итеп,**
**Кабатладым гозеремне:**
**«Гарше җирдә яшәү уен**
**Кабул итми сынган күңлем.**
**Бу уй белән яшәп булмый! —**
**Үлем сорыйм синнән, Үлем!»**

**Әйтте Үлем, көлемсерәп**
**(Итагатьле — йөзе кара!):**
**«Картаясың, күрәм, дускай,**
**Инде гомрең үтеп бара.**
**Башың тулы авыру синең,**
**Сырхау күрәм аруыңда.**
**Йөрәгеңдә... недостача...**
**Киңәйгәндер бавырың да.**
**Беркая да дәваланмый**
**Авыруыңны йөрсәң сузып,**
**Язның...беренче көнендә**
**Дөмегерсең Алла кушып!**

**Җирдә үлем эзләмәгән**
**Адәм генә үлем тапмый,**
**Күмәрбез без кабереңә,**
**Рәхәтләнеп**
**таптый–таптый...**
**Тыныч кына яшәрсең син**
**Җайлап яңа фатирыңда,**
**Гүзәл оҗмах бакчасына**
**Карап торыр балконың да.**
**Ләкин сиңа бүген генә**
**Үлем вәгъдә итә алмыйм,**
**Кичерә күр мине, дускай,**
**Мин Ходайдан уза алмыйм...»**

**Кайгы көен көйли–көйли,**
**Бик ямансу үтте көнем.**
**Җиңеләеп**
**сулыш алдым**
**Ташлап чыккач үлем җенен.**
**Елый–елый, урам буйлап,**
**Үз–үземне барам җәлләп...**
**Ә кайдадыр**
**балта асып,**
**Басып торадыр ла җәллад!**

---

## Кайтаваз

Ихластан әйтәм, «Казан утлары» журналының яңа басылып чыккан санын алып уку миндә ләззәт хисләре уята. Беренче танышу алдында гына туа тырган дулкынлану белән бизәкләргә бай тышлы журналның чираттагы санын кулыма алам. Хәзер кулымда октябрь аенда чыккан 10нчы сан. Анда Фирүзә Жамалетдинованың биш хикәясе кертелгән: «Яралы күгәрчен», «Нәфес җиңүе», «Себердә», «Кояшлы келәмнәр» һәм «Йөк».

«Яралы күгәрчен» исемлесенә аерым тукталыйм әле. Ул эчтәлеге белән үземә зур тәэсир ясады. Хикәядә сүз ерак юл шоферы, аның бакча баласы яшендәге кызы һәм юл буенда яраланып яткан күгәрчен турында. Исләрең китәрлек тә инде, нинди ерак җирләрдән әйләнеп очып кайта иске урынга бу күгәрчен, үзен бәладән коткарган кыз баланы эзләп. Ул кызның әтисе дә киң күнелле адәм. Кызының яралы күгәрченгә күрсәткән игелеген анлый белә: баласының кошчык хәле турындагы сорауларына җавапларны табып кына тора. Үскән вакытында баланың күнеленә мәрхәмәтлек чаткыларын сибеп калдырып булганын бик шәп күрсәтә бу мисал.

Инде хөрмәтле язучыбызның икенче хикәясенә күчеп, аның турында да бер-ике сүз әйтим инде. Ул «Казан утлары» журналының быелгы 3нче санында басылып чыккан иде. «Кеше күнеле - кара урман» дип аталган, авыл тормышы чагылдырылган бу хикәянең герое – авыл диванасы Пәттери. Авылдашларының Пәттеригә ихтирамы үзе бер тормыш мәктәбе югарылыгына күтәрә әсәрне.

Рәхмәт сиңа, Фирүзә ханым, күнелгә рәхәтлек бирә торган хикәяләрең өчен!

**Мансур ЖӘЛӘЛИЕВ**
*Казан*

## *«Рухи тормышыбыз энциклопедиясе»*



*«Казан утлары»ның меңенче саны чыгу уңаеннан «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китабыбыз нәшер ителүгә (2006 ел, декабрь) жиде ел тулды. Бу вакыт эчендә китап Татарстан һәм Россиянең барлык төбәкләренә дә диярлек барып ирешге, Төркия, Англия, Америка, Австралия, Кытай кебек илләргә дә юл тапты. Аның турында матбугатта бик матур фикерләр әйтелде. Менә аларның кайберләре.*

**Айдар Хәлим,**
*язучы:*

—Үткән һәм килгән еллар чигендә төрки-татар халкы тарихында, юк, бөтен дөньяның мәдәни харитәсендәдер, чын-чынлап кабатланмас, гаҗәеп вакыйга булды: бик шәп проза, новеллистика, поэзия, публицистика, фотоиллюстрацияләрнең һәм ижади фикер документларының яраткан журналыбыз «Казан утлары»ның меңенче саны чыгу уңаеннан бер түбә астында берләштерелгән бик зур, 90 табаклы томы дөнья күрде... Бу уникаль басма турында тагын ни әйтим? Аны күрергә кирәк. Аны тоярга кирәк. Һәм сезнең алда соңгы йөзьеллыкның бөтен әдәби-рухи тарихы ачылачак.

*Звезда Поволжья. 2007, 7 март.*

**Хатыйп Миңнегулов,**
*филология фәннәре докторы, профессор:*

—Китапларның төрлесен күргән, «Казан утлары»ын да бик күптәннән укып барган кеше буларак, бу басманы мин, йә, ни майтардылар икән дигәндәй, скептик рәвештәрәк кулга алдым һәм... исләрем-акылларым китте. Чын мәгънәсендә бер хәзинә бу...

Журналның гына түгел, ә гомумән татар рухи тормышының, милли яшәешенең бер белешмәсе, чыганагы, энциклопедиясе, хрестоматиясе кебек тә ул.

*Мәдәни җомга. 2007, 2 март.*

**Рәис Даутов,**
*тәрҗемәче, әдәбият белгече:*

—Үткәндәге мәдәни-ижтимагый тормышыбызның куанычлы һәм аянычлы этапларын язма әдәби материаллар мисалында объектив рәвештә яктырткан уникаль китап-антология... Тарихи әһәмияткә ия зур бер яңалык, казаныш.

*Балачак әдипләре. Дүртенче китап. 2008, 230 б.*

**Мәхмүт Әхмәтҗанов,**
*публицист, тәнкыйтьче:*

—Жыентык, һичшиксез, халкыбызның үзаңын үстерүгә өлеш кертәчәк!.. Бу жыентыкта берничә докторлык диссертациясе өчен «азык» бар.

*Мәгърифәт. 2007, 14 апрель.*

**Ркаил Зәйдулла,**
*язучы:*

—Укучылар кулына инде «Татар энциклопедиясе», «Татар тарихы» дигән олуг хезмәтләрнең кайбер томнары килеп ирешә. Һичшиксез, «Сүнмәс утлар балкышы» дип аталган китап та киштәбездә шулар янәшәсендә урын алырлык.

*Идел. 2007, № 4.*

**Рафаэль Мостафин,**
*әдәбият белгече, тәнкыйтьче:*

—Татар әдәбиятының бу үзенчәлекле антологиясен укыганда тулы бер дәверне яшәп чыккан кебек буласың, еш кына катлаулы һәм авыр, кайчакта исә фаҗигале дә булган вакыт сулышын тоясың.

*Звезда Поволжья. 2007, 31 май.*

**Адлер Тимергалин,**
*язучы:*

—Уртакул америкаң төрмә бинасына тартым «хрущоба»ның кысан фатирмәгарәсендә, һава житмәгәндә тәрәзә ачкалап утырам. Теземдә кызыл мәрмәрдәй саллы том—үзе бер китапханәгә бәрабәр «Сүнмәс утлар балкышы». Мин бу утларның саллы жылысын тезләрем белән дә, күңелем белән дә тоям...

Әгәр дә мәгәр бер мәлне мине адәм заты яшәми торган утрауга озатасы булып, үзем белән ун китап алырга рөхсәт итсәләр, шуларның берсе һичшиксез «Сүнмәс утлар балкышы» булыр иде. Алай-болай ерак йолдызара сәяхәткә чыгып китсәм дә үзем белән алыр идем мин аны...

*Казан утлары. 2008, № 1.*

**Рәфыйк Шәрәфиев,**
*язучы, тәнкыйтьче:*

—Язучыларның гына түгел, үзен зыялы санаган, күңелендә милләт язмышы хакында аз-маз уй-фикер, милли хис йөрткән һәр татарның өендә бу китап булырга тиеш ләбаса. Чөнки әлеге җыентык чын мәгънәсендә уникаль, кабатланмас басма, татар халкының хәзерге буыны андыйны бүтән күрә алмаячак...

*Мәдәни җомга. 2007, 13 апрель.*

**Булат Солтанбәков,**
*тарихчы:*

—Дәвер тарихы—бу уникаль басманы шулай дип атыйсы килә... Аның гомере озын буласына һич шикләнмим. Татар мәдәниятенең үзенчәлекле бер энциклопедиясе булган ошбу китап бөтен уку йортларыбызда һәм китапханәләребездә булырга тиеш.

*Республика Татарстан. 2007, 29 май.*

**Лирон Хәмидуллин,**
*язучы, тәнкыйтьче:*

— Милләтебез байрагына тиң басма.

*Гасырлар авазы. 2012, № 1-2.*

*Китапның төзүчесе –* ***Рәфикъ ЮНЫС****,*
*шеф-мөхәррире* ***Равил ФӘЙЗУЛЛИН***

## Без дә студентлар идек...

Яшьлегем Казан каласында «калынайды». 1966 елда Педагогия институтына Кызыл диплом белән амин тоттым. Университетта, аспирантура тәмамлап, белемне гыйззәтләдем. «Казан утлары»нда Г.Ибраһимов, Г.Бәширов, С.Хәким һ.б.лар теле турында мәкалә бастырып, галимлек дәрәҗәмне шәүкәтләдем. Г.Ибраһимов хакында язган трилогия-эпопея («Пәйгамбәр таны», «Күкнең жиденче катында», «Оҗмахка бер адым» романнары) «Казан утлары»нда Сезнең иманлы рухиятегез ярдәмендә дөнья күрде. Аннан соң трилогия ун ел эчендә ике мәртәбә татар телендә, бер тапкыр башкорт телендә басылды. Татарстан китап нәшриятында пьесалар җыентыгым, «Тел – күңелнең көзгесе», «Мәктәптә әдәби әсәрләр телен өйрәнү» дигән хезмәтләрем дә нәшер ителде. «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» дигәне дә яшьлегемнең бер җимеше. «Яшьлекнең Казан каласында калынаюы» шушыдыр инде.



«Казан утлары»нда әдипләрнең фотоларын бирү бик күңелле күренеш. Сорап хат язуыгыз да бик хәерле. Шуны уйлап, мин дә фото җибәрмәк булдым. Андагы студентларның кайсыберләре (Илдар Юзеев, Газиз Мөхәммәтшин) мәрхүмнәр инде (җаннары җәннәттә булсын, амин!). Илдар Юзеев Татарстанның Халык шагыйре булды. Мин фәкыйрегез – Башкортстанның Халык язучысы. Татар, башкорт, рус телләрендә 60тан артык китап бастырып чыгардым. Һәммә язганнарны төрле әдәбият кибәненә сипкәләсән, 30 том чамасы булыр кебек. Ләкин бастыру нияте «контратакага» очрый да тора бит ул хәзер. Фронт теле белән сөйләшәм кебек. Гафу!..

Акрын гына атлап тормыш баскычларын, кулга алдым 90 яшьнең ачкычларын. 2014 елның 29 августында Суфиян бабагызга 90 тула. Алла боерса! Ышанасы килми хәтта. 90 яшькә бирәр әйбер җибәрми калмамдыр инде. «Казан утлары»н алдыруга, аны Башкортстанда таратуга 55 ел икән инде. Бу ут, «Промстой уты» шикелле, дөнья йөзенә гыйззәтле, шәфәгатьле, шәфкатьле иман тарата. Аллага шөкер! Сезнең үз талантыгызга, кешелеклелек сыйфатыгызга, белемегезгә дә сокланып яшим! Патриот булыйк!! Иманлы рух телим!!! Әйткәнем фәрештәнең «Амин» дигән чагына туры килсен!!!

1963 елгы бу фоторәсемдә Казан Педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары. Чүгәләп утырганнары Илдар Юзеев (сулда) һәм без фәкыйрегез. Басып торучылар – Газиз Мөхәммәтшин (сулдан икенчесе) һәм Марат Әмирханов (уннан беренче).

**Суфиян ПОВАРИСОВ**

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнен сәхифә!

*Ак җилкән*



Линар
Закиров

# ҖАНСЫЗ МӘХӘББӘТ

ХИКӘЯ

— Кәрлә, бер сорау бирим әле: маңка ни дигән сүз ул?

— Белмим... Каян ишеттең син моны? — дип кызыксынды Кәрлә.

— Кичә икенче рәттә утыручы бер әби оныгына: «Маңкаңны ашама!» — диде. Чәченә «кар яуган» ул әбинең тавышы яңгырап торды. Ут яктысы аңа гына төшкән иде, оныгы караңгыда утырды. Нәрсә ашаганын күреп булмады. Күргән булсам, маңканың да ни икәнен белер идем, — дип көрсенде Кәрләбикә.

— Сүзе матур! Француз теленнән кермәгәнме икән?

— Мөмкин. Французларда да «ң» бар икән бит. Ике атна элек дүртенче рәттә утырган бер малайдан ишеттем. Иптәшенә шулай дип сөйләп утыра иде, — диде Кәрләбикә.

Кәрлә белән Кәрләбикә — авыл клубындагы курчак театрының өлкән курчаклары. Аларны Фәрит абый исемле агач остасы ун ел элек ясады. Касса алар уйнаган спектакльләр хисабына тула иде... Тора-бара алар халыкка кызыксыз була башлады. Ә халыкның күңел скрипкасында уйный алмаган курчакларны клуб җитәкчелеге тиз арада сафтан чыгара, алар урынына яңаларын ясый.

Фәрит абыйның күңеле утлы диңгез кебек, гел җилкенә, нәфислек тудырырга омтыла. Чәченә чал иртә кунды. Авыл халкы: «Фәрит күп эшли, күп уйлый. Шуңа чәче тиз янды», — дип шаярта. Куллары кирәк кадәр. Кәрлә белән Кәрләбикәне ашыгыч рәвештә ясарга кушылганда, аның кул астында ике кыска утын пүләне генә бар иде. Шуңа күрә курчаклар бик кыска буйлы булып, шундый исемгә ия булдылар.

Авылда агачка кытлык, алтын бәһасенә йөри. Өйләр дә утын белән генә җылытыла. Шуңа күрә сафтан чыгарылган курчакларны Фәрит абыйга истәлеккә дип үзендә калдырырга рөхсәт итмиләр, клубны җылыту өчен мичкә ягарга кушалар... Ул ясаган курчакларны беренче тапкыр мичкә олактырганда, моны күргән Фәрит абыйның «керәкләре» калтырап торды. Иренен нык кына кысып, уң як читеннән бер тамчы кан саркып чыкты. Бераздан күзеннән энә күзедәй әче күз яше тәгәрәде дә, кан саркып чыккан ирен читенә кадәр шуышып төште... Әле шуннан соң да Фәрит абый курчакларына җан җылысы бирергә

тырышты-тырышуын. Тик һәрберсендә ирен читеннән атылган җансыз канның эзе кала барды...

Кәрләбиканең уң як яңагын ай яктысы кытыклап алды. Зөһрә кыз, гүя көянтәсен читкә куеп, мөлдерәмә күзләре белән шушы ике курчакка гына карап тора.

— Кәрлә, өстән безне берәү карашы белән бораулый. Минем аны безнең тамашаларда күргәнем булмады.

— Минем дә, — диде Кәрлә.

— Ә ул шундый сары-ы-ы, — дип шаркылдады Кәрләбикә. — Кара, күзеннән тамчылар бөтерелеп чыга. Дөрес истә калдырган булсам, күз яше дип атала ул. Теге спектакльдә уйнаганда, өченче рәттәге бер егет янында утырган кызга, «күз яшеңне сөрт», диде. Ул вакытта кызның күзеннән нәкъ шундый чык бөртеге тәгәрәп төшкән иде.

Театрда һәр курчакның исеме бар. Аларны Фәрит абый куша. Аннары шул исемнәр белән яратып эндәшә үзләренә. Спектакль беткәч, курчакларның киемнәрен салдырып, тартмаларга бикләп куя... Ә бүген Кәрлә белән Кәрләбикәне тартма өстендә калдырып киткәннәр. Бүген алар тормыш тамашасы белән күзгә-күз беренче тапкыр таныша. Көннәр буе караңгы зинданда ятып, ут яктысын спектакль уйнаганда гына күрәләр. Кешеләрнең дә йөрәк уты тансык аларга. Тик кешедәге ул хиснең ничек аталганын белмиләр. Атна саен Фәрит абый курчакларын йонлач кулы белән караңгы тартмадан берәм-берәм чыгарып, тышкы кыяфәтләрен тикшерә. Төсе уңган булса, буйый. Уңмаган булса, сөйләшеп алган була шунда. Андый вакытта кешеләргә җансыз булып тоелган, әмма чынлыкта җанлы курчакларның йөзендә канәгатьлек чаткылары биешә...

— Әйдә, тегендә меник әле, — дип, өстәл янындагы тәрәзәгә ымлады Кәрләбикә. — Спектакль уйнаганда кырый күзем гел шул тәрәзә төбенә төбәлә иде. Шундый ымсындыргыч! Ни бар икән анда?

Курчаклар шыгырдавык аяк-куллары белән башта урындыкка менеп атландылар, аннары — өстәлгә. Өстәлдә теге пьесаның сызгаланган битләре таралып ята. Режиссер Марат абыйның сәер гадәте бар: ул спектакльләрнең сүзләрен гел үзгәртә. Шуңа күрә кайбер кешеләр бер үк спектакльне карарга бернична тапкыр килә. Чөнки һәр куелышы үзгә килеп чыга. Кәрләбикә бер биткә саксыз басып, таеп егылды да идәнгә гөпелдәп төште.

— Һи-и, кызык булды әле бу. Колагымда бертөсле аваз яңгырый. «Зы-ы-ы-ң», «зы-ы-ы-ың», дип.

— Бетәр, борчылма, — дип көлде Кәрлә. — Мен монда... О-о-о, — дип авызы «о» хәрефе булып ачылды курчакның.

— Нәрсә бар? — дип кабалана-кабалана шыгырдавык аяклары белән менә торды Кәрләбикә.

— Бөтен дөнья... ап-ак. Каян алдылар икән шулкадәр мамык? Җитмәсә, өстенә вак таш сибеп чыкканнар. Шундый матур итеп җемелдиләр. Теге спектакльдә, мин сине кулыңнан тоткач, күзләрең нәкъ шушы ташлар сыман ялтырый, — диде Кәрлә.

— Марат абый артистка: «Кәрләбикәнең күзләрен ялтырат!» — дигәч, ялтыратам инде — диде Кәрләбикә.

— Нинди сүзләр әйткәндә шулай эшли әле күзләрең? — дип сорады Кәрлә.

— ... Исемдә түгел. Күптән уйнаган юк бит инде, — диде Кәрләбикә.

— Кара, тегендә ике кеше тора. Берсенең башында бүрек, икенчесе яулык каплаганмы соң?

— Егет белән кыз диген инде. Хи-хи-хи. Бүрек белән яулык дигән була, хәсрәт төенчеге, — дип, ирен читләре кыяр-кыймас кына җәелде Кәрләбикәнең

— Мин бит, сиңа караганда, спектакльләрдә күбрәк катнашам, шуңа күрә күбрәк сүз беләм... Кара, кочаклашалар. Кара-кара, безнең кебек кулга-кул тотынышалар. Ләкин спектакльдә мин сине этеп җибәрәм. Кәрлә, дөресен әйткәндә, сине никтер этәсем дә килми. Марат абый кушканга гына шулай эшлим...

— Ай кызы хәзер безгә түгел, егет белән кызга бага, — диде Кәрлә, Кәрләбикәнең сүзен колагы аша үткәрмичә.

— Ә син тегеләргә күз сал. Кызның күзләре мамык өстендәге таштан да ныграк ялтырый. Их-х, минеке дә шулай җемелдәсен иде-е-е! — дип, шыгырдавык аяклары белән үзе тирәли әйләнә башлады Кәрләбикә.

— Бәлки, безгә дә спектакльдә шулай кочаклашыргадыр? Нык иттереп! Нык-нык! — диде Кәрлә.

— Нык иттереп кыссаң, бәбәкләрем атылып чыгачак бит. Хи-хи-хи. Алай түгел... бүтәнчә кирәк. Сүзен таба алмыйм... Аңлыйсыңмы?

— Аңларлык әйбер әйтмәдең дә бит.

— Кирәкми, кочаклама алай. Марат абый кушмады. Кушмагач, алай эшләргә ярамый, — дип кырт кисте Кәрләбикә.

Кәрлә белән Кәрләбикә ап-ак манзарага хозурланып утыра. Икесенең дә йөзендә ай яктысы. Күзләрендә, әйтерсең, янгын: дөрли, котыра, ажгыра. Ләкин курчаклар үз карашларында нәрсә барлыгын сизми дә. Бер-берсенә дә карамыйлар... Кинәт Кәрләбикә кулын тәрәзәгә тидерде.

— Бер көнне безнең спектакльгә бер тиктормас малай килде. Әнисе мәҗбүри китергән иде инде. Шул малай, спектакль карарга теләмичә, залдагы тәрәзәгә кулын тидереп, суык бабай ясаган бизәкләрне эретеп утырды. Ә менә мин тидергәч, эреми, — дип авыз турсайтты Кәрләбикә.

— Бәлки, кулыңны яндырып җибәрергәдер? — диде Кәрлә.

— Ә ни өчен теге малай тәрәзәдәге бизәкләрне кулын яндырмыйча эретә алды соң? — дип гаҗәпләнде Кәрләбикә.

— Бәлки, аның эчендә ут янадыр?

— Ә ник безнекендә янмый? — дип гаҗәпләнүе арта барды Кәрләбикәнең.

— Чөнки без курчаклар, — диде Кәрлә.

— Беләм! Беләм, без курчаклар! Без курчаклар! Без курчаклар! — дип бер урында сикергәләде Кәрләбикә. — Ә минем курчак буласым килми! Минем тәрәзәдәге бизәкләрне эретәсем килә. Ай кызы тегеләргә карап әнә ничек елмая. Ә безгә алай карамый... Безгә... сагышлы... И, каян, ничек чыкты бу ят сүз минем авыздан?! Кайсыдыр спектакльдә әйткән булганмындыр инде...

Урам уртасында кочаклашып торган кыз белән егет аяк астындагы карны туздыра-туздыра әкрен генә атлап баралар. Хәтта күз ачып булмаслык итеп тоташ яуган кар да салмак кына төшә. Аста да, өстә дә аклык хакимлек итә. Мәхәббәт ике дөнья арасында бөтерелә. Әйтәләр бит, иң көчле мәхәббәт кыш көне туа, дип. Ул җиргә сеңми, чөнки туң туфрак аша үтә алмый. Мәхәббәт хисе күккә дә очып китми, баһадир болытлар аны тышка чыгармый. Зөһрә кыз мәхәббәт ияләрен офыкның теге башына чаклы назлы карашы белән иркәләп озатты. Һәм, хушлашырга теләгәндәй, күк йөзенә киң кызыл тасма сызды... Тасма торган саен тарая, тарая барды...

— Кәрләбикә, әйтим әле!

— Әйт, — диде Кәрләбикә.

— Ялгышмасам... Ничек әле ул?.. Ә! Мин сине яратам!

— Анысы ни дигән сүз?

— Белмим. Ләкин кичә Марат абыйның кулында пьеса күрдем. Тышында «Мин сине яратам!» дип язылган иде. Хәрефләре шундый зу-у-ур, шундый мат-у-ур. Шулвакыт әчем яна башлады кебек... — диде Кәрлә.

— Бәхетле! Димәк, син тәрәзәдәге бизәкләрне эретә аласың!
— Юк, минем ул җылыны сиңа бирәсем килә.
— ...
— Марат абый Фәрит абыйга: «Мин сине яратам!»га яңа курчаклар әзерлә! Кәрлә белән Кәрләбикәне утынга җибәрербез, — диде.
— Безне пенсиягә чыгарырга җыеналармы әллә? Кешеләр үзләрен «утынга җибәрүләрен» шулай дип атый бит, ахрысы? — диде Кәрләбикә.
— Пенсиягә чыккач, кеше яши, ичмасам... Ә безне ни кө...
Имән ишекнең шыгырдап ачылганы ишетелде. Фәрит абый керде. Бүген клубта кунган.
— Ah-h, салкын!!! Корт чаккыры! Төне буе суык бабай белән көрәшеп чыктым. Мичне ягып җибәрми булмас. Кичә үк ягарга дип йөри идем. Кая соң әле теге курчакларым? — дип, Фәрит абый тартмалар янына атлады. Курчакларның барысы да үз урынында, тик Кәрлә белән Кәрләбикәнең генә тартмалары буш. Анда инде салкынлык оялаган. Фәрит абый бәсләнгән күзлеге аша өстәлгә бакты.
— Бәрәч, каян килеп чыктылар икән болар монда? Артистлар калдырдымы әллә? Маратка әйтергә булыр әле, яшьләрең курчаклар белән саграк кылансын, теләсә кайда калдырып йөрмәсеннәр, дип. Инде яңаларын әмәлләп бетереп киләм. Ә боларын... Мичкә, диделәр... Ярарсана, бер яхшы ягы да булыр — суык бабайга «хана» күрсәтәчәкмен! О-о-х, тешләр дә шыгырдый башлады инде.
Фәрит абый, бозланган күзлеген салып, Кәрлә белән Кәрләбикәгә сынаулы карашын ташлады. Күз алдында теге ике кыска утын пүләне. Ул вакытта куллары көрәк кадәр түгел иде әле Фәрит абыйның... Җәй. Останың маңгаеннан борчак-борчак тир тага. Марат абый: «Курчакларың иртәгәгә әзер булсын!» — дип ашыктыра. Фәрит абыйның хәтта эчендәге бүреләрен дә тынычландырырга вакыты юк. Кулына нәзек пумала алып, ювелирларча саклык белән Кәрлә һәм Кәрләбикәнең күзләрен зәңгәр төскә буяганда, ирен читен ныграк кысып куйды да... Кан сауды... Фәрит абый, уйларыннан айнып киткәндәй: «Бу мәкерле бабайны нишләтергә икән? Маңка да ага башлады менә, корт чаккыры», — дип ныгыттырып кына маңкасын тартты. Менә бит, Кәрләбикә дә белде аның ни икәнен. Ачыш! Кәрлә ишеттеме икән? Кәрләбикәнең елмаясы килде, әмма Фәрит абый янында ярамый. Курчаклар үзара һәм үз-үзләре белән генә сөйләшә ала. Зинданда, ялгызлыктан ычкынып, үз-үзе белән сөйләшүче курчаклар бик күп. Фәрит абый томанлы карашын читкә ташлап, елмаеп торды, торды да... «Их-х» дип кулын селтәп, Кәрлә белән Кәрләбикәне култык астына кыстырды...
— Мин сине яратам! — диде Кәрлә Кәрләбикәгә, зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп. Карашында кояшның тәүге нурлары чагыла иде. Бернинди пьеса сүзе белән дә аңлатып бирә алмаслык тирән хис. Ул хис мамык өстенә сибелгән ташларда да бар. Кәрләбикә күзен челт-мелт китерде дә... берни дәшмәде... Фәрит абый авыл халкын еларга өйрәткән «Җансызлык» спектакленең җанлы курчакларына: «Бәхил булыгыз!» — диде.



# Ләйлә Хәбибуллина

*Мин максатчан, гаделлекне һәм ихласлыкны яратучы кеше. Үземне хәтерләгәннән бирле җырга-моңга гашыйкмын. Татар һәм чит ил әдәбиятын яратып укыйм. Милли стильдә эшләнгән киемнәргә, бизәкләргә, гомумән, халкыбызның күңел нечкәлекләрен чагылдыручы бернигә дә битараф кала алмыйм.*

* * *

**Юксынулар җанга суык өсти...**
**Без булмаган язны сагынам.**
**Кояш уйнап, күз камашыр иде**
**Тәрәздәге пәрдә агыннан.**

**Кара төшкән ак битләрне, уйнап,**
**Өстәлемә җилләр таратыр.**
**Сөймәсәң дә була мине, бары**
**тик үзеңне генә яраттыр.**

**Яңгыраган җырдан сине эзләү**
**Сагышланган җанны юатыр.**
**Үзем генә төнге юллар иңлим,**
**Икебезгә, бәлки, таң атыр.**

**Йөрәгемдә сине саклап йөртәм**
**Язмышларның текә ярыннан.**
**Юксынулар җанга суык өсти...**
**Без булмаган язны сагынам.**

## Тик син генә

**Йөрәгемне телгәлиләр хисләр,**
**Якты уйлар кинәт сүрелде.**
**Хәтта сиңа, әни, ача алмыйм**
**Бикләнелгән олы серемне**

**Аңлыйсың да,беләм... Тик куркамын**
**Рәнҗетергә сине ялгышып.**
**Бушанганчы бер елыйсы иде,**
**Сабый сыман сиңа елышып.**

**Һәрбер сүзең җанга дәва минем.**
**Югалалар уйлар – кирәксез...**
**Ә мин үзем–бер рәхмәтсез бала,**
**Үпкәләтәм сине сәбәпсез.**

Елмаюлы караш җитәр иде
Җан җылысын салган аңарга.
Мең табышмак чишү кирәк, ахры
Күңелемне минем аңларга.

Сүзсез генә укып уйларымны,
Күңелемә дәва саласың.
Кайгыларны якын китермисең,
Саклагандай күзең карасын.

Тик син генә, әни, кичерәсең
Минем кылган барлык гамәлне.
Мөмкин булса, җыеп бирер идем
Бөтен яхшылыгын галәмнең.

## Сагыш...

Иреннәргә елмаюым әлеп,
Җан ачысын тышка чыгармам.
Кемнәр генә, әйтче,Җир йөзенә
сагыш хисен уйлап чыгарган?

Кемнәр генә,әйтче, кешеләргә
бүлеп–бүлеп бәхет тараткан?
Бераүләргә өеп биргән чакта,
Нигә алар мине оныткан?..

Кемнәр генә,әйтче, тормышларга
Шул кадәрле серләр яшергән?
Хисләремнән давыл кузгатырлык,
Гөлләр үстерерлек яшемнән.

Елмаюым йозак итеп әлеп,
сагышымны тышка чыгармам.
Дәшмәвемне ишетергә өйрән —
башка синнән берни сорамам...

## Тик үтеп барышым

Мин сине күрмәдем, сизмәдем карашың –
Минем бит яныңнан тик үтеп барышым.
Текәмә күзләрең, ялварып сорама.
Тимәче яңадан ачылган ярама.
Эзләмә җаваплар, нур сүнгән күзләрдә.
Ничәмә кар яткан, без салган эзләргә.
Язмачы хатларың – укымыйм аларны.
Кайтарма үткәнне. Мин бары яраттым...
Яратсам?! Бу сөю – язмышның каргышы....
Шуңадыр, яныңнан тик үтеп барышым...

## Без булмаган яз

Юксынулар җанга суык өсти...
Без булмаган язны сагынам.
Кояш уйнап, күз камашыр иде
Тәрәздәге пәрдә агыннан.

**Кара төшкән ак битләрне, уйнап,**
**Өстәлемә җилләр таратыр.**
**Сөймәсәң дә була мине, бары**
**тик үзеңне генә яраттыр.**

**Яңгыраган җырдан сине эзләү**
**Сагышланган җанны юатыр.**
**Үзем генә төнге юллар иңлим,**
**Икебезгә, бәлки, таң атыр.**

**Йөрәгемдә сине саклап йөртәм**
**Язмышларның текә ярыннан.**
**Юксынулар җанга суык өсти...**
**Без булмаган язны сагынам.**

## Нәни йөрәк

*Синең нәни генә йөрәгең минем*
*өчен бик кадерле.*

А.Мансуров

**Нәни генә йөрәк...**
**Күпме сыйган анда**
**Олылары тәүге хисләрнең.**
**Иң түренә**
**Бөртек–бөртек җыйган**
**Иң–иң матурларын төсләрнең**

**Нәни генә йөрәк...**
**Җиһан яктылыгын**
**Әйтерсең лә үзенә туплаган.**
**Меңәр кабат**
**Телгәләнгән дә ул,**
**Меңәр кабат янып туктаган.**

**Мәңге типсен,**
**Мәңге дөрләп янсын**
**Синең нәни генә йөрәгең.**
**Бар күңелең белән**
**Тоеп яшә**
**Шул йөрәкнең миңа кирәген.**

## Чәчәк булыр идем

**Мин бер чәчәк булыр идем...**
**Никтер ап–ак төстә.**
**Бер гүзәл кыз**
**мине дәфтәр арасыннан**
**алган саен,**
**сөйгән ярын төшерер иде искә.**
**Миңа карап, якты хатирәләр**
**сафландырыр иде**
**соры көнелләрне.**
**Кояш кебек ихлас елмаюлар**
**бизәр иде гади көннәрне.**
**Мин бер чәчәк булыр идем...**

Тик...
булып бик нәзберек,нәфис,
явыз куллар өзеп китсәләр?!
Һәм...
ачылмыйча калган
таҗлар минем
аерым-аерым җилдә кипсәләр?!
Минем якты хисләр,уйлар
Җирдә кабат шыта алмаса?..
Сөенеп,елап
искә алыр өчен
бер хатирә хәтта калмаса?..
Юк-юк!
Бу уйларым әле куеп торыйм.
Алар хәзер кирәк түгел һич тә!
Мин бер чәчәк булып
шытыйм әле ошбу кичтә.
Нәкъ менә ак төстә...

***

Акрын гына
җәй дә ахырына таба:
моңсурак кояш,
ярымкөзге һава...

Тик әлегә миңа
көзләремә иртә.
Минем юллар әле
Яшьлек аша үтә.

Минем юллар әле
гел җәйләргә илтә.
Йөрәгемдә җылы,
чыклы җәйге иртә...

...Сүлпәнрәк кояш,
яртылаш көз тышта.
Ашыкмагыз! Миңа
җәйле тукталышка.

***

Күпме сүзләр әйтелмичә,
Күпме шигырь язылмыйча
калды...
-Җиңелме?!
-Юк! Шундый авыр миңа.
Уйлар талды...
Эзләнүдән.
Күңелдән яшь тама.
Хисләр ачылмады.
Җавап табылмады.
Гомер ага...

Ә мин һаман
Сарган томан арасыннан
Сине эзлим.
Кыйпылчыктан яраланган
Йөрәк түзми...
Ватыклардан бәхет төзим.
Килеп чыкмый,туры килми!
Уйлар талды...
Күпме сүзләр әйтелмичә,
Күпме шигырь язылмыйча
калды...

***

Әрнеп-әрнеп куя сизгер йөрәк,
Күңел тулы мөлдерәмә хисләр белән.
Ә мин сине төнге урамнардан
Тын һаваны ерта-ерта эзләп киләм...

* * *

Мин бәхеттән сиңа таган ясап,
ай очына элеп куярмын...
Төннәреңне сагышлардан урлап,
Бәхет төсләренә буярмын.

Факил
Сафин

# ТУЛГАН АЙ

БӘЯН

## I

Мәктәптән кайтып җитәргә өлгермәдем, артымнан бастырып кышкы эңгер куып җитте. Җәй көннәрендә бу вакытта офык итәге әллә кайда, Агыйдел аръягында шәйләнсә, хәзер күгелҗем офык чиге Үмер урманына ук төртелеп тора. Үмер урманы безнең Әмәкайдән өч-дүрт чакрым булса булыр. Кышкы салкынча көн, күксел тынлыкны оетып кына кар бөртекләре төшкәли. Юл ак җәймә ябынып өлгергән. Ак канатлы кар бөртекләре шул кадәр җиңел: аяк җиленә дә сизгерләр, атлаган уңайга, калын олтанлы киезитек астында калырга теләмичә дәррәү читкә сибеләләр, үртәп шаярырга теләгәндәй киезитеккә килеп сырышалар, итек йөзенә өелеп барган булалар да янә кышкы сукмакка сикерешәләр. Җиңел, рәхәт көннең тәэсиреме, җанда күңелле җилкенү тоям. Өйдә мине ниндидер сер көткән сыман. Күңел алгысынуына бирешеп, адымнарны кызулый төшәм, җәһәт кенә җилкапканы ачып, ишегалдына керәм.

Өч яшькә олырак Камил абыем инде кайтып җитешкән икән, мәктәп киемен алыштырып та тормыйча, ишегалды түреннән урам капкасына табан агач көрәк белән кар көри. Кыска пәлтәсенең төймәләре ычкынган, ул селтәнгән җайга кып-кызыл галстугының ике очы җилпенеп–талпынып торалар. Ашкынып кайтуым шуның өчен икән, эш көтеп тора мине монда.

Мине күреп алуга, көтеп торган сыман, Камил абый көрәген бер читкә ташлап, кул изәп, үз янына чакырды. Хәзер йөгереп барам ди! Миңа карны көрәп бетерергә куша да, үзе каядыр чыгып олагырга чамалый инде. Төлкенең дә иң хәйләкәре, ди аны әнкәй кайчак, кисәк гаип булу маһирлыгына шаккатып. Башта киемнәрне алыштырыйм, капкалап алырга кирәк, эшкә өлгерермен әле. Шуңа күрә, Камил абыйның кул изәвен күрмәмешкә салышып, тизрәк өйгә атладым.

— Фирүз, дим, Фирүз! Кил әле, бер нәрсә күрсәтәм.

Һе, күрсәтерсен инде, беләм, минем кулга көрәк тоттырып, үзеңнең урамга чыгып шылу кайгысы синдә. Шулай да нидер бар кебек. Башка вакытта булса: «Кил, бер нәрсә бирәм», — дип юмалый торган иде. Бүген икенчерәк такылдый, нидер күрсәтмәкче әнә. Кызыксыну җиңде, ишеккә үрелгән кулны кире алып, Камил абыйга табан ике-өч адым атладым.

— Нәрсә күрсәтәсең? Кай арада кайтып җиттең, дәресләр тәмамланганга кайчан гына.

— Озын тәнәфестән соң безне кәнсәгә утын кисәргә җибәрделәр. Равил белән. Эһ иткәнче ярты ат йөге әрдәнә кисеп ташладык. Хафизә апа ташып өлгерә алмый изаланды. Бусы пүчтәк аның, кил әле, бер нәрсә күрсәтәм...

Сумканы баскыч төбенә ташлап, ирексездән Камил абый янына киттем. Күңел сизенә, нидер бар, төрледән төрле хикмәт эшләргә аңа гына куш. Әле бөркөнне тарих дәреслегеннән дошман ауларына каршы таш аткыч җайланма

— ыстан турында укып алган да, әткәйнең йөк бауларын алып чыгып, тактадыр, киртәдер юнәтеп, шул ыстанга охшаган бер нәмәрсә эшләп мәш килде. Кичкә кадәр маташкач, таш аткыч җайланма әзер дә булды. Дүрт почмаклы зур гына тартманы хәтерләтә иде ул. Инде аны сынап карарга кирәк. Кыш көне таш каян табасың ди. Башка бер җаен чыгарырга кирәк. Камил абый ыстанны мунча ягына каратып, калакка ошаш аткычны артка каерып, миңа шулай гына тотып торырга кушты. Карап торуга гына җиңел сыман, нык тартыла бу, көч-хәл белән каерган хәлдә тотып торам. Үзем алай бөтенләй хәлсез малай да түгел мин... Шуннан шул, Камил абый утын өеме астыннан ярылмый калган юантык каен бүкәнен өстерәп чыгарып, ыстан уртасында тырпаеп торган калак башына терәп үк тотты һәм, тирән тын алганнан соң, кисәк кенә:

— Ычкындыр! — дип, фәрман бирде.

Кулымны җибәрүем булды, калак алга чөелде, Камил абый тотып торган бүкән туп урынына атылып та китте. Баштагы мәлдә сызгырган тавыш кына ишетелеп калды, бүкән мунча тәрәзәсен шалтыр иттереп, эчкә кереп юк булды. Аптырап, һуш-акылны җыя алмый тора идем, Камил абый, канәгатьсез хәлдә, мунча эченнән килеп тә чыкты. Кулында каен бүкәне.

— Ләүкә астыннан табып алдым. Тәрәзә пүчтәк, бүкән мич авызын җимергән, — диде ул, шиңгән тавыш белән. — Әткәй кирәкне бирә инде. — Аннан бөтен гаепне миңа аударгандай, өстәде. — Нишләп мунча тәрәзәсенә төзәдең тупны, абзар ягына җибәрсәң, чуртым да булмый иде...

— Үзең бит.. Ни кыланганыңны белмисең. Әлләниләр уйлап чыгарасың да, кешене гаепле итәсең.

Камил абый бозлы бияләе белән минем бүрекнең кашына чәпәп алды.

— Үзең, үзең... Уйларга кирәк иде, син бит төзәүче — наводчик, мин бүкән куеп торучы, ягъни мәсәлән тупны коручы — заряжающий булам. Тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка атмыйлар аны, энекәш!

Әткәй сугышта тупчы булган, җае чыга калса, безгә сугышта күргәннәрен сөйләп, хәтерен яңартып ала иде, шуңа күрә артиллерия, туп дигәндә, бераз чамасын белеп сөйләшәбез. Әмма Камил абыйның бөтен гаепне миңа аударырга маташуы кәефне нык җибәрде ул көнне.

Әткәйнең эштән кайтканын шөбһәләнеп кенә көтеп алдык. Мунча тәрәзәсен кырган, мичен ишкән өчен рәхмәт әйтмәде инде, билгеле. Алай гаеплеләрне сораштырып вакыт та әрәм итмәде, өлешне икебезгә дә тигез чыгарды. Әле шаукымы һаман да бетеп җитми. Шуңа күрә кызыксыну җиңсә дә, бүген Камил абыйның ниндидер серлелек белән үз янына чакырып алуына артык ышаныч багламадым...

— Ни хикмәт уйлап таптың тагын? — дидем, җәелеп китмичә. Бу сүзләрне әткәй әйтергә ярата иде.

Камил абый, елмаюын яшерә алмый, мунча алды ишеген ачып җибәрде.

— Кил, әйбәтләп кара! — диде ул,пышылдый төшеп.

Түр почмакта нидер кыймылдаган кебек. Эчкә үткәч, егылып китә яздым: каршыма туп кадәр генә сап-сары көчек йөгереп чыгып килә. Ничек өстенә китереп басмаганмын диген. Йомшак йомгак шикелле җан иясе. Ул миңа, мин аңа хәйран калып карашып торабыз. Менә ул мунча эчендәге караңгылыктан курыккан сыман, кыска койрыгын болгап, еламсыраулы аваз чыгарды.

— Кем бирде? — дип, көчекне кулларыма алып, түшемә кыстым. — Туңып беткән бит бу, дер-дер килә әнә.

— Һе, аның туны җылы, әле мин аңа сөт бирдем, — диде Камил абый, минем һуш җыя алмыйча торуыма куангандай. — Равил бирде. Кичә Карамалыга барган икән, туганнары биреп җибәргән бу көчекне. Әткәсе Нуретдин абзый риза булмаган, чыгарып ташларга куша икән. Үзебезгә алып кайттым менә.

Шундый да матур көчекне ничекләр яратмыйсың инде. Кара кучкыллы

борыны белән минем бияләйне исни, күкрәгемә төртеп ала, күзләрен челт–челт йомгалап әле миңа, әле Камил абыйга күз ташлый, үзе шундый йомшак, җылысы кулга бәрелеп тора. Шулай сөенеп бетә алмадым, күңел күгә чүгеп куйды.

— Әткәй ни әйтер? Әнкәй беләме?

— Әнкәй күрде инде, элек аларның умарталыгында шундый эт тә булган әле. Тулганай исемле иде, ди. Сөтне әнкәй үзе салып бирде. Әткәй белми әле. Мин иске тәпәннән оя ясадым, мунча алдында тора. Әткәйгә әйтми торыйк, аннан күз күрер. Кара әле син аңа, йомарланып ятуын әйтәм, чыннан да сап–сары тулган ай диярсең! Әйдә исеме дә Тулганай булсын!

Камил абый сөйләргә оста инде ул. Әмма Тулганай дигәненә генә күнегеп булыр микән? Безнең авылда этләр «Шарик» та «Тузик». Бөтенләй ят исем һәм бу исемдә нәрсәдер бар да сыман...

— Һай-һай, — дидем күңелсезләнеп, — әткәй эт асрарга ризалык бирер микән? Моңарчы тотмаганны.

— Этсез булмый, — диде Камил абый кем беләндер бәхәскә кергәндәй. — Күрәсеңме, янбакчада алмагачлар үсеп килә. Үткән яз чәчәк аттылар, бер-ән-сәрән алмалары да булды. Мондый тәмле алмалар тирә-якта юк, дип сөенеп йөрде әткәй. Инде көч җыйдылар, киләсе җәйдә ботаклары сыгылып торачак, ди әнә. Аны кем саклар дип беләсең? Бер төн эчендә ботарлап бетерәчәкләр бакчаны. Быел ук кереп чыктылар инде.

## II

... Иртән әткәйнең ачулы тавышына күзне ачтым:

— Кайсысы көчек кундырды мунча алдында?

Сорау әнкәйгә бирелгән иде, җавап көттермәде.

— Малайлар кичә бер көчек күтәреп йөриләрие. Әллә мунча алдында оя тапканмы? — Әнкәй тавышы йомшак иде. — Бик матур көчек ие ул. Мин бәләкәй чакта безнең дә нәкъ шундый этебез бар ие. Караклар умарталыкка төшкәндә кистән белән харап иткәннәр. Берсен умырып алган, үлгәндә дә җибәрмәгән, каптырдылар угрыларны.

Әнкәйнең ни әйтергә теләгәнен әткәй ярты сүздән аңлап алды бугай. Ачуы сүрелә төште.

— Көчек чакта матур була ул эт җәнлеге. Үскәч, бөтен ишегалдын б... батырачак. Чыгарып атсыннар!

— Кирәге булыр, мин әйтәм, атасы. Бакча киңәя бит. Үткән җәйдә яшьләр ботарлап чыктылар бакчаны. Өч-дүрт алма кызарып утыра иде. Шуңа да кызыкканнар, явызлар.

— Эт белән генә җиңәрсең ул мәлгуньнәрне! Мылтык кирәк аларга.

— Һе, әнә Түбән оч Һади мылтык атып карады инде. Ярый әле кешесе исән калды, юкса төрмәдә башы черисе иде. Ел саен пешеп торасы алма өчен кеше гомере әрәм итәләр ди. Кая акылың?

Әткәйнең бирешергә исәбе юк. Без Камил абый белән тын алырга да куркып ятабыз. Бәхәстә кем өстен чыгар?..

— Юк, юк, карчык, бала-чага сүзен сүләп торма, эт асраган булып, эт оясын чистартып, исен иснәп йөрисем юк? Чыгарып җибәрсеннәр!

Әнкәй сүз көрәштерүдән ялыкты, ахры. Ничектер, безне хәйләләгән сыман:

— Ярый, малайларга әйтермен. Бар, шул көчеккә җылы сөт эчереп кер әле. Урамга чыгарып җибәргәч, безгә рәнҗеп йөрмәсен. Эт рәнҗеше бик нык төшә ди бит ул. Әнә безнең этне сугып харап иткән угры Мәрдине Кәҗә авылы урыслары кыйнап үтерделәр. Берсенең келәтенә төшкән булган.

Әткәй ризасызлык күрсәтеп, сөйләнә-сөйләнә чыгып китте. Без Камил

абый белән юрган астыннан идәнгә атылдык. Беравыздан әнкәйгә ялына башладык:

— Әнкәй, ныгытып әйт инде әткәйгә, үгетләп кара, көчекне бездә калдырсын. Исемен дә куштык — Тулганай ул, — диде Камил абый.

Әнкәйнең күзе дымланды.

— Ишетеп яттыгыз бит инде, көчекне бер дә чыгартып җибәрәсем килми. Әткәгез тагын ни әйтер, әлегә бик каршы тора, — диде әнкәй, һәм мич алдында җырлап утырган самавырның капкачына кунган көлне «әф–фң» итеп өреп төшерде дә, җиңелчә генә күтәреп, өстәлгә дык иттереп китереп куйды. Ни беләндер риза булмаса шулай эшли ул. — Атаңа каршы килеп кара син, бер кирегә сукалый башласа...

Әнкәй сүзен әйтеп бетермәде, ишек шартлап ачылды, әткәйнең ачулы йөзе күренде.

— Явыз, ничек кылана бит! Эттән эт тумый нәрсә тусын!

— Нигә чәпчисең, шөпшә таладымы әллә? — диде әнкәй, эшнең кирегә киткәнен аңлап. Инде әткәйне көйләп торуның файдасы юклыгы күренеп тора.

— Нәрсә булсын, эт талады! — дип әткәй, өскә чөелгән канлы баш бармагын әнкәйнең йөз турысына китерде. — Савытына сөт салдым, чап-чап китереп эчә, шунда, күңел йомшарып, башыннан сыйпыйсы иткән идем, сизми дә калдым: «Һәү-үң» килеп өргәндәй итте дә, баш бармагымны тешләп тә алды. Чыгарып җибәрсеннәр, малайларга әйт. Хәерсез нәрсә булган бу. Эт — иясен симерсә генә тешли диләр ие, ә бу тумас борын гадәтсезләнеп бара. Кая, чүпрәгең бармы, бәйләп куй тизрәк. Эт тешләгән яра тиз генә төзәлми дә бит әле ул.

Камил абыйның да, минем дә ирексез күз яшьләре атылып чыкты. Әткәйнең кан саркып торган баш бармагын бик кызгансак та, чынлыкта Тулганайны жәлләп елый идек. Шул сары йомгактан калсак, дөньяның бер яме бетәр иде безгә. Һи, сантый көчек килешмәгәнне кыланып ташлаган шул. Инде әткәйне кире чигендереп кара!

Әнкәй, безгә күз ташлап алгач, әткәйне тынычландырырга кереште:

— Йә инде, кыш көне ничек куып чыгармакчы буласың шул җан иясен? Каргышы төшеп куяр, мин әйтәм, карт. — Бу «карт» сүзен ул бик сирәк әйтә. Моны ишетсә, әткәйнең маңгае кызарган кебек тоела безгә. Шундый тылсымлы сүз иде бу аның өчен. — Ике улыбыз тупырдап үсеп киләләр. Бала вакытта эт белән әвәрә килә инде малайлар, борынгыдан калган. Әллә нигә үземә дә матур булып күренде ул... Исемен дә тапканнар бит — Тулганай, ди.

— Әнкәй каяндыр ак чүпрәк табып, аны тасма итеп телеп алды да, яралы бармакны шытырдатып бәйләп куйды.

Әткәй күтәрелеп бәрелмәде, йөзен чыта төшеп, тырпаеп калган бармагына караш ташлап алгач:

— Калса калсын инде, — диде сүрән генә. — Үзенекен бирмәскә маташуы әйбәт, тик беренче эш итеп хуҗасын тешләргә тотынуы яман.

Болай булгач, әнкәй җиңде! Үзен этнең хуҗасы дип танытмакта бит әткәй.

— Белмәгән бит ул, белми... бәләкәй шул әле... — диде Камил абый ашыгудан сулышы кабып.

— Белмәс, эт бик сизгер була ул. Көчек дигәч тә, анда эт җаны. Өйдә кем хуҗа икәнен әллә каян сизеп ала. Бу исә — усаллаша.

— Үзен өнәп бетермәвеңне сизгәндер, карт, — диде әнкәй, сүзен аяк астына салып таптамавына күңеле булганын сиздереп.

Камил абый кай арада чыгып киткәндер, көчекне күкрәгенә кысып, әткәй каршына килеп басты:

— Күр, кара, бел моннан соң, Тулганай, бу - әткәй, синең дә хуҗаң булыр. Моннан соң ялгышып та тешли күрмә!

Тулганай гөнаһсыз күзләрен елтыратып әле түшәмдәге утка, әле безгә карап ала. Авызын зур ачып, кызыл юка телен чыгарып, иреннәрен ялмап мәшәләнде. Ул шактый тавышка китергән, үзенең язмышын кыл өстендә калдырган бармак вакыйгасы хакында уйлап та карамый инде, оныткан да, ахры.

— Һи, кыланмышы, — диде әнкәй, көчекнең муен тирәсеннән сыйпап.

Әткәй йөзен сытты.

— Төчеләнмә, эт — эт инде ул. — Аннан Камил абыйга каршы килмәслек итеп кистереп әйтте. — Моннан соң өйгә алып керәсе булмагыз! Кышкы салкыннар үткәнче мунча алдында торсын да, язга чыгуга келәт артына бәйләп куегыз. Бәйдә токкан эт кенә усал була. Бакча сакларга, дисез бит. Болай, эре сөякле нәселгә охшаган...

Безнең башлар күккә тиде.

## III

Март башларында Тулганайның муенына бау тагып, урамга алып чыга башладык. Безнең арттан калышмый йөгерә, сикерә, уйный. Шактый үсте үзе, әмма киноларда күрсәткәнчә бозау кадәрле үк булмаячак, ди әткәй. Таманча эт буласы, ди.

— Бик бәләкәй булуы да әйбәт түгел, бәләкәй эт һаман көчек була ул, ашау да уен гына булсын аңа. Бакча сакларга нәкъ шушындый эт кирәк, — ди ул, аягына сырышып чәү-һаулап йөргән Тулганайга карап. — Исәя бу, көннән көн алга табан!

— Чын сак эте ул, — дип шаулашабыз Камил абый белән. — Без мәктәп капкасыннан чыгуга, шуны белеп өрергә тотына. Күршеләрне дә, үзләрен күргәнче үк, әллә каян танып ала. Аларга өреп тә карамый, чит кешегә ярты чакрымнан сөрән сала, — дип, Тулганайны мактарга тотынабыз.

Каршы як күршебез Кәлимулла абзый сугыш вакытында этләр өйрәткән икән.

— Этка мина бәйләп куя идек тә, немеч танкысына каршы җибәрәбез, җиргә сылашып бара-бара да, танк килеп җитәрәк кенә дәррәү күтәрелеп, аның астына ташлана. Эт тә юк, танк та юк..., — диде, ул беркөнне үкенечле итеп. — Сугыштан кайткач, эт асрамакчы булып карадым. Булмый, танк астына ташланган мәхлуклар күз алдына килә дә баса. Күпме дошман танкын юк иткәннәрдер, күпме безнең солдатларның гомерләрен саклап калгандыр алар, санап карауч бар микән? Юктыр, сугышта үлгән кешеләрнең дә исәбенә чыга алмаганны. — Аннан сүзне икенчегә борды. — Эттә кеше акылы бар анда. Сөйләшә генә белми. Аннан файда күрәсегез килсә, кечкенәдән үк яхшы гадәткә өйрәтергә кирәк. Үскәч соң була. Тулганайның нәкъ акыл җыя торган чагы менә.

— Ничек өйрәтик соң? — диде Камил абый, әңгәмә җебен элэктереп.

— Иң элек Тулганай сезнең гаиләдәге урынын белергә тиеш. Кемне хуҗасы итеп тоя — шуңа карап башкалар белән хисаплаша. Ул Фирүзне хуҗа итеп танысын, ул чакта калганнарыгызны санлый торган була. Зурракларны хуҗа итеп таныса — Фирүзне тыңламый торганга әйләнә. Дөньяның шундый хикмәте бар аның. Утырып торырга өйрәтегез. Сезне утырган хәлдә тыңларга өйрәнсен. — Безгә күңелле булып китте, Тулганайның тыңлап утыруын күз алдына китереп, авызлар колакка кадәр ерылды. Кәлимулла абзый моны чамалап, орышкандай итте. — Көлмәгез, гел сезнең белән маташырга вакытым юк, иң элек үзегез тәртипле булыгыз, тыңларга өйрәнегез. Тәртипсез кешене эт санлап та карамый ул. Колагыгызга киртләп куегыз — һәр хәрәкәтегезне игътибар белән күзәтә белсен, шуңа күнектерегез. Фәкать дус дип таныганнарга гына, исәнләшү билгесе итеп, ал тәпиен бирергә өйрәнсен. Сез еракка ыргыткан әйберне эзләп табып,

кире китереп бирергә өйрәнсен. Күрерсез, көннән көн һөнәре арта аның. Иренмәскә генә кирәк.

Иренмибез, билгеле. Кәлимулла абзый әйткәннәрдән дә артыгын өйрәтәсе килә. Аның кыланмышларын күреп, башка малайларның һушлары китә. Бер көнне Равил, кызыгып китеп, этне бездән алмакчы булып, сүз көрәштерә башлады әле. Кызыкмаслыкмыни!

— Минем эт ул, берегез кире! Мин аны Карамалыдан сигез чакрым күтәреп алып кайттым, — дип, Тулганайга үрелгән иде, Камил абый ике уйлап тормады, эткә «цап» дип фәрман бирде. Тулганай бәхәсне кызыксынып күзәткән җирдән, ал тәпиләре белән гөрс итеп Равилнең күкрәгенә сикерде. Кисәк булган бу хәлдән Равил исен җыя алмыйча, арт ягына мәтәлде. Тулганай исә, фәрманны шәп үтәвенә сөенеп өрә–өрә Равилнең читкә тәгәрәп бөреген минем аяк астына китереп салды. Малайлар Равилне үртәп көлә башладылар, ул исә гарьлегеннән Тулганайга аягы белән селтәнеп алган иде, этнең янәдән үзенә ташланырга маташуын күреп шым булды. Шулай итеп бәхәскә дә нокта куелды.

Кояшлы язгы көннәрнең берсендә Тулганайны урамга алып чыктым. Авыл советында эшләүче Фәсхи агай эштән кайтып килә иде. Тулганайны күреп хәйран калды. Моңарчы күрмәгән булгандыр, ахры. Барган җиреннән тукталып, мине сөйләндерә башлады:

— Этең шәп икән, малай. — Кәефле чакларында урамдагы бала–чага белән сөйләшеп алырга ярата ул. Кәефсез чакта янына якын килмә инде. Сөйләшкәндә «малай» дип кенә җиппәрә безнең ишеләргә. — Этең бик терчән күренә, кырга куян тотарга алып чыктыңмы әле?

— Куян тотмый әле ул, бәләкәйрәк...

— Бәләкәй эткә куян тотарга өйрәтү бигрәк тә уңайлы ул, — диде Фәсхи агай, хәйләкәр елмаеп. — Суганыгыз бармы?

— Бардыр инде... — Әнкәйнең ашка суган салганын бер дә өнәмим. Ник сала торгандыр шуны.

— Булса, зерә дә шәп! — диде Фәсхи агай кулын кулга сугып. — Яз көне суган ачый ул, күздән яшьне коя гына. Эрерәк суганнарны җыеп, бәрәңге бакчагызга карга төртеп чык. Хәзер куяннарның ач чагы, азык эзләп йөрешләре. Бүген кичкә табан кар өстенә суган төртеп чыксаң, исен сизеп, иртән кояш чыгуга куяннар сезнең бакчага килеп тулачак, мин әйткән иде диярсең. Куян суган ашый башлауга, күзеннән яшь коела, елга булып ага башлый. Шул чагында йоклап калмаска кирәк тә инде — этеңне өстереп җибәрәсең генә. Эһ иткәнче өч-дүрт куянны эләктереп, алдыңа китереп салачак ул синең. Эт бер куян тотырга өйрәнсә, ач итми хуҗасын.

Фәсхи агай, минем шаккатып тыңлап торуыма күңеле булып, кайту ягына кузгалды. Мин өйгә атылдым. Шул каһәр суккан суганның бер файдасы бар икән әле.

— Әнкәй, бездә суган бармы? — дип, сорау ыргыттым кергән шәпкә.

Әнкәй он или иде, иләген читкә куеп, аптырап миңа текәлде.

— Ник кирәк сиңа суган? Барлыкка бар инде ул. Саклап торкач...

— Куян тотабыз Тулганай белән. Суган гына кирәк, — дип, Фәсхи агай сөйләгәннәрне тезеп чыктым әнкәйгә.

Әнкәй тыела алмый көлә. Күзеннән яшь ага. Суган ашаган куяннан ким түгел.

— Һи-и, Фәсхи абзыеңның «исәнме» дигән сүзе дә дөрес түгел бит аның, — дип, әнкәй алъяпкычы итәге белән күз тирәләрен сөртеп алды. — Сезнең ише малай-шалайны сөйләндереп гомере үтә шунда.

Ике көн үтүгә Фәсхи агайга тагын тап булдым мин. Каникул вакыты булгач, мин көне буе урамда, әлбәттә. Тулганайсыз бер адым атлау юк. Камил

абый зуррак малай булгач, әткәй белән ихатада нидер эшләп йөриләр. Мин беренчедә генә әле. Шуңа да миңа иркенлек, хөрлек бирелә.

— Этең шәп, — диде нәкъ теге көндәгечә. Тик бүген Фәсхи агайның күзләре елтырабрак тора. — Мондый этләр дөньяда сирәк. Әле авыл советына бардыңмы? — Тавышы сорау биргәндә катырак чыкты кебек.

— Нигә? — дидем күзләрне зур ачып.

— Ничек инде нигә? — Фәсхи агай йөзенә янә җиди төс чыгарды. — Эткә туу турында таныклык алырга кирәк. Атасы ниндирәк алабай, анасы нинди көнтәй. Таныклыксыз эт эт түгел ул.

Алдаша бу, егылып, тәгәрәпләр үлеп китим, алдаша. Этне мактавы дөрес, калган сүзләре — шыр ялган.

— Син алдашасың, Фәсхи агай, — дидем, Тулганайны үземә тарта төшеп. — Синең «исәнме» дип сүзеңә дә ышанасы түгел!

Фәсхи агайның балкып торган йөзе шундук җимерелде.

— Кем әйтте аны? — дип җикерде ул.

— Үзем беләм! — дидем, болай әйтергә кирәк икәнен чамалыйм инде. Белмәс җирең
нән белерсең.

... Беркөнне Камил абый уеннан кайтып кергәч һич тынычлана алмый, тыйгысызга әйләнеп шаяра шулай. Мине җәфалап бетерде. Әле маңгаема китереп чиртә, әле этеп җибәрә, әнкәйне дә үртәп ала. Әткәй каш җыерып бер әйтте, ике кабатлады — абый тынычланды гына, әмма тагын онытылып, мине үрти башлады. Әткәй түзмәде, миңа төбәп:

— Бар әле улым, сыек чыбык алып кер, бу малай шашына, чыбык сорый, — диде.

Сөендем инде. Тәмам тенкәгә тигән иде Камил абый. Ишек алдына ук булып атылдым. Утынлык тирәсеннән шәп кенә чыбык сайлап алдым. Өйгә йөгереп керсәм, Камил абый берни булмагандай мыштым гына дәрес әзерләп утыра. Кулымдагы чыбыкка каш астыннан бер караш ташлады да, өстәлгә сеңде.

«Әһә, куркасыңмы?!» — дидем эчтән генә. Әткәй, көлемсери төшеп, чыбыкны матчага кыстырып куйды.

— Кирәге чыгар... — диде. Әткәй күп сөйләшми безнең.

Тик эшнең болай тыныч кына үтеп китүенә күңел риза түгел. Камил абый тенкәгә нык тигән иде. Үч аласы килә, инде мин аны үрти башладым, әле китабын алып куям, әле төртеп китәм. Эндәшми, түзә бу. Чыбык куркыта. Ә чыбыкны алып кергән кеше мин! Әткәй миңа ышана шул. Тагын ничек кенә Камил абыйның тавышын чыгартасы инде, ә?.. Ачу белән, чәчен нык кына тартып куйдым.

— Кит инде... Дәрес әзерлим бит, күрмисеңме әллә?.. — Абыйның тавышы зәгыйфь иде. Минем күңел исә канат кагына.

Әткәй кисәк кенә матчадан чыбыкны суырып алды да, чаж–ж, минем аркага сыздырып та алды.

Күләргәме, еларгамы?.. Баштагы буталыш исәнгерәйткән иде, әткәй кулга чыбыкны тоттырып та куйды.

— Бар, чыгарып ташла, син абыеңнан да уздырасың икән.

Шулкадәр күңел кителде. Өйгә керәсе килми. Керми чара юк, кышкы көндә ялан өс озак торышлы түгел.

Керүемә, Камил абый авызын ерып алга килеп басты:

— Өлешеңне алдыңмы? Менә шулай була ул, сатлыкҗан булма бүтән.

Онытылмаслык дәрес булды бу миңа. Шуңа Фәсхи агайның «кем әйтте», — дип соравына, «әнкәй әйтте» дип җавап бирү уйга да килмәде. Дөньяда иң начар нәрсә — кешегә начарлык теләү, кеше сату. Әйбәт төшендем.

Фәсхи агай кашын җыерып миңа нәрсәдер әйтергә маташа иде, Тулганай алга ыргылып өрә башлады.

— Алып кит каршыдан этеңне, малай актыгы, — диде Фәсхи агай ачу белән, — Урам сасыта.

— Начар кешегә генә шулай өрә ул, — дигәнне сизми дә калдым.

Фәсхи агайның бөтенләй ачуы чыкты. Кулларын болгап, мине ачулана башлады:

— Тик тор, малакасус, күрсәтермен мин сиңа кемнең начар, кемнең әйбәт икәнен. «Исәнмең» дә дөрес түгел дигән була бит... Дөресләрмен әле мин сезгә! Кем икәнемне оныталар. Өйдә шулай сөйләшәләр, шул ияреп чыга урамга. Сәвит диләр мине, сәвит!

Икенче көнне әнкәйне авыл советына чакырттылар. Балаларыңа дөрес тәрбия бирмисең, сәвит җитәкчесенә каршы котыртасың дип каты шелтә белдергәннәр. Ике көн эчендә налуг хисабына йөз күкәй тапшырып, кәпитәнсәсен сәвиткә кертеп бирергә кушканнар. Әнкәй нигәдер мине ачуланмады, авыл советында ниләр булганын әткәйгә сөйләгәннән соң, үзалдына елмаеп, чиләк күтәреп күрше–күләннән күкәй җыярга чыгып китте.

Әткәй мине шелтәләп алды :

— Син инде, улым, олы кешеләр каршында озын телле булма. Телне теш артында тотарга өйрән. Дөреслек күзне төртеп тишә ул. Элекке чак булса... Әнкәңнең Нурулла хәзрәт кызы икәнен дә искә төшерерләр иде.

Боларны мин аңлап җиткермәдем.

*Дәвамы киләсе санда*

---

***

**Төн уртасы. Казан йоклый**
**Кар юрганын ябынып**
**...Төнлә туды яңа әсәр,**
**Күңелләрне сындырып.**

**Мәхәббәт турында иде,**
**Саф мәхәббәт хакында.**
**Ургылып чыкты күңелдән,**
**Туды шәм яктысында.**


**Төннең кара савытыннан**
**Бер тамчы кара алдым...**
**Алдым да аны күңелнең**
**Хисе белән бутадым.**

**Таң алдыннан шәмем сүнде.**
**Шигырь язу тукталды.**
**Хисләрем шушы урында**
**Әллә нишләп буталды!**

**Ә мәхәббәт шәм түгел ул:**
**Сүнми дә, сүрелми дә.**
**Җанны җылытучы булып,**
**Яши һаман күңелдә.**

**Ильмира КАМАЕВА.**
*Азнакай районы*

# РЕБУС




Ребусны чишсәгез, Камил Кәримовның афоризмын укырсыз *(җавабы 181 биттә).*

**Зөфәр ХИСАМОВ** *төзеде.*

---

## Халык әйтсә, хак әйтә

*Егетнең кашына карама, эшенә кара.*

*Җегет булсаң, җебек булма.*

*Оялчан кыз – сөйкемле кыз.*

*Уналты яше тулган кыз энә өстендә бит.*

*Кыз намусын бирмәс.*

*Салкын ярдан эссе мич яхшы.*

## Марат Закир

### Ашкыныр чак

Әйди безне алга юллар —
Алга икән алга бак!
Бездә генә, бездә генә —
Җилдәй җитез аргамак!

Җилдәй исеп үтәр гомер —
Ашыгып кал, ашкынып!
Янса янсын яшь чагында
Без яшьләргә яшел ут.
Янса янсын яшь чагында
Яшь егеткә яшел ут!

Ниләр көтә безне алда —
Томан сарган юлларда?
Томан сарган юллардан да
Серлерәге юк анда.

Ниләр көтә безне алда —
Таулардагы карлы боз?!
Карлы боздан бара-бара,
Бәхеткәйне яуларбыз!

### Телефон

...Син — ул ярда, мин — бу ярда
Калдык хисләр кочагында.
Күңел юатырга бер сүз,
Бер сүз җитми кайчагында.

Син — ул ярда, мин — бу ярда...
Ярларны ярга ялгарга
Әле дә ярый, әле дә ярый
Тылсымлы телефон бар ла...

### Уян!

...Һай, ай-һай,
Татлы да соң йокы...
– Уян! –
Яңгыратып тәчкерде таң, —
Исәнлеккә бу! — күрерсең,
Олы Төнгә өлгерерсең,
Уян, дускай, тор син, тор син!

Вакыт аты кешни анда.
Вакыт аты,
Вакыт аты!
Солы сыман сибелеп кала
Асыл көннәр бер-бер артлы...

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

**Хәтерләсәгез, узган санда бәйге игълан иткән идек. Аны кабат исегезгә төшерәбез. Шушы башламнарның күңел теләгәнен дәвам итеп хикәя языгыз әле. Күләме бер журнал битеннән артмасын.**

**Җиңүче автор – журналның «Сүнмәс утлар балкышы» дигән уникаль китабы белән, тагын ике автор «Яңа базар» дигән сатирик хикәяләр җыентыгы белән бүләкләнәчәк.**

**Хикәяләр 20 декабрьгә кадәр кабул ителә.**

***

«Күз – кызлар күңеле төсле,
Бер елмая, бер – төксе», — дип язып куйды да Камил, тәрәзәдән урамга күз салды. Алтын таңкәләрдәй коелышкан каен яфракларына хозурланып, серле генә елмаеп, урамда Рәсимә басып тора иде...

***

Волонтёр кыз, юл уртасына ук чыгып, кабалана-кабалана такси туктатты. Ян тәрәзәне төшерүгә, кабина эченә учлап чәйнәлгән сагыз исе бөркелде.

— Миңа «Кояш»лыга. Срочно!

— Универсиаданың беткәненә ике атна бит инде, кая шулай ашыгасың?

Һәм таксист, бәя турында да килешеп тормыйча, алгы ишекне ачты.

***

Кызның күзе егетнең беләгендәге татуировкага төште. Анда тигез хәрефләр белән «Гөлия» дип язылган иде.

***

— Исәнмесе-е-е-ез! Хуҗалар өйдәме-е-е? — дип сөрән салды Хәсән, зур урыс капканы ачып ишегалдына аяк басуга.

— Исәнме, абый, сиңа кем кирәк?..

Хәсән «дерт» итеп китте. Аның каршында тач үзенә охшаган, зур башлы, зур колаклы җиде-сигез яшьләр тирәсендәге бер малай басып тора иде...

***

Тавышын калынайтып, йөрешләрен никадәр генә үзгәртергә теләсә дә, Кыш бабай булып улын котларга керүченең яшьлек дусты Фирдүс булуын тиз чамалады Әминә.

***

Бу кызны ул троллейбус тәрәзәсеннән күрде. Күрде дә, гашыйк булды! Төшеп калып, бик озак эзләде ул аны. Таба алмады. Кайтып подъезддан керсә... шул кыз... аларның ишеген... ачкыч белән ачып маташа иде!

***

Күке, туктамыйча, санады да санады. Аларга рәхәт иде...

---

*179 биттәге ребусның җавабы:*
*«Мин-минле автор язудан туктаса донос жанрына күчә».*

Альберт Хәсәнов

# ТАБИГАТЬ ТУРЫНДА ПАРЧАЛАР

### Эт белән мәче төсле...

Наполеон кушаматлы песиебез бар безнең. Ярты гомерен диванда, ярты гомерен түбә кыегында үткәрә. Карап торырга бик интеллигент кыяфәтле. Үз кадерен үзе белеп, аяк очларына гына басып йөри. Чисталыкны бик ярата. Өсте һәрчак ялык-йолык килеп тора. Битен көненә өч тапкыр юа. Мыеклары да галәмәт аның. Аларны гел сыпырып, майлап, кадерләп кенә тота. Үз-үзенә сокланып һәм тәмам мөкиббән китеп көзге каршында сәгатьләр буе утырырга ярата торган песи бу. Драма театры артисты диярсең, валлаһи! Инде эрелеккә, тәкәбберлеккә килсәк, аңа тиңнәрне бүтән табарсыңмы әле! Үзенә тиңнәр белән дә тик ике метр ярым биеклектәге койма башыннан торып аралаша. Түбәнрәк төшсә, авторитеты төшүдән курка, күрәсең. Кыскасы, үзен тота белә, кыланчык нәрсә.

Безнең әле Сарбай исемле бик акыллы маэмаебыз да бар. Дөньяда бер тырыш, намуслы җан иясе инде. Көнен генә түгел, кышкы озын төннәрне дә керфек тә какмыйча саклый ул безнең йорт-җирне, мал-мөлкәтебезне. Күрше тавыгы түгел, алмагачка ят чыпчыклар килеп кунса да, шундук тавыш куптара. Янә өстәп әйтим әле: һәрчак шат күңелле, юктан да үрле-кырлы сикереп сөенүчән безнең Сарбай, һәр елны мин аның туган көненә яңа муенчак бүләк итәм. Бу көннәрне сөенеченнән Сарбайның түбәсе күккә тия.

Менә әлеге Наполеон белән тырыш җан Сарбай бер-берсен, кем әйтмешли, йөзгә-йөз танып беләләр. Белмәскә соң, икесе дә бер оешмада хезмәт итәләр, ягъни безнең мал-мөлкәт сагында торалар. Әмма шушы ике җанның бер-берсенә бер генә мыскал да ихтирам хисе юк. Сөймиләр берсен-берсе. Югыйсә конкурентлар, көндәшләр дә түгел.

Кайчакны шулай Наполеон, диванда аунаудан туеп, яки эшсезлектән интегепме, лапас түбәсенә чыгып ята. Анда һәрчак ышык, һәрчак кояш кыздыра. Сарбайның оясы да каршыда гына.

Наполеон түбә башында тын гына кызынып ятса бер хәл, анда чыгу белән Сарбайны ирештерә башлый:

— Әй, картлач, синең тормышны да әйтер идем инде, чын эт көнендә яшисең бит. Нигә карама муеныңда чылбыр-галстук. Нужәли бер дә туймыйсың? Салып ташла да шуны, минем янга мен. Дөнья дигәнең ул бит әнә ничек киң, әнә ничек чиксез.

— Кит моннан, оятсыз җан, ата ялкау! Минем муенымда нинди галстук булуда синең ни эшең бар?! Мин хуҗама намуслы хезмәт итәм. Шуның белән үземне бәхетле саныйм, — дип, ярсып-ярсып Сарбай аны орышырга керешә. — Синең урыныңда булсам, оялыр идем мин мондый сүзләр сөйләргә. Әй кыегында төне буе мәхәббәт уены уйныйсың. Көне буе йоклыйсың. Гомер эчендә бер идән астына төшеп караганың юк. Анда тычканнар, тәмам котырынышып, сабан туе ясап яталар. Әрәмтамак! Белмим, аңламыйм хуҗабызны. Син әрәмтамакны ни дип кенә асрый торгандыр? Әй, таптым тагын кем белән нервыларымны бозарга,— дип, оясына ук кереп китә.

Менә шулай яши бу ике җан иясе, нәкъ эт белән мәче кебек. Әмма күптән түгел искиткеч бер хәл булып куйды. Печәнгә төшәргә атна-ун көннәр кала урманчы Сәлимҗан килеп чыкты. Атын капка баганасына бәйләде. Арбасында бозау тикле йонлач маэмай ята. Хуҗасы кая атласа, монысы шунда сикерергә күнеккән. Сәлимҗан артыннан маэмае да ишегалдына килеп керде.

— Кая, кая керәсең? Кем дәште әле сине монда? һау, һау! — дип, Сарбай бу йонлачны бик коры каршылады. — Тәртәләреңне кире бор. Юкса мин күп сорап тормам, һау, һау!

Әмма урманчының маэмае да хуҗасы кебек әрсез җан икән, кире чигенергә җыенмады. Болар шул арада, бер-берләренә ташланып, аяк астыбызда бөтерелә дә башладылар, һич аерып хәл юк үзләрен. Наполеоны да шушында ук казык башына чыгып кунаклаган. Андый чакны мәзәк карарга аңа бир инде. Күрше әтәчләренең сугышканын, күрше малайларының чәкәләшкәннәрен дә ул, тәм табып, казык башында күзәтеп утырырга ярата.

Ике маэмай, бер түгәрәк йомгак булып, ишегалды буйлап тәгәриләр. Кычкырып та, таяк белән дә кизәнеп карадык. Колакларына да элмиләр. Әй, чәнчелеп китсеннәр лә шунда! Безнең үз мәшәкатьләребез дә муеннан. Печәнгә төшәбез дип кенә торганда яңгырлар китте. Кояшлы көннәр тиз генә кайтмаса, белмим, ничек кенә чабып алырбыз быел ул билдән печәнне.

Ике маэмай җан-фәрманга кызып сугыша. Әмма Сәлимҗанның йонлачы хәйләкәррәк, әмәл белән сугыша. Бер араны оста әмәл кулланып, безнең Сарбайны сыртына салды. Сарбай — аста, йонлач – өстә. Урманчы этенә хәзер Сарбайны ничек җәзаласа да була. Әлеге көтелмәгән хәл менә шушы мизгелдә булып куймасынмы, валлаһи! Әлеге ызгышны күзәтеп торган Наполеон нечкә тавыш белән ямьсез мыраулап җибәрмәсенме?!

— Җәмәгать, нәрсә карап торасыз! Безнекеләрне тукмыйлар бит! – диде, ахрысы, һәм әлеге казык башыннан таш булып урманчы эте өстенә атылды. Дүрт тәпие белән берьюлы тегенең йонлач башыннан каптырды.

Урманчы эте шундук чинап җибәрде. Кемнең, каян һөҗүм итүен дә аңламыйча урамга йөгерде. Ә Наполеон мыекларын төзәтеп алды да янәдән җәһәт кенә багана башына үрмәләде.

Сарбай да торып басты. Чак кына кан саркыган иренен ялап алды.

«Безнең маэмайлар арасында андый гына конфликтлар булып ала инде ул. Катышмасаң да була иде. Мин ул нахалны үзем дә акылга утырта идем, һау!» — дип куйды.

Әмма Наполеонның ярдәме бик вакытлы булды. Сарбай да бу «һау-һау!»ны чын күңеленнән рәхмәтен белдереп әйтте төсле.

— Безнең дә кем икәнне белеп торсыннар. Җыен килмешәктән бер-беребезне кыерсыттыра башласак, нәрсә була ул, мияу?! — дип куйды Наполеон үзе утырган багана башыннан.

Менә шулай яшиләр инде алар. Эт белән мәче төсле. Бер-берләренә мыскал да симпатияләре юк...

## Акыл иясе

Иртә таңнан аякта булып, кортларыбызны баш күтәрми карап, тәмам арып-алҗып, авызларыбыз кибеп, алан уртасындагы учак янына җыйналыштык. Битлекләребезне салып, җиргә сузылыштык. Учакта кайнаган чәйне генә әйт син! Мондый тәмле, мондый шифалы чәйне тик бирегә генә татырга мөмкин! Чөнки чәйнек эчендә нинди генә хуш исле, нинди генә шифалы үләннәр юк!

Шулчак якында гына чырт-чырт итеп коры куак чыбыклары сынган тавыш ишетелде. Кем булыр икән бу уттай кызу эш өстендә?

— Кем булсын? Гөмбәче-мазардыр. Адашып килеп чыккандыр, — дип куйды арабыздан берсе. – Әйдә, килсен. Кунакларга бездә һәрчак якты йөз. Менә тәмле чәй белән сыйларбыз үзен.

Кем, дисезме?! Шулчак аланга, артына ут капкандай атылып, Озын Колак-Кылый Күз Куян хәзрәтләре килеп чыкмасынмы?! Килбәтсез озын сыйраклы үр куяны. Чыбыкларны шатыр-шытыр сындырып куаклыктан ул чапкан икән. Күзләре шар. Йөрәгенең ярылырдай булып дөп-дөп типкәне безгә дә ишетелә. Әллә соң бу бичара акылыннан язганмы? Акта-карада эше юк моның, әллә безне дә күрми инде? Ракета тизлеге белән аланны әйләнеп чыкты да, инде нишли бу дип торсак, кыл уртабызга керде дә ятты. Колакларын шиңдереп, үләнгә үк сеңде. Аптырап карап торабыз. Мондый хәлне күрү түгел, ишеткән дә юк. Берни аңламыйбыз. Әйе, керде дә ятты уртабызга, җиргә сеңде. Күлмәк сәдәфедәй зәңгәрсу, нәни, кылый күзләрен безгә төбәгән. Нидер ялвара, сорый төсле. Зинһар, коткара күрегез, дия сыман. Ләкин, телен белмәгәч, нәрсә эш-лик, ничек ярдәм итик? Аптырашып тора бирәбез.

— Нәрсә, Кылый Күз, әллә бал татып карыйсың килдеме? Юк бит әле. Бал төшкәнне үзебез дә көтәбез генә. Ә менә тәмле чәйдән авыз ит. Шикәрне сиңа ничә кашык салырга?

Нәкъ шул чакны аланга, туптан аткандай атылып, икенче бер кунак, төлке-хәйләкәр килеп чыкмасынмы! Акны-караны күрми, күзләрен тәмам кан баскан. Әлсерәгән. Телен асылындырган, гыж-гыж сулый.

Атылып килеп чыкты да бер мәлгә аптырап калды. Янәсе, кая, кемнәр янына килеп чыктым мин?! Безнең арада җиргә сеңеп яткан куянны шушы комсыз куып килгән булырга тиеш. Тәмле куян ите татып карыйсы килгәндер инде.

Кем утырып, кем ятып торган җиребездән сикерешеп торып, төлкегә таба йөгерештек. Хәйләкәр җан — Озын Койрык бик тиз зиһененә килде. Кырт кире борылып, куе куаклык эченә сикерде. Койрыгын гына күреп калдык. Алай да сызгырып, артыннан шаян сүзләр кычкырып, бармак янап озаттык үзен.

Инде кире борылып, янәдән алан уртасына, учагыбыз янына килсәк, Озын Колак-Кылый Күздән дә җилләр искән. Менә син, ә?!

Куркак җан куянга безнең уртага кереп яту өчен никадәр тәвәккәллек, никадәр батырлык, акыл һәм зиһен кирәк булгандыр. Ул бит кыргый җәнлек. Әмма шушы авыр чакта, менә куып җитәм, менә тотып ботарлыйм, дип артыннан мәрхәмәтсез ерткыч куганда, бик дөрес карар кабул иткән ул. Юкса, мәкерле җан төлке аны һичшиксез куып җиткән, тотып ботарлаган булыр иде. Җитмәсә, без аның буаз куян икәнен, менә-менә бәбәйләргә торуын күрдек. Бу килештән ул ерак китә алмаган булыр иде. Үлем куркынычы янаганда куян әнә нинди зирәк карарга килгән, башка чакны үзе дә коты алынып курыккан кешеләр янына чыккан, безгә сыенган.

Без, гадәттә, куянны иң куркак җанга саныйбыз. Ләкин ул әле зирәк акыл иясе дә икән. Бу табигатьнең серләрен белеп кенә бетерешлеме соң?!

# 2013 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

2013 елда Татарстан республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. № 5

Бөтендөнья татар конгрессының 20 еллыгы уңаеннан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов котлавы. № 1

Фәйзуллин Р. Телне, милләтне саклыйк дисәк. № 6

Татарстан язучылары җыены. № 7

Татарстан гимны. Р. Яхин көе, Р. Байтимеров сүзләре, Ф. Пираев тәрҗемәсе. № 4

### ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ахир. Кәбисә елы. *Сатирик бәян.* № 8

Әмирханов М. Ир-Мамай. *Тарихи бәян.* №№ 5 – 7

Әмирханов М. Утлы камчы. *Хикәя.* № 12

Батулла. Туган ягым – Зәй төбәге. *Хатирәләр.* №№ 2, 3

Гали В. Гомер чилләсе. *Бәяннан өзек.* № 6

Галиуллин Т. Замана балалары. *Истәлекләр.* №№ 7, 8

Гыйматдинова Н. Үзем генә беләм... Бәян. № 4

Җамалетдинова Ф. Кеше күңеле – кара урман... *Хикәяләр.* № 3

Җамалетдинова Ф. *Хикәяләр.* № 10

Зәйнуллин З. Курск дугасы батыры. *Документаль бәян.* №. 7

Имамов Ф. Күләгә. *Детектив роман.* №№ 9,10

Камалов Х. Сугыштан кайткан сөю. *Кыйсса.* № № 1, 2

Кәрим Кара. Матильда. *Бәян.* № 12

Маликова М. Көмеш билбау. *Роман.* №№ 10,11

Мирхәйдәров Р. Дингез аша ялгыз. *Бәян.* № 8

Мөхәммәтша Р. *Хикәяләр.* № 9

Низами Р. Сүзгә – мәрхәбә! *Эссе.* № 4

Рахман Р. *Хикәяләр.* № 11

Салах Ә. Аккан сулар... *Яшьлегем хатирәләре.* № 1

Сафин Р. Садыйкның уянуы. *Бәян.* № 5

Хәлим А. Чын җиңүче кем? *Хикәя.* № 5

Хәлим А. *Хикәяләр.* № 11

Шәфигуллин Р. Утлы дулкын. *Документаль бәян.* № 9

Якупова С. *Хикәяләр.* № 1

### ШИГЪРИЯТ

Акъегет Р. Күңелем – салават күпере. *Шигырьләр.* № 3

Әхмәдиев Н. Хатирәләр үлми, искерми. *Шигырьләр.* № 6

Әхмәтҗанова С. Арча капкасы. *Шигырьләр.* № 5

Әхтәмова Г. Изгелектә безнең бар ният. *Шигырьләр.* № 6

Бәйрәмова Г. Ил кадерен белер – илсез калган. *Шигырь.* № 2

Булатова К. Яшәүгә омтылыш шундый нык. *Шигырьләр.* № 2

Вәлиева Л. Урап ала моң дәрьясы. *Шигырьләр.* № 8

Гәрәева С. Горурлыкка таулар өйрәткән. *Шигырьләр.* № 11

Гыйззәтуллина Ф. Яңу дәверләрендә. *Роман-поэмадан өзекләр.* № 3

Гыйләҗев И. Җаным ирек, хөрлек тели. *Шигырьләр* № 1

Гыйләҗев И. Яшәү өчен көрәш кискен. *Шигырьләр* № 12

Диндаров И. Саный татар вакытын... *Шигырьләр.* № 7

Закиров Р. Без уянсак кына. *Шигырьләр.* № 6

З ә й д у л л а Р. Чарасыздан җанны бер өн били. *Шигырьләр.* № 10

И б р а һ и м о в Б. Мөкатдәс саз тынды уйнавыннан. *Шигырьләр.* № 3

И д и я т у л л и н Р. Энҗе сүз эзгердә балкый. *Шигырьләр.* № 11

К ә р и м о в М. Кайларга чабасың, гомерем... *Шигырьләр.* № 1

К ә р и м о в а Г. Сан алганда. *Шигырьләр.* № 9

К о р б а н о в а Г. Юшкыннарны вакыт юа. *Шигырьләр.* № 9

М ә х м ү д о в Ә. Эзлим дөнья тоткасын. *Шигырьләр.* № 5

М и ң н у л л и н а Й. Өтүкән җирендә ут яна. *Шигырьләр.* № 10

М и р з а М. Бербөтенлек хакның таләбендә. *Шигырьләр.* № 1

М у с и н Ч. Дөнья иркен – җанда кысанлык. *Шигырьләр.* № 5

М ө д ә р р и с о в а Х. Безгә инде язлар кагылмаслар... *Шигырьләр.* № 4

Н ә г ы й м у л л и н а Д. Бәхетемне сиңа бүләк итәм. *Шигырьләр.* № 12

Н и з а м и Р. Мәңгелеккә килеп тоташам. *Шигырьләр.* № 2

Р а х м а н Р. Ә сагышым – моңлы җыр иде. *Шигырьләр.* № 6

Р ә х и м Г. Минем өчен шигырь – тормыш ул. *Шигырьләр.* № 8

С ә л а х Р. Җиһанның бар яктылыгы үзгә... *Шигырьләр.* № 4

С ө л ә й м а н о в Р. Язмыш – Ходай кушканча. *Шигырьләр.* № 8

С ө л ә й м а н Җ. Җан җебеннән үрдем күперләр. *Шигырьләр.* № 9

Т а р х а н о в а Ф. Күңелемә ятты моңлы көй. *Шигырьләр.* № 12

Ш а һ и е в а Р. Ана теле – гүзәллек. *Шигырьләр.* № 10

Ш ә е х Л. Без сайлаган юллар хата түгел. *Шигырьләр.* № 9

Ш ә р и п о в Р. Бу Яңа ел. *Шигырь.* № 1

Я н с у а р Л. Дөньялыктан саркыламы сагыш... *Шигырьләр.* № 7

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

З ә й д у л л а Р. Минем дустым Чыңгызхан. *Сатирик комедия.* № 12

**« ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН»**

Г ы й л ь м и Ф. Салават күпере. № 10

К у т у й Г. Рәссам. № 11

Л а т ы й ф и Ф. Өч хикәя. № 6

С а р ь я н Х. Зәңгәр күл сагышы. № 2

Х ә й д ә р. Әбиләр чуагы. № 12

**ПУБЛИЦИСТИКА**

З а р и п о в Р. Онытылган «Алтын Йолдыз» иляре. № 5

М и р х ә й д ә р о в Р. Карга күзен карга чукымый. Россия Конституциясе һәм милек. *Мәкаләләр.* № 10

Ф ә т т а х Н. Балтач районында китап сәүдәсенең торышы. № 5

Ш ә р ә ф и е в Р. Сездә ничек, бездә шулай саталар китапларны. № 5

Х а т и п о в Ф. Агымсуда электр ташкыны. № 3

Ш ә р и ф Х. Күңел авазы яки мең дә бер сорау. *Эссе.* № 8

Ш ә р и ф у л л и н Н. Без бетәбез инде, сез каласыз. № 4

Ш ә р и ф у л л и н Н. Мең тиленең күмәк акылы яки гыйлемлелек «зарары» хакында. № 12

**ТАТАР ГАЛӘМЕ**

Ю н ы с Р. Кытайдан зәңгәр тауга кем яулык болгый? № 7

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Ә х м ә д у л л и н А. Заманчалык. № 10

В ә л и у л л а И. Тәүбәле еллар, тәүбәле юллар... № 10

Г а л и у л л и н Т. «Ян син, йөрәк» *(Әнвәр Давыдов иҗатында замана сурәте).* № 12

Г а н и е в а Р. Рухи-әхлакый янарышка таба. № 1

Д а у т о в Г. Тәрәзә кыегын кем төзәтер? № 11

З ы я т д и н о в А. Буыннар язмышы. № 1

М и ң н е г у л о в Х. Төрки дөнья хәзинәләре. № 12

Х ә л и м А. «Мин гаделлек җиле...» *(Фәрит Габдерәхимгә 80 яшь).* № 1

Х ә л и м А. Без аны көтә идек. № 6

Ш ә р ә ф и е в Р. «Шундый матур аның шигырьләре...». № 7

Я х и н Ф. Шигъри рух тантанасы. № 5

### ФӘН

Бакиров М. Болгарга тоташкан тамырларыбыз. № 9

Гарипова Ф. Авылларыбыз тарихы. №№ 1 – 12

Гарифуллин Г. Тарих мәйданында сәлҗүк төркиләре. *Фәнни-популяр очерк.* № 5

Мәрданов Р. «Кыз хикәяте» кыйссасы. № 4

Хәбипова З. Атка мәдхия яки «Идегәй» дастаны ат турында ни сөйли? № 11

### ТАРИХ

Биктимирова Т. Татарстанда ачлык фаҗигасе. № 1

Вәли Р. Халкына багышланган гомер. № 2

Заһидуллина Д. «Алтын чорның» алтын шәхесләре. № 11

Исхаков Д. Бөек Ауразиячёнең бер ялгышы. № 3

Ярмәкәев И. Фәнгә багышланган гомер. № 3

### СӘНГАТЬ

Абдуллин М. Җырланмаган әле безнең җыр. № 10

Әхмәтҗанова Н. Җырга бирде бар көчен. № 10

Бәйрәмова Г. «Мин арый торган кеше түгел». № 7

Зарипов Ә. Кадерле хатирәләр. № 8

Игъламов Н. Язмыш буразналары. № 11

Низами Р. Яруллиннар йолдызлыгы. № 12

Сәгъди Р. Зур тарихлы театр. № 11

Хәмзин А. Яратабыз сине, Әлфия апа! № 1

Хәмзин А. Шәрәфине сөйләштерү. № 4

Шакир Ә. Артист язмалары. № 2

Шаһиева Р. Кинлек дәрте *(Милли мәдәният музее оешуга 20 ел).* № 3

Һадиева Э. Рәссамла кунакта. № 11

### ХӘТЕР

Әхмәдиев Ш. Шагыйрь моңая. № 12

Бадюгина А. Рушад абый чын көрәшче һәм әйбәт кеше иде. № 6

Гыйләҗев А. «Без бит бәхетсез заман җимеше». № 2

Гыйләҗева Н. Кар башына кар җитә... № 2

Гыйлаҗев Т. Фидакарь затлар онытылмый *(Ибраһим Нуруллинның тууына 90 ел).* № 4

Гыйлаҗев Т. Халыкка хезмәттә ямь дә, тәм дә бар... *(Шәһид Әхмәдиевнең тууына 125 ел).* № 12

Закирҗанов Ә. Мәгърифәт юлына маяклар кагучы *(Закир Һадиның тууына 150 ел).* № 3

Исмәгыйлев Х. Кырым татарлары фаҗигасе. №№ 5,6

Ихсанова В. Иртәдән кичкә кадәр. № 6

Мостафина А. «Зәңгәр күлгә ташлар аттың...» *(Марс Шабаевның тууына 80 ел).* № 7

Мөхиярова Р. Корымас гөл. № 2

Сафин Ф. Чын иҗат үксез булмый ул. № 6

Сәхәбиев Р. Минем сәхнә укытучым. № 9

Трескин Э. Язмышның хикмәтле кулы *(Нияз Даутовның тууына 100ел).* № 9

Фәттах Н. Четерекле булды безнең заман. *Истәлекләр.* №№ 7 – 10

Харисова Ч. Күренекле тел галиме (Г.Алпаровның тууына 125 ел). № 12

Хисаметдинов Р. Җәлилче булуым белән горурланам. № 6

Шабаев М. Мизгел. Шигырьләр. № 7

Шәрипов М. Нинди җир ул Суслонгер? № 12

Юныс Р. Тормышым сәхифәләре. № 8

### ШИГЪРИ ХӘТЕР

Галиев Ш. Ышанычым арта. *Шигырьләр.* № 11

Сафин Ф. Сагынам. *Шигырьләр.* № 7

### ӘДӘБИ МИРАС

Мөхәммәтшин Г. Дулкыннар җыры. *3 пәрдәле трагедия.* № 3

Сөләйманов Б. Кояшым, җаем идең син... *Шигырьләр.* № 5

### ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ – ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Кутлу Ф. Тәрҗемәчелек – заман таләбе. № 3

Шәех Л. Телләрнең күптөрлелеге – бөтен дөнья байлыгы. *(Халыкара ПЕН-клубның Кырым конференциясе).* № 3

ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ВАФАТЫНА 100 ЕЛ

Гафури М. Г. Тукай вафатыннан соң. *Шигырь.* № 4

Газиев И. Тукай әсәрләре – граммофонда. № 4

Таһиров И. Тукай – мәңгегә халык күңелендә. № 4

ЮБИЛЕЙЛАР

НӘҖИП ДУМАВИНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ. № 5

РИЗА ИШМОРАТНЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ.

Закирҗанов Ә. Якты юл. № 10

ЗАРИФ БӘШИРИНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

Зәйдулла Р. Бәхетсез почмакның иясе. № 5

ФАТИХ СӘЙФИ-КАЗАНЛЫНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ. № 3

МӨХӘММӘТ ГАЛИНЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ. № 3

ӘХМӘТ ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ. № 3

ГАРИФ ГАЛИЕВНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ. № 5

МӨХӘММӘТ ГАЙНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ. № 8

АБДУЛЛА САЙГАНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Мусабәкова Р. Олуг галимне искә алып... № 5

ӘМИНӘ БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ.

Бикчәнтәева Ә. Дәү әнием. *Шигырьләр.* № 2

СӨББУХ РӘФЫЙКОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ. № 7

МӨХӘММӘТ САДРИНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ. № 5

МИН ШАБАЙНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ. № 4

МӘХМҮТ ХӨСӘЕННЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ.

Хөсәен М. Исә җилләр. *Шигырьләр.* №4

РИЗА ШӘФИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ. № 2

ИЛДАР ЮЗЕЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Шәех Л. Илдар абыйлы вакытлар. № 1

Юзеев И. Тирәкләрем , нигә боектыгыз?.. *Шигырьләр.* № 1

ХӘКИМҖАН ХАЛИКОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ. № 2

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 75 ЕЛ

Юныс Р. Кояшка үрелгән егет. № 2

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Мәгариф» журналына 100 ел

Шәмсетдинов Г. Гыйлем һәм мәгърифәт учагы. № 3

МАРСЕЛЬ БАКИРОВКА 80 ЯШЬ

Закирҗанов Ә. Һәркайда үз кеше. № 12

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Заһидуллина Д. «Шаш, рухым — дуласын җан!». № 8

Сабиров Р. Уйлар, уйлар, уйлар... № 8

Хәлим А. Йөрәк җебе өзелгән җирдә. *Эссе.* № 8

КИТАП КҮЗӘТҮ

Гаташ Р. Тансык һәм бай бу кәрван... № 2

Гайнуллина Г. Язмыш турындагы сер. № 3

Даутов Г. «Йозак» ачкычы. № 5

Солтанов Ф. Фән һәм дин берлеге. № 4

Фәйзуллин Р. Әдип галим турында галим әдип. № 3

Хатипов Ф. Канатлы биюче. № 9

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН

Гамзатов Р. Шөлдерле лачын турында җыр. *Шигырьләр.* № 9

Зәйдулла Р. Таулар биеклегендә. № 9

КЛАССИК ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Гоголь Н. Борын. № 9

АК ҖИЛКӘН

Галиев Ф. Көне-төне уйлап янам. *Шигырьләр.* № 11

Гобәйдуллина Ч. Хис дулкыны ярга бәрелә. *Хикәя.* № 11

Закир М. Ашкынып чак. *Шигырьләр.* № 12

Закиров Л. Җансыз мәхәббәт. *Хикәя.* № 12

Камаева И. *Шигырь.* № 12

Сафин Ф. Тулган ай. *Бәян.* № 12

Хәбибуллина Л. Юксынулар җанга суык өсти... *Шигырьләр.* № 12

Хәсәнов А. Табигать турында парчалар. № № 11, 12

Хикәя аза аласызмы? № № 11,12

ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Галиев Г. Йөрәк ярасы. № 10

Макаров М. Ике төр бәндәнең үлеме. № 7

Тарханова Ф. Укол. № 4

Хәбибулла Р. Сынау. № 12

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Гайнетдинова И. Өмә. *Хикәяләр*. № 4

Закир М. Иннәреңдә канат барда... № 4

Мансуров А. Дога. *Хикәя*. № 4

ФИКЕР

Ханзафаров Н. Казан, исемең матур... № 12

КАЙТАВАЗ

Юныс Р. «Тегә солдат» яки Яхшылык эшлә дә суга сал. № 9

ПЕЧӘН БАЗАРЫ

Ахир. Кабул итү булмасендә. *Сатирик поэма*. № 12

Әблиева Л. Парчалар. № 6

Гаделшин Д. Соңгы бүләк. *Сатирик хикәя*. № 10

Фәсхи Ф. Фарисизмнар. № 10

ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР

Баттал Ф. Башта ук шулай дияргә иде!.. № 3

Баттал Ф. Өстәл китабы. № 8

Гәрәев М. Төшләренә дә кермәде. № 9

Гомәр Г. Гулаг тоткыны. № 1

Гомәр Г. Өч борынга – бер һәйкәл. № 4

Гомәр Г. Фәйләсүф жан. № 7

Салах Ә. «Ошадың әле...». № 6

Универсиада. Саннар. Фактлар. № 8

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. №№ 2 - 12

«Рухи тормышыбыз энциклопедиясе». № 12

Укучы сүзе. № 12

2014 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. Төзүче-мөхәррир Хажи Абдулла Дубин. № 12

Ребус. Төзүчесе Хисамов З. № 12

Мәшһүрләр мәзәге (Дусай М. ) №№ 7,10,11

«Казан утлары» архивыннан. №№ 1 - 12

Ижтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№ 1 - 12

Яна китаплар. №№ 1,3,5,7,9,10,11,12

Хушлашу сүзе (Аллер Тимергалин. № 2; Әхсән Баян. № 6).

---

## Электрон почта да төпсез түгел

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, жинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

**Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.**

**Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар жибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.**

## İctimaği-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### КАЗАН — ЯҢА БИЕКЛЕКТӘ

Казан дөньяның спорт башкалаларының берсе дип танылган. Башкала, Лондон, Дубай һәм Окленд белән беррәттән, халыкара спорт чаралары уздыру өчен дөньядагы иң яхшы урыннарның берсе буларак, махсус призга лаек булган. Бу хакта Лондонда узган 7нче Internationa Sports Event Managemenl Awards — 2013 (ISEM) — спорт менеджменты өлкәсендә уңышларга ирешкән өчен иң зур халыкара премия тапшыру тантанасында билгеле булган. Премия Казанга июль аенда узган Бөтендөнья җәйге Универсиадасы өчен бирелгән.

### ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ ЮБИЛЕЕ

Быелның декабрь аенда Кыргызстанның халык язучысы, Социалистик Хезмәт Герое, Ленин һәм СССР Дәүләт премияләре лауреаты Чыңгыз Айтматовның туууына 85 ел тула. Бу уңайдан Кыргызстанда гына түгел, ә бөтен төрки дөньяда һәм шулай ук Россиядә язучының юбилее зурлап билгеләп үтелә.

24 октябрьдә Мәскәүдә Бөтенроссия дәүләт чит ил әдәбиятлары китапханәсендә Чыңгыз Айтматовка бюст-һәйкәл ачылды. Мәдәни чаралардан, әлбәттә, Татарстан да читтә калмады. Чөнки татарлар өчен Айтматов исеме икеләтә якын. Мәгълүм булганча, язучының әнисе Нәгыймә Абдувалиева ягыннан нәсел тамырлары Татарстанның Кукмара районы Мәчкәрә авылына барып тоташа.

25-26 октябрьдә Казанда оештырылган юбилей чараларында Кыргызстанның мәдәният, мәгълүмати сәясәт һәм туризм министры Солтан Раев җитәкчелегендә мәртәбәле делегация катнашты. Башкалада Чыңгыз Айтматовның сеңлесе Роза ханым да кунак булды. Делегацияне республика җитәкчелеге кабул итте, күренекле фән, мәдәният һәм сәнгать әһелләре белән очрашулар үтте.

Айтматовка багышланган төп вакыйгалардан — Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институтында узган халыкара фәнни-гамәли конференция булды.

Халыклар дуслыгы йортында оештырылган фотокүргәзмәдә Кыргызстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Александр Фёдоров хезмәтләре урын алган иде. Ул язучы белән озак еллар аралашып яшәгән, аның архивында легендар шәхеснең меңгә якын фотосурәте саклана. Фоторәссам «Чыңгыз Айтматов һәм аның җире» исемле альбом чыгарган, Казандагы күргәзмәдә шушы альбомнан илле хезмәт тәкъдим ителде.

Кыргызстан кунаклары шулай ук Татарстан Милли китапханәсендә Айтматовның татар теленә тәрҗемә ителгән «Бәхил бул, Гөлсары!», «Анам кыры», «Җәмилә», «Беренче мөгаллим» кебек танылган повестьларын үз эченә алган яңа җыентыгын тәкъдим итү кичәсендә дә катнашты.

Чыңгыз Айтматовның юбилее уңаеннан чираттагы халыкара вакыйга Бишкәктә үткәрелде.

### ХАЛЫК ШАГЫЙРЕН ОЛЫЛАУ

12 ноябрьдә Мәскәүдә язучыларның үзәк йортында (ЦДЛ) Равил Фәйзуллин иҗатына багышланган зур кичә узды. Тамашачылар белән тулы залда Мәскәү татарлары һәм килгән кунаклар арасында күренекле шәхесләр күп иде: галим-академиклар, сәясәтче-депутатлар, язучылар, сәнгать кешеләре, хуҗалык җитәкчеләре... Кичәдә рәсми котлаулар белән Татарстанның мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Республиканың матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Ирек Миннәхмәтов, Татарстанның Россиядәге вәкаләтле вәкиленең беренче урынбасары Илдар Мөхәммәдъяров, Россия язучылар берлегенең беренче секретаре Геннадий Иванов, Язучылар берлекләренең халыкара берләшмәсе рәисе урынбасары Марина Переяслова, баш мөхәррирләр: Ринат Мөхәммәдиев («Татар иле» федераль газетасы), Илфак Ибраһимов («Чын мирас» журналы), «Дружба народов» журналының баш мөхәррир урынбасары Фәрит Нәгыйм чыгыш ясады.

Әдәбият һәм сәнгать бәйрәме булып үткән бу тантанада Равил Фәйзуллинның шигырьләре, җырлары яңгырады. Аларны республикабызның күренекле артистлары Зилә Сөнгатуллина, Илдус Әхмәтҗанов, Мөнир Якупов, Илсур Сафин, Михаил Меркушин, Гөлнара Мурзиева, Мәскәү җырчысы Альбина Латыйпова һәм башкалар башкарды. Шулай ук, танылган шагыйрьләр Ркаил Зәйдулла һәм Газинур Морат үзләренең шигырьләрен укыды, юбиляр шагыйрьгә котлауларын ирештерделәр.

Соңыннан Равил Фәйзуллин татар һәм рус телләрендә үзенең шигырьләрен укыды, җыелган халыкка рәхмәт әйтте.

***

Равил Фәйзуллинның 70 еллык юбилее уңаеннан очрашулар, әдәби кичәләр Чаллы, Әлмәт, Лениногорск шәһәрләрендә дә үтте. Аларда киң җәмәгатьчелек — әдәбият сөючеләр, мәгариф системасы хезмәткәрләре, китапханәчеләр, укучы яшьләр катнашты.

### РУХИЯТ ҮЗАРА ЯКЫНАЙТА

Халыклар бердәмлеге көнендә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында «Татарстан — туган йортыбыз» республикакүләм этномәдәни фестиваленең йомгаклау концерты узды. Анда чыгыш ясап, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Президент Рөстәм Миңнехановның фестивальдә катнашучыларга котлавын укып ирештерде.

Татарстанда яшәүче халыкларның бердәмлеген һәм рухи байлыгын ныгыту, республиканың күпмилләтле мәдәниятен үстерү һәм популярлаштыру максаты белән ел да уздырыла торган фестивальнең быелгысы 20 сентябрьдән бирле барды. Аның III этабы җиңүчеләре исә шушы гала-концертта осталыгын күрсәтте. «Татарстан — туган йортыбыз» этномәдәни фестиваленең кыйммәте — аның конкурстан республикакүләм фестивальгә әйләнүендә. Теләсә кайсы халык коллективы катнаша алган фестивальдә төрле милләт вәкилләре үз халкының мәдәнияте, гореф-гадәтләре турында сәхнәдән сәнгать теле белән сөйли алды.

### ТЕАТР ЮБИЛЕЕ

Театр тарихында үз урыны булган К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрына 80 ел тулды.

Коллективны әлеге юбилее белән тәбрикләргә Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова килгән иде. Ул үзенең чыгышында театрның әйдәп баручы артистлары коллективның горурлыгы булуын, режиссер Рәшит Заһидуллинның элекке режиссерларның эшен дәвам итүен әйтте.

Татар театры сәнгатенә керткән өлеше өчен, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Исламия Мәхмүтова «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде. Татарстанның халык артисты Ләлә Миннуллина белән Татарстанның атказанган артисты Шамил Фәрхетдиновка Президентның Рәхмәт хаты тапшырылды.

Яшь артист Гөлназ Нәүмәтовага Татарстанның атказанган артисты исеме бирелде. Коллективны юбилейлары белән республика театрларының директорлары һәм режиссерлары котлады. Шулай ук Россия Театр әһелләре берлеге рәисе Александр Калягинның телеграммасын да ирештерделәр.

### МИЛЛӘТНЕ САКЛАУ ӨЧЕН

Татарстан Хөкүмәте Татарстаннан читтә яшәүче татарларның ассимиляцияләнүен туктату максатын куйган программа кабул итәргә җыена. Документны Бөтендөнья Татар конгрессы һәм Татарстанның Мәдәният министрлыгы әзерләгән. Ул 2014-2016 елларга исәпләнгән. Программа нигезендә җыеннар, бәйге, конференцияләр үткәрү, «Ана теле», Татар иле» порталларын үстерү күздә тотыла. Шул рәвешле татарча сөйләшүче татарлар саны ел саен 1 процентка артыр дип исәпләнелә. Проектны тормышка ашыруга 89,9 миллион сум акча каралган.

### АЛИШ ВАРИСЛАРЫ

Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреатларының саны бүгенгә 32гә җиткән. Бүләкләнүчеләр исемлеге 1996 елда Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиевтән башлана. Быел исә язучы Солтан Шәмсинең балалар әдәбиятын үстерүдәге эшчәнлеге әлеге премия белән билгеләп үтелде.

Әгәр лауреатлар белән якыннанрак танышырга теләсәгез, Казан шәһәренең 20нче татар гимназиясенә рәхим итегез. Монда директор Рәхимә Арсланова, шагыйрә Йолдыз Шәрәпова, укучылар, укытучылар һәм ата-аналар тырышлыгы белән «Алиш варислары» музее ачылды. Һәр лауреатның фоторәсеме һәм тәрҗемәи хәле стендта урын алды. Монда хәзер Алиш лауреатлары белән очрашулар даими уза. Аларның иҗаты белән кызыксынучылар өчен иркен зал буйлап экскурсияләр дә үткәрелә.

### ТӨРКИЛӘРНЕҢ ҮЗ TURKVISIONЫ БАР

Киләсе елда «Евровидение» бәйгесенең аналогы булган Turkvision җыр фестивале узачак. Биредә дөньядагы барлык төрки

төбәкләр катнашыр дип көтелә. Ноябрь ахырында Казанда әлеге бәйгедә республика данын яклаячак артистны сайлаячаклар. Төркиядә узачак әлеге фестивальдә Россиядән Татарстан, Башкортстан республикалары, Алтай өлкәсе катнашачак.

### ИСЛАМ КАНАЛЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ

Россиядә мөселманнарның тормышын тасвирлаучы, тәүлек буена алар турында сөйләүче «Әл-РТВ» каналы барлыкка килде. Аны оештыручы — Россия Европа өлеше мөселманнарының Диния нәзарәте. Мөселманнар өчен беренче федераль телевизион каналга Интернет аша (www. airtv.ru) тоташып булачак. Каналда илдәге мөселманнарның тормышыннан видеоматериаллар карарга була, ислам дәүләтләренә сәфәрләр оештырылачак, аларның яшәеше белән таныштырачаклар, ислам дине турында сөйләүче тапшырулар, руханилар белән очрашу, әңгәмәләр, нәфис, документаль фильмнар һ.б. күрсәтеләчәк. Каналның баш мөхәррире — танылган журналист Рөстәм Гарифҗанов.

### МЕТРО ТАГЫН ДА ОЗЫНАЯ

Киләчәктә Казан метросының икенче линиясе дә барлыкка килер дип көтелә. Метроның яна өлешендә барлыгы 13 станция урнашачак: «Фучик/Имәнлек», «10нчы микрорайон», «Ломжа», «Сахаров», «Халыкара ат спорты комплексы», «Космонавтлар», «Компрессор заводы», «Футбол стадионы», «Шәһәр хастаханәсе», «ЗАГС», «Декабристлар/Яшьлек», «Восстание». «Имәнлек» станциясен төзергә рөхсәт бирелгән инде.

### ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш керткәне, актив фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Филология һәм сәнгать институты XX-XXI гасыр татар әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры **Галиуллин Тәлгат Нәби улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

### МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары **Беломоина Нурия Абдулла кызына** «Татарстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кышкы пейзаж.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Рүзәл Мөхәммәтшин**.

# Яңа китаплар




**Мәгъсум Хужин.** Кочасы иде дөньяны... – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.- 574 б. Тиражы – 2000 данә.

90нчы елларда "Казан утлары"нда да эшләгән мәрхүм Мәгъсум Хужин – талантын тулаем хикәя жанрына багышлаган сирәк язучыларның берсе. Әдипнең әдәби мирас буларак нәшер ителгән бу китабы ике бүлектән тора. "Каләм ияләре" дигән беренче бүлегенә асылда танылган язучыларыбыз турындагы хатирәләре кергән, икенче бүлек исә тормышта булган хәлләрне тасвирлаган хикәяләр, хикәячекләр һәм парчалардан гыйбарәт.




**Рәшит Әхмәтжанов.** Әсәрләр. I том. Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.- 320 б. Тиражы – 2000 данә.

Бу томга күренекле шагыйрь Рәшит Әхмәтжановның төрле елларда иҗат ителгән шигырьләре тупланган. Китапка бу нечкә лирикның үзенчәлекле образын һәм шигырьләренең асыл кыйммәтен ачкан шәп кереш сүзне Марсель Галиев язган.

Рәшит Әхмәтжанов әсәрләренең II томы да әзерләнеп бетеп килә.



Рүзәл Мөхәммәтшин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)